Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты

**Л.Р. Мортазина**

# ВАТАННАН ЧИТТӘ БЕЛЕМ АЛУ ҮЗӘКЛӘРЕ ҺӘМ ТАТАР МӘГАРИФЕ

## *(XVII гасыр – XX гасыр башы)*

**Казан • 2025**

УДК 37
ББК 74
М 66

**Фәнни редактор**
*Гибатдинов М.М.*, педагогика фәннәре кандидаты

**Рецензентлар:**
*Габдрафикова Л.Р.*, тарих фәннәре докторы, ТР ФА профессоры
*Шәкүров Ф.Н.*, тарих фәннәре кандидаты

***Мортазина Л.Р.***
**М 66 Ватаннан читтә белем алу үзәкләре һәм татар мәгарифе (XVII гасыр – XX гасыр башы). –** Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты, 2025. – 246 б.

ISBN 978-5-94981-408-6

Китапта татар мәгарифе үсешенең төп үзенчәлекләреннән берсе булган ватаннан читтә белем алу мәсьәләсе турында сүз алып барыла. Чит мәмләкәтләрдә гыйлем эстәгән татар яшьләре, алар укыган белем йортлары, уку һәм яшәү шартлары, белем алу үзенчәлекләре, шәкертләрнең үз алларына куйган максат һәм бурычлары, уй-кичерешләре турында мәгълүмат бирелә. Китап тарихчыларга, татар мәгарифе тарихы белән кызыксынучы киң катлам укучыларга адреслана.

ISBN 978-5-94981-408-6 УДК 37
ББК 74

© Мортазина Л.Р., 2025
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2025

## ЭЧТӘЛЕК


**Кереш** ..................................................................................................... 5

**I. ТАТАР МӨСЕЛМАН МӘГАРИФ СИСТЕМАСЫНЫҢ ҮСЕШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ ЧИТ МӘМЛӘКӘТЛӘРДӘ БЕЛЕМ АЛУ ҮЗӘКЛӘРЕ** ........................................ 7

1. Татар мәгарифе үсешендә Дагыстан белем бирү үрнәгенең роле ............... 13
2. Бохара белем бирү системасы һәм татар шәкертләре ................................. 25
3. Мисырдагы «Әл-Әзһәр» мәдрәсәсендә һәм башка мөселман мәгарифе үзәкләрендә татарлар.......................................................... 44
4. Һиндыстандагы «Дарел-гыйлем» мәдрәсәсендә татарлар ........................... 53
5. Хиҗаздагы «Казанлы» мәдрәсәсе ................................................................ 56

**II. ТАТАР ШӘКЕРТЛӘРЕ ДӨНЬЯВИ БЕЛЕМ ЭСТӘҮ ЮЛЫНДА** ............................................................................................. 68

1. Истанбул – тәрәккъыйпәрвәрлеккә бер күпер............................................ 78
   Фатих Кәрими ................................................................................................ 93
   Зыя Насыйри .................................................................................................. 95
   Харис Фәйзи-Чистапули ................................................................................ 96
2. Бәйруттагы Америка көллияте ................................................................... 101
   Габдулла Газизов (Сакмарый) .................................................................... 105
3. Европа уку йортларында татарлар ............................................................ 110
   Бәдретдин Сәйфелмөлеков .......................................................................... 122
   Габдулла Тимер............................................................................................ 124
4. Америка уку йортларында татар шәкертләре............................................ 126
   Хәбибулла Байбулатов ................................................................................. 127
   Закир Габдуллин ........................................................................................... 131
   Фуад Әнвәров, Галимҗан Сәйфелмөлеков ................................................ 135
   Зыя Мөҗавир................................................................................................. 144
   Фазыл Бәкер ................................................................................................. 148
5. Япониядә белем алган татар егете ............................................................. 151

**III. ВАТАННАН ЧИТТӘ БЕЛЕМ АЛУНЫҢ МАТДИ ҺӘМ БАШКА ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ** ... 160

1. Чит мәмләкәтләрдәге татар шәкертләренә иганәләр һәм ярдәм җәмгыятьләре ... 160
2. Татар хатын-кызлары югары белем юлында ... 170
   Сара Шакулова ... 173
   Фәүзия Ибраһим ... 177

**Йомгак** ... 180

**Чыганаклар һәм әдәбият** ... 182

**Кушымталар**
1. Мөселман Көнчыгышында белем алган татар яшьләренең якынча исемлеге ... 198
2. Ватаннан читтә дөньяви уку йортларында белем алган татар шәкертләренең якынча исемлеге ... 216
3. Чит мәмләкәтләрдә укыган татар шәкертләренең XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында басылып чыккан кайбер язмалары ... 225

# КЕРЕШ

Татар мәгарифе халкыбыз яшәешенең һәр чорында да белем һәм мәгърифәт тарату белән беррәттән, милли үзаңны сакларга ярдәм итеп килгән. Гаиләдә алган тәрбия дә, мәдрәсәләрдә бирелгән белем дә милли-дини кыйммәтләрне, халкыбызның иң матур традицияләрен, белемгә булган җылы мөнәсәбәтен алдагы буыннарга тапшыруны күз алдында тоткан. Мәмләкәттән читтә белем алучылар да, нигезле белем туплау, һөнәри осталыкка өйрәнү белән беррәттән, татарлыкны саклау, милли һәм дини гореф-гадәт, традицияләрне үстерү, алган белемнәрен милләт һәм ватан мәнфәгатьләре өчен файдалануны төп максатлары итеп куйганнар. Баштагы чорларда бу дини бердәмлекне (мөселманлыкны) ныгыту кысаларында алып барылса, XIX–XX гасырлар чигендә дөньяви белем, заманчалык шартларында татар милләтенең алгарышын тәэмин итү, миллилекне саклау, милләтне башка кыйтгаларда һәм төрле халыклар арасында күрсәтү кебек юнәлешләрне үз эченә алган.

Татар мәгарифе үсешенең төп үзенчәлекләреннән берсе булган ватаннан читтә белем алу проблемасы бик әһәмиятле, мөһим фәнни мәсьәләләрдән саналса да, бүгенге көнгәчә аз өйрәнелгән проблемаларның берсе булып кала бирә. Вакыт ягыннан караганда шактый зур дәверләрне берләштергән бу күренеш, чыганакларның аз саклануы сәбәпле, тикшеренүчеләрнең игътибарыннан читтә калып килде. Чыннан да, чит мәмләкәтләрдә белем алган татар яшьләре хакында архив материаллары бай түгел. Моңарчы бу проблеманың кайбер яклары Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин кебек күренекле татар галимнәренең фәнни даирәләрдә яхшы билгеле хезмәтләре аша алып барылды. Соңгы елларда олуг галимнәребезнең моңарчы тикшеренүчеләрнең игътибарыннан читтә калып килгән китаплары җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителү белән, башка мәмләкәтләрдә дини белем үзләштергән татар шәкертләре буенча мәгълүмати база шактый киңәйде, моңарчы билгеле булмаган яңа исемнәрне һәм фактларны күз алдына китерү мөмкинлеге ачылды. Бу юлда иң әһәмиятле, кыйммәтле чыганакларның тагын берсе булып XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты, төрле елларда язылган хатирәләр, юлъязмалар, сәяхәтнамәләр, истәлекләр тора. Соңгыларына таянып, татарларның XX гасыр башында ватаннан читтә белем алуларының кайбер үзенчәлекләрен, закончалыкларын билгеләргә, татар шәкертләренең уй-хыялларын, максатларын ачыкларга мөмкинлек туа.

Татар мәгарифе үсешенең үзенчәлеге буларак чит илләрдә белем алу проблемасының кайбер аспектлары, бигрәк тә аерым шәхесләр мәсьәләсе, соңгы чор зыялылары һәм галимнәре – И.Рәмиев, М.Бөдәйли, Р.Әмирханов,

А.Хәбетдинов, И.Гыйләҗев, Җ.Миңнуллин, Л.Габдрафикова, Ф.Шәкүров, Т.Биктимирова, А.Мәхмүтова, М.Фархшатов, М.Рәхимкулова, Р.Гайнетдинов, Д.Мөхәммәтҗанова, С.Рәхимов һ.б.ларның хезмәтләрендә искә алына. М.Бөдәйлинең «Татар әдәбиятында кулланылган псевдонимнар»[1], И.Рәмиевнең «Әдәби сүзлеге»ндә[2] гасырлар чигендә дини һәм дөньяви белем үзләштергән татар яшьләренең кайберләре турында шактый тәфсилле мәгълүмат бирелә. Р.Әмирханов хезмәтләрендә, беренчеләрдән буларак, проблемага фәнни күзлектән чыгып якын килү күзәтелә, аерым шәхесләрнең исемнәре атала, татарларның чит мәмләкәтләрдә белем алу үзенчәлекләре билгеләнә[3].

Бу проблема, инде әйтеп узылганча, шактый киң, һәм ул вакыт ягыннан зур дәверне үз эченә ала. Бик борынгы заманнарда ук бабаларыбызның белем, мәгърифәт артыннан сәфәргә чыгуны зур мәртәбә санаганлыклары яхшы билгеле. Гасырлар үтү белән, бу традиция юкка чыкмаган, киресенчә, үсә генә барган, яңа шартлар, үзенчәлекләр белән баеган. Һәр чорның, тарихи үсеш белән бәйле рәвештә, үзенә генә хас булган сыйфатлары, билгеләре барлыкка килгән. Бу, әлбәттә, җәмгыять, мәгариф алдына куелган бурычларга бәйле булган. Моннан тыш, күп очракта ул мәҗбүри сайлау ирегe булмау, альтернативасызлык белән дә билгеләнгән, чөнки аерым чорларда мәмләкәттән читтә максатчан белем алу дини, һөнәри, мәгърифәти үсештә бердәнбер юл булган. Ләкин төп максат – милләтне һәм динне үстерү, ватан һәм халык мәнфәгатьләрен яклый алырлык дәрәҗәдә яхшы белем алу һәр чор өчен дә уртак булган.

Әлеге китапны язудан максатыбыз – чит мәмләкәтләрдә белем алган татар шәкертләре турындагы мәгълүматларны бергә туплап бирү, яшьләребезнең халкы, дине, ватаны алдындагы изге бурычларын фидакарьләрчә үтәүләрен күрсәтү. Моңарчы билгеле булган, тормыш юллары һәм эшчәнлекләре яхшы өйрәнелгән шәхесләргә аерым тукталмыйча, исемнәре билгесез яисә аз билгеле татар шәкертләренең ватаннан читтә белем алу юлындагы эшгамәлләренә басым ясарга тырыштык, алар турындагы мәгълүматны фәнни әйләнешкә кертүне максат иттек.

---

[1] Һади Мәхмүт Бөдәйли. Татар әдәбиятында кулланылган псевдонимнар // КФУ СККБ. 2501 т.

[2] Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. 399 б.

[3] Амирханов Р.У. Некоторые особенности развития народного образования у татар в дооктябрьский период // Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. Казань, 1992. С. 52–53; Амирханов Р.У. Система конфессионального образования у татар: становление и формы функционирования // Ислам в Среднем Поволжье: история и современность». Очерки. Казань: Мастер Лайн, 2001. С. 149–169.

# ТАТАР МӨСЕЛМАН МӘГАРИФ СИСТЕМАСЫНЫҢ ҮСЕШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ҆ҺӘМ ЧИТ МӘМЛӘКӘТЛӘРДӘ БЕЛЕМ АЛУ ҮЗӘКЛӘРЕ

Ислам традицияләренең төп нигезен белем алу тәшкил итә. Бик борынгы заманнарда ук мөселманнар өчен махсус уку йортлары – мәдрәсәләр эшләп килгән, аларда дин белгечләре, дини гыйлемгә ия булган укымышлылар әзерләнгән. Белем бирүнең төп максаты җәмгыятьнең рухи тормышы таләпләренә туры килгән, киңкырлы дини белемнәргә ия булган шәхесләр тәрбияләүдән гыйбарәт булган. Әлбәттә, бу белемнәр кешегә яшәү, яшәешнең барлык өлкәләрендә мөмкин кадәр тулы тормыш алып бару, үсү өчен мөмкинлекләр тудырган.

Татарлар, авылга нигез салу белән, иң беренче эш итеп мәчет салганнар, аның янында мәктәп төзегәннәр[1], бу, әлбәттә, аларның тормышында белем һәм мәгърифәтнең ни дәрәҗәдә югары торуын раслый. Мөгаен, тагын да камилрәк, тирәнрәк белем туплау, күзаллауларын яңадан-яңа мәгълүматлар белән баету максаты белән, алар, үз төбәкләрендә генә белем алу белән чикләнмичә, башка, мөселман мәгарифе алга киткән ислам илләренә юл алганнар. Көнчыгышның дөньякүләм танылган фән һәм мәгариф үзәкләре – Бохара, Сәмәрканд, Нишапур, Балх, Багдад, Мәрв һ.б. уку йортларында белем алган болгарлар шул заманның алдынгы фән казанышлары, югары Шәрык мәдәнияте белән танышканнар[2]. Борынгы чорларда ук барлыкка килеп, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән «Белемне Кытайга булса да барып ал» гыйбарәсе бабаларыбызның белемгә, мәгарифкә булган мөнәсәбәтләрен күрсәтеп тора.

Татарларның мәгариф өлкәсендәге Идел Болгары, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларында ук нигез салынган традицияләре, аерым үзгәрешләр кичереп, XX гасыр башларына кадәр килеп җитә. Әлбәттә, һәр дәвердә мәгариф үсешенең үз үзенчәлекләре булган, алар илдәге һәм эчке, һәм тышкы сәбәпләргә бәйле булган.

Казан ханлыгы җимерелеп, дәүләтчелек югалганнан соң, билгеле булганча, илдә белем туплау, мәгарифне үстерү буенча мөмкинлекләр чикләнә. Гасырлар дәвамында тупланып килгән рухи мирас, кулъязма китаплар,

[1] Мәрҗани: Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вилаятенә йөз ел булу (1233–1333) мөнәсәбәте илә нәшер ителде. Казан: «Мәгариф», 1915. Б. 331.

[2] Гибатдинов М., Муртазина Л., Биктимирова Т. Система национального образования татар: история и современность // Казанский федералист. 2006. №4. С. 27.

китапханәләр, мәчет-мәдрәсәләр яндырылып юкка чыгарыла, галимнәр, укымышлылар күпләп юк ителә. Моңарчы нигездә шәһәр мәгарифе буларак үсеш кичергән татар мәгарифе авылга күчкән, авыл муллаларының, дин әһелләренең тырышлыгы белән генә бөтенләй өзелеп бетмичә сакланып калган: «кайбер авылларда кечкенә генә һәм күбесе яшерен рәвештә гыйбадәтханәләр ачыла, муллалар ир һәм кыз балаларны үз өйләренә җыеп иман һәм намаз өйрәтәләр»[3]. Гыйлемгә өйрәтү мөселманлыкның, ислам диненә тугрылыкның билгесе булып әверелә[4]. Ләкин мондый кискен шартларда тулы рәвештә белем алу авыр булган. Шуңа күрә дә татар яшьләре башка илләргә барып белем алу мөмкинлекләрен эзләгәннәр. Татарларны сыендырган, аларның белем алуга булган ихтыяҗларын канәгатьләндергән илләрнең берсе – Дагыстан. Бу чор татарларның дөньяга карашы, ислам диненә һәм мәгарифенә мөнәсәбәте формалашуга, фән үсешенә дә йогынты ясаган.

Галимнәр татарлар белем алган, яңа фикерләр үтеп кергән, иҗтимагый, дини һәм педагогик фикер үсешенең кыйбласын билгеләгән ике юнәлешне аерып күрсәтәләр. Болар – Дагыстан һәм Урта Азия (Мәвараэннәһер)[5]. Гомумән алганда, татарларга «галимлек кергән» мөселман үзәкләре арасында, алда искә алынганнардан тыш, Кырым һәм Төркия бар. Чикләрнең ябык булуына карамастан, Урта Азиядәге мөселман уку йортларына бару юллары кала[6] – көнчыгыш телләрен яхшы белү сәбәпле, татарларның төрки-мөселман дөньясы белән бәйләнешләре кимеми: алар тылмачлар буларак җәлеп ителә, дипломатик эшләрдә катнашалар.

Бохара, Сәмәрканд һ.б. шәһәрләрдә яшәгән гыйлем ияләре, галимнәр, остазлардан барып белем алу һәр дәвердә дә абруйлы, мәртәбәле саналган. Бу уку йортларын тәмамлаганнар үз җирләренә кайтып, шул Бохара ысулы үрнәгендә уку йортлары ачканнар, татар яшьләренә белем бирүдә үзләре белем алган остазларының тәҗрибәсен, эш алымнарын кулланганнар. Шул рәвешле, Бохара системасы Россиянең үзәк төбәкләренә үтеп кергән һәм ныклап урнашкан. Меңнәрчә шәкертләр Урта Азия мәдрәсәләрендә гыйлем туплаган, аларның шактые турындагы мәгълүмат белән Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин хезмәтләре аша танышырга мөмкин. Ләкин исемнәре билгесез кала биргәннәре дә, әлбәттә, шактый. XIX гасыр ахырларына таба татарлар арасында бу уку йортларының роле беркадәр кими башлаган. Яңалыкларга омтылган, бер үк

[3] Фәхретдин Р. Уфа шәһәрендә Губернский исполнительный комитетка сайланган котлуг татар егетләренә һәм, гомумән, бүген эш башында торучы иптәшкәләргә ачык мәктүб // Болгар вә Казан төрекләре. Казан: Татар.кит.нәшр., 2021. Б. 305.

[4] Шакуров Ф.Н. Вступая в век надежд. Казань: Изд-во «Заман», 2000. С. 4.

[5] Идиятуллина Г.Г. Развитие мусульманской мысли после падения Казанского ханства (XVI–XVIII вв.) // История мусульманской мысли в Волго-Уральском регионе. Казань: Изд-во ДУМ РТ, 2009. С. 99.

[6] Мухаметзянова Д.С. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. С. 74.

вакытта төпле дини белем алуга өметләнгән яшьләр белем бирүдә заманчалык принцибын нигез итеп алган Госманлы дәүләте уку йортларына юнәлгәннәр. Шул рәвешле заманча укыту алымнары, яңалыклар татар мәдрәсәләренә дә үтеп кергән, татар мәгариф системасын үзгәртеп коруга күпмедер дәрәҗәдә йогынты ясаган.

Гомумән алганда, чит мәмләкәтләрдә белем үзләштерүнең үз үзенчәлекләре булган. Бу билгеләр белем алуның максат һәм бурычлары, шартлары, эчтәлеге белән билгеләнгән. Һәр чорда бу үзенчәлекләр беркадәр аерылып торганнар. Ләкин төп максат – ул бер үк: яхшы белем алу һәм бу гыйлемнәрне үз милләтең, өммәтең мәнфәгатьләрендә файдалану. XX гасыр башында дини белем алу, элеккеге заманнардан аермалы буларак, шәкертләргә өстәмә бурычлар да йөкләгән, алар дини өлкәдәге хезмәт вазифаларыннан тыш (имамлык, мөдәррислек), яңа шартларда милләтне тәрбияләргә, аның фикерен формалаштырырга тиеш булалар: «Русия мөселманнарына бу соң елларда язу вә укыту илән иң күп хезмәт иткән вә халыкның фикерен ачарга чынлап иҗтиһад иткән кешеләребез – ислам мәмләкәтләрендә укып кайткан кәнежләремездер (яшьләребездер)»[7]. Бу чорда дини мәнфәгатьләр белән беррәттән, миллилек мәсьәләсе дә алгы планга чыга. Атаклы дини белем бирү үзәкләренең иң мәшһүрләреннән берсе булган «әл-Әзһәр»дә укыган татар яшьләре дә дини белем алудан беренче чиратта милләт алдындагы бурычларны хәл итүне күз алдында тотканнар. Бу хәл гомуммөселман даирәсендә аларны башка милләтләрдән аерып куйган: «Хәтта ки безнең шәкертләрнең милләт эше вә милләт истикъбале өчен кайгырып, шуның өчен тырышуларын бүтәннәр (гарәп, мәгъриби (көнбатыш) төрекләр) тәгаҗҗеб итәләр (гаҗәпләнәләр) имеш»[8].

Әлбәттә, бу мәсьәләләрне караганда чорның үз үзенчәлекләрен дә истә тоту мөһим. Җәдитчелек хәрәкәте, җәдит мәктәпләре барлыкка килү, яңача укыту ысуллары кулланыла башлау гомумән мәгариф алдында торган бурычларны тамырдан үзгәрткән. Дини белем бирү системасының максатлары заман тенденцияләреннән чыгып беркадәр үзгәргән. Яшьләрнең фикерләүләре дә чорның гомуми үзенчәлекләре, белем бирү системасының шартлы рәвештә «кадимчелек» һәм «җәдитчелек» дигән ике капма-каршы өлешкә аерып куелуы, икенчесен идеаллаштырып карау, һәм, димәк, беренчесенең беркадәр күләгәдә калуы, карагруһлык ярлыгы тагылу белән билгеләнгән. Шул ук вакытта иске мәктәпнең татар мәгарифе үсешендәге ролен истә тоту мөһим. Халкыбызның мәдәни, дини өлкәдә күп гасырлык традицияләрен, гореф-гадәтләрен, холкын (характерын), әдәп-әхлак нормаларын саклап килүдә бу системаның әһәмияте зур була. XX гасыр башында иске мәктәпнең кризи-

---

[7] Мисырда. Татар таләбәсе җәмгыяте // Казан мөхбире. 1906. 9 апрель.

[8] Шунда ук.

сында аның эчке тәртипләреннән бигрәк, тирәлегендәге тышкы вазгыятьнең дә роле була[9].

Татар мәгарифе үсешенең төп үзенчәлекләреннән берсе – аның күпбаскычлылыгы. Бу үзенчәлек түбәндәгедән гыйбарәт булган. XIX гасырда ата-аналарның күбесе, баласы 7–8 яшьләренә җиткәннән соң, аны авыл мәктәбенә[10] укырга бирергә тырышкан; моннан тыш, гыйлемлерәк гаиләләрдә өйдә башлангыч белем нигезләрен бирү, укырга-язарга өйрәтү, дини тәрбия бирү күренеше дә күзәтелгән. Ягъни яшүсмерлек чорында татар балаларының байтагы хәреф таныган, укый белгән дигән сүз. Бу – күпчелек өчен мөмкин булган белем дәрәҗәсе саналган. Моннан соң ир бала укуын авыл мәдрәсәсендә яисә күрше-тирәдәге җәмәгатьчелек тарафыннан танылган берәр уку йортында дәвам итә алган. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, укуга аеруча сәләтлеләре остазының киңәше белән тагын да билгелерәк, дәрәҗәлерәк мәдрәсәгә (мәсәлән, Каргалы, Мәчкәрә, Түнтәр һ.б.) китә алган. Югары дини белем үзләштерергә теләгән татар яшьләренең кайберләре Бохарага һәм башка Урта Азия мәдрәсәләренә юл алганнар. Бу система бик төгәл һәм көйле эшләгән, ләкин шулай да мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе шарт булган: бер баскычтан икенчесенә алдагы баскыч дәрәҗәсенә караган белемнәрне тулаем үзләштергән кеше генә үтә алган. Югары дини белемгә иң тырышлары гына ия булган – татарларда сәләтле һәм булдыклы яшьләрне сайлау механизмы әнә шулай эшләгән.

Мәмләкәттән читтә белем алуның, шәкертләрнең шәхси белемнәре, һөнәри мөмкинлекләре арту, дөньяга карашы формалашу, күзаллаулары киңәю белән беррәттән, гомумән татар мәгарифе үсешенә дә йогынтысы зур булган. Нәкъ менә әлеге гыйлем үзәкләре үрнәгендә ватанда белем учаклары ачылган, шәкертләр белән бергә уку-укыту өлкәсенә яңа фикерләр, укыту алымнары, уку әсбаплары кайткан. Бу исә татар мәгарифенең эчтәлек ягыннан баюына, үзгәрешенә китергән.

XVIII гасыр урталарында Оренбург тирәсендә барлыкка килгән Татар Каргалысы (Сәгыйть бистәсе) үзенең күп санлы мәдрәсәләре белән дан тоткан. Анда Дагыстаннан, Хәрәземнән, Багдадтан килгән остазлар белем биргән, Урта Азиядә, Сүриядә, Дагыстанда, Кабулда белем алган татарлар үзләренең белемнәрен арттыру һәм яңа буын галимнәрне тәрбияләүгә өлеш кертү өчен җыелганнар. Екатерина II идарә иткән чорда татарларга карата сәясәтнең бераз йомшаруы, «мәчетләр төзергә һәм алар каршында мәдрәсәләр ачар-

---

[9] Рахимов С. Социально-правовой статус татарских учебных заведений последней четверти XIX – нач. XX вв. // Ислам в татарском мире. Казань, 1997. С. 75.

[10] Ул вакытларда татар уку йортларын мәктәп (башлангыч белем йорты) һәм мәдрәсәләргә (урта һәм югары белем йортлары) төгәл бүлеп йөртү булмаган, барлык уку йортлары, Гарәбстан үрнәгендә «мәдрәсә» дип йөртелгән. Хәзергечә бүленеш бары тик XIX–XX гасырлар чигендә генә тулысынча урнашып бетә (Бу турыда кара: Махмутова А.Х. Становление светского образования у татар. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1982. С.13).

га рөхсәт бирелү»[11] дә уку-укыту системасы үсешенә зур йогынты ясаган. Нәтиҗәдә XVIII гасырның ахырларына таба төрле төбәкләрдә: Казанда Ахун һәм Апанай мәдрәсәләре, 1780 елда – Әмирхановлар йортында, Мәчкәрә, Ташкичү, Мәңгәр, Сатыш, Саба, Бәрәскә, Эстәрлебаш һ.б. авылларда мөселман уку йортлары барлыкка килә[12]. Шулай итеп, сыйфатлы белем алу мөмкинлекләре арта. Ләкин аларның барлыкка килүләрендә һәм эшчәнлекләрендә Көнчыгыш мөселман мәгарифенең йогынтысы булуын истән чыгарырга ярамый.

Галимнәрнең фикеренчә, Каргалы мәдрәсәләре комплексы[13], үзенең культурологик роле, Идел-Урал төбәгендә уку йортлары челтәре үсеше ягыннан караганда, Урта Азия мәдрәсәләренә караганда әһәмиятлерәк булган. Ләкин шул ук вакытта, бу уку йортларының барлыкка килүендә һәм баштагы чорда үсешендә Казан арты галимнәре белән беррәттән, Дагыстан (Казый ака ахун), Урта Азия (Ишнияз бине Ширнияз, Хәрәзем)[14], Гарәбстан (Вәлиэтдин хафиз Багдади) галимнәре һәм педагоглары катнашуын, Урта Азиянең атаклы суфи шәехләре – Фәезхан Кабули, Ишан Имла, Ниязколый Төрекмәни һ.б.ларның фикри йогынтысы булуын истә тотарга кирәк[15].

Татарларда кадими системаның ныклап урнашуына йогынты ясаган тагын бер фактор – төбәктә нәкышбәндия мөҗәддидия тарикате таралу. Белемнәрен камилләштерү максатыннан Бохара, Хива, Кабул кебек белем бирү үзәкләренә юл тоткан шәкертләр, мәдрәсәләрдә гыйлем туплау белән беррәттән, атаклы шәехләрдә укып, рухи камиллеккә ирешкәннәр. Татарлар белем алган иң күренекле шәехләрдән Ниязколый Төрекмәни һәм Фәезхан Кабулины аерып күрсәтергә мөмкин.

Бу чорларда ватаннан читтә белем алган татарларның саны шактый булган. Тикшеренүчеләрнең исәпләүләре буенча, 1800–1860нчы елларда, тулы булмаган мәгълүматларга караганда, хәзерге Башкортстан җирлегендәге мөдәррисләрнең 21%ы, ә 1886–1890 нчы елларда 13,5%ы чит илләрдә белем

[11] Әмирхан И. Иманга тугрылык. Казан: Татар.кит.нәшр., 1997. Б. 150.

[12] Мухаметзянова Д.С. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. С. 20.

[13] 1746–1920 елларда Оренбург губернасы Сәгыйть (Каргалы) бистәсендә эшләгән мөселман мәктәпләре комплексы.

[14] Ул шулай ук Казан тирәсендәге мәдрәсәләрдә, мәсәлән, Казаклар авылында да укыткан. Артык гыйлемлелеге белән аерылып тормаса да, заманының атаклы галимнәренең берсе булып таныла алган // Марджани Ш. Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С. 244–245.

[15] Мухаметзянова Д.С. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. С. 27.

алган. Иң эре мәдрәсәләрне алар җитәкләгән, һәм төбәктә уку-укыту эшенең оештырылышына бу галимнәрнең тәэсире зур булган[16].

Ватанда шактый төпле уку йортлары ачылса да, читтә белем алу традициясе дәвам итеп килә. XIX гасырның икенче яртысында татарларның күпчелек өлеше Мисыр, Анатолия һәм Хиҗаз мәдрәсәләрен сайлыйлар. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Уфадагы «Галия», Казандагы «Мөхәммәдия» кебек яңа ачылган мәдрәсәләрдә яңача, җәдиди ысуллар нигезендә, дини һәм бер үк вакытта дөньяви фәннәр укытыла башлый. Алар дөньякүләм танылган атаклы ислам белеме үзәкләре үрнәгендә яңартылган, заман шартларына җавап биргәннәр.

Шулай итеп, татар мәгарифенең XVII гасыр – XX гасыр башына кадәрге чордагы үсешендә чит мәмләкәт галимнәре һәм белем системаларының йогынтысы зур булган. Бу татарларда әлеге чорда дини мәгариф үсешенең төп үзенчәлекләренең берсе булып тора.

[16] Әлеге мәгълүматларны, А.Хәбетдинов хезмәтләренә таянып, И.Заһидуллин китерә (Загидуллин И. Традиционные мусульманские общины // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань: 2013. С. 411).

# Татар мәгарифе үсешендә Дагыстан белем бирү үрнәгенең роле

Галимнәрнең фикеренчә, Казан ханлыгы чорында татарлар арасында Бохара уку йортлары популяр булган[1]. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, аның шәһәрләре, бина-йортлары, мәчет-мәдрәсәләре, матди мәдәнияте белән беррәттән, халыкның рухи кыйммәтләре – китап-дәреслекләре, галим-голямалары, атаклы дин әһелләре күпләп юк ителгән бер чорда мәгърифәт-белем алу мөмкинлекләре дә бик нык чикләнә, классик белем алу бөтенләй дә мөмкин булмый. Моңарчы гөрләп үскән, чәчәк аткан мәгариф системасы җимерелә, татар мәгарифе авыл шартларында гына яшәвен дәвам итә, сакланып кала. Югары шәһәр мәдәниятенең юкка чыгарылуы гыйлем юлында яңа мөмкинлекләр эзләүгә этәрә. Башка ислам дәүләтләрендә белем алу, аерым алганда, Дагыстан юнәлеше, мәсьәләнең чишелешенә беркадәр ярдәм итә.

Татарларның Дагыстанда укулары мәсьәләсе бүгенге көндә аз өйрәнелгән проблемаларның берсе булып кала. Бу аңлашыла да: әлеге чордан калган чыганаклар юк дәрәҗәсендә, Дагыстанда белем алган шәкертләр турындагы беркадәр мәгълүмат белән XIX–XX гасыр башы татар галимнәре Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин, М.Рәмзи, Х.-Г.Габәши хезмәтләре аша гына танышырга мөмкин[2]. Әлеге мәсьәләнең кайбер аспектлары хәзерге тикшеренүчеләр А.Хәбетдинов, Ш.Шихалиев, Г.Идиятуллина язмаларында искә алына[3].

Ризаэтдин Фәхретдин Казан ханлыгы яулап алынганнан соңгы чорда татар фәнни-дини тәгълиматы үсешендә 4 дәверне билгели – «аптырау дәвере», «Дагыстан дәвере», «схоластик дәвер» һәм «уяну дәвере»[4]. Беренче чор мөселманнарның «дин ирегенә хуҗа булмаулары», «ислам диненең, рәсми дин

---

[1] Давлетшин Г. Духовная культура Казанского ханства // История татар с древнейших времен в семи томах. Том IV. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2014. С. 534.

[2] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989; Фәхретдин Р. Болгар вә Казан төрекләре. Казан, 2021; Рәмзи М. Тәлфик әл-әхбәр вә тәлких әл-әсар фи вәкаигъ Казан вә Болгар вә әл-мөлүк әт-татар. Оренбург, 1908 һ.б.

[3] Шихалиев Ш.Ш. Краткие сведения о контактах мусульман Дагестана и Волго-Уральского региона в XVIII–XX вв. // История, археология и этнография Кавказа. Т. 16, №1. 2020. С. 104–128; Шихалиев Ш., Каяев И. Научные и религиозные контакты мусульман Дагестана и Волго-Уральского региона во второй половине XIX – первой трети XX вв. (по материалам арабографичных источников). Махачкала, 2024. 184 с.; Хабутдинов А. Миллет Оренбургского Духовного Собрания в конце XVIII–XIX веках. Казань: Иман, 2000. 160 с.; Идиятуллина Г.Г. Развитие мусульманской мысли после падения Казанского ханства (XVI–XVIII вв.) // История мусульманской мысли в Волго-Уральском регионе. Казань: Изд-во ДУМ РТ, 2009. С. 98–114.

[4] Фәхретдин Р. Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Гыйльме хәдистән / басмага әзерләүче А. Гайнетдинов. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019. Б. 44–46.

буларак, хөкүмәт тарафыннан танылмавыннан» гыйбарәт була. Моннан тыш, галим раславынча, татарлар яшәгән төбәкләрдә «башкорт гаугалары дәвам итеп тора». «Шул сәбәпле, мөселманнарның хәлләре өметсезлектә һәм аптырауда үткән, гыйлем һәм мәгърифәт юлында бер адәмгә дә йөрергә мөмкин булмаган»[5].

Дагыстан чорын Р.Фәхретдин яңа юллар, яңа мөмкинлекләр эзләү чоры буларак билгели. «“Дагыстан дәвере” дип исем бирүебез, бу дәвердә мөселманнар үз акылларын башларына җыеп, шулай хиссез һәм хәрәкәтсез торудан гүзәл нәтиҗә чыкмаячагын аңлап, укырга дигән фикергә килгәннәр һәм ничә мәшәкатьләргә дучар булсалар да, Дагыстан тарафларына шәкертләр җибәреп, гыйлем алдырдылар», – дип яза[6]. Дагыстан һәм аның мәгариф системасы илдәге вазгыять шартларында проблеманы хәл итүдә бердәнбер юл булып күренгән. Икенче бер хезмәтендә Р.Фәхретдин Казан ханлыгы җимерелгәннән соң бабаларыбызның «Дагыстан голямасы тәртипләре рәвешендә [...] гыйлем тәхсил иткәнлекләре мәгълүм» дип яза[7]. Хәзерге галимнәр дә Дагыстанда гыйлем туплаган шәхесләрнең XVIII гасырда Казанда, Казан артында һәм Урал буенда классик мөселман мәгарифен һәм суфичылыкны торгызуга керткән өлешен ассызыклыйлар[8].

Дөрестән дә, шул ук Р.Фәхретдин сүзләре белән әйткәндә, «Мәктәпләр, мөгаллимнәр вә укыр өчен китаплар булынмадыгы сәбәбеннән Казан шәһәре Русия кулына төштеге көннән унсигезенче гасыр милади башына кадәр әһле ислам тәмам каралып йитмеш» көннәрдә «һәр никадәр бәгъзе адәмнәр Дагыстан тарафыннан вә бәгъзе берләре Бохара вилаятьләрендә тәхсил итеп (укып) кайтырлар вә монда кайттыклары соң, мәдрәсә ачып, дәрес илә мәшгуль булырлар», әмма «болар бик аз, вә дәресләре асылсыз булдыгыннан, халыкның хаҗәтен тәэмин итәр мәртәбәдә түгел иде»[9].

Р.Фәхретдингә ияреп, без дә шартлы рәвештә бу чагыштырмача зур булмаган – XVII гасырның икенче яртысыннан алып XVIII гасыр ахырына кадәрге – чорны «Дагыстан дәвере» дип атарбыз. Бу чор һәм аның белем бирү системасы үзенчәлекләргә ия булган һәм татар мәгарифе тарихында билгеле эз калдырган. Татарларның Дагыстан һәм Дагыстан укымышлылары белән бәйле булган белем системасын «Дагыстан белем бирү моделе (үрнәге)» дип билгеләү дә ялгыш булмас. Дагыстан белем бирү моделе ике төрле юл белән тормышка ашырылган: Дагыстан мәдрәсәләренә барып уку һәм Идел-Урал

[5] Фәхретдин Р. Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Гыйльме хәдистән / басмага әзерләүче А. Гайнетдинов. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019. Б. 44.

[6] Шунда ук. Б. 45.

[7] Фәхретдин Р. Без – шималь (Болгар) төрекләрендә гыйлем тәхсил итү рәвешләре // Фәхретдин Р. Болгар вә Казан төрекләре. Казан, 2021. Б. 298.

[8] Хабутдинов А. Миллет Оренбургского Духовного Собрания в конце XVIII–XIX веках. Казань: Иман, 2000. С. 36.

[9] Казандагы гарәби хәрефле матбага // Шура. 1908. № 17. Б. 525.

җирлегендәге уку йортларында Дагыстан галимнәреннән белем алу. Беренчесе элеккерәк чорлар өчен хас булса, икенчесе Дагыстан Россия составына кушылганнан соң мөмкин булган, Идел-Урал мөселманнары һәм Дагыстан голямаларының педагогика өлкәсендәге бәйләнешләренең татарлар яшәгән төбәкләрдә үсүе белән билгеләнгән.

Татарлар ни өчен гыйлем алу өчен нәкъ менә Дагыстанны сайлаган соң? Мөгаен, беренче чиратта, бу татарларның сәүдә юллары белән бәйле булгандыр. Татар сәүдәгәрләре Идел буенча Әстерханга, аннан соң Кавказ аръягына, Иранга һәм Төркестанга барганнар. Бу вакытларда хаҗ юлы да Дагыстан аша узган.

Икенчедән, ул заманда Дагыстан мөселман дөньясында «Бәхер әл-голүм», ягъни «фән диңгезе» буларак билгеле булган. XVI–XVII гасырларда гарәп мәдәниятенең «үзенчәлекле ренессансы»н кичергән бу ил XVIII гасырга кадәр Көнчыгыш Урта диңгез буйларындагы гарәп илләре, Йәмән, Иран белән бик тыгыз элемтәләрдә булган[10]. Гарәп илләреннән күченеп килеп урнашкан, туган телләрен саклап калган халыкның бу төбәктә яшәве дә үзенең ролен уйнаган. Дагыстан уку йортларында гарәп телен укытуның бик югары дәрәҗәдә куелуы, аңа зур әһәмият бирелүе, белем бирүнең чиста гарәп телендә алып барылуы да соңгы фактор белән бәйле булгандыр, мөгаен. Шуңа да биредә белем алган яшьләр, шул исәптән, татарлар да, гарәп телен югары дәрәҗәдә белүләре белән башка уку йортларын тәмамлаучылардан аерылып торганнар. Морад Рәмзи фикеренчә, Дагыстан чын мәгънәсендә «гарәп теле чыганагы» булган[11]. Р. Фәхретдин дә бу фактны ассызыклаган. Аның фикеренчә, Дагыстан голямаларының абруе бу системаның гарәп телен тирәнтен рәвештә үзләштерергә мөмкинлек бирүендә. Моннан тыш, Кавказ мәгарифнең чагыштырмача иреклелеге һәм дәүләт ягыннан контрольнең булмавы белән дә аерылып торган[12]. Бу үзенчәлекләр Дагыстанда яшәүчеләрне генә түгел, башка төбәкләр, әйтик, Идел-Урал мөселманнарын да җәлеп иткән.

Билгеле булганча, Дагыстандагы иң мәшһүр мәдрәсәләрнең берсе атаклы галим Мөхәммәт бине Муса әл-Кудуки (1652–1717[13]) тарафыннан ачылган була. Әл-Кудуки гыйлемле, Йәмәндә һәм башка гарәп илләрендә белем алган

[10] Идиятуллина Г.Г. Развитие мусульманской мысли после падения Казанского ханства (XVI–XVIII вв.) // История мусульманской мысли в Волго-Уральском регионе. Казань: Изд-во ДУМ РТ, 2009. С.99.

[11] Шихалиев Ш.Ш. Краткие сведения о контактах мусульман Дагестана и Волго-Уральского региона в XVIII–XX вв. // История, археология и этнография Кавказа. Т. 16, №1. 2020. С. 109.

[12] Мухаметзянова Д.С. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. С. 81.

[13] Р.Фәхретдин Мөхәммәд әш-Ширванинең 1727 елда үз кулы белән язган хатын күргәнлеге турында хәбәр итә, шул сәбәпле вафаты соңрак булырга тиеш дигән фикерне әйтә (Фәхреддин Р. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 35).

галим була. Хисап, астрономия, грамматика, мантыйк, риторика буенча дәреслекләр язган. Фәндә ул шәригатькә каршы килүче гадәтләрне (адат)[14] бетерү яклы галимнәрнең берсе буларак билгеле[15]. Аның мәдрәсәсе Төньяк Кавказда гына түгел, Идел-Урал төбәге мөселманнары арасында да киң танылган. Р.Фәхретдин Мөхәммәт әл-Кудукиның Болгар һәм Казан шәехләренең остазы булуына басым ясый[16]. Тик, кызганычка каршы, «Асар»да да, галимнең тормыш юлы һәм эшчәнлегенә багышланган башка хезмәтләрдә дә әл-Кудукиның Идел буе мөселманнары арасыннан укучыларының конкрет исемнәре күрсәтелми. Шулай да, Р. Фәхретдингә ияреп (ул «Безнең Болгар һәм Казан ишаннарының гыйлем силсиләсе бу затка тоташа», – дип яза[17]), татарлар арасында әл-Кудукидан белем алган затларның булганлыгы турында фараз итә алабыз.

Дауд әл-Усиши (1757 елда вафат), Дамадан әл-Мухи (1724 елда вафат), Мөхәммәт әл-Убри (1733 елда вафат) кебек үзләренең мәдрәсәләрен тоткан зур галимнәрнең исемнәре шулай ук Дагыстаннан читтә дә бик яхшы билгеле була[18], мөгаен, әлеге остазларда татарлар да белем алгандыр.

Дагыстан мәдрәсәләре мәгариф үзәкләре генә булып калмыйча, төрле фәннәр буенча гарәп теленнән тәрҗемәләр ясау, кулъязма китаплар күчерү сәнгате үсеше ягыннан да яхшы билгеле булганнар. Р.Фәхретдиннең фаразлавынча, «Шурут әс-салат» (Намаз шартлары) һәм «Тагаллүм әс-салат» (Намазга өйрәтү) кебек атаклы хезмәтләр Идел-Урал төбәгенә нәкъ менә Дагыстан мәдрәсәләрен тәмамлаган яшьләр тарафыннан алып кайтылган[19]. Шушы ук юл белән «Устувани», «Алты бармак» кебек әдәп-әхлакка багышланган, шәкертлек чорында күчереп язылган кулъязма китаплар да татарлар арасында таралган. Бу чорда «дәресләр хөласа (йомгак) кеби бәгъзе бер китаплар укытмактан гыйбарәт булмыштыр» дип язганда, Р.Фәхретдин бу

---

[14] Гадәт (гарәп теленнән, «әдәб», «гадәт») – мөселман халыкларында традицион гореф-гадәтләр җыелмасы. Рәсми хокук системасына – шәригатькә каршы куела. Мал-мөлкәт, гаилә мөнәсәбәтләре һ.б. өлкәләргә караган мәсьәләләрне гореф-гадәтләр һәм халыкның хокукый тәҗрибәсенә нигезләнеп хәл итүгә нигезләнә (Большой юридический словарь. Составители: А.Я. Сухарев, В.Е. Крутских, А.Я. Сухарева, 2003 год. URL: http://law.niv.ru/doc/dictionary/big-legal/index.htm)

[15] Идиятуллина Г.Г. Развитие мусульманской мысли после падения Казанского ханства (XVI–XVIII вв.) // История мусульманской мысли в Волго-Уральском регионе. Казань: Изд-во ДУМ РТ, 2009. С. 100.

[16] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 35.

[17] Шунда ук.

[18] Шихалиев Ш.Ш. Краткие сведения о контактах мусульман Дагестана и Волго-Уральского региона в XVIII–XX вв. // История, археология и этнография Кавказа. Т. 16, №1. 2020. С. 106.

[19] Фәхретдин Р. Без – шималь (Болгар) төрекләрендә гыйлем тәхсил итү рәвешләре // Фәхретдин Р. Болгар вә Казан төрекләре. Казан, 2021. Б. 297–298.

системаның нигезендә китап, дәреслекләргә, ягъни язма мирасны куллануга игътибарның зур булганлыгын күздә тотса кирәк[20].

Дагыстанда уку-укыту эшенең бик югары дәрәҗәдә булуы турында башка татар галимнәре дә язган. Хәсәнгата Габәши, мәсәлән, белем бирүнең беренчел чыганаклар нигезендә алып барылуына басым ясый. Дагыстанда укып кайтканнар белем бирүдә турыдан-туры Зәмәхшәри, Мөхәммәт әл-Кодури, Әбу Җәгъфәр әт-Тәхави, Әбелләйс әс-Сәмәрканди, Фәхрелислам әл-Пәздәви кебек танылган акыл ияләренең китапларына таянганнар. Үзенең Ш.Мәрҗанигә багышланган мәкаләсендә Х.-Г. Габәши бүген дә, ягъни XX гасыр башында, Дагыстанда ислам фәннәрен, шулай ук гарәп телен укытуның дәрәҗәсе югары, «без күргән галимнәрнең шул фәннәрдә гыйлемнәре бик төпле күренә», – дип яза[21]. Хәзерге галимнәр дә Дагыстан мөселман белем бирү системасының шул төбәктә генә түгел, башка илләр күләмендә дә ислам белгечләре әзерләүдә роле зур булуын, аның XIII–XIV гасырларда ук формалашканлыгын, традициянең аннан соңгы дәверләрдә дә дәвам итүен ассызыклыйлар[22]. Х.-Г. Габәши Дагыстан тарафыннан кайткан галимнәрнең һәм аларда укыганнарның безнең төбәктә динне тиешле дәрәҗәдә тотарга ярдәм итүләре нәтиҗәсендә татарларның үзләрен мөселман халкы буларак саклап кала алулары турындагы фикерне әйтә[23].

Шулай итеп, татарлар белем алган чорда Дагыстан белем бирү моделенең төп үзенчәлекләреннән аның гарәп телен төпле укытуга юнәлгән булуын һәм укытуны беренчел чыганакларга нигезләнеп алып барылуын күрсәтергә мөмкин. Нәкъ шуның белән Дагыстан уку йортлары татар яшьләрен үзенә тартып торган да. Бу үзенчәлекләр, һичшиксез, татар мәгарифе үсешендә дә чагылыш тапкан, алай гына да түгел, зур йогынты ясаган. Чөнки Дагыстанда укып кайткан шәкертләр ватаннарында нәкъ шул үрнәктә, остазларының тәҗрибәсенә таянып татар балаларына белем бирергә тырышканнар. Р.Фәхретдин бу хакта болай дип яза: «Дагыстаннан килгән шәкертләрнең рәсми язулары дөрес, гүзәл булып, мәмләкәтебездә булган иске язма хезмәтләр [шул] буыннар һәм буыннарның шәкертләре тарафыннан язылган булулары мәгълүм. Боларның укыткан нәрсәләре җитди, файдалы булып, кешеләрнең әхлак һәм гадәтенә яхшы тәэсир иткән. Бу дәвердә никадәр Коръән һәм хәдис гыйлемнәре укылмаган булса да, кешеләр арасында гүзәл холык, ислам

[20] Казандагы гарәби хәрефле матбага // Шура. 1908. № 17. Б. 525.

[21] Габәши Х. Мәдрәсәләрдә дәрес укытылу тәртибе – программа хакында // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 611–612.

[22] Ярлыкапов А.А. Становление и развитие исламского образования на Северном Кавказе (VIII–XX вв.) // Духовные ценности ислама и образование: историко-культурная традиция и современность. Томск: Изд-во Том. ун-та, 2008. С. 11.

[23] Габәши Х. Мәдрәсәләрдә дәрес укытылу тәртибе – программа хакында // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 612.

буенча, туганлык, әдәп, инсафлылык таралу җәһәтеннән «алтын дәвер» дип саналган»[24].

Татар тарихында һәм татар мәгарифе үсешендәге Дагыстан чорына Р.Фәхретдин бик югары бәя биргән. Ул аны бар яктан да уңай дип санаган. Дагыстан голямаларының гарәп теленең сарыфы һәм нәхүен генә түгел, ә бәлки фикъһ, гакаид, тәфсир, хәдис белеме кебек фәннәрне укытуда да зур тәҗрибәгә ия булуларын ассызыклаган. Аның фикеренчә, «Дагыстанда булган дин ысулы гади вә файдалы булуыннан безнең мәмләкәтебез өчен гадәттән тыш файда биргән», һәм, «әгәр дә Дагыстан дәрес ысулы безнең халкыбыз кебек белемле кавем арасында урнашса иде, һәр яктан башка кавемнәрдән бер-ике баскыч югары торуыбызда шөбһә юк»[25].

Ш.Мәрҗани һәм Р.Фәхретдин хезмәтләрендә Дагыстан галимнәреннән белем алган татар мөдәррисләре – татар даирәсендә Дагыстан укыту тәртипләре үрнәгендә татар балаларына белем һәм тәрбия биргән, шул рәвешле татар педагогик фикере үсешенә өлеш керткән кайбер шәхесләр искә алына.

Татарлар арасында Дагыстанда белем алганлыгы билгеле булган беренче татар кешесе булып Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети (1723 елдан соң вафат) санала[26]. Тикшеренүчеләрнең фаразы буенча, ул Мөхәммәт әл-Кудуки мәдрәсәсендә белем алган булырга тиеш[27]. Әлеге мәгълүмат Р.Фәхретдин хезмәтләрендә дә урын ала[28]. Галимҗан Баруди исә аның Урта Азия якларында укып кайтуы турында яза: «Мулла Мортаза Хафиз бине Котлыгыш Казан вилаятендә тәхсил вә гыйлем кылдыктан соң, Бохара вә Төркестан вилаятьләрендә гыйлем арттырып, «Тарикате Йәссәвия»дән өлеш алып кайткан соң, уникенче гасыр Һиҗри башларында Казан вә Болгар йортының гыйлемгә иң мохтаҗ вакытында халыкка дин үгрәтеп дәрес укыта»[29]. Кайбер тикшеренүчеләр Баруди мәкаләсенең 8 елга соңрак язылуына һәм дәлиләр китерүенә (Йәссәвия тарикатенә караганлыгы) таянып, аның Урта Азиядә белем алуы хакындагы мәгълүматның дөреслеккә туры килү ихтималы зуррак

[24] Фәхретдин Р. Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Гыйльме хәдистән / басмага әзерләүче А. Гайнетдинов. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019. Б. 44–45.

[25] Фәхреддин Р. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре // Фәхреддин Р. Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр: сайланма хезмәтләр. Казан: Рухият, 2011. Б. 177.

[26] Хабутдинов А.Ю. Этапы развития образования у мусульман Оренбургского магометанского духовного собрания в XVIII – начале XX вв.: региональный аспект. URL: http://idmedina.ru/books/materials/faizhanov/2/plenary_habutdinov.htm (дата обращения: 12.01.2022).

[27] Шихалиев Ш.Ш. Краткие сведения о контактах мусульман Дагестана и Волго-Уральского региона в XVIII–XX вв. // История, археология и этнография Кавказа. Т. 16, №1. 2020. С. 108.

[28] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 35.

[29] Баруди Г. Иман шарты // Әд-дин вәл-әдәп. 1906. № 10. Б. 318.

булуы турында язалар[30]. Ләкин бу мәсьәләне тулысынча хәл ителгән дип санау өчен нигез җитәрлек түгел.

Ватанга әйләнеп кайтканнан соң, Мортаза әс-Симети Казан губернасы Мамадыш өязе Симет авылында мәдрәсә ачкан, берничә хезмәт язган, шуларның берсе намаз кагыйдәләренә багышланган[31]. Мортаза әс-Симети, моннан тыш, безнең көннәргә килеп ирешкән татар телендәге беренче сәяхәтнамә авторы буларак та татар әдәбияты тарихына кереп калды. Әлеге әсәр 1698 елда иҗат ителгән[32]. Анда авторның Гарәбстанга хаҗга баруы, хаҗ юлы турында мәгълүмат бирелә, хаҗга баруның әһәмияте, мәҗбүрилеге турында сөйләнә. Ул үзенең шәкертләрен исламның изге урыннарын күрергә, хаҗ сәфәренә барырга өнди[33]. Хаҗнәмә текстын өйрәнгән Р.Фәхретдин исә текстта төгәлсезлекләрнең һәм дөреслеккә бик үк туры килеп бетмәгән, бәхәсле моментларның булуы турында искәртә[34]. Мортаза бине Котлыгыш үзен суфи буларак тәкъдим итә һәм «Йәссәвия» тарикатенә каравын белдерә[35]. Аның укучылары арасында Әгъзәм бине Габдрахман әт-Тинеки, Габдрәшит бине Кадыйрмөхәммәт әс-Сабави, Рафикъ бине Таййиб әл-Курсави[36], Диния нәзарәтенең беренче мөфтие Мөхәммәтҗан Хөсәеновның бабасы Мансур әл-Борындыкый[37], Ибраһим ән-Нократый (? – 1780) бар. Соңгысы үзенең бик күп авылларда укытуы һәм һәрбер укыткан авылында мәдрәсә ачуы белән билгеле. Ш.Мәрҗанинең язуы буенча, Ибраһим хәзрәтнең мәдрәсәсе 1753 елда Хәсәншәех авылында булса, соңрак Казакълар, Шашы һ.б. авылларда барлыкка килә[38]. Бу XVIII гасырда татар мәгарифе үсешендәге бик кызыклы үзенчәлек турында сөйли: татарларда белем йорты аның мөдәррисе белән турыдан-туры бәйле булган һәм аның белән күчеп йөргән. Ибраһим ән-

[30] Яхин Ф.З. Татар дини китапларыннан – «Иман шарты» // Образование и право. 2022. № 8. С. 131.

[31] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит.нәшр., 1989. Б. 234.

[32] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 38–39.

[33] Гайнетдинов М. На пути истины. Литературная критика. Казань: Тат. кн. изд-во, 2001. Б. 52–53.

[34] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 38–39.

[35] Хабутдинов А.Ю. Этапы развития образования у мусульман Оренбургского магометанского духовного собрания в XVIII – начале XX вв.: региональный аспект. URL: http://idmedina.ru/books/materials/faizhanov/2/plenary_habutdinov.htm (дата обращения: 12.01.2022).

[36] Марджани Ш. Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С.475.

[37] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 235.

[38] Шунда ук. Б. 241.

Нократый ислам фәннәрен яхшы белүе һәм укучыларының саны күп булуы белән дә билгеле[39].

Болардан тыш, Ш.Мәрҗани тагын Мөхәммәтрәхим бине Йосыф бине Габделкәрим әл-Ашытины (1818 елда вафат) искә ала. Ашыт авылында өч ел имамлык иткәннән соң, ул, белемен ныгыту максатын күздә тотып, иптәше Ибраһим бине Хуҗаши (1826 елда вафат[40]) белән Дагыстан якларына юнәлә. 10 ел дәвамында алар Гали әд-Дагыстани әш-Ширвани кебек атаклы галимнәрдә укып, гыйлемнәрен арттырганнар[41]. Ш.Мәрҗани аның турында түбәндәге мәгълүматны язып калдырган: «Мелла Мөхәммәтрәхим үз вакытының бик мәшһүр остазы булган»[42]. Аның шәкертләре арасында Габденнасыйр әл-Курсави, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртуши, Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани һәм башка билгеле шәхесләр булган.

Ибраһим бине Хуҗаши[43], 1780 елда Дагыстаннан кайтканнан соң, Казан арты авылларында имамлык итә, балалар укыту белән шөгыльләнә. Соңыннан Казан шәһәренә күченеп килә һәм Беренче мәхәллә мәчетенә (ул чорда «Юныс мәчете» буларак та билгеле була, хәзер Мәрҗани мәчете) имам итеп билгеләнә. Аның мәдрәсәсендә әлифба, иман шарты, гыйльме нәхү, гыйльме сарыф, мантыйк, гакаид, тәфсир, хәдис шәриф, гыйльме фәраиз, астрономия кебек предметлар укытылган (соңгысы Дагыстан уку йортларында киң таралган була). Астрономияне үзләштерер өчен тригонометрия буенча белемнәр таләп ителгән, димәк, мәдрәсә шәкертләренең фикерләү дәрәҗәләре шактый югары булган, дип нәтиҗә ясарга мөмкин[44]. Ш.Мәрҗани Хуҗаши шәхесе белән шәһәр мөселманнары мәдәниятенә кертелгән күп кенә яңалыкларны бәйләп карый[45]. Морад Рәмзи мәгълүматларына караганда, үз заманында Хуҗаши Казан шәһәренең иң атаклы галимнәреннән саналган, хәтта 1798 елда

---

[39] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 241.

[40] Марджани Ш. Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С. 271.

[41] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 263–264, 266.

[42] Шунда ук. Б. 264.

[43] Ибраһим бине Хуҗаши Бөгелмә өязе Шарлама авылында дөньяга килә // Марджани Ш. Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С. 489.

[44] Мухаметзянова Д.С. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. С. 83–84.

[45] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит.нәшр., 1989. Б. 266–269.

император Павел I Казанга килгәндә аның кулыннан алтын сәгать[46] алуга ирешкән[47].

Р.Фәхретдин Дагыстан мәдрәсәләрен тәмамлаучылар арасында Тукмөхәммәт бине Нияки бине Түнчәлине искә ала. Ул җәмәгатьчелек арасында шулай ук Тукмөхәммәт хафиз, Тукмөхәммәт шәех буларак та билгеле була[48]. Тукмөхәммәт Түнчәлинең улы Ишмөхәммәт Адай авылында 36 ел дәвамында имам һәм мөдәррис булып торган[49], XVII гасыр ахырында суфичылык остазы буларак танылган, оныгы Габделкәрим Бине Балтай бине Ишмөхәммәт (1757/58 елда вафат) шулай ук ата-бабалары юлын дәвам иткән, шәех, Сәгыйть Каргалысында имам һәм мөдәррис булган[50]. Аның Бохарада белем алуы, нәкышбәндия тарикатенә караганлыгы турында мәгълүмат сакланган[51].

Татар галиме Морад Рәмзи, үз илендә белем алганнан соң, Дагыстанга барып «кайбер голямалардан гыйлем алган» татар галиме Әмирхан бине Кучкар бине Йагъкуб (1826–27 елларда вафат), Дагыстанда укып кайтканнан соң Уфадан ерак булмаган бер авылда мәдрәсә ачкан Фазыл бине Ибраһим әл-Ачкыни турында яза[52].

Р.Фәхретдин хезмәтләрендә татар галиме, чыгышы белән Казан өязе Комыргуҗа авылыннан булган Сәйфулла бине Үтәгән бине Надир (1853 елда вафат) искә алына. «Тирә-ягындагы мөгаллим вә мөдәррисләрдән укыганнан соң, Сәгыйть бистәсенә барган, соңыннан Дагыстан якларына сәфәр кылган»[53]. Автор шулай ук Казанда, Бохарада һәм «күпмедер вакыт Дагыстан вилаятендә сәяхәт итеп йөргән», чыгышы белән Спас өязе Баллыкүл авылыннан булган шәех Җәгъфәр бине Салих әл-Кулаткый турында мәгълүмат

[46] Ш.Мәрҗани император Ибраһим хәзрәткә баш киеме бүләк иткән дип күрсәтә. Әмма хезмәтне басмага әзерләүчеләр Хуҗашиның Павел I тарафыннан алтын медаль алуы турында язалар (Марджани Ш. Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С. 271, 489).

[47] Шихалиев Ш.Ш. Краткие сведения о контактах мусульман Дагестана и Волго-Уральского региона в XVIII–XX вв. // История, археология и этнография Кавказа. Т. 16, №1. 2020. С. 108.

[48] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 237.

[49] Мухамедьяров Ш.Ф. Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства (XV – первая половина XVI вв.). Казань: Изд-во «Ихлас»; Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2012. С. 110.

[50] Ислам на Урале: энциклопедический словарь. М.: Издательский дом «Медина», 2009. С. 21.

[51] Марджани Ш. Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С. 477.

[52] Шихалиев Ш.Ш. Краткие сведения о контактах мусульман Дагестана и Волго-Уральского региона в XVIII–XX вв. // История, археология и этнография Кавказа. Т. 16, №1. 2020. С. 108, 109.

[53] Фәхреддин Р. Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. Б. 58.

бирә[54]. Бик күп җирләрдә булып гыйлем туплаган Җәгъфәр шәех, күзләре начар күрсә дә, мөгаен, Дагыстан җирләрендә дә гыйлем туплавын дәвам иткәндер. Бохарада Габделхаликъ хозурында тарикать юлына басуы да[55] сәбәп булырга мөмкин.

Күренекле татар галиме, акыл иясе, шагыйрь, татар дөньясында киң билгеле булган, мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек буларак кулланылып килгән «Рисаләи Газизә» әсәренең авторы Таҗетдин бине Ялчыголның да (1763–1838) Дагыстан голямаларыннан белем алуы турында мәгълүмат бар. 1775 елда ул әтисе белән бергә Дагыстанга китә, аннан соң Диярбакырда туктала. Ул белем алган галимнәр арасында дагыстанлы Җомгакилде әфәнде була. Дәлил итеп Ялчыгол күчереп язган китапларның берсе – «Хидаятель-хикмәт»нең ахырындагы сүзләрне китерергә мөмкин. Р.Фәхретдин хәбәр итүенчә, анда мондый юллар бар: «бу фәннән Дагыстан вилаятендә Әл-Җаксай шәһәрендә Җомгакилде әфәнде мәдрәсәсендә дәрес алдым. Һәм бу нөсхә 1243/1828 елда Таҗетдин бине Яхшыколый әл-Болгари әл-Иштәки кулы белән рамазан аенда күчерелде»[56].

Татар шәкертләренә гарәп телен укытуны торгызган[57], «Казан шәһәрен Русия басып алганнан соң, әүвәл мәртәбә буларак гарәп теленең сарыф вә нәхүен укыткан»[58] мөдәррис – Мөхәммәт бине Гали әд-Дагыстани (? – 1796) татарлар арасында «Казакай ахун» тәхәллүсе белән яхшы билгеле шәхес[59]. Ул Әхмәт Дагыстанида белем алган, анысы исә Мөхәммәт әл-Кудукиның шәкерте була[60]. Әлеге галим XVIII гасыр урталарында Оренбург тирәсендәге Кондырау Нугай авылында үзенең мәктәбен һәм мәдрәсәсен булдыра. Р.Фәхретдиннең күп кенә замандашлары, Дагыстаннан сөрелеп җибәрелүе, шунда мөфти булып хезмәт итүе фактына нигезләнеп, аның дагыстанлы (кавказлы) булуын дәлилләләр. Ш.Мәрҗани[61] һәм Р.Фәхретдин дә бу фикер яклы була-

[54] Фәхреддин Р. Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. Б. 92–93.

[55] Шунда ук. Б. 92.

[56] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 151.

[57] Махмутова А. Традиционные учебные заведения и новометодное образование // История татар с древнейших времен в семи томах. Том VI. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2013. С. 792.

[58] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 54.

[59] Шунда ук. Б. 53.

[60] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит.нәшр., 1989. Б. 270.

[61] Ш.Мәрҗани аның Азәрбайҗаннан булуы турында яза // Марджани Ш. Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С. 248.

лар. Хәзерге тикшеренүчеләр арасында да әлеге версия алга сөрелә[62]. Шулай ук аның Казан татары булуы хакындагы фикерләр дә бар. Р.Фәхретдин, халык арасында таралган риваятькә таянып, Мөхәммәтнең морзаларда кучер булып хезмәт итүе, үзенең матди хәлен яхшыту максатыннан морзалар оештырган кичәләрдә төрле музыка уен коралларында уйнап, кунакларның күңелен ачуы турында яза. Шундый кичәләрнең берсендә, аның «бер галим, бер гыйлем диңгезе икәнен аңлап» алган кунаклар хуҗадан Мөхәммәтне азат итүен үтенгәннәр. Менә шуннан соң ул балалар укыту һәм тәрбияләү белән шөгыльләнә башлаган, «шәкертләренә фән ысулларын һәм мәгърифәт нигезләрен укыткан»[63]. Үзенең бар көчен мөселман мәхәлләсен ныгытуга куйган, «дини кардәшлекне вә милли бердәмлекне берек тоту өчен бар куәтен сарыф иткән». Р. Фәхретдин аның безнең мәмләкәтебез мөселманнары өчен иткән хезмәте һәм күрсәткән эшен бик югары бәяли: «Үз иленнән куылып, безгә җибәрелүе милләтебез өчен зур бәхет булып хисаплана», – ди[64]. Мөхәммәт ахунның Дагыстан белем бирү традицияләренә таянып, гарәп телен тирән һәм нигезле укытуы тирә-юньнән шәкертләрне тарткан. Аның укучылары арасында Диния нәзарәтенең беренче мөфтие М.Хөсәенов (1758–1824), суфи, шәех һәм шагыйрь Вәлит әл-Кайбычи (1753–1802), дин әһеле, педагог Габдрахман бине Мөхәммәтшәриф әл-Кирмәни (1744–1827) һ.б. була. Соңгысына Р.Фәхретдин «мәмләкәтебездә булган галимнәрнең иң гыйлемле һәм укымышлыларыннан» дип бәя биргән[65]. Моннан тыш, Нигъмәтулла әт-Тәүзихи, Муса бине Габдрәшит әт-Түнтәри һ.б. да Мөхәммәт әд-Дагыстанида белем алганнар. Шулай итеп, Дагыстан мөдәррисе нигез салган мәдрәсә Идел-Урал төбәгендә мөселман дине белгечләрен әзерләүдә иң мөһим үзәкләрнең берсенә әверелә, Дагыстан белем бирү үрнәгенең татар җирлегендә ныгып урнашуына нигез булып хезмәт итә. 1795 елда Мөхәммәт әд-Дагыстанинең вафатыннан соң мәдрәсәдә әлеге укыту системасы үзенең көчен югалта башлый, ләкин традиция берникадәр вакыт дәвам итә әле.

Ш.Мәрҗани хезмәтләрендә сөргенлеккә эләгеп, башта Пермь, Казанда яшәгән, соңыннан Әстерханда гомер иткән, 1877 елда 65 яшьләр тирәсендә вафат булган Мәхмүт бине Мөхәммәт бине Садыйк бине Мостафа бине Гали әш-Ширвани искә алына. Чыгышы белән Ширваннан булган остазны ул галим, изгелекле, рәхимле, дингә нык бирелгән, дини йолаларны үтәүгә зур игътибар бирүче зат буларак бәяли. Моннан тыш, әш-Ширвани хаттат булган һәм бәетләр, шигъри әсәрләр иҗат иткән (алар арасында Идел Болгары халкына дан җырлаган текстлар да була) оста шагыйрь буларак та танылган.

[62] Шихалиев Ш.Ш. Краткие сведения о контактах мусульман Дагестана и Волго-Уральского региона в XVIII–XX вв. // История, археология и этнография Кавказа. Т. 16, №1. 2020. С. 107.

[63] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 54.

[64] Шунда ук.

[65] Шунда ук. Б. 116.

Мәхмүт әш-Ширванинның шәкертләре арасында Идел буе татарлары Закир бине Габделваһһаб бине Габделкәрим әс-Саснави, Габделгали бине Гобәйдулла бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви, Габдулла бине Габделгафур әл-Чәкмәки һ.б. була[66].

Гомумән алганда, XVIII гасырның икенче яртысында Идел-Урал төбәгендә татар мәгарифе үсешендә Дагыстан традициясенең тәэсире әкренләп кими башлый. Моңа бер үк дәрәҗәдә һәм сәяси, һәм социаль-икътисади факторлар сәбәп була: Кавказда Россия йогынтысы арту, Кавказ сугышы башлану[67], ике арада икътисади бәйләнешләрнең булмавы, Урта Азия белән, киресенчә, сәүдә һәм дипломатик элемтәләрнең киңәюе һ.б. Дагыстан белем бирү моделеның татар җирлегендә озак яшәмәвенең тагын бер сәбәбен галимнәр, Бохара системасыннан аермалы буларак, эзлеклелек булмауда, ягъни Дагыстанда укып кайткан кешеләрнең укучыларын үз уку йортларына җибәрмәүләрендә, нәтиҗәдә дәвамчыллык чылбырының өзелүендә күрәләр. Болар барысы да Дагыстан белем бирү үрнәгенең көчсезләнүенә китергән. Шулай итеп, моннан соңгы чорда мәгариф өлкәсендә беренчел позицияләр Урта Азия уку йортлары карамагына күчә.

[66] Марджани Ш. Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С. 355–356.

[67] Махмутова А. Традиционные учебные заведения и новометодное образование // История татар с древнейших времен в семи томах. Том VI. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2013. С. 795.

# Бохара белем бирү системасы
# һәм татар шәкертләре

XVIII гасырның икенче яртысында Урта Азия белән икътисади-сәүдә һәм дипломатик бәйләнешләр ныгу татар яшьләренең белем артыннан мөселман гыйлемлелек үзәге булган Бохара һәм Сәмәрканд якларына күбрәк юнәлүләренә сәбәп була. Төбәкнең Россиягә кушылуыннан соң, андагы белем йортлары, уку-укыту системасы белән кызыксыну тагын да арткан. «Екатерина II, Төркестан вә Бохара тарафлары белән элемтәләр булдырыр өчен, бу Казан тирә-ягы сәүдәгәрләренә мөрәҗәгать иткән. Ул вакыт, бер яктан, Дагыстан тарафларына (төрле вакыйгалар сәбәбеннән) китү уңайсыз, икенче яктан, ул вакыт Бохара олуг мәдрәсәләре илә мәшһүр булганлыктан, безнең сәүдәгәрләребез шәкертләребезне Бохара тарафларына алып бара башлаганнар»[1]. Моннан тыш, мәдрәсәләрдә белем туплау белән беррәттән, татар шәкертләренең күпчелеге суфичылык серләре белән кызыксынып, шул җирләрдәге шәехләрдән иҗазәт (рөхсәт) алырга тырышканнар. Шәкертләр белән бергә уку-укыту тәртибе генә түгел, суфичылык фикерләре дә кайткан, ныклап урнашкан. Татарларның дини мәгариф системасының бу чордагы үсеше шул үзенчәлекләр белән билгеләнә.

Урта Азия мөселман мәгарифенең башка илләрнең укыту системасы белән охшаш һәм алардан аерылып торган яклары бар. Иң беренче чиратта, аның, башка галәми белем үзәкләре кебек үк, шул төбәк халкы өчен генә түгел, ә бүтән илләр, аерым алганда Россия мөселманнары өчен дә хезмәт итүен әйтергә кирәк. Бу традиция бик борынгы заманнарда ук башланып, Россия дәүләтенә кушылганнан соң да дәвам иткән. Төрле чорларда үз үзенчәлекләре дә булган, әлбәттә.

Фәндә, гомумиләштереп, «Бохара уку йортлары» дип атап йөртелгән Урта Азия мәдрәсәләре тарихы тикшеренүчеләр тарафыннан шактый өйрәнелгән. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында дөнья күргән хезмәтләрдә Урта Азия дәүләтләре тарихына бәйле рәвештә җирле мәдрәсәләргә («Олугбәк», «Ширдар», «Тиллә-кари» һ.б.) кагылышлы мәгълүматлар бирелсә дә, нигездә шул чор чагылыш таба (рус-туземецлар мәктәпләре, җәдитчелек һ.б.). Совет чоры фәнендә бигрәк тә җәдитчелек дәвере һәм җәдиди мәктәп-мәдрәсәләр эшчәнлеге, советлар дәвере тасвирланды. Соңгы елларда басылып чыккан хезмәтләрдә Урта Азиянең төрле ханлыкларында мәдрәсәләр тарихы буенча кызыклы мәгълүматлар табарга мөмкин, һәм алар совет идеологиясеннән азат булып, мәсьәләне объектив яктыртырга тырышулары белән аерылып тора. Мәсьәләнең икенче, бигрәк тә безнең өчен кызыклы булган ягы – татар шәкертләренең Урта Азия мәдрәсәләрендә белем алулары проб-

[1] Габәши Х. Мәдрәсәләрдә дәрес укытылу тәртибе – программа хакында // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 612–613.

лемасы әлегәчә ачык булып кала. Моңа аңлатма да бар кебек – бу чорны чагылдырган материаллар архивларда аз сакланган яисә бөтенләй дә сакланмаган. Мәдрәсәләр эшчәнлегенә караган мәгълүматларның булмавы сәбәпле, урта гасырларда мәгариф торышын яктырткан югары мәдрәсәләр тарихы турында җентекләп язу мөмкинлеге чикле булуын үзбәк галимнәре дә ассызыклый[2]. Татар шәкертләре белән бәйле рәсми информация белән танышу шулай ук мөмкин түгел. Шәкертләрнең мәдрәсәләргә түгел, ә остазларга ориентлашуы да үз ролен уйнагандыр. Бохара системасы һәм бу төбәктәге уку йортлары тарихы классик тикшеренүчеләр Н.А.Бобровников[3], В.В.Бартольд[4] һәм хәзерге үзбәк тикшеренүчеләре хезмәтләрендә чагылыш таба, татарлар турындагы мәгълүматларны туплауда төп чыганаклар булып Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин кебек олуг галимнәребезнең китаплары тора. Материалларның икенче бер төрен Бохарада укыган татар шәкертләренең бүгенгәчә сакланып калган хатлары, хатирәләре, кулъязма китаплары һ.б. тәшкил итә. Бохара мәдрәсәсендә укыган чорда казанлы Салих бине Исхак тарафыннан язылган (күчерелгән?) кулъязма КДУның Н.Лобачевский исемендәге китапханәсендә, Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә А.Фәтхи фондында саклана[5]. Аларны җентекләп өйрәнү мәсьәләгә беркадәр ачыклык кертергә мөмкин.

Соңгы елларда үзбәк галимнәренең бу темага багышланган саллы хезмәтләре барлыкка килде. Мисал итеп, Абдусаттор Җуманазарның Бохарада уку-укыту тарихына, Ибраһимҗон Алимовның Коканд ханлыгында мәдрәсә һәм мәктәпләр, Уктамбек Султоновның Ташкент мәчетләре һәм мәдрәсәләре тарихына багышланган китапларын китерергә мөмкин[6]. Аларда Урта Азия уку йортлары турында бик бай һәм кызыклы мәгълүматлар тәкъдим ителә, мәдрәсәләрнең барлыкка килүе, вакыф мәсьәләләре белән беррәттән, укыту тәртибе, фәннәр, остазлар турындагы материаллар бирелә. Ләкин, кызганычка каршы, татарлар буенча информация юк дәрәҗәсендә. А.Җуманазар хезмәтенең Турсунҗан мәдрәсәсенә багышланган бүлегендә генә Әмир Хәйдәрнең яңа бер остазы буларак тәкъдим ителгән Фәхретдин бине Ибраһим әл-Казани турында кыскача хәбәр китерелә. Китап авторы язуынча, ул Россиянең атаклы галимнәре белән таныш була, Габдулла әл-Мәчкәрәви

---

[2] Жуманазар А. Бухоро таълим тизими тарихи. Тошкент: Akademnashr, 2017. Б. 6.

[3] Бобровников Н.А. Русско-туземные училища, мектебы и медресы Средней Азии: Путевые заметки. СПб.: Сенат. тип., 1913. 90 с.

[4] Бартольд В.В. История культурной жизни Туркестана. Л.: Изд-во АН СССР, 1927. 256 с.

[5] КДУ КСКБ. Альберт Фәтхи фонды. Ф. 6. Б. 38.

[6] Жуманазар А. Бухоро таълим тизими тарихи. Тошкент: Akademnashr, 2017. 592 б.; Алимов И. Қўқон хонлиги мадраса ва мактаблари тарихи. Тошкент: «Фан» нашриёти, 2017. 304 б.; Султонов Ў. Тошкент масжидлари тарихи. Тошкент: «Янги аср авлоди», 2010. 158 б.

һәм Габденнасыйр Курсави белән бер мәдрәсәдә эшли[7]. Гомумән алганда, Урта Азия уку йортлары һәм анда укыган татарлар турындагы мәгълүматлар күп очракта соңгырак чорга карый, алар җәдиди мәктәпләр һәм XIX гасыр ахыры – XX гасыр башын үз эченә алган чор белән бәйле рәвештә карала[8].

Р.Фәхретдин татар мәгарифе үсешенә зур йогынты ясаган бу чорны шартлы рәвештә «схоластик дәвер» дип атый һәм аның кабат тернәкләнеп китүен Оренбург шәһәре төзелү белән бәйли. «Сахра халыклары Русия гражданлыгын кабул итүләре сәбәпле, Төркестан белән Русия арасында сәүдә юллары ачылып, кәрваннар йөри башлаган, моннан файдаланып, гыйлем алу максаты белән Русия мөселманнары Бохара тарафларына сәфәр кылдылар. Бу вакытта Русия дәүләте дин иреге игълан иткән һәм ислам динен рәсми рәвештә тануыннан, Бохарадан кайткан галимнәр хәтта олы мәдрәсәләр төзеп, тулы ихтыярлары белән укыта башлаганнар»[9], – дип яза галим.

Билгеле булганча, Урта Азия мөселман уку йортлары бик борынгы заманнарда ук барлыкка килеп, озак гасырлар дәвамында үзләренең абруен һәм традицияләрен саклап калган мәртәбәле белем учаклары булганнар. Гарәп басып алулары нәтиҗәсендә төбәккә ислам дине үтеп керә, күпләп мәктәп-мәдрәсәләр ачыла. Озакламый Бохара бөтен Урта Азиянең ислам мәгарифе һәм рухи мәдәният үзәге булып әверелә, анда фән һәм мөселман мәгариф системасы формалаша, үзенчәлекле укыту ысуллары барлыкка килә. Урта Азиянең гыйлемлелек буенча торкан дан-шөһрәтен әл-Бохари, Әбугалисинә, Гомәр Хәйям һ.б. бик күп акыл ияләренең хезмәтләре аша таныйбыз. Бу вазгыять XVIII–XIX гасырның беренче яртысына кадәр сакланып килә. Бохарада әлеге чорда җәмгысе 150 дән артык мәдрәсә булган, аларда укучылар саны 30 меңгә кадәр җиткән[10]. Габдрәшит Ибраһимов мәгълүматлары буенча да саннар якынча шул тирә – «200гә якын мәдрәсә һәм 27 меңгә якын шәкерт булуы билгеле»[11].

Иң атаклы уку йортлары арасында «шөһрәте галәмгә таралган»[12] «Мир Гарәб», «Абдул-Азизхан», «Күгелташ», «Бохараның иң борынгы һәм иң мәшһүр мәдрәсәсе»[13] «Мирза Олугбәк», «иң абруйлы мәдрәсәләрнең берсе»[14]

---

[7] Жуманазар А. Бухоро таълим тизими тарихи. Тошкент: Akademnashr, 2017. Б.416.

[8] Расулов А.Н., Исокбаев А.А., Насретдинова Д.М. Татары в Туркестане на изломе эпох (начало XX века). Казань: ИЯЛИ, 2021. 256 с.; Насретдинова Д.М. Туркистоннинг маданий ҳаётида татар-бошқирд аёлларининг тутган ўрни (XIX аср охири – XX асрнинг биринчи чораги). Тарих фанлари номзоди илмий даражасини олиш учун тақдим этилган диссертация автореферати. Тошкент, 2011. 29 б.

[9] Фәхретдин Р. Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Гыйльме хәдистән / басмага әзерләүче А. Гайнетдинов. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019. Б. 45.

[10] Иванов П.П. Очерки по истории Средней Азии (XVI – середина XIX вв.). М.: Изд. восточной лит-ры, 1958. С. 107–108.

[11] Ибраһимов Г. Ислам дөньясы // Безнең мирас. 2017. №3. Б. 52.

[12] Жуманазар А. Бухоро таълим тизими тарихи. Тошкент: Akademnashr, 2017. Б. 339.

[13] Шунда ук. Б. 353.

«Фәтхулла Кошбиги», «Чор Минор» кебек мәдрәсәләр булган. «Күгелташ» мәдрәсәсен галимнәр Бохара дәүләтенең үзенчәлекле фәннәр академиясе дип бәялиләр[15]. Бохарадан кала икенче урында Сәмәрканд шәһәре торган. Анда унлап мәдрәсә – «Ширдар», «Олугбәк», «Казый Адбул Гафур» һ.б. эшләп килгән. Бу яктан караганда, Бохараның беренче урында торуы аңлашыла да, шуңа күрә дә Урта Азия белем бирү йортларында укыту тәртипләренең, гомумиләштереп, «Бохара системасы» дип аталуы сорау тудырмый.

Галимнәрнең билгеләвенчә, Бохара мәдрәсәләре Төркестанда гына түгел, башка төбәкләрдә дә яхшы танылa. «Бирегә Хива, Коканд, Гиссар, Сәмәркандтан һәм бик күп татар өлкәләреннән шәкертләр киләләр»[16]. XIX гасырда да үзенең дини белем бирү үзәге дигән элеккеге данын саклап кала алган Бохара Идел буеннан килгән шәкертләрне аеруча нык җәлеп иткән[17].

Бу чорда ислам тарихы һәм татар мәгариф системасы үсеше суфичылык, Урта Азия шәехләренең йогынтысы белән турыдан-туры бәйләнгән. Гомумән алганда, суфичылыкның татар иҗтимагый-дини һәм педагогик фикере формалашудан тыш, әдәбият үсешенә керткән өлеше дә зур. Урта гасырларда татар шигърияте суфичылык белән тыгыз үрелеп үскән, шагыйрьләрнең күпчелеге суфилар булганнар. Баштагы чорда йәссәвия традицияләренә өстенлек бирелсә, XVIII–XIX гасырларда нәкышбәндия тарикате киң тарала. Мисал өчен Г.Утыз-Имәни, Г.Курсави һ.б. исемнәрне атап китү дә җитәр. Алар шәригать нигезләрен тирәнтен өйрәнгәч кенә тәсаувыф (суфичылык) юлына басканнар[18].

«XVI гасырның икенче яртысы – XVIII гасырларда татарлар арасында суфичылык киң тарала. Белем бирү шәех-мөрид чылбыры рәвешен ала, остазы шәехкә мөриднең берсүзсез буйсынуына корылган кырыс тәртипләр һәм ябык тарикатьләр урнаша. Суфичылык асылда мөселман өммәтен берләштерә һәм авыр шартларда мөселман уку-укыту системасын саклый һәм үстерә. Әмма Урта гасырлардан килгән стереотипларны саклау һәм иске ысулларга гына таянырга омтылу аңа көчәеп үсәргә комачаулый»[19].

Татарлар арасында XIX гасырда нәкышбәндия мөҗәддидия тармагы үсеш ала. Бу юнәлеш тарафдарлары мәктәп һәм мәдрәсәләрдә укытканнар, имамнар булып халыкка хезмәт иткәннәр.

---

[14] Жуманазар А. Бухоро таълим тизими тарихи. Тошкент: Akademnashr, 2017. Б. 424.

[15] Шунда ук. Б. 308.

[16] Записки о Бухарском ханстве (Отчёты П.И. Демезона и И.В. Виткевича). М.: Наука. 1983. С. 46.

[17] Бартольд В.В. История культурной жизни Туркестана. Л.: Изд-во АН СССР, 1927. С. 123.

[18] Батыршин Ф. Идел буенда тарикатьләр: тарихы һәм хәзерге заман. URL: https://dumrt.ru/help-info/theology/analytics_4709.html?curPos=20 (мөрәҗәгать итү датасы: 22.04.2022).

[19] Татар теле: үткәне һәм бүгенгесе / хезмәтне әзерләүчеләр: Р.Г. Галиуллин, Г.К. Һадиева. Казан, 2021. Б. 55.

Иң күренекле суфилардан мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәеновны, татар суфилары турында төп чыганак булып торган хезмәтләрнең авторлары Ш.Мәрҗани, М.Рәмзи һәм Р.Фәхретдинне атарга мөмкин (соңгылары нәкышбәндия мөҗәддидия әгъзалары буларак билгеле)[20]. Бу хезмәтләр аша татарларда XIX гасырда суфичылык үсешенең Бохара һәм Кабул остазларына барып тоташканлыгы күренә. Болар – Ниязколый әт-Төрекмәни һәм Фәезхан бине Хозырхан әл-Кабули. Урта Азия мәдрәсәләрендә белем алган татар шәкертләре нәкъ шул шәкертлек чорында нәкышбәндия мөҗәддидия тарафдарлары булганнар. Алда искә алынган суфилар Идел-Урал татарларының һәм башкортларының күпчелегенең остазлары булганнар. Ватаннарына кайтып педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнгән кичәге Бохара шәкертләре үз укучылары арасында суфичылык фикерләрен таратканнар, суфичылык үзәкләренә нигез салганнар. Ниязколый мөридләре арасында Уралдагы иң эре суфичылык үзәге булып хезмәт иткән Эстәрлебаш мәдрәсәсе җитәкчесе Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрлебаши, күренекле галим, имам һәм мөдәррис Габденнасыйр Курсави, шагыйрь Әбелмәних Каргалый да була. Фәезхан әл-Кабули дәвамчылары арасында тумышы белән Уфа тирәсендәге Чишмә авылыннан булган шәех Җәгъфәр бине Габдине (1823/24 елда вафат), шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәнине, Каргалыдан Вәлид бине Мөхәммәт әл-Әминне (1802/03 елда вафат) аерып күрсәтергә мөмкин. Гобәйдулла бине Җәгъфәр әл-Кизләви (1822/23 елда вафат) Кизләү авылында суфилар династиясенә нигез салучы буларак билгеле[21]. Болардан тыш, М.Кэмпер Гали Чокрыйның әсәренә нигезләнеп, ул искә алган суфилардан Хәбибулла әл-Орувины (1817/18 елда вафат), Габдулла Мәчкәрәвине (1859 елда вафат), Гали әт-Түнтәрине (1875 елда вафат), Харис бине Нигъмәтулла әл-Эстәрлебашины (1870/71 елда вафат) атый. Соңгысы Эстәрлебашта үз хисабына бик зур китапханә һәм үзе ачкан суфи үзәге өчен кунак йортын оештыручы буларак билгеле. Автор аларның күбесенең Фәезхан әл-Кабули тарафдарлары булуларын ассызыклый[22].

XIX гасырның икенче яртысыннан татар шәкертләренең ватаннан читтә белем алуларының юнәлешләре үзгәрү белән суфичылык традицияләре туктамый. Бу чорда Идел-Урал мөселманнары Төркиядәге «бохара» шәехләренә, Мәккә һәм Мәдинәдәге гарәп булмаган мөридләр белән эшләүче мөҗәддидия шәехләренә ияргәннәр[23]. Шул ук вакытта Мәккә һәм Мәдинә юлындагы Истанбул, Багдад, Дәмәшкъ кебек шәһәрләрдә татарлар халидия юнәлешенә нигез салган шәех Мәүләнә Халид Багдади (1776/1780–1827) фикерләре бе-

[20] Кемпер М. Суфийские традиции в первой половине XIX века // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань, 2013. С. 375.

[21] Шунда ук.

[22] Шунда ук. С. 381.

[23] Сибгатуллина А. Суфизм в Волго-Уральском регионе во второй половине XIX – начале XX вв. // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань, 2013. С. 383.

лән танышканнар. Мәккәдә иң танылган шәех – Морад Рәмзи була. Моннан тыш, Азәрбайҗаннан Пермь төбәгенә сөрелгән Мәхмүт Дагыстани әш-Ширвани (1877 елда вафат) үз тирәсенә Уфа, Казан, Әстерхан губерналарыннан күп санда мөридләр җыйган. Алар арасында иң танылганнардан Ә.Сибгатуллина Мөхәммәтзакир ишан Камалов әл-Чиставины (1815–1893), Габделваһһаб әл-Хаҗитарханины (1899 елда вафат), Габделгани бине Гобәйдулла әл-Бәйрәкәвине (1901 елда вафат) мисалга китерә. Чистайдагы Мөхәммәтзакир ишан Үзәк Россиядә нәкышбәндия-и-халидия юнәлешенең иң мәшһүр тарафдары була, ул җитәкләгән «Камалия» мәдрәсәсендә Р.Фәхретдин, Ф.Кәрими, Х.Фәйзи-Чистапули һ.б. белем алган[24]. Бу чорда Идел-Урал төбәгендә дагыстанлы Сәйфулла Башларовны (1853–1919), шәех Зәйнулла Рәсүлевне (1833–1917), Бохара суфичылык традицияләре дәвамчысы Гали бине Сәйфулла әт-Түнтәрине (1874 елда вафат) һ.б. билгеле шәхесләрне күрсәтергә мөмкин. Төркиядә уку дәверендә татар шәкертләре һәм хаҗилар госманлы шәех Әхмәт Зыяэтдин Көмешханәвинең (1813–1893) карашлары белән танышканнар[25]. Шунысын да әйтеп узыйк: Зәйнулла ишан иҗазәтне 1869 елда вафат булган казакъ бае Ершибай өчен хаҗга барган вакытта Истанбулда шәех Әхмәт Зыялетдин бине Мостафа Көмешханәви хәзрәттән ала[26].

Урта Азия мәдрәсәләренә әйләнеп кайтыйк. Бу уку йортларын тәмамлаганнан соң, күпчелек татар яшьләре, өстәмә рәвештә хәнәкәләрдә гыйлем алып, мөршидләреннән иҗазәт алганнар. Идел-Урал төбәгендәге атаклы муллаларның, галимнәрнең күпчелеге суфилар булганнар. Бу аңлашыла да: тәсәувыфта тәрбияләнү татар руханиларының рухи яктан үсешендә мәҗбүри элементларның берсе буларак каралган[27].

Шулай итеп, Бохара һәм Сәмәрканд әкренләп Идел-Урал, Фирганә, Кашмир кебек өлкәләрдән килгән шәкертләр өчен белем учакларына әвереләләр. Бу укучылар, укуларын тәмамлап, үз ватаннарына кайталар һәм үз төбәкләрендә суфичылык фикерләрен таратучылар булып әвереләләр. «Бу затларның һәммәсе тәдрис (уку) илә вә бәгъзесе тәдрис һәм шәйхухәт итеп (шәехлеккә өйрәнеп), бәлад (шәһәр) Болгарда булган җәмгъ голямага [...] остазлардыр»[28].

Ш.Мәрҗани күрсәтүенчә, Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, Мәвараэннәһергә сәяхәт иткән беренче кеше ахун Юныс бине Иванай Орыви

[24] Сибгатуллина А. Суфизм в Волго-Уральском регионе во второй половине XIX – начале XX вв. // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань, 2013. С. 384.

[25] Шунда ук. С. 385.

[26] Расих А. Внук ишана. Казань: Татар.кн.изд-во, 2016. С. 33.

[27] Мухаметзянова Д.С. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. С. 29.

[28] Идарәгә мәктүб. Бохара шәрифтән // Бәянелхак. 1906. 8 май.

(1639–1689/90) була[29]. Тикшеренүчеләр аның бу якларга Себер аша баруы мөмкинлеге турында әйтәләр. Бу бердәнбер очрак булмаска кирәк. Шулай итеп, Бохарага илтүче «Себер юлы»н татарлар белем алу максатында файдаланган булулары бик ихтимал[30]. Юныс ахун бик атаклы хәттат була[31]. Үз мәдрәсәсен ача, фарсы телен бик яхшы белә, фарсы телендә язылган сарыф (гарәп теле морфологиясе) дәреслегенә төрки телдә шәрех (комментарий) яза. Бу факт татарлар арасында ислам гыйлеменең башлангычлары торгызыла башлау турында сөйли, чөнки әлеге дәреслек аша гарәп теле нигезләре буенча шәкертләргә азмы-күпме белем бирергә мөмкин булган[32].

Шул ук Ш.Мәрҗани мәгълүматларына караганда, Урта Азия рус дәүләтенә кушылганнан соңгы чорда Идел буе төбәгеннән Бохарага барып белем алган беренче татар кешесе Мансур Борындыкый була[33]. Идел буенда Бохара уку йортлары традицияләрен таратуда аның роле, мөгаен, зур булгандыр. Шул ук вакытта, Дагыстанда белем алган остазы Мортаза әс-Симетидә белем алуы да, аның педагогик эшчәнлегендә азмы-күпме Дагыстан белем системасына бәйле үзенчәлекләр дә чагылыш тапкан булуы мөмкин. Шулай да, һичшиксез, М.Борындыкый Идел-Урал төбәгендә Бохара системасының урнашуына зур өлеш керткән галимнәрнең берсе.

Р.Фәхретдин Мансур Борындыкыйны үз мәдрәсәсен Бохара уку йорты тәртипләренә нигезләнеп төзегән, моңа кадәр өстенлек тоткан дәреслекләр (сарыф буенча – «Зәнҗани», нәхүдән «Мисбах» белән «Ифтитах» китаплары) урынына, сарыфтан «Бидан» вә «Шәрхе Габдулла», һәм шулай ук нәхүдән «Кавагыйд» һәм «Гауамил» әсәрләреннән дәрес бирү кагыйдәсен уйлап тапкан һәм «Гавамил» өчен фарсы телендә сүзтезмәләр дә язган дип хәбәр итә[34]. Фәнни даирәдә ул шулай ук Мансур Габдрахманов, Габдулла әл-Болгари тәхәллүсләре белән дә йөртелә[35]. М.Борындыкый фарсы телендә

[29] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 415 б. Б.232–234.

[30] Мухаметзянова Д.С. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. С. 77, 80.

[31] Марджани Ш. Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С. 469.

[32] Мухаметзянова Д.С. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. С. 80.

[33] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 236.

[34] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 36.

[35] Зиннәтуллина А.Ә. Дин һәм дәүләт эшлеклесе Мансур әл-Борындыкый // Фәнни Татарстан. 2020. №3. Б. 97.

язылган фәнни хезмәт авторы һәм Диния Нәзарәте мөфтие Мөхәммәтҗан Хөсәеновның бабасы буларак яхшы билгеле[36].

1727 елда Мансур әл-Борындыкый «Әл-гавамилел-мийә» китабына шәрехләр рәвешендә «Тәракыйбе Мансурия» дигән хезмәтен тәмамлый. Р. Фәхретдин бу китапның XX гасыр башында да татар мәдрәсәләренең башлангыч сыйныфларында дәреслек буларак файдаланылуы турында яза[37]. Моннан тыш, авторның әлегәчә киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган, 1740 елда язылган тагын бер хезмәте бар. «Тарих әл-Чыңгызхан» китабы, тикшеренүчеләр билгеләп үткәнчә, бүгенге көнгә Россия мөселманнарының тарихи жанрда иҗат иткән хезмәтләреннән беренче үрнәк булып тора[38]. Бохарада белем алган шәхеснең эшчәнлегенә караган әлеге берничә фактка нигезләнеп, күпмедер дәрәҗәдә Бохара белем системасының татар җирлегендә таралу үзенчәлекләре, аның татар мәгарифе һәм фәнни фикере үсешендәге урыны турында фикер йөртергә мөмкин.

Инде әйтеп узылганча, Бохарада белем алган татар шәкертләре арасында исемнәре тарихка кереп калган шәхесләр шактый. Аеруча танылганнарыннан Габденнасыйр Курсавины, Мөхәммәтҗан Хөсәеновны, Шиһабетдин Мәрҗанине, Габдрәхим Утыз-Имәнине, Галимҗан Барудины һ.б.ны санап узарга мөмкин. Урта Азия мәдрәсәләрен тәмамлап, ватаннарында имамлык, мөдәррислек иткән авыл муллалары да шактый. Алар арасында тарихта яхшы билгеле булганнары да, аз билгелеләре дә бар. Шундыйлардан Бәйрәкә авылының имамы һәм мәдрәсә мөдәррисе Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуатны атарга мөмкин[39]. Әлеге тикшеренү кысаларында, төрле чыганакларга таянып, Урта Азия мәдрәсәләрендә белем алган татар яшьләренең шактый исемнәрен тупларга мөмкин булды[40]. А.Хәбетдинов мәкаләләрендә аерым шәкертләрнең исемнәре атый[41]. Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел әхбар», «Вафиятел әсляф», Р.Фәхретдиннең «Асар» хезмәтләрендә Бохарада укыган шәхесләр турында шактый кызыклы мәгълүматлар очрый. Бу китаплар әлеге мәсьәлә белән шөгыльләнүче тикшеренүчеләр өчен шул яктан да әһәмиятле, анда татар шәкертләре белем алган Бохара, Сәмәрканд һәм Кабул мәдрәсәләре мөдәррисләре, ягъни татар яшьләренең остазларының исемнәре дә

[36] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 212.

[37] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 36.

[38] Ахун Мансур ибн Абд ар-Рахман ибн Анас ал-Бурундуки. История Чингисхана / вступ. сл. Д. Мухетдинов; встп. ст., подготовка текста, указ. И.В. Зайцев. М.: Медина, 2018. С. 17.

[39] Мортазина Л.Р. Бәйрәкә авылында мәгариф тарихының кайбер сәхифәләре // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2021. №1. Б. 140–152.

[40] Кара: Кушымта 1.

[41] Хабутдинов А. Бухарское образовательное влияние на татарскую элиту в XVIII–XIX вв. URL: http://islamsng.com/uzb/dialogue/923 (дата обращения: 12.01. 2022).

искә алына. Бу педагоглар, мөселман яшьләренә тирән дини белем биргән гыйлемле белгечләр генә булып калмыйча, аларның дөньяга карашларын формалаштырганнар, алдагы фәнни эзләнүләрендә юл күрсәткәннәр. Мисал өчен бер-ике генә шәхеснең исемнәрен атап узыйк. Бу – Гайсә бине Рәхмәтулла әл-Хоканди, Гаяз бине Заһир әс-Суди, Салих бине Надир әл-Хоҗанди, Шир әл-Хоканди, Миркаҗан әл-Бохари, ишан Ниязколый, Гатаулла бине Йосыф бине Һади бине Әмин әл-Бохари, Ходайбирде әл-Байсуни, Әбу-Сәгыйть бине Габделхәй әс-Сәмәрканди һ.б.[42] Татарлар арасында Ниязколый әт-Төрекмәни шәхесенең абруе зур булу турында сөйләүче фактлар җитәрлек. Күпләр аның хәлифәсе булырга тырышканнар (мәсәлән, Мөхәммәтхарис хәзрәт әл-Эстәрли[43] һ.б.). Бу шәехнең үзендә яки аның хәлифәләрендә (дәвамчыларында) гыйлем туплаучылар арасында Мөхәммәтхарис хәзрәтнең балалары да бар[44].

Моннан тыш, аерым татар галимнәренә, мәгърифәтчеләргә багышланган монографик хезмәтләрдә, фәнни мәкаләләрдә дә татарлар белем алган Урта Азия шәехләре турында мәгълүмат очрый. Мисал өчен, Буа мәдрәсәсе мөдәррисе һәм имам Нургали Хәсәновның остазлары арасында «Күгелташ» мәдрәсәсе мөдәррисе ахунд Ихтияр хәзрәт бар[45]. Фаразлавыбызча, сүз үзбәк галиме А. Жуманазар китабында искә алынган, «Күгелташ» мәдрәсәсенең революциягә кадәрге иң соңгы мөдәррисләренең берсе Ихтиярхон Шәһрисабзий турында бара[46].

Мөселман белем бирү системасында укытучы, остаз абруе бик зур роль уйнаган. Шуңа күрә шәкертләр, уку йортын сайлаганда, иң беренче чиратта анда кайсы остазның белем бирүенә игътибар биргәннәр, ягъни мәдрәсәне түгел, ә остазны сайлаганнар. Фәннең төрле өлкәләрендә үзләрен яхшы таныткан, дәрәҗәле, гыйлемле остазларда белем алу зур мәртәбә саналган. Һәрбер галим үзендә белем алган шәкертенә үзе шәһадәтнамә биргән, шуңа күрә уку йортын тәмамлаучының белем дәрәҗәсен уку йорты түгел, ә остаз билгеләгән. Шәкерт берничә галимдә белем алган, һәм һәрберсе аңа үзенең фәне буенча шәһадәтнамә биргән[47]. Остазга карата булган аеруча мөнәсәбәт тә нәкъ шуның белән билгеләнгән.

[42] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 266, 274, 289, 304, 339, 354.

[43] Тукаев М. Тарихы Эстәрлебаш // Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 2 нче кисәк. Казан, 2019. Б. 18.

[44] Шунда ук. Б. 21.

[45] Амишов Р. Татарский богослов Нургали Хасанов. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С. 21.

[46] Жуманазар А. Бухоро таълим тизими тарихи. Тошкент: Akademnashr, 2017. Б. 315.

[47] A. Thurston. Islamic Universities and Their Global Outreach. URL: http://www.oxford islamicstudies.com/Public/focus/essay1009_Islamic_Universities.html (Accessed: 10.05.2021).

Иң атаклы һәм татар галимнәре хезмәтләрендә еш искә алына торган остазлар арасында чыгышы белән Хәрәземнән булган Ишнияз бине Ширнияз, шәех Хөсәен бине Йосыф әт-Төрки әл-Бохари (1832 елда вафат), Бохарада Ш.Мәрҗани остазларының берсе булган Хөсәен бине Гомәр әл-Кирмәни (соңрак әл-Каргалый) (1858 елда вафат, рәсми мөдәррис түгел)[48], Гатаулла бине Йосыф бине Һади бине Мөхәммәтәмин әл-Галәви әл-Бохари (1839 елда вафат)[49], Салих бине Надирмөхәммәт бине Габдулла әл-Фәргани әл-Хуҗанди (1840 елда вафат)[50], Күгелташ һ.б. атаклы мәдрәсәләрдә укыткан Хәсән бине Хәл әл-Бохари (1856 елда вафат)[51], Нияз бине Бинийәмин әл-Балхи (1860 елда вафат)[52], Бохарада казый һәм мөдәррис Мирзасалих Әгълам (1840 елда вафат)[53] һ.б. атарга мөмкин.

Татар шәкертләрен Россия шартларында Бохара мәдрәсәләре рухында тәрбияләүгә өлеш керткән галимнәр арасында Ишнияз бине Ширнияз бине Ярмөхәммәт Хәрәзмине (1725–1790/91) аерып күрсәтү дөрес булыр. Чыгышы белән Үргәнеч шәһәреннән булып, 1770 нче елларда татар яшьләренә белем бирү максаты белән Хәрәземнән Казан артына килеп урнашкан Ишнияз хәзрәт турында әлегә фәндә күп билгеле түгел. Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин хезмәтләрендә әлеге зат турында мәгълүматлар бар, шулай ук аның кабер ташы язуын өйрәнгән Марсель Әхмәтҗанов та галимнең тормышы һәм әдәби иҗаты турында фикерләрен әйтеп үтә. Ишнияз бине Ширнияз башта Казан артының Кышкар, Элә Казаклары кебек авылларның мәдрәсәләрендә укыткан, 1776 елда Оренбург янындагы Каргалы мәдрәсәсенә килеп урнашкан. М.Әхмәтҗанов фаразлавынча, Ишнияз остаз Хәрәземдә зур дини белем алган, дин галиме гаиләсендә тәрбияләнгән кеше булырга тиеш[54]. Аның татар галәмендә дан-шөһрәте зур була, бу хакта Ишнияз бине Ширнияз хозурына белем алыр өчен төрле җирләрдән имам-мөдәррисләрнең үзләренең шәкертләре белән бергә күченеп килүләре сөйли[55]. Моннан тыш, ул берничә кульязма китап авторы буларак та билгеле. Дини реформаторлык карашлары салынган хезмәтләре белән XIX гасырда татарларның уяну хәрәкәте башлануга

[48] Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 55–56.

[49] Марджани Ш. Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С. 292.

[50] Шунда ук.

[51] Шунда ук. С. 323–324.

[52] Шунда ук. С. 328.

[53] Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 46.

[54] Әхмәтҗанов М. Әдип Ишнияз бине Ширнияз Хәрәзми (1725/(?)–1790/91) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2005. №1. Б. 79.

[55] Шунда ук. Б. 80.

этәргеч бирүчеләрнең берсе һәм татар халык әкиятләре үрнәкләренә таянып әдәби әсәрләр язган беренче мәгърифәтчебез дип исәпләнергә лаек[56].

Татарларга иҗазәт биргән нәкышбәндия мөҗәддидия шәехләре арасында Ниязколый әт-Төрекмәни (1820/21 елда вафат), Фәезхан Кабули (1802 елда вафат)[57], Гобәйдулла бине Ниязкол бине Шаһнияз әт-Төрекмәни әл-Бохари (1852 елда вафат)[58] исемнәре еш очрый. Мисал өчен, шагыйрь, дин белгече Габдеррәхим Утыз Имәнинең (1754–1834) рухи остазы шәех Фәезхан әл-Кабули; мәгърифәтче Габденнасыйр Курсавиның (1776–1812) – шәех Ниязколый әт-Төрекмәни; тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818–1889) – шәех Гобәйдулла бине Ниязколый, Габделкадыйр әл-Фарукый әл-Һинди, Мәзһәр бине Әхмәт әл-Һинди булуы билгеле[59].

Иң зур остазларның берсе булган Ниязколый әт-Төрекмәни, Бохарага килеп төпләнгәнче, Хәрәземдә гыйлем алган, шунда ук мөршид булган. Ул чиста ислам тарафдары буларак билгеле, шәригать кануннарының берсүзсез үтәлүен яклаган. Морад Рәмзи мәгълүматларына караганда, Идел-Урал төбәгенннән чыккан ундүрттән артык кешенең остазы булган[60].

Урта Азия мәдрәсәләрендә татар шәкертләренә белем биргән галимнәр һәм остазларның санына килгәндә, Габдрәшит Ибраһимов язуынча, бу хакта төгәл мәгълүмат юк[61]. Аларның кайберләренең исемнәре белән китап ахырында тәкъдим ителгән якынча исемлектә тулырак танышырга мөмкин.

Татар яшьләре арасында белемгә омтылышлы, булдыклы, зирәк шәкертләр күп булган. Шуңа да аларның кайберләре үзләре белем алган мәдрәсәдә калдырылган, педагогик эшчәнлеккә җәлеп ителгәннәр. Әйтик, Мөхсин бине Биккол әш-Шаши, Бохарадагы атаклы «Фәтхулла Кошбиги» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, шунда ук мөдәррис итеп калдырылган[62]. Шиһабетдин Мәрҗанинең атасы Баһаветдин әл-Мәрҗанине дә Бохара әмире Хәйдәр бине

---

[56] Әхмәтҗанов М. Әдип Ишнияз бине Ширнияз Хәрәзми (1725/(?)–1790/91) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2005. №1. Б. 80–81.

[57] Идиятуллина Г. Развитие богословской мысли в Волго-Уральском регионе во второй половине XVIII – начале XIX вв. // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. V. Казань, 2014. С. 530.

[58] Марджани Ш. Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С. 315.

[59] Батыршин Ф. Идел буенда тарикатьләр: тарихы һәм хәзерге заман. URL: https://dumrt.ru/help-info/theology/analytics_4709.html?curPos=20 (мөрәҗәгать итү датасы: 22.04.2022).

[60] Мәгълүмат түбәндәге хезмәткә нигезләнеп китерелә: Идиятуллина Г. Развитие богословской мысли в Волго-Уральском регионе во второй половине XVIII – начале XIX вв. // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. V. Казань 2014. С. 530.

[61] Ибраһимов Габдрәшит. Ислам дөньясы // Безнең мирас. 2017. №3. Б. 52.

[62] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 276.

Мәгъсум Торсынҗан бай тарафыннан салынган яңа мәдрәсәдә эшкә калырга чакыра, яшәр өчен бүлмә тәкъдим итә. Әмма ул әлеге тәкъдимне кире кагып, туган авылына кайтып китә, Ябынчыда имам итеп билгеләнә[63]. Питрәксе авылыннан Таһир Әлмүшевнең Бохарада укыганнан соң шундагы мәчетләрнең берсенә имам итеп калдырылуы билгеле. Аның бертуган энесе Хәмидулла (1855–1929) ун ел дәвамында Бохара һәм Сәмәрканд мәдрәсәләрендә белем алып, дин гыйлемен, гарәп, фарсы телләрен һ.б. фәннәрне үзләштерә. Шәкертлек чорында ук үзен хафиз итеп таныта, Ислам тарихы, Көнчыгыштагы мөселман халыкларының тормышын сурәтләгән берничә әсәр яза, дини, фәнни китапларны күчереп язып, яшәр өчен акча эшли. Шул хезмәтләре белән ул үзен сәләтле яшь дин белгече итеп таныта[64].

Тагын бер мисал. Буа мәдрәсәсе мөдәррисе Нургали Хәсәнов (Нургали бине Хәсән әл-Морзави әл-Буави әл-Казани, 1852–1919), Бохарадагы «Мир Гарәб» мәдрәсәсендә белем һәм мөфти Габделхәкимнән, Ихтиярхон хаҗидан, шәех Нуретдин әл-Хаварезмидән иҗазәт алганнан соң, Бохарада берничә йөз голяма алдында имтихан тотып, галимлеген раслый һәм 1883–1885 елларда шундагы мәдрәсәләрнең берсендә дәрес бирә. 1885 елда ул Бохарадагы «Гатар» мәдрәсәсе мөдәррисе итеп билгеләнә, тик бу вазифада озак эшләргә насыйп булмый, ватанына кайтып китә һәм Буа мәдрәсәсенең җитәкчесе итеп билгеләнә[65].

Шул рәвешле, шушы берничә мисал аша да Урта Азия уку йортларында белем алган татар яшьләренең төп ватаны булган Идел-урал төбәгеннән читтә дә югалып калмаулары, уңышларга ирешүләре турында фикер йөртергә мөмкин.

Урта Азия мәдрәсәләренә шәкертләр күп очракта балигълык чорында, үз төбәгендә мәдрәсә тәмамлаганнан соң барганнар. Әйтик, Ш.Мәрҗанигә Бохарага киткәндә 20 яшь була. Ләкин татарлар арасында бала, яшүсмерлек чорында ук бу белем бирү системасы белән якыннан танышкан затлар да булган. Алда искә алынган Хәмидулла Әлмүшевнең, мәсәлән, 8 яшьлек вакытында ук әтисе тарафыннан Бохарага укырга җибәрелүе билгеле. Хәмидулла ун ел дәвамында Бохара һәм Сәмәрканд мәдрәсәләрендә белем алып, дин гыйлемен, гарәп, фарсы телләрен һ.б. фәннәрне үзләштереп, Петербург шәһәренә кайта һәм 20 ел дәвамында башкала мәчетенең имамы булып хезмәт итә[66].

---

[63] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 315.

[64] Энциклопедический словарь «Ислам на Нижегородчине». URL: https://idmedina.ru/books/encyclopedia/?794 (дата обращения: 22.04.2022).

[65] Амишов Р. Татарский богослов Нургали Хасанов. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. Б. 19–24.

[66] Энциклопедический словарь «Ислам на Нижегородчине». URL: https://idmedina.ru/books/encyclopedia/?794 (дата обращения: 22.04.2022).

Бохарада гыйлем алу бик мәртәбәле эш саналган. Бохара мәдрәсәсен тәмамлаучыларны, олылап, «дамулла», ягъни бөек мулла дип атап йөрткәннәр, мәхәллә биргәннәр, имам-хатыйб итеп билгеләгәннәр. XVIII гасырның икенче яртысыннан, Идел-Урал төбәгендәге галимнәрнең һәм муллаларның күпчелеге Бохарада белем алган. Алар оештырган мәдрәсәләр татар мәктәбенең алга таба үсешенә өлеш керткәннәр. Бохара укыту тәртипләренең тулысынча безнең уку йортларының нигезенә алынуы шуның белән бәйле. 1773 елда Екатерина патшабикәнең дин иреге турындагы боерыгы дөнья күреп, мөселманнар мәчет янында мәдрәсә төзү мөмкинлеге алганнан соң, бу хәл яңа көч белән дәвам итә[67].

Бохарада мәдрәсә тәмамлап кайтканнар күп кенә очракта үзләренең остазлары үрнәгендә уку йортлары булдырганнар, татар шәкертләренә белем биргәндә аларның тәҗрибәсен, эш алымнарын, уку-укыту ысулларын һәм калыпларын кулланганнар. Бу табигый да. Кайбер шәкертләр, мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, остазының үрнәге һәм киңәше белән, белем алуларын Урта Азия уку йортларында дәвам иткәннәр[68]. Гаклият фәннәрен укыту буенча Казан төбәгендә алдынгы урыннарны биләгән Кышкар мәдрәсәсе имамнары арасында Бохара мәдрәсәләрендә белем алган аталы-уллы Исмәгыйль һәм Габдрахман Үтәмешевләрне күрсәтергә мөмкин[69]. Мондый мисаллар җитәрлек. Бу хәл, ягъни дәвамчылык, Бохара системасын башка төр модельләр, әйтик, Дагыстан белем бирү ысулы, белән чагыштырганда, яшәүчәнрәк иткән. Шуңа да XIX гасыр башларында, Кавказ юнәлеше тәмам ябылганнан соң, Идел-Урал төбәгендәге күп кенә мәдрәсәләрнең нәкъ менә Бохара белем йортларын тәмамлаучылар тарафыннан оештырылуы гаҗәп түгел. Бу чорда «татарларда белем бирү системасы күп яктан Бохара системасына тәңгәл килгән»[70]. Бохарада укып кайткан хәзрәтләр үз мәдрәсәләрендә Бохара системасының күп элементларын кулланганнар. Бер мисал. Мөхәммәтхарис әл-Эстәрлинең улы Хәбибулла хәзрәт, әтисе, агалары кебек үк Бохарада белем алып кайтканнан соң, 1884 елда Эстәрлебаш мәдрәсәсендә шәкертләргә «Тәфсире Казый»дан дәрес бирә башлый. «Дәреснең башында «Хайрукүм мән тәгалләмәл Куръәнә вә галләмәһү» (Сезнең иң хәерлегез Коръәнне өйрәнеп, башкаларга өйрәткәнегездер) хәдисе шәрифен укып, «Амин шулай булса иде» дип, нотыклар әйтеп, догалар үтенеп, Бохараи шәриф тәртибе

[67] Фахреддин Р. Кутуб ситта и их составители / перевод, введение, примечания и комментарии Р.Н. Гатина. М., 2023. С. 53.

[68] Мухаметшин Р. Мусульманское образование у татар в дореволюционной России: состояние, проблемы и перспективы // Minbar. Islamic Studies. 2009. №2 (4). С. 80.

[69] Фархшатов М. Просвещение // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. V. Казань, 2014. С. 572.

[70] Махмутова А. Традиционные учебные заведения и новометодное образование. История татар с древнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань, 2013. С. 795.

буенча ифтитах (кереш) мәҗлесе ясап дәрес башлар иде»[71]. Мөхәммәтхарис хәзрәт укыткан чорда мәдрәсәдә бик күп дәресләр укытылып, «китабәт һәм мөкәмәлә кылышу (гарәпчә язу һәм сөйләшү)» киң таралган була һ.б.[72]

Гомумән алганда, бу чорда татар мәктәп-мәдрәсәләрендә чагылыш тапкан традицион «бохара» дәрес бирү тәртибе фәннәргә бүленеш ягыннан караганда йомшаграк булган. Анда гарәп теленең грамматикасы (сарыфы һәм нәхүе), мантыйк, фәлсәфә (хикмәт), гакыйдә, фикъһ укытылган, теге яки бу предметны өйрәнү өчен аерым вакыт билгеләнмәгән, имтиханнар үткәрелмәгән. Бердәм уку планнары, сыйныфларга бүленеш булмаган. Кайбер мәдрәсәләрдә өстәмә рәвештә риторика, астрономия, математика, каллиграфия укытылган. Ләкин алар дин гыйлемен һәм фикъһне өйрәнүдә ярдәмче ролен генә үтәгәннәр[73].

«Бохара» ысулы нигезендә белем бирү рәвеше түбәндәгедән гыйбарәт булган: мөдәррис яисә аның иң яхшы укучыларыннан берсе бик күп гасырлык тарихка ия булган уку китабыннан өзекне укыган, аннан соң укылган материалны конкрет мисаллар ярдәмендә, әлеге хезмәткә шәрех (аңлатма) язган башка абруйлы урта гасырлар галименең хезмәтенә таянып җентекләп аңлаткан, аннан соң шәрхе-шәрехләргә (шәрехкә карата язылган шәрехкә) мөрәҗәгать иткән, аерым урыннарга ачыклык керткән, үз фикерен белдерүдән сакланган[74]. М.Фархшатов билгеләп үткәнчә, дамуллаларда белем алу гомуми белемгә караган фәннәр буенча еш кына зәгыйфь булып чыккан: хисап белеме, мәсәлән, бары тик шәригать буенча мирас бүләр өчен генә яраган, аларны җир кишәрлеген ничек үлчәргә өйрәткәннәр һ.б. География, тарих буенча алынган белемнәр дә өзек-өзек булып чыккан, күп очракта тормыштан аерылып торган[75]. Бохара уку йортларын тәмамлап кайткан мөдәррисләр үзләренең мәдрәсәләрендә дә шул традицияне дәвам иткәннәр. Нәтиҗәдә «Бохарада рәсми дәресләр юнан (борынгы грек) методлары, китап кереш сүзләре, шәрехләрнең һәм хашияләрнең (аңлатмаларның) бәхәс һәм сүз көрәштерүләр булуыннан, боларны үрнәк итеп тоткан безнең мәдрәсәләребездә Коръән һәм хәдис гыйлемнәре белән җитди рәвештә шөгыльләнә алмаганнар»[76].

Татар яшьләре Урта Азия уку йортларында белем алуны мәдрәсәләр белән генә чикләмәгәннәр, өстәмә рәвештә шөгыльләнгәннәр, үзлектән укыганнар. Моның сәбәпләре төрле булган: бер яктан, бу тагын да тирәнрәк белем

---

[71] Тукаев М.-Ш. Тарихы Эстәрлебаш // Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 2 нче кисәк. Казан, 2019. Б. 21.

[72] Шунда ук. Б. 14.

[73] Фархшатов М. Просвещение // История татар с древнейших времен. Т. V. Казань, 2014. С. 577.

[74] Шунда ук. С. 578.

[75] Шунда ук. С. 579.

[76] Ризаэтдин Ф. Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Гыйльме хәдистән / басмага әзерләүче А. Гайнетдинов. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019. Б. 45.

алырга мөмкинлек биргән; аерым шәкертләрне мәдрәсәдәге тәртипләр яисә укуның эчтәлеге бик үк канәгатьләндермәгән һ.б. Шиһабетдин Мәрҗанинең, мәсәлән, Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләрендә уку белән беррәттән, өстәмә рәвештә үзенең белемен арттыруы, дин гыйлеме, фәлсәфә, тарих, телләр өйрәнүгә зур игътибар бирүе, Шәрыкның иң мәгърур китапханәләрендә шөгыльләнүе, китаплар күчереп язуы билгеле. Нәкъ шушы чорда аның булачак фәнни эшчәнлегенә нигез салына, фәнни-мәгълүмати базасы туплана да инде.

Бохара мәдрәсәләрен тәмамлаучылар арасында укуларын дәвам итү өчен Кабулга юл алучылар да була. Белем алу системасының бу рәвештә оештырылуы булачак галимнәрнең, мөселман руханиларының дөньяга карашларының киң һәм төрле булуына ярдәм иткән, алдагы эшчәнлекләрендә зуррак мөмкинлекләр тудырган. Хәмзә бине Мөхәммәт әл-Бәрәзәви, мәсәлән, Кабулдагы остазларыннан хисап һ.б. фәннәрне тирәнтен өйрәнгән, шуңа да аны «Хәмзә мөнәҗҗим» дип йөрткәннәр[77].

Бохара белем бирү системасы үз вакыты өчен бик мөһим укыту үзәкләренең берсе булган. Идел-Урал буе төбәге мөселманнарының дини мәгарифе үсешендә аның роле, һичшиксез, зур булган. XVIII–XIX гасырларда татар дөньясында мәйданга чыккан күренекле татар галимнәренең, педагогларның, дин һәм җәмәгать эшлеклеләренең фәнни күзаллаулары формалашуда аларның абруйлы Бохара уку йортларында яисә шунда укып кайткан мөгаллимнәрдән белем алулары төп рольне уйнаган. Күп гасырлар дәвамында дөньядагы иң көчле мәгърифәт үзәкләренең берсе булып торган Бохара мәдрәсәләре соңгырак чорларда үзләренең позицияләрен беркадәр югалта башлыйлар. Әлбәттә моның сәбәпләре төрле була, һәм проблемага да төрле яктан якын килергә мөмкин. XX гасыр дәвамында галимнәр Бохара моделенең схоластикага корылуы, шул сәбәпле шәкертләр тарафыннан беркадәр игътибардан читтә калулары турында яздылар. Бохара системасының татарлар арасында әһәмиятен беркадәр югалтуның сәбәбен дә, мөгаен, җәдитчелек хәрәкәте һәм аның белән бәйле рәвештә җәмгыятьтә һәм мәгариф өлкәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр белән бәйләп карага кирәктер.

Чыганаклар хәбәр иткәнчә, Бохара һәм Урта Азиянең башка шәһәрләрендәге уку йортларында укыту ысуллары бик озак вакытлар үзгәрешсез калып килә. «Төп ысул булып китап ысулы тора, ул аерым гыйбарәләрне, китапларны һәм алардан өзекләрне, Коръәннең аерым өлешләрен, пәйгамбәрләр тормышыннан риваятьләр ятлауга нигезләнә»[78]. Габдрәшит Ибраһимов, бу системаны тасвирлап: «Укыту ысулы бик начар. Шәкертләр бер

---

[77] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 270.

[78] Джурабаев Д.Х. Система мусульманского образования в Бухарском ханстве в конце XVIII – начале XIX вв. (по материалам русских источников) // Вестник Таджикского государственного университета права, бизнеса и политики. Серия: «Общественные науки». 2013. № 3(55). С. 215.

китапның кереш өлешен 5 ел буе укып өйрәнәләр, 20–30 ел мәдрәсә бүлмәсендә утырып, бөтен гомерләрен гарәп телен өйрәнеп үткәрсәләр дә, ике кәлимәне бергә кушып гарәпчә сөйләшә алмаган кебек, бер юл гарәпчә яза да алмыйлар. Ләкин Бохара голямасы һәм шәкертләр арасында уяну, күтәрелеш бөтенләй юк түгел», – дип яза[79].

Урта Азия белем бирү системасы турында сөйләгәндә, еш кына аның схоластикага корылган булуы турында язалар. Җәдитчеләр нәкъ менә шушы сәбәп аркасында аның татарларга белем бирүдә кулланыла алмавы турындагы фикерне әйттеләр. Үзе Бохара мәктәбен узмаган Ризаэтдин Фәхретдин Урта Азия белем бирү системасына тәнкыйди караган, аның схоластикага корылуын төп кимчелекләренең берсе итеп күрсәткән. 1908 елда ул болай дип яза: «безнең халкыбызда схоластика инде менә бер гасыр дәвам итә. Румнар схоластика сәбәпле юкка чыктылар. Греклар да схоластика ярдәме белән югалдылар»[80]. Җәдитчеләр еш кына схоластиканы барлык бәлаләрнең чыганагы итеп караганнар. А.Хәбетдинов, бу ситуацияне тасвирлап, «Р.Фәхретдиннең карашы схоластика чынлап та үз алдына куйган барлык бурычларны үтәп бетергән һәм җәмгыять үсеше өчен тормоз булган заманда формалашкан», – дип яза[81]. Бу чорда дини белем милли мәгариф системасының иң әһәмиятле өлешләренең берсе булса да, дөньявилыкка ныклы адымнар ясалу белән билгеләнә. Р.Фәхретдин дә гомумән милли мәгариф алдында торган максатларны күздә тоткан[82].

Схоластиканы тәнкыйтьләүчеләр аның төп кимчелеге итеп фәлсәфи белемнәрнең дини тәгълиматка буйсынуын санаганнар. Чынлыкта схоластика барлык дини белем бирү системаларына хас булган. Һәм бу, беренче чиратта, мантыйк һәм кәлям кебек фәннәргә караган, чөнки сарыф яки нәхүнең схоластикага нигезләнүе турында бөтенләй дә сүз алып бару дөрес түгел[83].

Гомумән алганда, XX гасыр башында Бохара мәдрәсәләренең заманчалык принцибыннан күпмедер дәрәҗәдә артка калуы, яңалыкларга чагыштырмача ябык булуы турында вакытлы матбугатта дөнья күргән язмалар да сөйлиләр. «Өлфәт» газетасының 1906 елгы 6 апрель санында басылып чыккан «Бохараи шәрифтә дәрес ысулы» дигән мәкаләдә бу фикер чагылыш таба. «Һәркемгә мәгълүм булса кирәк, Бохараи шәрифтә дәрес ысулы бик иске булып, бәлки дөньяда һичбер мәмләкәттә бу кебек бер дәрес ысулы юктыр». «Искелек»нең төп сәбәбе итеп автор бу ысулга нигезләнгән дәрестә һәр фәннең үзенә төп игътибар бирелмәвен саный: «фәкать дибаҗә (кереш сүз, беренче бит) вә мөкатдәмәсен (сүз башы) ике-өч сәнә укырлардыр; бер диба-

[79] Ибраһимов Г. Ислам дөньясы // Безнең мирас. 2017. №3. Б. 53.

[80] Фәхретдин Р. Нәсихәт. Ялгыз кыз балалар өчен // Мәгариф. 1992. №6. Б. 53–54.

[81] Хабутдинов А.Ю. Миллет Оренбургского Духовного Собрания в конце XVIII–XIX веках. Казань: Иман, 2000. С. 41.

[82] Мухаметзянова Д.С. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. С. 178.

[83] Шунда ук. С.179, 180.

җәдән икенче дибаҗәгә күчәрләр иде; матлуб булган (таләп ителгән, тиешле) дәресне һич укытмак гадәт түгелдер», – дип яза[84].

Шәкертләргә белем бирү белән шөгыльләнгән аерым муллалар арасында да Бохара укыту системасының кимчелекләрен таныган һәм бу хакта фикерләрен җиткерүне кирәк санаганнар була. Эстәрлетамак өязе Балыклы Күл авылы имамы һәм ахуны Хөснетдин бине Шәмсетдин бине Җәгъфәрнең бу хактагы сүзләрен Р.Фәхретдин теркәп калдырган. Имам мәшһүр, дәрәҗәле кешеләр җыелган бер мәҗлестә болай дип сөйләгән: «Безнең халкыбызның надан калуының иң олуг сәбәбе – Бохара шәһәренең гыйлем чыганагы икәненә ышанып, уку нияте белән шунда барулары вә анда ни күрсәләр, сабый балалар мисалында мәмләкәтебезгә гыйлем исемендә китереп сату; дөньяда бер тиенлек файдасы булмаган вә ахирәттә дә үкенечтән башка бер нәтиҗәсе күрелмәячәк нәрсәләрне саф күңелле шәкертләребезгә ятлатып каннарын бозу, әхлакларын табигый хәлләреннән чыгарудыр»[85].

Мондый фикерләр Ш.Мәрҗани, Х.-Г. Габәши кебек галимнәрнең хезмәтләрендә дә очрый. Х.-Г. Габәши бохаралыларның һәм аларга ияргән галимнәребезнең борынгы традицияләрдән тайпылуын тәнкыйтьли: «әүвәлге изге мөселманнар вә элек яшәгән галимнәр ысулларын бөтенләй ташлаганнар. Вә аларның китапларын дәрес программаларыннан чыгарып бетереп, урыннарына соңгы заман галимнәре тарафыннан төзелгән китапларны тутырганнар», – дип яза[86]. Бу яктан караганда, бу система беренчел чыганакларны өйрәнүгә нигезләнгән Дагыстан мәдрәсәләреннән нык аерылып торган. Габәши хезмәтеннән бер генә мисал китерү дә җитәр: «Менә күрегез! Игътикад бабында бер заман бөтен ислам дөньясында сөелеп укылган «Гакыйдәи Әбү Җәгъфәр әт-Тахави»не чыгарганнар да аның урынына аннан 216 ел соң вафат Гомәр ән-Нәсәви гакыйдәсен вә биш йөз еллар соң Тәфтазанинең «Шәрхе гакаид»ен [...] укытырга тотынганнар»[87].

Ш. Мәрҗани Бохарада укыган шәкертләрнең белемнәренең бик үк тулы булмавы хакында яза. Үзе дә шул мәктәпне үткән кеше буларак, аның җитешсезлекләрен яхшы күрә. Аеруча ул дәрес бирү тәртипләреннән канәгать булмый. Бохарадагы дәрес ысулларын үзгәртү хакында остазлары белән киңәшләшеп караса да, нәтиҗәсе күренмәгән, алардан: «Бу фикерне сөйләү җиңел булса да, Бохарада дәрес тәртипләрен үзгәртү гаять мөшкел эш», – дигән җавапны гына алган[88]. Мәрҗанинең Урта Азиягә киткәннән соң Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләре арасында камил укыту тәртипләре эзләп йөрүенең, нәтиҗәдә үзлегеннән белем алуга, Бохара китапханәләрендә кыйммәтле хез-

[84] Бохараи шәрифтә дәрес ысулы // Өлфәт. 1906. 6 апрель.

[85] Фәхреддин Р. Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. Б. 122.

[86] Габәши Х. Мәдрәсәләрдә дәрес укытылу тәртибе – программа хакында // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 613.

[87] Шунда ук.

[88] Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 51.

мәтләрне өйрәнүгә күбрәк вакытын сарыф итүенең сәбәпләренең берсе дә, мөгаен, шул хәл белән бәйле булгандыр.

Ш.Шәрәф билгеләп узганча, «Мәрҗани мәдрәсәләрдә максат итеп куелган фәннәр укылмыйча, шәрех, хашийәләр, әһәмиятсез мантыйк, кәлям бәхәсләре илә гомер үткәрүне, китапларның сүз башын, керешләрен генә укуны мәслихәт күрмәгән. Һәммәсеннән бигрәк дини гыйлемнәр укытуга бирелгән мәдрәсәләрдә Коръән, хәдис вә гарәп әдәбияты дәресләре укытылмавына гаҗәпләнгән һәм кайгырган»[89].

Р.Фәхретдин билгеләп узуынча, укытуда төп басым кәлямгә ясалган. Аннан соң гарәп теле, мантыйк, фикъһ һәм әл-ысул гыйлеме өйрәтелгән. Хәдисләр һәм Коръән тәфсире калган вакытта гына укытылган һәм шәкертләр күп очракта бу фәннәрне үзләре юлларын табып мәдрәсәдән тыш үзләштергәннәр. Дәреслекләр берничә төрле булган: төп әсәр, аңа шәрех, шәрехкә шәрех һәм аңлаешсыз сүзләр (глосса, хашия)[90].

Мәрҗани үзенең «Мөкаддимәт китаб Вафийәт әл-әсляф вә тәхиййәт әл-әхляф» китабында Бохара белем бирү системасының методик нигезләрен бик тәфсилле тасвирлый: «Безнең халыкта Мәвараэннәһердә кулланылган, аеруча Бохара тәртипләренә нигезләнгән укыту бик югары бәяләнсә дә, чынлыкта алар фәннән (мәгарифтән) бик ерак, оештыру ягыннан аксыйлар, бары тик кайбер формаль яклары буенча гына аерылып торалар. Болар түбәндәгеләр. Алар «әл-Фәвәгыйдь әд-дыягыйә» китабын аның авторындагыча һәм фәндәгечә укымыйлар. Башта баш килештәге (әл-мәрфугат) исемнәрне өйрәнәләр, аннан соң иялек килешендәге (әл-мәҗрурәт), аннан – үзгәрми торган кушымчалы сүзләрне (әл-мәбнийят), соңыннан, тәртипкә кире кайтып төшем килешендәге (әл-мәнсубәт) сүзләрне өйрәнәләр. Аннан соң китапның башына кайтып, үзгәрешле кушымчага ия сүзләрне өйрәнәләр. Башка өлешләрне калдыралар. Моңа өч елдан артык вакыт китә. Аннары ике ел дәвамында «Шәрх әш-Шәмсийә» һәм «Шәрифә әл-Җурҗани шәрехенә шәрех»не (субкомментарий) китапның керешендәге: «Кереш дигәндә монда шул күз алдында тотыла» дигән җиргә кадәр өйрәнәләр. Аннан соң әт-Тәфтазаниның «Шәрех әл-Гакаидән-Нәсәфийә» һәм «Хашийә әл-Хәйали», аннан – «Шәрех әл-Җами», аннан «Шәрех әт-Тәһзиб» китабын башлап, аның бары тик «Әлхәмделииләһи» гыйбарәсен һәм [...] өйрәнәләр.

Аннан өч ел дәвамында әл-Кятибинең «Хикмәтел-гайн» китабының илаһийәт өлешеннән сайлап укыталар, аның тәртибен бозып бетерәләр. Аннан соң «Шәрех әл-Гакаид әл-Гадудийә» һәм файдасы аз булган, сай эчтәлекле «Хаваши әл-Карабагы» китабын өйрәнәләр. Моңа дүрт елга якын вакыт сарыф ителә. [...] «Шәрех әл-Викайя», «әл-Һидайя», «Шәрех әл-Тәлхыс»

[89] Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 49.

[90] Фахреддин Р. Кутуб ситта и их составители /перевод, введение, примечания и комментарии Р.Н. Гатина. М., 2023. С. 51–52.

кебек китапларга килгәндә, аларны яки өйдә, яисә кечерәк мәдрәсәләрдә генә өйрәнәләр. Шулай итеп, белем алу ахырына якынлашканда, аларның белемнәре чынлыкта бик тар һәм тулы булмый»[91].

Шул сәбәпле Мәрҗани, мәдрәсәдәге дәресләрен дәвам итсә дә, мөдәррисләр укыткан дәресләргә генә канәгать итмәгән, башкалар кебек китапның кереш өлешен һәм башламын гына түгел, бәлки ахырына кадәр укып чыккан, фикерләрен яза барган[92].

Х.-Г. Габәши дә Бохара тәртибенең кешедә фикер көче арттырмавы турындагы фикерен әйтә, «күңел күзе вә фикер мөстәкыйльлеге вә инициативалылык бирми генә түгел, бәлки аларны үтерә, никадәр вә ничә еллар укып чыксалар да, һич кеше булып чыкмый», – дип нәтиҗә ясый[93].

Бохара, аның галимнәре, мәгарифе үзенчәлекләре турындагы фикерләрен туплап, Ш.Мәрҗани Бохарада уку чорында ук китапчык яза, тик аны үзе укыган дәвердә таратудан тыела. Бохарада бик билгеле булмаса да, бу хезмәт татарларга тәэсир итә. Казан һәм аның тирә-юнендә Мәрҗани «Бохараи шәрифкә, анда булган голямага вә укытуларына тел озайтканы өчен күп адәмнәр тарафыннан сүгелгән», шул ук вакытта «Мәрҗани сүзләре мәйданга чыккач, халкыбыз Бохара тәртипләренең бозык булуын белеп, икенче җирдән гыйлем чыганаклары карарга мәҗбүр булганнар. Истанбул, Мисыр тарафларына барып гыйлем ала башлаганнар»[94].

Ш. Мәрҗани Мисыр һәм Истанбулда гыйлемгә күбрәк әһәмият бирәләр дип санаган, шул сәбәпле улы Борһанетдинне Истанбулга җибәргән[95].

Әлбәттә, татар мәгърифәтчеләренең, җәдитчеләрнең бу фикерләренә беркадәр тәнкыйть белән, шул заманның үзенчәлекләрен истә тотып якын килергә кирәк. Бу яктан караганда, Бохара мәдрәсәләренең чагыштырмача ачык булуын да әйтеп узарга кирәк – шәкерткә үзенә ошаган уку йортын, остазны сайлау, өстәмә рәвештә шөгыльләнү, димәк үзе теләгән рәвештә үсү мөмкинлеге бирелгән. Бу аны шактый киң система буларак характерлый торган сыйфат.

XIX гасырның соңгы чирегендә – XX гасыр башларында татарлар дини һәм дөньяви белем бирүнең башка үзәкләренә күрбәк игътибар итә башлыйлар.

---

[91] Марджани Ш. Введение к библиографическому словарю «Верность предшественникам и приветствие потомкам» (Мукаддимат китаб Вафиййат аль-асляф ва тахиййат аль ахляф). Казань: Магариф-Вакыт, 2022. С. 298–299.

[92] Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 54.

[93] Габәши Х. Мәдрәсәләрдә дәрес укытылу тәртибе – программа хакында // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 616.

[94] Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 52.

[95] Шунда ук.

## Мисырдагы «Әл-Әзһәр» мәдрәсәсендә һәм башка мөселман мәгарифе үзәкләрендә татарлар

Идел-Урал мөселманнарының ислам дөньясының Багдад, Мәдинә, Мәккә, Каһирә, Истанбул кебек шәһәр мәдәнияте үзәкләре белән мәгариф өлкәсендәге бәйләнешләре XVIII гасырның ахырында, Россиядә үтә кырыс миссионерлык сәясәтенең җимерелүе һәм хакимиятнең ислам диненә карата йомшару сәясәтен башлавыннан соң торгызыла[1]. Бу хәл XIX гасыр ахырына таба, Бохара мәдрәсәләренең беркадәр үзләренең абруйларын югалтулары вазгыятендә тагын да киңрәк юнәлеш ала. Заман үзгәрешләре, Европада барган яңарыш хәрәкәте мәгариф үсешенә дә йогынты ясый, уку-укытуның эчтәлеген үзгәртеп коруны таләп итә. Шуңа да элеккеге укыту тәртипләреннән азат була алмаган Урта Азия уку йортлары татар шәкертләрен артык җәлеп итми башлый, аларның таләпләрен канәгатьләндерми. Төпле дини белемнәр белән беррәттән, заманча фәннәрне укыту кирәклегенә басым ясаган җәдитчелек хәрәкәте барлыкка килү, аның мөселман мәгариф системасын яңарту, үзгәртеп коруга юнәлдерелүе дә зур роль уйный. Мәгариф өлкәсендә Европа мәдәнияте тәэсире сизелә башлый. Бу чорны Р.Фәхретдин «уяну дәвере» дип атый[2].

Шуның өстенә, бу чорда чит илләргә чыгу, паспорт алу өчен мөмкинлекләр күбәюне дә истә тотарга кирәк. Шулай итеп, белем бирү өлкәсендә яңалыкларга ачык булган Госманлы империясендәге мәдрәсәләр татар яшьләрендә зур кызыксыну уята. Заман таләпләренә җавап бирүне максат иткән әлеге уку йортларына Европа традицияләре җиңелрәк үтеп кергән һәм бу хәл аларның абруен арттырган. «Әл-Әзһәр»дә, мәсәлән, бу чорда уку-укыту программаларын яңарту, үзгәртеп кору, яңа фәннәр кертү процессы көчле күзәтелгән, бу исә дөньяның төрле кыйтгаларыннан белемгә сусаган мөселман яшьләрен, шул исәптән татарларны да, үзенә тарткан. «Әл-Әзһәр»дә укыган шәкертләр аша яңалыклар татар мәдрәсәләренә дә килеп җиткән. Бу мәсьәлә махсус рәвештә әлеге хезмәт кысаларында каралмаса да, шуны искәртеп узасы килә: әлбәттә, татар җирлегендә барлыкка килгән җәдит мәдрәсәләренең эшчәнлегендә рус һәм Европа уку йортларының тәэсире сизелерлек булган. Моны инкарь итеп булмый. Ләкин заманча мәктәпләр барлыкка килүдә «әл-Әзһәр» кебек дөньякүләм танылган мөселман мәгарифе үзәкләренең йогынтысы да искиткеч зур була. Бу урында мәсьәләнең әлеге ягына игътибарны күбрәк юнәлттек.

---

[1] Фархшатов М. Просвещение // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. V. Казань, 2014. С. 569.

[2] Фәхретдин Р. Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Гыйльме хәдистән / басмага әзерләүче А. Гайнетдинов. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019. Б. 45.

Якын Көнчыгышта һәм Мисырда белем алган шәкертләр җәдитчелек хәрәкәтендә һәм гомумән Россия мөселманнарының мәгарифе үсешендә зур роль уйнаганнар. Алар, Урта Азия мәдрәсәләрен тәмамлаучылардан аермалы буларак, Коръән һәм хәдис гыйлеме буенча тулырак хәбәрдар булалар. Р. Фәхретдин язуынча, «бу фәннәрнең урыннары инде Бохара түгел, бәлки, Хиҗаз һәм Мисыр иде. Шуның өчен шәкертләр бу вилаятьләргә сәфәр кылыр булдылар. Бу шәкертләрдән кайберләре, фәннәр һәм яңа белемнәр алгач, бу мәмләкәткә кайтканнан соң, гомуми бер уянуга сәбәп булдылар. Ислам мәмләкәтләреннән Коръән һәм хәдис гыйлемнәре алып кайтучылар нисбәтендә, схоластика әүвәлге куәтеннән төшеп, моның урынына шәригатебезнең нигезе булган сөннәт гыйлемнәре килде. Схоластика тәэсиреннән таралган булган бозык әхлак, тиз генә бетмәсә дә, иншә Аллаһ, киләчәк көннәрдә әкренләп бетәр булса кирәк»[3].

Җамал Вәлиди язуынча, җәдит мәктәпләренә мөгаллимнәрне нәкъ менә Каһирә, Истанбул һәм Мәдинә шәһәрләрендә белем алган шәкертләр арасыннан алганнар[4]. Алар XIX гасыр ахырында Идел-Урал төбәгендәге иң эре мәгариф үзәкләрендә җитәкчелек урыннарны биләгәннәр, үз мәдрәсәләренең нигезен коруда заманчалык принцибын нигез итеп алганнар. Әйтик, «Галия» мәдрәсәсенең педагогик коллективы тулаем диярлек Төркия һәм Мисыр уку йортларын тәмамлаучылардан гыйбарәт булган. Үзләре әлеге илләрдә белем алган җитәкчеләр кул асларына нәкъ менә шул илләрнең педагогик системалары, уку-укыту традицияләре белән таныш булган мөгаллимнәргә өстенлек биргәннәр, алар арасында «әл-Әзһәр»не тәмамлаган Зыя Камали да була[5]. Шунысын да искәртеп үтү мөһим: җәдит мәдрәсәләре, элеккеге уку йортларыннан аермалы буларак, дини белем белән беррәттән, дөньяви фәннәрне укытуга да зур әһәмият биргәннәр. Шул сәбәпле бу чорда дини һәм дөньяви белем мәсьәләләрен аерып карау мөмкин дә түгел. Чөнки мәдрәсәләрдә дини яктан гыйлемле, дөньяви фәннәр буенча белемнәргә ия булган заманча шәхесләр тәрбияләү максат итеп куелган. «Галия»дә төрле елларда Истанбулда педагогия институтында белем алган Хәбиб Зәйни, Гобәйдулла Саттар, Истанбул университетының физика-биология факультетында укыган Габдулла Сатиев, Бәйрутта һәм Каһирәдә укыган Закир Кадыйри, Фәхри Габдулла (Истанбул), Закир Аюханов (Каһирә), Тәкый Бәдигый (Хиҗаз), Мисырда һәм Гарәбстанда озак еллар яшәп гыйлем туплаган Лотфулла

---

[3] Фәхретдин Р. Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Гыйльме хәдистән / басмага әзерләүче А. Гайнетдинов. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019. Б. 46.

[4] Валиди Дж. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). М.-Пг., 1923. С. 79.

[5] Камалов Т. Зия Камали. Казань: Иман, 1997. Б. 20.

Байчурин һәм Хәтмулла Фазыйлов[6], Истанбулда педагогик белем алган Габдулла Ибраһимов-Шнасины һ.б.ларны күрсәтергә мөмкин[7].

Бу гадәт Идел-Урал төбәгендә урнашкан башка уку йортларында да күзәтелгән. Мисал өчен, Уфадагы «Госмания» мәдрәсәсендә педагогик эшкә шулай ук нигездә төрек һәм Мисыр уку йортларында белем алган белгечләр җәлеп ителгән – Хәбибулла Әхтәмов, Хәтмулла Фазыйлов, Зыя Камали[8]. Бу уку йортларын тәмамлаучылар арасында авылларда муллалык һәм мөдәррислек итүчеләр дә шактый була.

Әлеге зур проблеманың бер өлеше буларак Истанбул уку йортларын алыйк. Гомумән алганда, төрек уку йортларының татар шәкертләрен үзләренә җәлеп итүләре дин уртаклыгы, телләр һәм гореф-гадәтләрнең охшашлыгы белән билгеләнгән. Төрек мәгарифе, төрек әдәбияты татарларның мәдәни үсешендә сизелерлек роль уйнаган. Аерым алганда, хәзерге тикшеренүчеләрнең кайберләре татарларда җәдитчелек хәрәкәте белән турыдан-туры бәйле булган яңа аваз ысулы һәм шуның нигезендә укытуның үтеп керүендә төрек педагогларының да өлеше бар дигән фикерне алга сөрәләр. Төрек галиме Адилхан Адилоглу Исмәгыйль Гаспралының Төркиягә барып, төрек мөгаллимнәренең тәҗрибәсен өйрәнүе, нәтиҗәдә аваз ысулын Россия мөселманнары уку йортларына кертүе хакындагы фикерне җиткерә[9]. Җәдитчелек хәрәкәтенең башлангычлары Г.Курсави, Ш.Мәрҗани кебек татар мәгърифәтчеләренең хезмәтләрендә салынса да, аның төп идеологы И.Гаспралы булганлыгы билгеле. Ә ул, билгеле булганча, әлеге методиканың нигезләрен төзүдә Европа һәм төрек педагогларының хезмәтләренә таяна. Моннан тыш, Төркия һәм төрек мәдәнияте татар яшьләрендә һәрчак кызыксыну уяткан. Бу хәл бигрәк тә XIX–XX гасырлар чигендә ачык күренә: төрекчә киенү, төрек сүзләрен куллану һ.б. Төрек әдәбияты, төрек язучыларының әсәрләрен уку белән мавыгу да татарлар арасында еш күзәтелгән. Мисал өчен, танылган татар педагогы, мөгаллимә Фатыйма-Фәридә Нәүрүзова төрек телен белгән, төрек телендә язылган әдәби әсәрләрне укыган, шәхси китапханәсендә гарәп, төрек, татар, рус, фарсы телләрендә китаплар туплаган[10]. Аның бала вакытта

[6] Тузбекова Л.С. Медресе «Галия» – высшее мусульманское учебное заведение Башкортостана (1906–1919 гг.) // Медресе Южного Урала и Приуралья: история и современность: Хрестоматия. Уфа: БГПУ; 2010. С. 344–345.

[7] Санап узылган шәхесләр арасында дини уку йортлары белән беррәттән, дөньяви мәктәпләрне тәмамлаучылар да бар.

[8] Хабутдинов А.Ю. Опыт подготовки конкурентоспособной мусульманской элиты: джадидская система образования. URL: http://www.idmedina.ru/books/islamic/?412 (дата обращения: 12.01.2022).

[9] Adiloğlu A. Ceditçilik Dönemi. Kazan Tatar Edebiyatında Kadın Hak Ve Hürriyetleri Meselesi. Ankara: Gece Kitaplığı Yayınevi, 2020. S. 25.

[10] Мәхмүтова А.Х. Вакыт инде без дә торыйк... (Җәдидчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 299.

Төркиядә беркадәр белем алуы – мәхәллә мәктәбендә сабакка йөрүе дә[11] моңа сәбәп булгандыр. Төрек теле татарлар өчен Европа әдипләренең әсәрләре белән танышу каналы да булган: француз романнарын алар төрек теленә тәрҗемәдә укыганнар. Моннан тыш, аеруча XX гасыр башында татарларда фән үсешендә дә төрек авторларының роле аз түгел. Мәсәлән, төрле фәннәрдән мәдрәсә дәреслекләрен язуда төрек авторларының хезмәтләре актив файдаланылган.



*Истанбулда белем алган Бертуган Хәсән һәм Мөхәммәтвәли Рахманкуловлар (https://www.flickr.com/photos/brambeus/9927155205)*

Истанбул, Шамның Мәккәи Мөкәррәмәгә, ягъни изге хаҗга бару юлында урнашуы да төрекләр һәм Төркиягә карата аерата якынлык тудыруда үзенең ролен уйнаган.

Истанбул дини белем бирү буенча озак вакытлар үзенең дәрәҗәсен саклап килгән. Шулай да XX гасыр башында ул бигрәк тә дөньяви белем алга киткән илләрнең берсе булып таныла башлый. Шуңа күрә төпле дини белем алырга теләүчеләр, Истанбулда тоткарланмыйча, башка илләрдәге ислам мәгарифе үзәкләренә юл алганнар. Каһирә, Мәдинә, Мәккә кебек шәһәрләрдә урнашкан уку йортлары шундыйлардан. Зыя Камали, мәсәлән, үз теләге белән укуын «әл-Әзһәр»дә дәвам итәргә карар кыла, Каһирәгә юл ала[12]. 1900–1903 елларда «әл-Әзһәр»нең дин бүлегендә укыганнан соң, ул Мәдинә шәһәрендә бер ел дәвамында хәдис белемен һәм гарәп әдәбиятын өйрәнә[13].

Каһирә – ул чорда мөселман дөньясындагы иң эре, иң данлыклы дини белем бирү үзәкләренең берсе булып санала. Анда бик күп татар яшьләре белем ала. Галимҗан Барудиның бертуганы Габдрахман Галиев, Сабир Алимов (соңыннан «Хөсәения»дә укыта), Закир Кадыйри, Мөхәммәтвәли Рахманкулов, Габдулла Баттал, Муса Бигиев, Зыя Камали, Ибраһим Камалов

[11] Мәхмүтова А.Х. Вакыт инде без дә торыйк... (Җәдидчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 295.

[12] Фархшатов Ф.М. Камали З. Медресе Южного Урала и Приуралья: история и современность: Хрестоматия. Уфа: БГПУ, 2010. С. 293.

[13] Ергин Ю.В. Зия Камали – основатель медресе «Галия»: трагические 30-е годы. URL: https://cyberleninka.ru/article/n/ziya-kamali-osnovatel-medrese-galiya-tragicheskie-30-e-gody/viewer (дата обращения: 11.11.2022).



*Каһирәдә белем алган Мөхәммәтвәли Рахманкулов (https://www.flickr.com/photos/brambeus/9927312583/in/photostream/)*

һ.б. Ш.Мәрҗанинең ике укучысының Каһирәдә укулары билгеле. Болар – Камалетдин бине Сәйфетдин һәм Әбүбәкер бине Йаһүдә. Алар төрле елларда үзләре тәмамлаган уку йортында шәрык фәлсәфәсе буенча дәрес бирәләр[14]. Ш.Мәрҗани хәбәрләренә караганда, Камалетдин «әл-Әзһәр»дә төркиләр өчен ачылган махсус бүлектә кыйраәт дәресләре алып бара[15]. Хаҗ сәфәренә барган вакытта Шиһаб хәзрәт Каһирәдә була һәм үзенең шәкерте белән күрешә. Камалетдин остазына өч көн буе шәһәрнең атаклы урыннарын күрсәтеп йөри[16]. Татар кешеләренең үзләре тәмамлаган белем йортларында калдырылулары, педагогик эшчәнлеккә тартылулары моннан тыш та билгеле. «Әл-Әзһәр»дә укыткан татар шәкертләре арасында Кышкар авылыннан Шәмсетдин Кышкари да бар, ул әле XIX гасырның 20нче елларында ук Ибраһим паша тәкъдиме белән җиде ел дәвамында «әл-Әзһәр»дә фарсы теле укыткан[17].

Татарларның «әл-Әзһәр» кебек мәшһүр дини белем бирү йортларын сайлауларының үз сәбәпләре бар, әлбәттә. Бу, иң беренче чиратта, аларның бай тарихка ия булулары, ислам белеме бирүдәге традицияләре белән билгеләнә. Әле VIII гасыр башларында ук Мәккә, Мәдинә, Басра, Куфа, Шам (Дәмәшкъ) кебек Өмәвиләр хәлифәтенә караган шәһәрләрдә шактый зур һәм абруйлы галимнәр берләшмәләре булган, ә IX–X гасырларда Каһирәдәге «әл-Әзһәр» мәчете һәм Фәстәге «әл-Каравийййун» мәчете барлык мөселман дөньясыннан үзенә укучылар җәлеп иткән белем бирү үзәкләренә әверелә башлыйлар»[18]. XIX гасыр ахырында «әл-Әзһәр» мәдрәсәсе ислам университеты статусын ала, һәм монда аның җитәкчесе Мөхәммәт Габдүһнең (1849–1905) роле бик зур

[14] Әмирхан Р. Татар мәгарифе тарихыннан // Р.Әмирхан. Иманга тугрылык. Казан: Татар.кит.нәшр, 1997. Б. 179.

[15] Мәрҗани: Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вилаятенә йөз ел булу (1233–1333) мөнәсәбәте илә нәшер ителде. Казан: «Мәгариф», 1915. Б. 115, 117.

[16] Миңнуллин Җ.С. Аны Шәрык алкышлаган // Миңнуллин Җ.С. Мәкаләләр җыентыгы. Казан: Татар.кит.нәшр., 2023. Б. 199 (197–199).

[17] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 275.

[18] Thurston A. Islamic Universities and Their Global Outreach. URL: http://www.oxfordislamicstudies.com/Public/focus/essay1009_Islamic_Universities.html (Accessed: 10.05.2021).

була. Ул җәмәгатьчелек игътибарын әлеге белем йортын реформалаштыру мөһимлегенә юнәлтә алган. «Шәех әл-Гаттардан алып, әл-Әфгани һәм Мөхәммәт Габдүһне кертеп, шулай ук XIX гасырның икенче яртысында Мисырда барлыкка килгән мәгърифәтчеләрнең тырышлыгы белән, «әл-Әзһәр» илнең рухи һәм мәдәни үзәге ролен саклап кала ала»[19]. Шулай итеп, бу чорда «әл-Әзһәр» һәрбер мөселман кешесе өчен үрнәк, иң абруйлы белем үзәкләренең берсе булып әверелә. Бу анда уку-укыту эшләренең куелышы һәм эчтәлеге, урнашкан яңача тәртипләр һәм, әлбәттә, анда белем биргән галимнәр белән дә бәйле була.

М. Габдүһ татар зыялылары арасында да аеруча зур шөһрәт казанган галимнәрнең берсе була. Р.Фәхретдин аның мөселман белем бирү системасын үзгәртеп кору буенча эшчәнлегенә зур бәя бирә. Ул галимнең мөселман уку йортларына дөньяви фәннәрне укытуны кертү хакындагы фикерләрен хуплый. Шулай ук мөселманнарны чит телләргә өйрәтү, дин әһелләренең Европа телләрен белү мәҗбүрилеге турындагы карашларының әһәмиятенә басым ясый[20].

М.Габдүһ үз кул астында укыган татар шәкертләренең остазы булу өстенә, аларның галим булып җитешүләренә өлеш керткән. «Галия» мәдрәсәсе җитәкчесе Зыя Камали «әл-Әзһәр»нең фәлсәфә факультетында укыган чорда Мөхәммәт Габдүһ белән яхшы таныш була. Остазы аны укып бетергәннән соң университетта эшкә калырга чакыра, әмма З.Камали бу тәкъдимне кабул итми, үз ватанына кайтып өммәтенә һәм милләтенә хезмәт итү юлын сайлый. Зыя остазына аеруча зур хөрмәт белән карый, педагогик эшчәнлегендә, динне реформалау, ислам фәлсәфәсен булдыруда аның фикерләренә таяна[21]. Аның «әл-Әзһәр»дә укыган чорда формалашкан фикерләре, күзаллаулары һәм белемнәре алдагы тормышында чагылыш таба. Камалиның карашлары ислам нигезләрен аңлауга рациональ якын килү белән билгеләнә, ул үзе нигез салган мәдрәсәне дин галимнәре әзерләүче үзәккә әверелдерүне максат итә. З.Камали Коръәннең татар телендәге беренче тәрҗемәсен әзерли, моннан тыш «Фәлсәфә исламия» дип аталган дүрт томлык хезмәтен яза[22].

Татар җәмәгатьчелеген «әл-Әзһәр» һәм аның эшчәнлеге белән таныштыру, аның үзенчәлекләрен яктырту, шул рәвешле татар яшьләрен кызыксындыру максатында «Шура» журналында мәкаләләр циклы басылып чык-

---

[19] Москалец О.В. Об организации «Союз русских студентов в Египте» (1920–1922 гг.) // Minbar. Islamic Studies. 2019. № 12(4). С. 945–946.

[20] Фәхретдин Р. Дини вә милли мәктәпләребез хакында // Шура. 1913. № 24. Б. 738.

[21] Алмазова Л.И. Зыяэтдин Камали – мыслитель, просветитель и религиозный деятель // Камали З.Д. Философия ислама: в 2 т. Т. 1. Казань: Татар. кн. изд-во, 2010. С. 12.

[22] Шангараев Р.Р. История ислама и мусульманских народов России. Хрестоматия. Казань: ИД «МеДДоК», 2020. С. 95.

кан[23]. Анда «әл-Әзһәр»нең тарихы, укыту тәртипләре, укытылган фәннәр, дәреслекләр, дәресләр, имтиханнар, яшәү шартлары (ашау-эчү хаклары) һ.б. бик күп әһәмиятле мәсьәләләр белән танышырга мөмкин булган.

Татар педагоглары һәм галимнәренең «әл-Әзһәр»не дөньядагы иң алдынгы дини белем учакларының берсе дип санавы XX гасыр башында югары дини белем алырга теләгән татар шәкертләренең әлеге уку йортын сайлауларына этәргеч бирә. Мисал өчен, киләчәктә татар педагогы, дәреслекләр авторы булып танылачак Сөнгатулла Бикбулатов (1886–1954) «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, укуын дәвам итү өчен Каһирәгә җибәрелә. Анда ул «Татар-төрек шәкертләре җәмгыяте»н оештыруда катнаша, әлеге җәмгыятьнең сәркатибе була. «Әл-Әзһәр»дә гарәп теле һәм әдәбияты буенча дәресләргә йөрү белән беррәттән, Каһирәдәге югары педагогик уку йортына лекцияләргә йөри[24]. Шулай итеп, ул ватанына дини һәм дөньяви фәннәр буенча әзерлекле белгеч булып кайта. «Хөсәения»дә гарәп теле һәм Урта, Якын Көнчыгыш тарихын укыту белән беррәттән, ул фәнни-методик эш белән шөгыльләнә, ислам тарихы, гарәп теле тарихы, шәрык белеме буенча хезмәтләр, дин гыйлеме буенча дәреслекләр яза[25].

«Әл-Әзһәр»дә белем алу күп кенә татар галимнәренең – Муса Бигиев, Закир Кадыйри, Габделбари Баттал-Таймас, Габдрахман Рәсүли һ.б.ның фәнни күзаллаулары һәм кызыксынулары формалашуда зур роль уйнаган. Муса Бигиев, мәсәлән, Мөхәммәт Габдүһдән гыйлем алу өстенә, «әл-Әзһәр», Мисыр милли китапханәләрендәге кыйммәтле мирасны өйрәнеп, үзенең хезмәтләренә мәгълүмат туплаган. Каһирәдән соң ул ике ел дәвамында Хиҗазда яшәп, имам Насаʼиның «Сөннә»сен һәм имам Маликның «Муваттаʼ»сын өйрәнә[26]. Ватанына кайтканнан соң, Коръән тарихын һ.б. дини проблемаларны яктырткан фәнни хезмәтләр язган.

«Әл-Әзһәр»дә белем алган татарлар арасында дин галимнәре белән беррәттән, үзен дөньяви фәннәр өлкәсендә таныткан атаклы шәхесләр дә байтак. Шундыйларның берсе – педагог, журналист һәм галим-археограф Алимов Сабир Алим улы (1873[27]–1939). Ул чыгышы белән элеккеге Пенза губернасы Саранск өязе (хәзерге Мордва Республикасының Ләмберә районы)

[23] Мисыр әл-Каһирәдә «әл-Әзһәр» // Шура. 1908. №4. Б. 114–116; №6. Б. 168–171; №7. Б. 200–202.

[24] Марданшин М.М. Педагогическая деятельность С. Бикбулатова // Казанский педагогический журнал. 2008. №9. С. 116.

[25] Татар педагогик фикере антологиясе. 2 томда. Т. 2. Казан: Татар.кит.нәшр., 2016. Б. 34.

[26] Гёрмез М. Муса Джаруллах Бигиев / перевод с турецкого: А.Г. Хайрутдинова. Казань, 2010. С. 20–21.

[27] С.Алимовның туган елын билгеләүдә төрлелек күзәтелә. Н.Лобачевский ис. Фәнни китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге фондларында сакланган паспортына караганда, ул 1973 елда дөньяга килгән (2392 т.)

Татар Таулысы авылыннан була. Башлангыч белемне туган авылында һәм күрше авыл мәдрәсәсендә алганнан соң, укуын дәвам итү өчен Бохарага китә, «Мир Гарәб» мәдрәсәсендә (1896) укый[28]. Ләкин Бохара мәдрәсәләрендәге укыту тәртипләре белән килешеп бетми, һәм биш ай укыганнан соң Ташкентка китеп бара[29], татар мәктәпләрендә мөгаллимлек итә. Югары белем артыннан С.Алимов Каһирәгә килә, «әл-Әзһәр»гә укырга керә (1904). 1900–1910 елларда «Әл-Лива»[30] газетасында Россия татарлары һәм башка халыкларның тормышы турында мәкаләләр бастыра[31]. С. Алимов гарәп, фарсы, төрек телләрен бик яхшы белә. Бу исә аңа «Хөсәения» (1910 елдан укыта)[32], Әстерхан мәдрәсәләрендә укытырга мөмкинлек бирә. Моннан тыш, бу елларда ул фәнни эшчәнлек – борынгы кулъязмалар җыю эше белән шөгыльләнә башлый. 1935–1939 елларда С.Алимов СССР Фәннәр академиясенең Ленинград көнчыгыш институты хезмәткәре булып эшли. Биредә аның татар, нугай, төрекмән, казах теләрендәге кыйммәтле чыганакларны туплаган коллекциясе бар[33].

Каһирәдә татарлар, мәшһүр «әл-Әзһәр» университетыннан тыш, башка уку йортларында да белем алганнар. «Әл-Әзһәр» тирәсендә Мәһмәт бәй исемле төрек кешесе тарафыннан төзетелгән «Мәһмәт бәй мәдрәсәсе» булган. «Вакыфның куйган шарты буенча, бу мәдрәсә хөҗрәләрендә бары тик төрек шәкертләре генә яшәргә тиеш була. Шәкерт, бу хөҗрәдә бушлай яшәүдән тыш, тагын Мәһмәт бәй вакыфыннан, белмим, аена күпмедер көлчә (кабартма) һәм берничә куруш акча да алган. Шәкерт «әл-Әзһәр»дә алган дәресләрен дәвам итә алган, ләкин бу эш мәҗбүри булмаган. Бу шәкертләр болай да «университетлы» саналганнар. Шуңа күрә анда һичбер төрле дәрес дәвам итмичә, берни дә укымыйча, өйрәнмичә, еллар буе «көлчә» ашап, кесәсенә сары лира туплаган, хөҗрәне кулдан ычкындырмау өчен өйләнми яткан кемсәләр дә юк түгел иде. Ул вакытларда, ягъни минем 1904 тән 1908 елга кадәр Каһирәдә уздырган вакытта,



*Сабир Алимовның «әл-Әзһәр»дә укыган вакыты. (Tatars. Sabir 'Alimov (1873–1939))*

[28] Татар энциклопедиясе. 6 томда. Т. 1. Казан: ТЭИ, 2008. Б. 131.
[29] Миңнуллин Җ. Рухи мирасны барлаганда // Казан утлары. 1984. № 12. Б. 170.
[30] «Әл-Лива» – «Байрак».
[31] Татар энциклопедиясе. 6 томда. Т. 1. Казан: ТЭИ, 2008. Б. 131.
[32] РДТА (РГИА). Ф. 821. 133 тасв. 626 эш. 63 б.и.я.–78 б.
[33] Musali V. St. Petersburg doğu yazmalari enstitüsü'nde bulunan Dîvân-I Hikmet nüshalari // Türk Kültürü ve Hacı Bektaş Veli Araştırma Dergisi. Kış 2020/Sayı 96. S. 309.

бу вакыфның аерым хөҗрәләрендә казанлы һәм Кырым төрек шәкертләре дә яши иде», – дип яза бу хакта Габделбари Баттал-Таймас үзенең истәлекләрендә[34].

Моннан тыш, татарлар арасында теге яки бу уку йортына махсус рәвештә кермичә, хаҗ вакытында яисә башка максатлар белән мөселман илләренә килгән вакытта белем эстәү, теге яки бу остаздан дәресләр алу традициясе дә булган. Галимҗан Баруди, мәсәлән, Бохарада җиде ел дәвамында белем алганнан соң, 1886 елда ислам дөньясының иң эре белем бирү үзәкләрендә – Истанбулда, Мисырда, Хиҗазда сәяхәттә була, хаҗ кыла, белем туплый, һәм бу сәфәр аның дөньяга карашы тамырдан үзгәрүгә сәбәп була[35]. Нәтиҗәдә ул мөселман дөньясын гомум Европа һәм дөнья кыйммәтләренә якынайтмый гына аны алга җибәреп булмаячак дигән фикергә килә. Һәм бу, иң беренче чиратта, мәгариф өлкәсендәге яңалыклар һәм кыйммәтләр белән бәйле була. Шушы сәяхәте вакытында алган тәҗрибәсен, белемнәрен үз кул астындагы уку йорты – Россиядә җәдиди белем бирү үзәге булып танылган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен үзгәртеп коруда куллана башлый.

«Әл-Әзһәр»не, Каһирә университетын тәмамлаган татарлар арасында ватанына кайтып, дини мәдрәсәләрдә укыткан галимнәр белән беррәттән, дөньяви уку йортларында белем алуын дәвам иткән, совет чорында мәгариф, фән һәм мәдәният үсешенә зур өлеш керткән шәхесләр дә бар. Шуларның берсе – Закир Аюханов, 1911–1914 елларда Каһирә университетында белем алып, «Хөсәения», «Галия» мәдрәсәләрендә шәкертләргә белем бирә, 1918–1926 елларда Томск университетында югары белем алып, педагоглык эшчәнлеге белән шөгыльләнә, башкорт мәктәпләре өчен дәреслекләр төзүдә актив катнаша[36]. Ул – рус хәрефләре нигезендә башкорт алфавитын төзүчеләрнең берсе, башкорт телендә язылган балалар әлифбасы, «Өлкәннәр өчен әлифба» китапларын язган татар педагогы буларак билгеле.

XIX–XX гасырлар чигендә «Әл-Әзһәр» һәм башка мөселман Көнчыгышы илләрендәге уку йортлары татар яшьләре өчен иң мөһим гыйлемлелек үзәкләре булып торганнар. Алар үрнәгендә Идел-Урал буе мәдрәсәләрендә яңа тәртипләр, уку-укыту әсбаплары, яңа фикерләр кергән.

---

[34] Баттал Таймас Г. Мин бер яктылык эзләгән идем // Казан утлары. 1998. №5. Б. 148.

[35] Юсупов М.Х. Галимджан Баруди. Казань: Тат. кн. изд-во, 2003. С. 49.

[36] Аюханов Закир Насырович // Энциклопедия Башкирии: https://ufa-gid.com/encyclopedia/auhanov.html (дата обращения: 12.10.2023).

# Һиндыстандагы «Дарел-гыйлем» мәдрәсәсендә татарлар

Бу чорда татар яшьләре укыган тагын бер белем учагы – Һиндыстанның Деобанд шәһәре җирлегендәге «Дарел-гыйлем» мәдрәсәсе. Ислам дөньясында ул, әһәмияте буенча, «әл-Әзһәр»дән кала икенче урында торган уку йорты саналган[1]. Бүгенге көндә дә «Дарел-гыйлем» иң эре дини академик белем бирү үзәкләренең берсе булып тора.

Бу уку йортында белем алган татар шәкертләренең саны, «әл-Әзһәр» яисә башка танылган уку йортлары белән чагыштырганда артык күп булмаса да, 1910 еллар уртасында Деобанд мәдрәсәсен шактый шәкертнең сайлавы күренә. «Вакыт» газетасының 1914 елгы 13 май санында Россиядән килгән шәкертләрнең күбәюе турында хәбәр ителә[2]. Газета мәгълүматларына караганда, укучылар саны арту белән бәйле рәвештә «Җәмәгать әл-вагыйзин» дип исемләнгән җәмгыять ачу турында карар кабул ителә. Моңа кадәр татар шәкертләре, үзләренең махсус җәмгыятьләре булмау сәбәпле, әфган һәм һинд студентлары җәмгыятьләренә йөргәннәр. Инде үзләре дә шактый җыелгач, татар шәкертләре җәмгыятен төзергә карар итәләр һәм яңа җәмгыятьнең җитәкчесе Габделхәким әл-Бохари аша ватандашларына ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр. «Дарел-гыйлем»дә укучы татарлар өчен китапханә оештыру өчен татар телендә чыгып килүче газета һәм журналларны җибәрүне үтенәләр. Бу чара, аларның фикеренчә, ватаннарыннан читтә белем алучы яшьләргә төрки-татар дөньясындагы яңалыклар белән танышып барырга ярдәм итәчәк. Мәкаләдә «Дарел-гыйлем»дә укучы һәм «Җәмәгать әл-вагыйзин» җәмгыятендә әгъза булып торучыларның кайберләренең исемнәре китерелә: Миргасыйм бине Миршәриф әл-Минзәләви, Габдулла әт-Ташкәнди, Габделлатыйф әл-Куканди, Мөхәмммәтҗан әл-Әстерхани, Җәлалетдин әл-Миргиләни, Хөрмәтулла әл-Усави һәм мелла Сабит әл-Кабули[3].

Татарлар белән Һиндыстан арасында гыйлем өлкәсендәге бәйләнешләр «Дарел-гыйлем» мәдрәсәсе белән генә чикләнмәгән, әлбәттә. Илдәге башка уку йортлары, аерым галимнәр белән аралашулар да татарларга белемнәрен арттырырга, дөнья турындагы карашларын киңәйтергә булышлык иткән. Күренекле дин галиме Муса Бигиев Деобанд шәһәрендә ярты ел чамасы яшәп, андагы ислам белгечләре белән якыннан аралашкан, борынгы һинд чыганаклары белән танышкан[4]. Икенче бер галим һәм мәшһүр педагог И.Гаспралы исә, киресенчә, һиндлыларга белем бирү эшен оештыручыларның берсе

---

[1] Шуны искәртеп узу кирәк, Деобанд мәдрәсәсе, «әл-Әзһәр»дән аермалы буларак, бер генә мәзһәб – хәнәфи мәзһәбе белән генә чикләнгән.

[2] Һиндыстанда татар таләбәсе җәмгыяте // Вакыт. 1914. 23 май.

[3] Шунда ук.

[4] Вәлиәхмәтов Х. Ислам галәменең казык йолдызы // Безнең мирас. 2017. № 3. Б. 16.

буларак билгеле. 1912 елда ул Һиндыстанның Бомбей шәһәренә барып, мөселманнар өчен беренче җәдит мәктәбен ача, әлеге мәктәп өчен укытучылар әзерли[5].

Һиндыстан белән бәйле булган татар шәкертләреннән киң җәмәгатьчелеккә аеруча билгелесе, мөгаен, Кадермәтов Минһаҗетдиндер (1870–1925). Аның турында татар матбугатында шактый мәгълүмат сакланган булса да, кайда, кайсы уку йортында укыганлыгы төгәл әйтелми. Күпчелек авторлар аның Һиндыстанда белем алуы хакында язалар[6]. «Һинди» тәхәллүсе булуы да шуңа ишарәли[7]. Ул үзе чыгышы белән Саратов губернасының Хвалын өязе Иске Мастак авылыннан була. Аның эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр белән татар газета-журналларында танышырга мөмкин. Ләкин шул заман татар укучысы өчен ул, мәгърифәтче булудан бигрәк, үзенчәлекле сатира объекты – «Һинди Минһаҗ» булып әверелгән. Һәм бередә Г.Тукайның да роле зур. «Яшен» журналының 1909 елгы 8 апрель санында шагыйрьнең «Һинди Минһаҗ» исеме белән имзасыз басылган шигыре басылып чыга. Анда мондый юллар бар:

«Таш ташыйлар. Анда Минһаҗ галия[8] нигезен сала.
Туй ясыйлар. Монда Минһаҗ гаилә нигезен сала.
Салыныр да, төпләнер дә, бик уңайдыр соңгысы;
Шикләнәм мин әллә ник: булмас кеби әүвәлгесе»[9].

Әлеге шигырьнең герое Минһаҗетдин Кадермәтов, Һиндыстанда укуын тәмамлап кайтканнан соң, 1906 елда үзенең туган төбәгендә – Хвалын шәһәрендә һинд уку йортлары үрнәгендә дүрт катлы «Ислам университеты (дарелфөнүн)» салдыру уе белән яна. «Вакыт» газетасының 1906 елгы 21 ноябрь санында аның «Хвалында мәдрәсәи галия» дигән исем астында язмасы дөнья күрә. Анда ул: «Аз вакыт эчендә, Хвалын шәһәре шул мәдрәсәбез сәбәпле зур ислам мәркәзенә әйләнер, дигән өметебез бар. Башка губерналардан киләчәк шәкертләр һәм голяма әфәнделәр өчен дә, килү-китү харәҗәтләре (хаҗәтләре) һәм кыенлыклары азрак булачак. Чөнки Идел ярында ук

[5] Бу хакта тулырак кара: Муртазина Л.Р. «Единство языка, мысли и действий»: Вклад Исмаила Гаспринского в развитие просвещения мусульманских народов // Minbar. Islamic Studies. 2022. № 15(3). С. 635–652.

[6] Камал Г. Мәдрәсәи галия // Йолдыз. 1907. 26 август.

[7] М. Бөдәйли мәгълүматларына караганда, М. Кадермәтов Төркиядә белем алган (Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Псевдонимы в татарской литературе / төз.: Л.Ш.Гарипова, Г.Н.Зәйниева. Казан: ТӘһСИ, 2021. Б. 95).

[8] Галия – бу урында югары уку йорты, ягъни университет мәгънәсендә кулланылган.

[9] М.Гайнетдинов исәпләүләренә караганда, Г.Тукай 1908–1912 еллар аралыгында үзенең алты әсәрендә М.Кадермәти темасына кагыла. (Гайнетдинов М. Г.Тукай һәм Һинди Минһаҗ // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар: Г.Тукай тууына 125 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2011. Б. 38).

урнашкан. [...] Яз башыннан, иншә Аллаһ, мәдрәсәне кору эшенә керешәчәкбез. Инде бина сызмаларын (архитектор проектын) әзерләү эше башланды. Ул әзер булгач, бинаның озынлыгын-киңлеген, ничә катлы булачагын хәбәр итеп, фоторәсемен бастырып тарату ниятендәбез. Шәкертләребезгә камил гыйлем алулар насыйп булсын», – дип белдерә[10]. Алдан куелган максатлар, бик изге булса да, кызганыч, тормышка ашмый кала. Мәдрәсә салу өчен Минһаҗ Кадермәтов халыктан шактый күләмдә акча җыя, ләкин ни сәбәптәндер, җыелган акчаларны үз максатларында файдаланып бетерә. 1910 елда Диния нәзарәте каршында хисап тотып, яңа мәдрәсә ачу буенча эшчәнлеген төгәлләвен белдерә[11].

Минһаҗ Кадермәтов шәхесе шул заман татар җәмгыятендә шактый каршылыклы кабул ителсә дә, галим М.Гайнетдинов билгеләгәнчә, ул – «хөррият этабы мәдәни-әдәби яңаруы вәкиле. Аның да соңгы, «могҗизачылар» буыны вәкиле», хөррият заманына тәңгәл, күтәренке, оптимистик рух белән гади бәндә акылы җитмәслек эшкә алынган, шул эшкә ихлас, фидакарьләрчә бирелгән бер кеше булганлыгы ачык сиземләнә. Кадермәтинең үз эше хакында газета аша аваз салуы да – шул эшенә кемнедер чакыру авазы түгел. «Күрәсең, ул бу язмасы белән татар җанлануы мәйданында «һавалар үзгәрүе», хәрәкәт юлында тирән, хәвефле упкыннар барлыкка килү турында татар җәмәгатьчелеген кисәтергә теләгән». Тукайның тәнкыйди фикерләвендә дә, гадәттәгечә, халык язмышын ил язмышы белән бәйләү, аерым шәхесләр аша милли проблемаларга игътибарны юнәлтү ярылып ята: ул «Һинди Минһаҗ язмышында да милләт фаҗигасен күрә»[12]. Моннан тыш, М.Кадермәтов 1915 елда басылып чыккан «Мөшавәрәт календаре» китабының авторы буларак та билгеле.

Гомумән алганда, XIX–XX гасырлар чигендә Көнчыгышның атаклы мөселман белем бирү үзәкләренең берсе булган «Дарел-гыйлем»дә белем алган татар шәкертләре, аларның яшәеше, белем алу үзенчәлекләре турында мәгълүматлар бик аз, һәм алар бу чорда Һиндыстан уку-укыту системасының татар мәгарифе үсешенә ясаган йогынтысын билгеләргә мөмкинлек бирми.

---

[10] Кадермәти М.Й. Хвалында мәдрәсәи галия // Вакыт. 1906. 21 ноябрь.

[11] Уфа хәбәрләре // Вакыт. 1910. 29 май.

[12] Гайнетдинов М. Г.Тукай һәм Һинди Минһаҗ // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар: Г.Тукай тууына125 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2011. Б. 40.

# Хиҗаздагы «Казанлы» мәдрәсәсе

Хиҗаз уку йортлары, билгеле булганча, татарлар арасында аеруча популяр булганнар. Изге җирләрдә белем алуны мөселманнар зур дәрәҗә санаганнар. 1897 елда Мәдинәдә 42 татар шәкерте белем алган (чагыштыру өчен: Каһирәдә 7, Истанбулда 15)[1]. XX гасырның беренче унъеллыгында Мәдинә, Мәккә шәһәрләренә гыйлем эстәргә барган татарларның саны гел артып тора. 1911 елда, мәсәлән, анда укырга теләгән шәкертләр шулкадәр күп була ки, хәтта мәдрәсәләрдә урын җитешми; шул сәбәпле татар шәкертләрен, моңарчы алар укымаган «Мәдрәсәи Гыйрфания» кебек уку йортларына да алганнар[2].

Мәдинә, Мәккә шәһәрләрендәге мәдрәсәләрдә укучы шәкертләр, 1898 елда Хиҗазда эшлекле сәфәрдә булган штабс-капитан Г.Дәүләтшин[3] сүзләре белән әйткәндә, «Бохара уку йортларында белем алучылардан шактый аерылып торганнар: аларда шәригатькә карамаган бар нәрсәләргә карата артык фанатизм күзәтелми; Мәдинә шәкертләре киңрәк күзаллауларга, дөресрәк карашларга ия, алар күбрәк кызыксынучан»[4].

Шул ук вакытта, чит илләрдә, шул исәптән Хиҗазда, укуның уңай яклары белән беррәттән, җитешсезлекләре дә булган. Чит мохит, чит тел һәм гореф-гадәтләр, уку урыннары, укытучылар һәм дәреслекләрнең җитешмәве, яшәү һәм уку өчен шартлар булмау үз ватаныннан читтә белем алучы яшьләргә кыенлыклар тудырган. Кайбер очракларда мәдрәсәдә җирле шәкертләрдән бушаган вакытта гына укырга мөмкин булган, үзләре өчен махсус остаз ялларга туры килгән – бу өстәмә чыгымнар таләп иткән[5]. Мәсьәләне хәл итүнең юлын татарлар өчен махсус уку йорты ачуда күргәннәр. Мәккәдә укучы яшьләр шундый мәдрәсәне ачу проблемасын татар вакытлы матбугатында күтәреп чыкканнар[6]. Чыннан да, татарлар өчен махсус мәдрәсә оештыру моңарчы матди хәлләрен хаҗилар, аларны йөртү, юл күрсәтү хисабына хәл

---

[1] Давлетшин А. Отчет штабс-капитана Давлетшина о командировке в Хиджаз. СПб.: Военная типография, 1899. С. 62–63.

[2] Әл-Мәгади Г. Мәдинә Мөнәүвәрәдән мәктүб // Дин вә мәгыйшәт. 1911. № 7. Б. 108.

[3] Габделгазиз Габдулла улы Дәүләтшин (1861–1920), чыгышы белән Оренбург губернасыннан, хәрби Көнчыгыш белгече, генерал-майор (1913). Кавказ һәм Төркестан хәрби округларында хезмәт итә, гарәп һәм төрек телләрен белә. 1898 елда Хиҗазда эшлекле сәфәрдә һәм хаҗда була.

[4] Давлетшин А. Отчет штабс-капитана Давлетшина о командировке в Хиджаз. СПб.: Военная типография, 1899. С. 63.

[5] Муртазина Л.Р. «Учение и просвещение можно брать везде, где оно есть»: татарские учащиеся в странах мусульманского Востока на рубеже XIX–XX вв. // Minbar. Islamic Studies. 2022. № 15(1). С. 26.

[6] Мәккәи Мөкәррәмәдә русияле ислам тәләбәсенең җәмгыять гыйльмиясе тарафыннан игъланнамә // Вакыт. 1910. 28 август.

итеп килгән яшьләргә яшәү һәм уку өчен уңай шартлар тудырачагы көн кебек ачык була.

Яхшы матди нигезгә корылган мәдрәсә төзелгән очракта, яшәү мәсьәләсе дә уңай хәл ителәчәге шиксез[7]. Мәккәдә мондый мәдрәсә ачылу турында мәгълүмат юк, ләкин ул Хиҗазның икенче бер шәһәрендә – Мәдинәдә ачыла. Һәм ул нәкъ менә алда искә алынган мәсьәләләрне хәл итүне күз алдында тоткан.

Билгеле булганча, XVII–XVIII гасырлар чигендә дини белем алуның иң әһәмиятле, төп үзәкләре булып Һиндыстан һәм Хиҗаз саналган[8]. Бу традиция XIX гасыр ахырларында да үзенең позицияләрен югалтмый. Шуңа күрә татарларның үз шәкертләренә белем бирү өчен Мәдинә шәһәрендә мәдрәсә ачу уе барлыкка килүгә дә артык гаҗәпләнергә кирәкми. Биредә икенче бер моментны да искә алырга кирәк, ул да булса татарларның борынгы заманнардан ук килгән эшкуарлык сыйфаты – алар сәйяр халык, яңа җирләр, яңалыклар белән бик теләп танышканнар һәм кая гына барып чыксалар да, бирешмәгәннәр, яшәргә омтылганнар. «Казанлы мәдрәсәсе» дип исем бирелгән әлеге уку йортына нигез салуда аны оештыручыларның матди табыш алуны максат итүләре табигый хәл, чөнки һәрбер проект, шул исәптән мәгариф өлкәсендә дә, финанс кертемнәре һәм чыгымнары белән беррәттән, керем алуны да күз алдында тота. Тик шулай да мәдрәсә ачудан беренче чиратта максат милләт мәнфәгатьләрен кайгыртудан гыйбарәт булган, чөнки «Бу мәдрәсәне бина итүләреннән максатлары Мәдинәгә килгән Русия кәнеҗләренә (егетләренә) матди вә мәгънәви тәрбия бирү иде»[9].

Шулай итеп, мөселманнар өчен Мәккәи Мөкәррәмәдән кала икенче урында торган изге Мәдинәи Мөнәүвәрә шәһәрендә XIX гасыр ахырында Казан татарлары тарафыннан нигез салынган «Казанлы мәдрәсәсе» барлыкка килә. Аның ничәнче елда оештырылуы хакында төгәл мәгълүмат юк, Р.Фәхретдин язуынча, 1896 елда мәдрәсәдә инде шәкертләр белем алган. Үзенең «Асар» хезмәтендә галим 1896 елда беренче тапкыр Җәгъфәр базарында урнашкан мәдрәсәгә барган сәет Шәрифнең хатирәләрен китерә[10]. «Вакыт» газетасында дөнья күргән «Казанлы мәдрәсәсе» дигән мәкаләдә дә мәдрәсәнең якынча шул елларда оешуы хакында әйтелә[11].

Татар вакытлы матбугаты материалларына караганда, әлеге мәдрәсәне ачу кирәклеге турындагы сүзләр 1880 нче елларда ук алып барыла, ә төзелеш

[7] Хаҗилар вә татар таләбәләре // Вакыт. 1914. 4 октябрь.

[8] Кюгельген Анке фон. Расцвет Накышбандия-Муджадидия в средней Трансоксании с XVIII – до начала XIX вв.: опыт детективного расследования // Суфизм в Центральной Азии (зарубежные исследования). СПб.: Филологический факультет СПбГУ, 2001. С. 320.

[9] Мәдинәи Мөнәүвәрә шәкертләре // Йолдыз. 1907. 15 март.

[10] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 297.

[11] Юлдаш. Казанлы мәдрәсәсе // Вакыт. 1906. 17 октябрь.

эшләре 1880 елларның азагына таба башлана. Әлеге уку йортын салуны башлап йөрүче Габделсаттар әфәнде була[12]. Р.Фәхретдин мәгълүматларына караганда, Габделсаттар бине Җәббар бине Хәмад әл-Казани (1833–1909[13]) чыгышы белән Бүкәй урдасыннан була. Аның әтисе Җәббар хәзрәт (Спас өязенең Яңа Чаллы авылында туган, 1875 елда вафат) казакъ ханы Җиһангир бине Бүкәй янында имам һәм мөгаллим булып хезмәт иткән. 1859 елда Габделсаттар Җәббар улы Мәдинә шәһәренә күченеп килә[14]. Беркадәр вакыттан соң, ул татарлар өчен мәдрәсә ачарга кирәк дигән карарга килә.

Хаҗ юлында урнашкан шәһәрләрдә Казан татарларының эзе шактый тирән булган. Мөселман Көнчыгышы илләрендә яшәүче татар мөһаҗирләре сәяхәтчеләргә вакытлыча яшәү өчен торак урыннары тапшыру эше белән кәсеп иткәннәр. Бу шөгыль аеруча хаҗ юлында урнашкан илләрдә алга киткән. XIX гасыр ахырында кайбер татар байларының Мәккә юнәлешендәге шәһәрләрдә йортлары булган. Анда татар хаҗилары вакытлыча яшәгән. Үзенчәлекле «кунакханә» бизнесы белән Дәмәшкъ, Истанбул, Мәккә, Мәдинә кебек шәһәрләрдә яшәүче татар мөһаҗирләре шөгыльләнгән. Чыгышы белән Уфа губернасыннан булган, 1900 еллар башында гаиләсе белән Шам-шәрифкә килеп төпләнгән Талип аганың, мәсәлән, Дәмәшкъ каласы янында Касьюн тавы итәгендәге Салхия дигән мәхәлләдә[15] салынган йортын татар хаҗилары өчен кунакханә итеп кулланганлыгы билгеле. Ул аларны поездга барып каршы алган, өенә алып кайтып кунак иткән, Шамны күрсәткән. Ул хәтта татар телендә «Шам мосафирларына юлбашчы» дигән китапчык та язып бастырган[16], Шамның картасы, мәшһүр урыннарының рәсемнәрен кертеп, киләчәктә аны тагын да зуррак итеп әзерләү[17], махсус бина сатып алып, татар хаҗилары өчен кунакханә ясау турында хыялланган[18].

Габдрәшит Ибраһимов мәгълүматларына караганда, «Мәдинәдә Казан татарларының 4 тән дә ким булмаган йорты булган. Шундый йортларның

---

[12] Мәдинәи Мөнәүвәрәдә татар мәдрәсәсе // Өлфәт. 1906. 25 октябрь.

[13] Р.Фәхретдин Габделсаттар әфәндене 1909 елда вафат булган дип яза. «Йолдыз» газетасы исә аның 1910 елның башларында бакыйлыкка күчүе хакында хәбәр итә (М.Бәкер. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Йолдыз. 1010. 4 май).

[14] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 537–538.

[15] Бу урынны шәһәр хакимияте Россиядән күченеп килгән татар мөһаҗирләренә бирә. Тау-таш арасында, уңайсыз гына урында татар авылы барлыкка килә. Хәзерге вакытта бу район Дәмәшкъ шәһәре составына кереп беткән, һәм анда инде татар эзләре калмаган.

[16] КФУның Н.Лобачевский исемендәге китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә 3598 т саклау берәмлеге астында «Шам Шәрифнең истәлекле урыннарын күрсәтә торган рисалә (сәяхәтчеләргә юл күрсәткеч)» (авторы күрсәтелмәгән, 1900 нчы елларда язылган) дигән кульъязма китап саклана. Эчтәлегенә караганда, без сүз алып барган Талип ага китабы булырга мөмкин.

[17] Камал. Гарәп мохитендә татар туе // Вакыт. 1914. 1 июнь.

[18] Мортазина Л. Шам татарлары // Безнең мирас. 2018. № 11. Б. 34–39.

берсендә Габделсаттар әфәндедә ул үзе дә тукталган»[19]. Шулай итеп, «Казанлы мәдрәсәсе» ачылган вакытка Габделсаттар әфәнденең матди хәле шактый тотрыклы була, һәм ул, мөгаен, яңа мәдрәсәне ачуны да тагын бер уңышлы бизнес-проект буларак күзаллагандыр.

Мәдрәсә бинасын салу өчен Җәгъфәр базарында җир кишәрлеге сатып алына. Р.Фәхретдин язуынча, Габделсаттар хәзрәт гыйлемле, сабыр һәм гадел кеше була. Аның ялгышы финанс мәсьәләләренә рәсми (документаль) яктан салкын каравында була. Шул сәбәпле, «…халык тарафыннан шундый олуг максатлар белән җыелган мәбләгъләрнең (акчаларның) рәсми дәфтәрләр берлә йөртелмәве вә, һәр ел ахырында Мәдинәдә булган казанлыларны җыеп, хисап мазбатасын (беркетмәсен) укылуга әһәмият бирелмәве, вә бу мәмләкәттәге милли җәридәләрдә (газеталарда) хисаплар игълан ителмәве олуг косурлык (кимчелек) булып, низагларның зур сәбәбе шушы косурлык икәнлеге мәгълүм»[20]. Бу вакыйга татар вакытлы матбугатында бик ачык чагылыш таба.

Мәдрәсә бинасы Россия мөселман байларының матди ярдәме белән салына. Баштан 200 мең сум тирәсе акча җыела. Акча җыю эше мәдрәсә төзелеп беткәннән соң, 1906 елда да дәвам иткән. Бу акчалар мәдрәсә бинасының тышкы ягын җайга салу, тирә-юнен рәткә китерү өчен тотылган. 1906 елда мәдрәсә өчен җыелган акчаның күләме 17 мең сум була[21]. Татар җәмәгатьчелеге инде әллә кайчан төзелеп беткән мәдрәсәнең һаман да шулай зур суммалар таләп итүенә гаҗәпләнүләрен белдергән. «Русия исламнарыннан мәзкүр мәдрәсәсе илә йөз меңнәр илә парә җыелмыштыр. Ләкин һәнүз монда улган капчык тулмадыгыннан, ихтимал ки, моннан соң дәхый күп еллар һәмишә шу илә җыелыныр. Мәдрәсә бина иткәнче, Бәләбәй өязендә берәр бик мәсруф (чыгым, акча) илә 20 мәктәп салмак безем өчен ничә кәррәләр (тапкыр) файдалы улса кирәк»[22]. Җәмәгатьчелекне, бер яктан мәсьәләнең матди ягы борчыса, икенче яктан, «бу мәдрәсәнең эшчәнлегеннән һәм аны тәмамлаучылардан татар милләте өчен нинди дә булса файда булырмы?» дигән сорау тынгылык бирмәгән. «Юлдаш» тәхәллүсе астында язган автор мәкаләсендә шундый бер вакыйганы китерә:

«Икенче бер вакыт Сибириядә мәгъруф (билгеле) улан Нигъмәтулла хаҗи Карамшакъ улыннан: «Мәдинәдә булган Казанлы мәдрәсәсеннән кемнәр җитешәчәктер, гаҗәбән?» – дия сөаль әйттем. Хаҗи да һәрникадәр сабырлык вә хатирә ригаять итүче һәм дә гаять ихтыятлы (саклык белән эш итә торган) бер зат улдыгы хәлендә: «Әфәнделәр җитешер!...» – дия җавап бирде. Димәк, мәзкүр мәдрәсәдә укымыш Габдулла әфәнде вә Гобәйдулла әфәнде мәмлә-

[19] Ахунов А. «Татарская недвижимость» на Востоке // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2002. № 3/4. С. 81.

[20] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 79.

[21] Мәдинәи Мөнәүвәрәдә татар мәдрәсәсе // Өлфәт. 1906. 25 октябрь.

[22] Юлдаш. Казанлы мәдрәсәсе // Вакыт. 1906. 17 октябрь.

кәткә кайтып, шәһәрдән шәһәргә кунак булып йөриячәкләр вә улдыкча бәдәл хаҗ тиҗарәте[23] итәчәкләр»[24]. Аның фикеренчә, һәр елны 10 кеше уку йортын тәмамлап мөдәррис булып, ватанына кайтып халыкка аң-белем, мәгърифәт тарату белән шөгыльләнгән очракта да моның милләт өчен әллә ни файдасы булмаячак, чөнки бу шәкертләрне укытуга шактый зур күләмдә милләт акчасы салынган. «Мәдинәдә 100 мең сарыф итеп бер мәдрәсә салмага күрә, үземнең Чишмә башкортлары өчен 100 сум сарыф итеп бер мәктәп бина итмәк файдалыдыр»[25]. Россия мөселманнарының балалары арасында әле һаман да мәктәп-мәдрәсә челтәреннән читтә калган балалар байтак, мөгаллимнәр әзерли торган махсус уку йорты юк, дәреслекләр җитми. Менә шушы иң кирәкле мәсьәләләрне хәл итү урынында, татар байларының, бик күп милләт акчасын сарыф итеп, «Казанлы» мәдрәсәсен салып куюлары белән килешмәвен белдерә: «Безем моңа һич гакылымыз йитешмәс һәм йитешәчәк түгел...»[26].

Киң җәмәгатьчелек тотылган акчаларга хисап бирү мәсьәләсен дә күтәреп чыга. Халык фикерен белдереп, Юлдаш әфәнде оештыручыларның эшләнгән эшләре һәм сарыф ителгән чыгымнар турында гавәм алдында хисап тотарга тиешлеген, җәмәгатьчелекне вакыфнамә (әгәр андый бар икән) белән таныштырырга, аны вакытлы матбугатта бастырып чыгарырга, вакыф булмаган очракта, бинаны сатып, шул акчага Россиядә татарлар өчен дарелмөгаллимин[27] ачарга кирәклеге мәсьәләсен күтәреп чыга[28].

Мәдрәсәнең финанс ягыннан тәэмин ителеше, гомумән, тотылган чыгымнар мәсьәләләре татар вакытлы матбугатында иң күп яктыртылган темаларның берсе була. Аңа иң беренчеләрдән игътибар итүче Г.Бубый «Бәянелхак» һәм «Казан мөхбире» газеталарында берничә мәкалә бастырып чыгара. Әлеге язмаларның төп максаты – проблемага киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итү һәм аларны дискуссиягә тарту[29].

1906 елның 6 мартында «Казан мөхбире» газетасында дөнья күргән «Мәдинәдәге Казан мәдрәсәсе» дигән мәкаләсендә автор мәдрәсә өчен җыелган акчаларның дөрес бүленмәве мәсьәләсен күтәреп чыга. Чыгымнарның бик күп өлеше мәдрәсә янындагы мәчеттә хезмәт итүчеләрне («имам, наиб имам (имам урынбасары), мөәзин, наиб мөәзин, назыйр, мөдәррис, китапханәче һ.б. – барлыгы 15 кеше») тоту өчен сарыф ителә, ә шәкертләр, гәрчә

[23] Бәдәл – үз урынына кеше яллап Мәккәгә хаҗга җибәрү. Әлеге хезмәт белән махсус шөгыльләнүчеләр булган, шуңа ишарә итеп, автор аны «тиҗарәт», ягъни сәүдә (бизнес) дип атый.
[24] Юлдаш. Казанлы мәдрәсәсе // Вакыт. 1906. 17 октябрь.
[25] Шунда ук.
[26] Шунда ук.
[27] Дарелмөгаллимин – ирләр өчен педагогик уку йорты.
[28] Юлдаш. Казанлы мәдрәсәсе // Вакыт. 1906. 17 октябрь.
[29] Бубый Г. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Бәянелхак. 1906. 17 май.

акчалар аларга тәгаенләнгән булса да, калдык-постык суммалар белән канәгатьләнергә тиеш булалар[30].

Г.Буби Габделсаттар әфәнденең Мәдинә шәһәре үзәгендә ачылган мәдрәсә һәм мәчетнең бөтен мәхәллә мәнфәгатьләре өчен тотылуы, шуңа мөнәсәбәттә анда яшәүче халыкның бу мәдрәсәне оештыручыларга рәхмәт ирештерүләре турында зур сөенеч белдерүен аңлап бетермәве, алай гына да түгел, килешмәве турында хәбәр итә. «Хәлбуки, безнең байлар парәгә (бүлеп бирелгән акчага) бер мәхәлләне тәгъмир итү (яңарту, төзекләндерү) өчен түгел, бәлки татар шәкертләрен тәгълим итү өчен бирмешләрдер»[31]. Аның фикере буенча, бу кадәр зур суммага «Харам» мәчете каршында ук мәдрәсә ачарга мөмкин булган булыр иде[32]. «Бәянелхак» газетасында Г.Бубиның «Казан мөхбире»ндә чыккан мәкаләсенә каршы җавап хаты басыла. Аның авторы Таҗетдин Мангушев «Казанлы» мәдрәсәсен оештыручыны яклап, Габделсаттар әфәнденең чынлыкта төп мәчет тирәсендә урын эзләве турында әйтә. Шул ук вакытта әгәр мәчет тирәсеннән урын алынса, мәдрәсә бинасын салыр өчен ике тапкыр күбрәк акча кирәк булган булыр иде дигән фикерне җиткерә[33]. Г.Буби исә Габделсаттар әфәнденең чынлап та мәчет тирәсендә урын эзләвенә, татар шәкертләренең мәнфәгатен кайгыртуны беренче урынга куюына ышанып бетми, шәкертләргә дип тәгаенләнгән акчаның имамнар, мөәзиннәр һәм аларның якыннарына тотылу мөмкинлеге хакындагы шиген белдерә. «Харам» тирәсендә мәдрәсә салынган булса, аерым мәчет салуның да, имам һәм мөәзиннәр тотуның да хаҗәте булмас иде, ди[34]. Буби мәсьәләне хәл итүнең тагын бер җайлырак юлы булганлыгын – мәдрәсә бинасы өчен һиндлыларның «Харам» мәчете янындагы әзер тәккәләрен[35] чагыштырмача арзан бәягә алырга мөмкин булуын әйтә. Бу очракта, ди ул, 50–60 меңгә төшереп яңа бина салуда зарурлык булмас та иде. Габделсаттар әфәнде кул астындагыларга түлисе акча янга калыр иде, һәм барлык артып калган акчалар шәкертләргә, аларның мәнфәгатьләре өчен тотылыр иде. Авторның иманы камил: әлеге 8 кешегә һәм аларның гаиләләренә сарыф ителгән 2 мең акча укучыларның тормыш-көнкүрешен яхшыртуга тотылырга тиеш. Шәкертләр исә, Буби исәпләүләренә караганда, үзләренә тиеш булган 80 сумның бары тик 20 сумын гына алалар. Габделсаттар әфәнденең бина төзелешеннән артып калган 50 меңнең кайда һәм нинди максатларга тотылуы хакында киң җәмәгатьчелек алдында хисап тотмавын, әле һаман да «Казанлы» мәдрәсәсе кирәк-яраклары өчен Россиядә акча җыюны дәвам итүен тәнкыйтьли. Буби

[30] Бубый Г. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Казан мөхбире. 1906. 6 март.
[31] Шунда ук. 12 март.
[32] Шунда ук. 17 май.
[33] Мангушев Т. [«Казан мөхбире»нең ...] // Бәянелхак. 1906. 19 апрель.
[34] Бубый Г. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Бәянелхак. 1906. 17 май.
[35] Тәккә – мөселман дәрвишләренең гыйбадәтханәсе.

уйлавынча, әлеге акчаларны Габделсаттар әфәнде үз тирәсендәге 40 кеше өчен тота[36].

Бу мәсьәләгә беркадәр ачыклык кертү өчен тагын бер фикерне китереп узыйк. Кормыш өязе Питрәксе (Батырша) авылы мәчете имамы Х. Әлмүшев 1899–1901 елларда хаҗ сәфәрендә вакытта Хиҗазның төрле шәһәрләрендәге галимнәр, татар шәкертләре белән күрешә. Мәдинәдәге «Казанлы» мәдрәсәсендә алган тәэсирләре белән ул үзенең «Хаҗнамә»сендә[37] уртаклаша: «Татарлар 15 бина сатып алып, алардан кергән керемнәрне татар шәкертләренең уку һәм яшәү шартларын яхшыртырга уйлаганнар. Ләкин бу биналарның берсен имам әфәнде, икенчесен мөәзин, өченчесен – шәех әфәнде, шәехнең туганнары һ.б. алган. Боларның берсеннән дә шәкертләргә бер тиен дә бармый. Шәһәрдән ерак булу сәбәпле, аларны арендага алучы да юк»[38].

Вакытлы матбугатта «Казанлы» мәдрәсәсенең финанс хәлләрен ачыклауга багышланган дискуссия шактый озак дәвам итә. «Бәянелхак» газетасы битләрендә төрле фикерләр урын ала. Шулай да редакция, Г.Буби язмасына каршы язылган мәкаләләрнең күпчелегендә хурлау, рәнҗетү сүзләре булу сәбәпле, аларның барысын да урнаштыруны мөмкин санамый, бары тик Т.Мангушевның хатын гына бастырып чыгара. Габдулла Бубига исә үз фикерен әйтү мөмкинлеге бирелә[39]. Бу фактка таянып, редакция фикере абруйлы педагогның фикере белән туры килгән дип нәтиҗә ясарга мөмкин. «Нур» газетасында шулай ук берничә каршы язылган мәкалә дөнья күрә. Мәңгәр авылыннан З.Камали Г.Бубиның байтак фикерләрен, шул исәптән Габделсаттар әфәнде һәм мәдрәсә мөгаллиме Мансур хәзрәткә бәйлеләрен дә, кире кага. Бубыйның Мансур хәзрәтне үз эшен начар башкаручы зат буларак сурәтләвен тәнкыйтьли. З.Камали, Г.Бубига каршы килеп, Мансур хәзрәтнең белемле булуын, шул ук «Казанлы» мәдрәсәсен тәмамлавын, Мәдинә шәһәрендәге абруйлы остазлардан белем алуын яза, яшь булына карамастан, шәкертләр арасында танылып өлгерүен әйтә[40]. Габделсаттар әфәнде, Камали фикеренчә, бар җаны-тәне белән мәдрәсә эшенә бирелгән, калган вакытын догалар укып, гыйбадәт кылып үткәрүче зат[41].

---

[36] Бубый Г. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Бәянелхак. 1906. 17 май.

[37] Хадж-наме. Книга о хадже. Путевые заметки /пер. со старотатарского А.М.Ахунова. Н.Новгород, 2006. 112 с.

[38] Әлеге өзек рус телендә дөнья күргән китаптан тәрҗемә итеп бирелде (URL: https://idmedina.ru/books/history_culture/hadjj/1/almushev.htm (мөрәҗәгать итү датасы: 12.01.2021).

[39] Мангушев Т. [«Казан мөхбире»нең ...] // Бәянелхак. 1906. 19 апрель.

[40] Камали З. Мәктүбләр // Нур. 1906. 13 апрель.

[41] Мәңгәрле З. әл-Камали. Мәдинәи Мөнәүвәрә вә мөҗавирлар // Нур. 1906. 17 апрель.

«Бәянелхак» газетасының 1906 елгы 10 август санында Г.Бубиның тагын бер мәкаләсе басылып чыга. Ул анда үз фикерләрен яклап, З.Камалины ялган мәгълүматлар китерүдә гаепли, шәкертләрнең мөдәрристән дә, мәдрәсәдә уку һәм яшәү шартларыннан да канәгать булмаулары турында яза. Кайбер шәкертләр, ди ул, «Харам» мәчете тирәсендәге башка уку йортында уку мөмкинлеге чыгу белән, «Казанлы» мәдрәсәсен ташлап китәләр, ди. Мәдрәсәдән разый булсалар, Мәдинәдәге 50 дән артык татар шәкертенең ни өчен 30 тирәсе генә «Казанлы» мәдрәсәсендә белем ала, дигән сорауны куя. Г.Буби бу фикерләрен 20 шәкерт тарафыннан кул куелган хатка нигезләнеп әйтә. Автор язуынча, әлеге язуда шәкертләр үзләренең яшәү шартларыннан да, дин өлкәсендә тирән гыйлемнәр белән аерылып тормаган Мансур хәзрәтнең укытуыннан да ризасызлыкларын белдерәләр[42].

«Казан» мәдрәсәсе өчен халыктан җыелган акчаларга хисап мәсьәләсе 1910 елда Габделсаттар әфәнде вафат булганнан соң да дәвам итә: «Әллә, Русия мөселманнарының йөз меңнәрчә кылган хәйрат вә иганәләрен, электәге кеби, 5–10 могътәлл (авырулы кеше), паразит вә ялкау мөҗавирләрнең (мәчетнең хуҗалык эшләре белән шөгыльләнүче; мәчет янында хөҗрәдә яшәүче) черегән бугазларына һәдәф (мишень) итеп киттеме икән, дип хәтергә килә. Имде, табигый, шәех әфәнденең соңында калмыш хәлфәсе яки варис вә вәкилләре бардыр. Ихтимал, алар бу хосусда матбугат васитасы илә (аша) хисап вә мөфассаль (җентекле) отчет бирерләр»[43].

«Казанлы» мәдрәсәсе шәкертләренә буш вакытларында башка мәдрәсәләргә барып белем алу мөмкинлеге бирелмәгән. Бу шарт үтәлмәгән очракта, аларны уку йортыннан чыгарганнар. Укуны Мәдинәдәге башка мәдрәсәдә дәвам итү дә мөмкин булмаган, чөнки бу очракта шәкертләрне Казан татарлары өчен махсус мәдрәсәнең булуы сәбәбе белән кире борганнар[44].

1907 елның 15 мартында «Йолдыз» газетасында «Казанлы» мәдрәсәсе шәкертләренең мөселман мәгарифенә реформа ясау һәм үзләре укыган мәдрәсәдәге уку-укыту эшләрен үзгәртеп кору кирәклеге турындагы язмасы басылып чыга. Алар фикеренчә, мәдрәсәдә төрле фәннәрнең нигезләрен укыта торган махсус сыйныф ачу килеп чыккан ситуацияне уңай хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк. Авторлар шулай ук шәкертләр өстеннән карап торучы җаваплы кеше – назыйр билгеләү, мөдәррис итеп белемлерәк педагогны кую мәсьәләсен хәл итү кирәклеген ассызыклыйлар («Хәзерге мәдрәсәдә гыйлемнән әүвәл кадәр хәбәре улмаган бер гади адәм дәрес бирмәктәдер»). Алар

[42] Бубый Г. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Бәянелхак. 1906. 10 август.

[43] Бәкер М. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Йолдыз. 1010. 4 май

[44] Альмушев Х. Хадж-наме. URL: https://idmedina.ru/books/history_culture/hadjj/1/almushev.htm (дата обращения: 12.01.2021).

фикеренчә, сәләтсез, уку белән кызыксынмаган укучыларны мәдрәсәдән чыгару да уку йортында беркадәр тәртип урнаштырырга ярдәм итәчәк[45].

Шулай итеп, XX гасыр башында шәкертләр чит җирдә яшәү һәм уку буенча туган күп кенә проблемаларны үзләре хәл итү юлларын эзләгәннәр. Бу аларның уку-укыту мәсьәләләренә битараф булмаулары, үзләренең гамәлләре өчен җавап тотулары, өлгергәнлекләре турында сөйли.

Алда искә алынган язмаларга нигезләнеп, XX гасыр башында мәгарифне, мөселман белемен яңача шартларга, милләт мәнфәгатьләренә туры китерү, фәнни алгарышка юнәлтү мәсьәләләре шәкертләрне генә түгел, ә киң җәмәгатьчелекне дә кызыксындырган дигән нәтиҗәгә киләбез.

Инде «Казанлы» мәдрәсәсенең эчке һәм тышкы күренешләре, укыту тәртипләре хакында беркадәр сүз алып бару тиештер. Казан татарларының бу уку йорты тулы бер комплекс тәшкил иткән. Мәдрәсә янында мәчет, мәдрәсәнең үз китапханәсе һәм имамнар, мөәзиннәр, назыйрлар яшәү өчен махсус биналар булган. Алар барысы да мәдрәсә акчасына яшәгәннәр[46]. Укыту тәртипләренә килгәндә, баштагы чорда анда программа нигезендә укыту булмый. Х.Әлмүшев сүзләренә караганда, «Баштагы дүрт айда шәкертләр «Мишкәт әл-масабих» укыганнар. 8 ел дәвамында «Мөльтакаль-урбур», «Мәүләви Җами» кебек китапларны өйрәнгәннәр. [...] Укытудагы кимчелекләрне алар камиллеккә тиңлиләр, чын, белемле галимнәрне кертмиләр»[47].

Шулай да, XX гасырның беренче ун еллыгында мәдрәсәдә шактый үзгәрешләр була. Һәм алар нигездә укыту тәртипләренә карый. 1909 елда, мәсәлән, анда нәхү, бәлягать (матур сөйләү һәм язу), гаруз (метрика, шигырь үлчәве), әдәбият гарәбия, ысул фикъһ, хәдис һәм тәфсир фәннәре укытылган, шул фәннәр буенча ачык имтиханнар уздырылган. Гәрчә бик төзек программа нигезендә укытылмаса да (шәкертләр хәбәр итүенчә, киләсе 1910 елдан программа кабул ителергә тиеш), имтиханнар булуы мәдрәсәнең заманчалык принцибына иярергә тырышуы хакында сөйли, чөнки моңа кадәр Мәдинәи Мөнәүвәрәдә тәртип нигезендә укыту һәм имтиханнар ысулы күзәтелмәгән[48].

Мәдрәсәдә төрле елларда Бөре өязе Мортаза авылыннан Шакир әфәнде[49], әл-Вәдүди Мөхәммәтфатих бине Җиһангир[50], сәед Шәриф[51], Мансур

---

[45] Мәдинәи Мөнәүвәрә шәкертләре // Йолдыз. 1907. 15 март.

[46] Юлдаш. Казанлы мәдрәсәсе // Вакыт. 1906. 17 октябрь.

[47] Альмушев Х. Хадж-наме. URL: https://idmedina.ru/books/history_culture/hadjj/1/almushev.htm (дата обращения: 12.01.2021).

[48] Идарәгә мәктүб // Йолдыз. 1909. 6 сентябрь.

[49] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 297.

[50] Мәдинә шәһәрендәге «Казани» мәдрәсәсе шәкерте Мөхәммәдфатыйх Җиһангир улыннан Гариф муллага хат // Алдым каләм, яздым сәлам...: хатлар / төз. Р.Ф.Мәрданов. Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2018. Б. 72.

[51] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 297.

әфәнде (мәдрәсәне тәмамлаганнан соң шунда укытырга калдырыла) һ.б. белем ала.

Кемнәрдер бу мәдрәсәгә укыр өчен махсус килгәннәр, шулай ук хаҗ вакытында әлеге уку йорты белән танышып, шунда калучылар да булган. Гомумән алганда, Хиҗазда, мәдрәсәләрдә укыган шәкертләрдән тыш, хаҗ вакытында тоткарланып, аерым галимнәрдән һәм остазлардан белем алган кешеләр дә була[52]. Хаҗ сәфәренең ул заманда ике-өч елга сузылуын истә тотканда, бу вакыт эчендә җитәрлек дәрәҗәдә гыйлем туплау мөмкинлеге булуын күз алдына китереп була. Алар арасында Р.Фәхретдиннең остазы, «Сахих әл-Бохари» буенча иҗазәт алган Габделфәттах әш-Шәлчәли[53], Хәмидулла Әлмүшев һ.б. була. Әлмүшев хаҗ сәфәре вакытында татарлар укыган мәдрәсәләрдә була, шундагы атаклы галимнәр белән аралашып, белемен арттыра[54].

Бу мәдрәсә һәм аның тарихы, бигрәк тә финанс мәсьәләләре вакытлы матбугат битләрендә шактый тулы яктыртылса да, гомумән алганда, андагы шәкертләр, мөдәррисләр һәм башка педагоглар, укытуның эчтәлеге һ.б. буенча төгәл мәгълүматлар юк диярлек. Галимнәрнең исәпләүләре буенча, XIX гасырда Мәккә һәм Мәдинә кебек изге шәһәрләрдә яшәгән Казан татарларының саны шактый булган[55], һәм аларның күпмедер өлешен шәкертләр тәшкил итүе бәхәссез. «Йолдыз» газетасында дөнья күргән язмага караганда, «Казанлы» мәдрәсәсендә татар мөдәррисләреннән тыш, җирле гарәп педагоглары да дәрес биргән[56]. Р.Фәхретдин хезмәтләренә һәм вакытлы матбугат материалларына таянып кына бу мәсьәләгә ачыклык кертүче кайбер мәгълүматлар белән танышырга мөмкин. Мәсәлән, Р.Фәхретдин «Казанлы» мәдрәсәсендә укыткан Мөхәммәт Гали бине Заһир әл-Үтәрине (1845–1904) искә ала. Ул 1895–1896 елларда Россиядә – Бохара, Сәмәрканд, Әстерхан, Казан һәм Уфа шәһәрләрендә эшлекле сәфәре белән билгеле Мәдинә галиме. Уфада әл-Үтәри Мәрьям Акчурина йортында туктала[57]. Бу сәяхәте вакытында ул татарның атаклы галимнәре һәм аларның хезмәтләре белән таныша, татарларга булган ихтирамы арта. Соңгысы аның үзенең Россиядән шәкертләре

[52] Гатин Р. Особенности дореволюционного зарубежного образования мусульман Поволжья. URL: https://islamnews.ru/2023/5/29/osobennosti-dorevolyutsionnogo-zarubezhnogo-obrazovaniya-musulman-povolzhya

[53] Фәхретдин Р. Гыйльме хәдистән көтебе ситтә вә мөәллифләре Оренбург: Вакыт, 1910. Б. 53.

[54] Энциклопедический словарь «Ислам на Нижегородчине». URL: https://idmedina.ru/books/encyclopedia/?794 (дата обращения: 11.01.2021).

[55] Кылынч А. Идел-Урал татарларының Госманлы җирләренә XIX гасырның 70 нче елларына кадәрге күчешләре // Чын мирас. 2012. № 5–6. Б. 58.

[56] Идарәгә мәктүб // Йолдыз. 1909. 6 сентябрь.

[57] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 284–286.

артуга китерә[58]. Мөхәммәт Гали бине Заһир «Сахих әл-Бохари», «Сахих Мөслим», «Мишкәт әл-масабих» кебек дәресләрне укыткан[59]. М.Гаджиев әл-Инчхи мәгълүматларына караганда, шәехнең рухи варислары арасында татар шәехе Мөхәммәт Салих бине Габделхалик әл-Кирмәнхани да булган[60]. Шәкертләр арасында Мөхәммәтгали әз-Заһирда белем алуны максат итеп мәдрәсәне сайлаучылар да күзәтелгән. Алда искә алынган Хәмидулла Әлмүш, мәсәлән, хаҗ сәфәре вакытында «Казанлы» мәдрәсәсенә килеп, әлеге остаздан дәресләр алган[61].

Мәдрәсәдә шулай ук чыгышы белән Казан губернасы Чистай өязе Корманай авылыннан Мулла Әхмәт хәзрәт тә була. Ул бирегә улы белән Әфганстан аша килә. Мәдинәдә аның металл эшкәртү белән бәйле үз бизнесы булуы билгеле. Бүгенге көндә аның варислары Мәдинә шәһәрендә яшиләр[62].

1906 елда мәдрәсәдә 30–36 тирәсе шәкерт укыган[63]. Мәдрәсә шәкерте Мөхәммәтфатих бине Җиһангир әл-Вәдүди мәгълүматларына караганда, 1910 елда мәдрәсәдә яшәү һәм уку өчен шартлар шактый әйбәт була[64].

1906–1907 елларда хаҗ сәфәрендә вакытта Буа мәдрәсәсе мөдәррисе Нургали Хәсәнов «Казанлы» мәдрәсәсенә килә һәм андагы остазлар белән күрешә, бу хакта үзенең сәяхәтнамәсендә язып калдыра[65]. Мәдинә шәһәренә баргач, Р. Фәхретдин дә әлеге мәдрәсә белән таныша, акча мәсьәләсе тыгызрак булу сәбәпле, уку йорты бинасының шактый таушалган булуы турында хәбәр итә[66].

Татар шәкертләре шөгыльләнгән китаплар, дәреслекләр соңрак Мәдинә шәһәрендәге Ислам университетының китапханәсенә тапшырыла, биредә «Казан мәдрәсәсе» дигән махсус бүлек оештырыла. Мәдрәсә бинасы бүгенге көндә сүтелгән[67].

---

[58] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 300.

[59] Шунда ук. Б. 305.

[60] Гаджиев аль-Инчхи М. Мухаммад Али бин Захир аль-Витри. Электронный ресурс. URL: https://as-salam.ru/news/1505/ (дата обращения: 10.04.2023).

[61] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 304–305.

[62] Согуд Гарәбстанындагы Пәйгамбәр мәчете янында татар җире табылды. URL: https://atnya-rt.ru/news/mgyiyat/sogud-garbstanyindagyi-pygambr-mchete-yanyinda-tat (мөрәҗәгать итү датасы: 12.03.2021).

[63] Бубый Г. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Бәянелхак. 1906. 17 май.

[64] Мәдинә шәһәрендәге «Казани» мәдрәсәсе шәкерте Мөхәммәдфатыйх Җиһангир улыннан Гариф муллага хат // Алдым каләм, яздым сәлам...: хатлар / төз. Р.Ф.Мәрданов. Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2018. Б. 72.

[65] Амишов Р.И. Паломничество в Мекку богослова Нургали Хасанова (1852–1919) // Minbar. Islamic Studies. 2022. №15(1). С. 44.

[66] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 538.

[67] Согуд Гарәбстанындагы Пәйгамбәр мәчете янында татар җире табылды. URL: https://atnya-rt.ru/news/mgyiyat/sogud-garbstanyindagyi-pygambr-mchete-yanyinda-tat (мөрәҗәгать итү датасы: 12.03.2022).

Хиҗаз уку йортлары, аерым алганда «Казан мәдрәсәсе», гасырлар чигендә татар шәкертләренең генә түгел, гомумән татар җәмәгатьчелегенең күз уңында торган. Аларны тәмамлап кайтучыларны ватанда зур өметләр баглап көтеп торганнар.

* * *

Тикшеренү нәтиҗәләре мөселман Көнчыгышы илләрендә белем алуның татар мәгарифе үсешенә өлеш керткән зур, гасырларга сузылган, берничә дәверне үз эченә алган тарихы булган дигән фикерне тагын бер кат расларга мөмкинлек бирә. Әлеге дөньякүләм билгеле белем учакларында уку татар яшьләренең дини, ислам белеме, лингвистик, тарихи һәм педагогик белемнәре камилләшүгә юл ачкан, аларның киләчәктәге һөнәри күзаллаулары формалашуга ярдәм иткән. Ватаннарына кайтканнан соң, алар үз өммәтенә, диненә хезмәт итү юлын сайлаганнар, халкыбызның киләчәген тәэмин итүне максат иткәннәр, үз юнәлешләрен, мәктәпләрен булдырганнар, алган белемнәренә нигезләнеп, үз мәдрәсәләрен ачканнар, яшь буынны милли-дини рухта тәрбияләгәннәр. Бик күпләре галим булып җитешкәннәр, остазларыннан алган белемнәрен файдаланып, тарих, дин нигезләре, гарәп теле буенча фәнни хезмәтләр язганнар, дәреслекләр төзегәннәр. Болар барысы да татар мәгарифенең үсешенә, алгарышына уңай йогынты ясаган.

Дагыстан, Бохара, Каһирә, Мәдинә, Мәккә, Истанбул, Деобанд һ.б. шәһәрләрдәге атаклы уку йортларында уку аларның дини фикерләүләре һәм гыйлемнәре генә түгел, гомумән дөньяга карашлары формалашуга да зур өлеш керткән. Башка илләр, башка милләтләр һәм мәдәниятләр белән танышу киңрәк, масштаблырак фикерләүгә юл ачкан, яшьләрнең шул заманның ислам кыйммәтләрен үзләштерүләренә ярдәм иткән, барлык ислам дөньясы өчен уртак булган проблемаларны күрергә, үзара хезмәттәшлекне һәм аралашуны җәелдерергә мөмкинлек биргән. Дөньякүләм билгеле остазлардан белем алу, аларның хезмәтләрен өйрәнү, китаплар һәм китапханәләр белән танышу дини белем һәм тәрбия бирү мәсьәләләренә глобальрәк, киңрәк мәсләктән чыгып карарга мөмкинлек биргән. Болар барысы да, бер яктан, татарларның дини-милли берлеген саклап калырга ярдәм итсә, икенче яктан, аларга башка илләр белән бәйләнешләрне ныгытырга, чит мәдәниятләргә, телләргә юл ачкан.

# ТАТАР ШӘКЕРТЛӘРЕ ДӨНЬЯВИ БЕЛЕМ ЭСТӘҮ ЮЛЫНДА

*«Үз милләтемезнең яшәргә тырышуы, үз эшен үзе эшли алуы, хәят мәйданында изелеп калмавы өчен Аурупаның голүм вә мәгарифенә, һөнәр вә сәнәгатенә зур ихтыяҗымыз бар. Аурупаның мәктәпләрендә укымак – безнең өчен файдалы. Һөнәр вә мәгариф кайда булса, шунда барып тәхсил итәргә кирәк. Гыйлем берлә мәгарифнең хас ватаннары, хас лисаннары юк»*

(Шиһабетдин Мәрҗани)

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Европада, Россиядә барган үзгәрешләр татарлар арасына да үтеп керә. Бу үзгәрешләр иң беренче чиратта сәнәгать, сәүдә-икътисади, иҗтимагый фикер үсешендә чагылыш таба. Яңача шартларда эшли алырлык, дөнья казанышлары белән таныш булган белгечләргә ихтыяҗ арту укыту-белем системасы алдына да яңадан-яңа бурычлар куя. Европа мәдәниятенә якынаю һәм яшәешнең барлык өлкәләрендә заманчалык таләпләренә туры китереп үзгәртеп кору татар мәдрәсәләрендәге традицион укыту методларын яңартудан башлана. Билгеле булганча, бу чорда мәгариф өлкәсендәге яңарышның нигезен җәдитчелек хәрәкәте һәм яңа ысуллар кулланып укыту тәшкил итә. XX гасыр башында Идел-Урал төбәгендәге мәктәп һәм мәдрәсәләрнең күпчелек өлеше җәдитчә укытуга күчә, аларда дөньяви фәннәр буенча белем бирүгә зур әһәмият бирелә.

Татар зыялылары милләтне үстерү, аны шул заманның алдынгы Европа дәүләтләре дәрәҗәсенә күтәрүне аң-белем тарату, халыкны белемле итү, мәктәп-мәдрәсәләрне үзгәртү, китап бастыруны җайга салу, вакытлы матбугат булдыру аша алып бару фикерен күтәреп чыгалар[1]. Заманча белем бирүне тормышка ашыру максатында татар яшьләрен укыту өчен яхшы мәктәп-мәдрәсәләр ачу (1916 елда Казанда Ф.Аитова тарафыннан кыз балалар өчен гимназия ачыла), дәүләт мәктәпләренә кереп уку мөмкинлеген эзләү (татарлар өчен махсус урта һөнәри уку йортлары ачу омтылышы һ.б.), югары уку йортларына керү мәсьәләләрен хәл итәргә тырышу (гимназияләргә кереп уку

[1] Галләмова Ә.Г., Заһидуллин И.К., Фәхретдинов Р.Р. Татарстан һәм татар халкы тарихы. XIX гасыр – XX гасыр башы: 9 сыйныф: Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. Казан: Тат. бал. нәшр., 2019. Б. 76.

яисә экстерн рәвештә имтиханнар тапшырып аттестат алу) кебек эш-гамәлләр үтәлә.

Татар мәктәп-мәдрәсәләренә дөньяви фәннәрне, шул исәптән рус телен укытуны кертүне К.Насыйри, Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин кебек галимнәребез яклап чыга. Рус телен укытуга каршы булган юнәлеш вәкилләре аны милләтне христианлаштыру коралы итеп күрәләр. 1870 елның 26 мартында кабул ителгән «Россиядә яшәүче рус булмаган халыкларга белем бирү чараларына кагылышлы кагыйдәләр» нигезендә шул елдан соң ачылган мәктәп-мәдрәсәләр каршында рус сыйныфлары оештырылу карала, мәҗбүри рәвештә рус теле укыту кертелә, рус-татар мәктәпләре ачыла башлый. 1876 елда КТУШ (Казан укытучылар мәктәбе) эшли башлый, аны тәмамлаучылар арасыннан киләчәктә милли мәдәният, әдәбият, мәгариф үсешенә зур өлеш кертәчәк зыялылар катламы тәрбияләнеп чыга. Рус телен укыту яклылар рус телен өйрәнү татарларның күзаллауларын һәм мөмкинлекләрен киңәйтәчәк, рус һәм Европа мәдәнияте белән танышу, дөньяви белем үзләштерүгә юл ачачак дип саныйлар.

Татарлар өчен дөньяви белем бирүче рус уку йортларына – гимназия, университетларга кереп уку зур кыенлык тудырган. XIX гасыр дәвамында мондый уку йортларын тәмамлаган татар яшьләре бармак белән генә санарлык булган. Әйтик, Казан университетын 1835 елда оренбурглы Гайсә Бикмиев, 1836 елда Салихҗан Күкләшев, уфалы Сәйфулла Тукумбетов (өчесе дә филология белгечлеген үзләштергәннәр) бетергән, 1838–1855 елларда медицина факультетын тагын 12 кеше[2] тәмамлап чыккан[3]. Студентлар арасында М.Х.Сәйфуллин (1838) – татарлардан беренчеләрдән булып табиб дипломын алган кеше, М.Исмәгыйлев һ.б. бар[4]. 1856–1858 елларда Петербург, Киев университетларына кереп укучы татар яшьләре дә була. Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә дә беркадәр татар балалары күренә, әмма аларның барысының да морза яисә обер-офицер гаиләләреннән чыгуларын, димәк матди яктан бәйсез һәм кайберләренең килгән урыннарыннан җибәрелгән стипендия хисабына укуларын истән чыгарырга ярамый[5]. Мөселман руханиларының балаларны рус мәктәпләрендә укытуга, рус телен өйрәтүгә карашлары тискәре була. Шуңа да карамастан, морзалар белән беррәттән, баеп киткән татар эшмәкәрләре арасында да рус мәдәниятенә якынаю күренеше

[2] И.Рәми аларның милләтләрен билгеләүнең кыен булуын, мөган араларында һәм татар, һәм башкорт милләте вәкилләре булуы мөмкинлеген искәртә (Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. Б. 331).

[3] Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. Б. 330–331.

[4] Рәми И. Мәдрәсәдән – университетка // Казан утлары. 1966. №3. Б. 134–135.

[5] Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. Б. 327–331.

күзәтелә башлый[6]. Я.Г.Абдуллин фикеренчә, татарлар арасыннан рус уку йортларына кереп укый алган берән-сәрәннәрнең үз милләте белән бәйләнеше бик аз була, һәм алар милләтнең мәдәни алга китешенә, алгарышына тәэсир итәрлек дәрәҗәдә булмый. Аларны хөкүмәт, күпчелек очракта, үзенең Көнчыгыштагы сәясәтен тормышка ашыруда ярдәм итүче рәсми түрәләр итеп күргән[7]. XX гасыр башында инде вазгыfive башкачарак булган, дәүләти уку йортларын тәмамлаучыларның күпчелеге милләт мәнфәгатьләрен яклауны беренче урынга куйган.

XIX гасыр дәвамында татар мәгърифәтчеләренең, галимнәренең татар мәгарифен үзгәртеп кору, реформа ясауны максат иткән, Европа тибындагы урта мәктәп ачу буенча дистәгә якын проекты тәкъдим ителә, иң мәгълүмнәре – Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, Р.Фәхретдин проектлары[8]. Мисал өчен, Х.Фәезханов проекты Казанда Европа мәктәпләре үрнәгендә зур бер мәдрәсә ачуны күздә тота. Әлеге уку йорты, автор уенча, казна хисабына яшәргә тиеш. Анда 60–70 шәкерт укыячак, моннан тыш ирекле тыңлаучылар да булырга мөмкин. Бу мәктәптә дөньяви фәннәр дә, дини белемнәр дә өйрәтелә, гарәп, фарсы, рус, татар, европа телләре укытылырга тиеш. Шәригать белеме гарәп телендә, география, табигать фәннәре рус телендә, калганнары татар телендә укытыла. Мәктәпнең башлангыч сыйныфларында төрки, фарсы, гарәп, рус телләре, география, геометрия, кыйраәт (уку) укытыла, аннан соң шәкертләр белем алуларын ике бүлекнең берсендә – ислам бүлегендә яисә дөньяви бүлектә дәвам итәләр. Беренче бүлектә бик тирәнтен итеп шәригать фәннәре, гарәп, фарсы телләре, медицина һ.б. предметлар укытылса, икенче бүлек русларның гимназиясе күләмендә белем бирә, һәм аны тәмамлаган укучылар, һичшиксез, белем алуларын университетларда дәвам итә алачаклар, шулай итеп татар милләтенең алгарышына ярдәм итәчәкләр. Ләкин, кызганычка каршы, бу проект, башкалары кебек үк, тормышка ашмый – хөкүмәт тарафыннан кире кагыла. Шулай итеп, үз милли дөньяви мәктәбен ачу татар зыялыларының бары тик хыялы булып кына кала. Ләкин илдәге сәнәгать, мәдәният өлкәсендә күзәтелгән алгарыш татар дөньясында да чагылыш таба, татарлар арасында да заманча шартларга җавап биргән, фән һәм сәнәгать үсешенә туры килерлек белемнәргә ия булган белгечләргә ихтыяҗ артканнан-арта бара.

1880 нче елларда И.Гаспралы Россия мөселман җәмгыятен милли-төбәк традицияләрен саклауга нигезләнгән Европа моделе нигезендә үзгәртеп коруны тәкъдим итә. Ул дини тәрбия һәм туган телендә башлангыч белем алган балаларны рус уку йортларына бирү фикерен алга сөрә. Ш. Мәрҗани кебек, ул да иң беренче таләп итеп туган телне һәм иман нигезләрен белүне

[6] Габдрафикова Л.Р. Татарское буржуазное общество (втора половина XX – начало XX века). Казань: Татар.кн.изд-во, 2015. С. 42.

[7] Абдуллин Я.Г. Татарская просветительская мысль (Социальная природа и основные проблемы). Казань: Татар.кн.изд-во, 1976. С. 49.

[8] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. Казан: Татар.кит.нәшр., 1997. Б. 154.

куя, бары тик шул очракта гына милли үзаң тәрбияләп булачагын ассызыклый. «Ислам дөньясы һәм динилек», аның карашынча, бары тик фән һәм мәгариф аша гына үсешкә ирешә алачак. Милли мәктәптә телләр (туган, рус һәм чит тел) өйрәнү киләчәктә европача белемнәргә юл ачачак[9].

Беренче Россия революциясеннән соң, җәмгыятьтәге демократлаштыру процессы моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә күзәтелә, нәтиҗәдә рус уку йортларына керергә теләүчеләрнең саны бермә-бер арта.

Классик гимназия, башка кайбер өстенлекле мәктәпләрдә белем алган, рәсми шәһадәтнамәгә ия булганнар укуларын югары уку йортларында дәвам итә алганнар. Татарлар өчен махсус һөнәри-урта белем бирү мәктәпләре ачу мәсьәләсе күтәрелсә дә, бу проблеманы хәл итү бик авыр була. Моны Казан шәһәрендә С.А. Сметанинның мөселманнар өчен сәүдә мәктәбе ачу юлында кылган эш-гамәлләре мисалында ачык күрергә мөмкин. Рәсми документлары, программасы һәм дәлилле проекты булуга карамастан, хөкүмәт тарафыннан әлеге мәктәпне ачарга рөхсәт бирелми. Мондый мәктәп күпмедер вакыттан соң Петербург шәһәрендә ачыла, әмма аның эшчәнлеге ни дәрәҗәдә уңышлы һәм дәвамлы булуы билгесез. Татарлар, төрле юлларын эзләп, рус телендә укытыла һәм православие дине нигезләре буенча белемнәр бирә торган сәүдә мәктәпләренә кереп укуларын дәвам итәләр. Әлбәттә кайбер мәктәпләрдә мөселманнар өчен ислам дине дәресләре кертү мәсьәләсе дә күтәрелә, кайбер проектлар хәтта тормышка да аша. Әмма, тулаем алганда, болар гына проблеманы тулысынча хәл итә алмый[10].

Дәүләт уку йортларында белем алырга теләүче татар яшьләре өчен каршылыклар күп була. Садри Максудиның, мәсәлән, 1901 елда Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаганнан соң, Петербург университетына укырга керергә ниятләве билгеле, тик рус булмаган халыкларга карата империя сәясәте киртәләренә юлыгып, бу хыялы тормышка ашмый[11]. «Тәрҗеман» газетасы исә, төп сәбәп итеп аның әлеге уку йортына керер өчен белем дәрәҗәсе җитеп бетмәүне күрсәтә[12]. Бакчасарайга «рухи атасы» Исмәгыйль Гаспралы белән күрешергә баргач, Садри аңа үзенең Төркиягә китеп белем алырга теләве хакында әйтә, Гаспралы исә егеткә Европада, Парижда укырга киңәш итә: «Ара-тирә “Тәрҗеман”га мәкаләләр язарсың, мин дә гонорар җибәргәләрмен, сине ач тотмабыз», – ди, шул рәвешле яшь

[9] Загидуллин И.К. Татарское национальное движение в 1860–1905 гг. Казань: Татар.кн.изд-во, 2014. С. 51.

[10] Бу хакта тулырак түбәндәге мәкаләдә танышырга мөмкин: Муртазина Л.Р. К вопросу об истории развития коммерческого образования среди мусульман России в начале XX века // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2023. № 2. С. 22–36.

[11] Гайнанова М. Низаметдин хәзрәт улы Садри Максуди: беренче адымнар // Садри Максуди: фәнни-популяр җыентык / авт-төз. Гайнанова М.Р. Казан: «Җыен», 2023. Б. 22.

[12] [Мы слышали, что...] // Тәрҗеман – Переводчик. 1901. 24 август.

егеткә ярдәм кулын сузарга теләвен белдерә[13]. 1902 елда С.Максуди, Европа мәдәнияте белән ныграк танышу максаты белән, Төркиягә килә. Биредә ул француз, латин телләрен өйрәнә. Төрек зыялысы Әхмәт Мидхәт тә сәләтле яшь егеткә, Гаспралы кебек үк, белемен үстерү өчен Европага барып укырга киңәш итә[14]. Шулай итеп, Садри Максуди, рухи остазларының хәер-фатихасын алып, Парижга китә һәм Сорбонна университетының хокук (юридик) факультетына укырга керә.

Мәсьәләнең шактый четрекле булуына карамастан, XX гасырның унынчы елларында югары белем алучы татарлар саны сизелерлек арта. 1913 елда 26 татар укыган Казан университетыннан тыш, хәлле гаиләләрдән чыккан яшьләр Санкт-Петербург, Мәскәү, Киев шәһәрләрендәге югары уку йортларына кереп белем алалар[15]. Мисал итеп, 1911–1912 елларда Киевта Учительская семинариядә укыган Мостакаев Габделкаюм Габдрәхим улын (1885 – ?, Хвалын өязе Иске Зеленай авылыннан)[16] күрсәтергә мөмкин.

Югары уку йортларына кереп укыган татар яшьләренә диплом алып чыкканнан соң да каршылыклар туып тора. Мәсәлән, «Вакыт» газетасы 1914 елда Петербургта хокук шөгъбәсен (факультетын) тәмамлап шәһадәтнамә алган Хәсән Сабировның Ташкент хөкем (судебная) палатасына хезмәткә керү өчен язган гаризасынына Гаделия (Юстиция) министры тарафыннан рөхсәт бирелмәгәннән соң, Дәүләт банкына урнашырга теләве, әмма анда да «Мөселманны ала алмыйбыз», – дигән җавап алуы хакында хәбәр итә. Бичара егет, белгечлеге буенча бер җиргә дә эшкә урнаша алмагач, кабат Петербурга китеп, яңа һөнәр үзләштерергә – Авыл хуҗалыгы институтына укырга керергә карар кыла[17].

Илдәге вазгыять татарларны ватаннан читтә белем алу мөмкинлекләрен эзләргә этәрә. Педагог Каюм Насыйриның «Россиянең үзендә генә дә безгә җитәрлек гыйлемлек бар. Россиядә барында ни өчен заграницага барырга кирәк. Без Россия кешесе. Бу Россиядә булган нәрсә безгә җитә», – дип язуына карамастан[18], чынлыкта илдә урта һөнәри һәм югары белем алу өчен мөмкинлекләр бик чикле була. Бу чикләр, башка сәбәпләр белән беррәттән, рус телен камил белү мәҗбүрилеге, рус мәктәпләрендә православие дине нигез-

---

[13] Гаффарова Ф.Ю. Садри Максуди. Казан: ДАС, 2001. Б. 168.

[14] Әмирхан Р. Максатка тугры Максуди // Казан утлары. 1999. №5. Б. 154.

[15] Галләмова Ә.Г., Заһидуллин И.К., Фәхретдинов Р.Р. Татарстан һәм татар халкы тарихы. XIX гасыр – XX гасыр башы: 9 сыйныф: Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. Казан: Татар балалар нәшр., 2019. Б. 76.

[16] Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Псевдонимы в татарской литературе / төз.: Л.Ш.Гарипова, Г.Н.Зәйниева. Казан: ТӘһСИ, 2021. Б. 118.

[17] Мөхбир. Кабул ителмәү // Вакыт. 1914. 3 сентябрь.

[18] Насыйри К. Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы // Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. 2 томда. Т.1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. Б. 53.

ләре, латин теле кебек предметлар укытылу һ.б. белән дә бәйле. Мәсьәләне хәл итүнең бер юлы буларак Төркия уку йортлары карала: «Рус мәктәпләрендә мөселманча тел вә дин дәресләренең булмавыннан яисә азлыгыннан курыккан вә балаларын голүм вә фөнүн (фәннәр) өстенә, үз тел вә динемез илә ислам дине күләгәсендә тирәнрәк мәгълүматлы итеп чыгарырга теләгән кешеләргә Истанбул мәктәпләре дә бик һәйбәт. Аларда рус мәктәпләрендәге кебек фәннәр укытыла, төрле мәгълүмат бирелә»[19]. Ләкин бер уңайсыз ягы бар – гәрчә биргән белемнәре ныклы һәм һәр җирдә файдаланырга мөмкин булса да, Төркия мәктәпләрен тәмамлау турындагы «шәһадәтнамәләре Россиядә рәсми эш күрергә ярамый»[20]. Алар нигездә татар мәдрәсәләрендә эшләгәннәр. Төркиядә уку татарлар өчен яңа күренеш булмаса да, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында ул үзенчәлекле бер яңарыш кичерә.

XIX гасыр ахырларында заманча, дөньяви гыйлем алырга теләгән татар яшьләренең чит илләргә омтылуы һәм шундагы уку йортларына кереп белем алырга тырышулары да, беренче чиратта, ватанда мондый белем алуның чикле булуы белән бәйле. Әлбәттә, инде күренгәнчә, Россиядән читтә белем алу тәҗрибәсе татарлар өчен ят түгел. Ләкин моңарчы ул нигездә дини белем алу белән бәйле була. Дөньяда, аерым алганда Европада, фән-техника, сәнәгать өлкәләрендә барган яңарышлар мәгариф үсешенә дә көчле йогынты ясыйлар. Бу үзенчәлекләр Россиягә дә үтеп керә, әлбәттә. Сәнәгатьнең алга китүе сәбәпле, алдынгы технологияләрне үзләштергән, техника, җитештерүнең төрле өлкәләренә караган яңалыклардан хәбәрдар булган белгечләргә ихтыяҗ бермә-бер арта. Элеккечә эшләү, нигездә кул хезмәтенә таянып кына җитештерүчәнлекне арттыру мөмкин булмавын татар эшмәкәрләре дә яхшы аңлый. «Мөлкәт ияләренә дөньяви гыйлемнең билгеле бер дәрәҗәсенә ия, производствоны киңәйтеп, эшне практик яктан алып барырлык кешеләр, кадрлар кирәк була»[21]. Бер яктан, бу хәл татар хәйриячеләрен татар мәктәбен үзгәртеп коруга, җәдиди белем системасын ныгытуга юнәлдерсә, икенчедән, әлегә татарның үз милли югары мәктәбе булмау сәбәпле, яшьләрне башка илләргә җибәреп, яңа технологияләрне өйрәнеп кайтуларына матди ярдәм итүләренә этәрә. Нәкъ шуның нәтиҗәсендә татарлар арасында заманча укуга, фәннең төрле өлкәләренә, бигрәк тә техника һәм сәнәгатькә караган белемнәргә ихтыяҗ арта. Әлбәттә, проблеманы хәл итүнең гамәли юлын сайлаучылар да була. Мәсәлән, Казан өязе Юртыш авылының эшмәкәре, шырпы заводы хуҗасы Шакир Хәмитовның әле XX гасырның беренче елларында ук яңа технологияләрне өйрәнү, ягъни стажировка өчен дөньяви белеме булмаган улы Гарифны Европа илләренә җибәрүе билгеле. Шырпы җитештерү

[19] Русия вә Истанбул мәктәпләрендә укыту // Вакыт. 1909. 16 июнь.

[20] Шунда ук.

[21] Әмирхан Р. Татар мәгарифе тарихыннан // Р.Әмирхан. Иманга тугрылык. Казан: Татар.кит.нәшр, 1997. Б. 158.

серләрен ул башта Австриядә, аннан соң Швейцариядә үзләштерә, соңыннан шырпы заводлары өчен җиһазлар ясау үзәге булган Германиягә килеп, үзенә кирәкле техникага заказ биреп, бер үк вакытта телләр өйрәнеп, кире үз авылына әйләнеп кайткан. Мондый рәвештә белем үзләштерүчеләр Европада университетларда укымаганнар, әмма төрле завод-фабрикаларда булып, җитештерүнең алдынгы ысулларын практик рәвештә өйрәнгәннәр, яңа техника белән танышканнар. Яңа тәр, заманча машиналарны куллану моңарчы нигездә кул эшенә генә корылган кече заводларга яңа сулыш өргән, алар яңача эшләп киткән, яңа биналар төзелгән, хезмәт җитештерүчәнлеге бермә-бер арткан, җитештергән продукциянең (бу очракта шырпының) сыйфаты яхшырган, бәясе төшкән, авыл кешесенә яңа эш урыннары булдырылган. Тагын бер яңалык – завод моңарчы кеше сәламәтлеге өчен заралы булган фосфор кулланудан баш тартып, яңа технология нигезендә зарарсыз продукция чыгара башлый[22].

Мәшһүр галимебез һәм мәгърифәтчебез Шиһабетдин Мәрҗанинең шундый сүзләре билгеле: «Үз милләтемезнең яшәргә тырышуы, үз эшен үзе эшли алуы, хәят мәйданында изелеп калмавы өчен Аурупаның голүм вә мәгарифенә, һөнәр вә сәнәгатенә зур ихтыяҗымыз бар. Аурупаның мәктәпләрендә укымак безнең өчен файдалы. Һөнәр вә мәгариф кайда булса, шунда барып тәхсил итәргә (белем алырга) кирәк. Гыйлем берлә мәгарифнең хас ватаннары, хас лисаннары (телләре) юк»[23]. Бу факт чын мәгънәсендә мәшһүр галим, көчле дин белгече, бик төпле дини гыйлем алган Мәрҗанинең заман вазгыятен яхшы аңлап, татар милләтенең үсешен һәм киләчәген аның дини һәм бер үк вакытта дөньяви белем алуда икәненә башкаларны да төшендерергә тырышуы, моңа юллар күрсәтүе турында сөйли. Үз сүзләрен тагын да ныгытып, ул шәкертләренә чит илләргә барып укырга киңәш биргән.

Чит мәмләкәтләрдә белем алучыларның күбәюе татар халкының да яңа, индустриаль үсеш чорына аяк басуы, шул сәбәпле дөньяви белем үзләштергән белгечләргә ихтыяҗның артуы белән бәйле. XIX гасыр ахырларында Россиядән китеп, чит илләрдә дөньяви гыйлем үзләштерүчеләрнең саны бармак белән санарлык кына булса, XX гасыр башында, аеруча 1905–1907 елгы революциядән соң, чит илләрдә урта һөнәри һәм югары белем алырга теләүчеләр бермә-бер арта.

Дөньяви белем алу, югары һөнәри белемнәр үзләштерү милләтнең алгарышы өчен иң әһәмиятле шартларның берсе буларак карала. Муса Бигиев, мәсәлән, милләт яңача, заманча белемнәргә мохтаҗ дип саный, һәм моны

[22] Мортазина Л. Татар шырпы заводлары // Безнең мирас. 2019. №9. Б. 20–23.

[23] Гобәйдулла углы Габдулла. Олуг галимебез шәех әл-Мәрҗани хәзрәтләре хакында хатирәләрем // Мәрҗани: Шиһабетдин әл-Мәрҗанин хәзрәтләренең вилядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәте илә нәшер ителде. Казан: «Мәгариф» матб., 1915. Б. 528.

тормышка ашыру өчен яшьләрне рус уку йортларына һәм Европа көллиятләренә укырга җибәрергә кирәк, ди[24].

Гомумән алганда, чит ил уку йортларында белем алу күренеше бу чорда Россиядә яшәүче күп милләтләр – руслар, яһүдләр, әрмәннәр арасында киң таралган була. Чит илдә укырга омтылышның төп сәбәпләренең берсе, галимнәр билгеләвенчә, ватанда югары уку йортына кергәндәге каршылыкларның булуыннан гыйбарәт: Россия уку йортларына имтиханнарсыз бары тик классик гимназия һәм берникадәр өстенлекле мәктәпләрне тәмамлаучылар гына керә алган. Реаль училище, сәүдә, техник училище дипломнарына ия булган яшьләр мондый хокукка ия булмаганнар. Укырга керү өчен алар экстерн рәвештә гимназия курсы буенча имтихан тапшырырга тиеш булалар. Икенче бер сәбәп дәүләт югары уку системасының тиешле дәрәҗәдә үсеш алмавы (аерым белгечлекләр буенча уку йортлары булмау яки бик аз булу һ.б.) белән бәйле. Шулай итеп, теге яки бу белгечлек буенча белем эстәргә теләге булганнар чит ил уку йортларына юл тотканнар[25].

Гомумән алганда, Россиядә архитектура-төзелеш, сәнәгать һ.б. җитештерү төрләре буенча белгечләрнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы сәбәпле, аларны Европадан чакыру традициясе күптәннән була. Россиялеләрнең үз араларыннан шундый белгечләр әзерләүне европалылар үзләренә Россиядә эшләү өчен каршылык тудырырга мөмкин булган шарт буларак күрәләр[26]. «Вакыт» газетасында басылган мәкалә авторы әлеге вазгыятьнең Россиянең үз эчендә, татарларга нисбәттә кабатлану мөмкинлеген күрә. Аның фикеренчә, мөселманнар арасында европача белем алган зыялылар күбәйсә, рус зыялылары аларны үз урыннары өчен низагъ итүчеләр итеп күрергә мөмкиннәр. Шуңа да булдыра алганча тырышлык куеп, мөселманнар арасыннан зыялылар әзерләргә һәм үзебезгә тиешле урыннарны саклап калырга тырышырга кирәк, ди. «Моның беренче чарасы – милләтне баетудыр. Бай милләт үз әгъзаларына җитәрлек «урын» вә «хезмәт» бирә алыр. Моннан аңлашылганга күрә, милләтнең байлыгы илә зыялыларның интереслары бердер вә аерылмаска тиештер»[27].

Соңгы вакытта Россия яшьләренең гамәли фәннәргә, заманча белгечлекләргә ихтыяҗы арту, әмма мондый уку йортларының илдә аз булуы, кайбер белгечлекләр буенча бөтенләй булмавы да аларны чит ил уку йортларына этәргән. Европа илләрендә, киресенчә, профильле югары уку йортларының чагыштырмача күп булуы үзенең ролен уйнаган. 1915 елга Германиядә,

---

[24] Миннуллин З. Землячества и благотворительные общества татарских учащихся в мусульманских странах (начало XX века) // Мир ислама. 1999. №1/2. С. 140.

[25] Иванов А.Е. Российское студенческое зарубежье: конец XIX – начало XX вв. URL: http://vivovoco.astronet.ru/VV/PAPERS/HISTORY/IVANOV.HTM (дата обращения: 20.09.2023).

[26] Заграницада рус шәкертләре // Вакыт. 1907. 20 февраль.

[27] Шунда ук.

мәсәлән, 21, Франциядә – 16, Бельгиядә – 4 һ.б. – барлыгы 116 университет эшләгән һәм аларга кереп уку мөмкинлеге чит илләрдән, шул исәптән Россиядән килүче яшьләргә дә бирелгән[28]. Шул ук вакытта бу чорда Европадагы кайбер уку йортлары Россиядән килеп укучыларга сак караганнар. Мәсәлән, Германия мәктәпләренең бары тик яртысы гына россиялеләр өчен ачык булган, ә Берлин университеты 1913 елда рус яшьләрен укырга алудан бөтенләй баш тарта. Моның сәбәпләренең берсе – чит илдән килеп укырга теләүчеләрнең артуы, ә урыннарның элеккечә калуында була. Шулай ук кайбер сәяси сәбәпләр дә үзенең ролен уйнаган. Россиялеләрдән, аттестаттан тыш, шулай ук матди яктан тәэмин ителеше һәм хокук бозмавы хакында белешмә таләп ителгән[29].

1910 нчы елларда татар яшьләре арасында чит илләргә барып белем алырга теләүчеләр саны чагыштырмача күп була. Бер генә мисал. 1911 елда «Вакыт» газетасы битләрендә Сан-Францискода укучы Х.Байбулатовның язмасы басылып чыкканнан соң[30], бик күп егетләрдән әлеге уку йортына керү шартлары, укуның тәртибе һәм үзенчәлекләре, һәм, гомумән, ватаннан читтә яшәү һәм белем алуның уңай һәм тискәре яклары турында сораган күпсанлы хатлар килә. Һәрбер затка аерым җавап бирү мөмкин булмау сәбәпле, Х.Байбулатов газета аша җавап бирә, иң еш очраган сорауларга аңлатмалар урнаштыра[31]. Мәкаләдән күренгәнчә, автор үзе укыган уку йорты белән укучыларны кызыксындыра алган, бу исә татар яшьләре арасында чит мәмләкәт уку йортларына барып белем алырга теләүчеләрнең саны артуга беркадәр сәбәп булган.

Бу чорда татарлар Госманлы дәүләте кул астында булган уку йортларында, соңрак Европа, Америка, Япония университетларында укыйлар. 1905–1907 елгы революциядән соң, илдә моңарчы күрелмәгән демократлаштыру күренеше шартларында, хакимият чикләүләренең колачы шактый кими һәм татар яшьләре рус уку йортларына күпләп кереп укый башлыйлар[32]. Петербург, Казан, Харьков кебек шәһәрләрдәге югары уку йортларында, югары курсларда белем алган татар студентларының саны күзгә күренеп арта. Ләкин моңа карап чит илләрне сайлаучылар да кимеми.

Шулай итеп, татар җәмгыятендә күзәтелгән тәрәккъыять, Европа мәдәниятенә йөз тоту моңарчы Бохарада укыган татар яшьләрен Төркия, Каһирә, соңрак Европа уку йортларына тарта. Бигрәк тә Париж, Льеж, Фрайбург,

---

[28] Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 10.

[29] Шунда ук. С. 13, 18, 22.

[30] Байбулатов Х. Американдан мәктүб // Вакыт. 1911. 11 сентябрь.

[31] Байбулатов Х. Американдан мәктүб // Вакыт. 1912. 9 март.

[32] Әмирхан Р. Татар мәгарифе тарихыннан // Әмирхан Р. Иманга тугрылык. Казан: Татар.кит.нәшр, 1997. Б. 156.

Лозанна[33] кебек илләрдә укучы татарлар саны арта. XX гасыр башында исә татарлар арасында Америка, Япония кебек илләргә барып белем алу омтылышы көчәя. Истанбул, Париж, Женева, Льеж, Лейпциг, Фрайбург, Нью-Йорк, Вальпараисо, Токио уку йортларында белем алган татар яшьләренең күпчелеге, ватаннарына кайтып, милләтенә хезмәт итү юлын сайлыйлар, татар җәмгыятен, милли мәгариф системасын үзгәртү, камилләштерү эшенә зур өлеш кертәләр.

Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, чит илләрдә белем алучы яшьләрнең күбесе укуларын тәмам итми, ватаннарына әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. Алар, әлбәттә, белем алуларын дәвам итәргә, диплом алып, эшкә урнашырга телиләр. 1914 елның октябрендә Европаның югары мәктәпләрендә укучы 110 егет, әлеге теләкләрен тормышка ашырырга теләп, Мәгариф министрына мөрәҗәгать итәләр, Россиядә технология институтына керергә теләүләре хакында җиткерәләр. «Аурупа гали һөнәр мәктәпләренең программалары безнекеләргә охшамый», – дигән сылтау астында аларның бу үтенече кире кагыла[34]. Шулай да соңрак Министрлар советы Европа университетларында укып, шушы 1914/15 уку елында уку йортларын тәмамлаучыларның «гомуми кагыйдәләргә муафикъ (ягъни җиңел рәвештә) рус дарелфөнүннәрендә имтихан кылынуларына рөхсәт бирергә» карар кыла[35].

Укуларын тәмамлап, кулларына диплом тотып кайткан яшьләргә дә үзләре алган белгечлек буенча эшләп китү мөмкинлеге бирелми. Мәсәлән, Әхмәтзыя Тупеевка Россиягә кайтканнан соң үзенең дипломын якларга туры килә[36]. Сорбонна университетын тәмамлап кайткан Сара Шакулова да 1915 елда Мәскәү университетында берничә имтихан тапшырырга мәҗбүр була. Бары шуннан соң гына ул үз һөнәре буенча эшкә урнаша ала.

Дөньяви белем артыннан чит мәмләкәтләргә юнәлгән татар яшьләре һөнәр һәм мәгариф өйрәнүне, бу өлкәдә алдынгы фикерләр белән танышуны максат иткән хәлдә, үз халкының һәм милләтенең алгарышы өчен хезмәт итүне үзләре өчен иң зур мәртәбә санаганнар һәм бу юлда зур тырышлыклар куйганнар.

---

[33] Лозанна Россиядән килеп белем алучы яшьләрнең иң яраткан уку йортларының берсе була. 1914 елда анда белем алучы 300 швейцарияле студентка 457 рус студенты туры килгән (Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 123).

[34] Дахили хәбәрләр. [Аурупа гали һөнәр мәктәпләрендә укучы ...] // Вакыт. 1914. 8 октябрь.

[35] Чит мәмләкәтләрдә укыган студентлар // Вакыт. 1914. 1 октябрь.

[36] Габдрафикова Л. Его звали Ахметзия Тупеев и он был... URL: https://dzen.ru/a/Yx4BSH5slkTg4enX?sidГасырлар%20авазы-412093825153198321 (дата обращения: 13.04.2023).

## Истанбул – тәрәккыйпәрвәрлеккә бер күпер

XIX–XX гасырлар чигендә татар яшьләре арасында Европа дәрәҗәсендә дөньяви белемгә, табиблык, хокук белгечлеге, инженерлык кебек һөнәрләрне үзләштерүгә ихтыяҗ арта. Европа идеалларына ирешүдә төп юл булып Истанбул саналган. Госманлы мәктәпләре һәм югары уку йортларында, төпле дини белем белән бергә, заманча дөньяви белемнәрне дә үзләштерегә мөмкин булган.

Югары уку йортлары турында хыялланган татар яшьләренең күбесе Россия университетларына кереп укый алмаган. Уку теле булган рус телен начар белүне генә сәбәп итеп китереп булмый, чөнки кайбер очракларда рус мәктәпләрен тәмамлаган, димәк, рус телен яхшы үзләштергән татар яшьләренең дә имтиханнарга үткәрелмәүләре билгеле. Пенза шәһәрендәге ирләр гимназиясен тәмамлаган Муса Акъегет, мәсәлән, бик теләсә дә университетка керә алмый һәм шул сәбәпле хыялын тормышка ашыру максатыннан Истанбулга китәргә мәҗбүр була. Ростовта Дәүләт реаль лицеен һәм Казанда Күл буе мәдрәсәсен тәмамлаган, Бохарада белем алган Муса Бигиев тә, ватанында университетка керә алмау сәбәпле, югары белем артыннан Истанбулга юнәлә, Инженерлык мәктәбенә укырга керә, соңрак, якташы М.Акъегет киңәше белән дини белем алуын дәвам итәргә карар кыла[1].

Госманлы дәүләте кул астындагы илләр, билгеле булганча, озак вакытлар дини белем бирү үзәкләре булып торган. XIX–XX гасырлар чигендә Истанбулда, дини гыйлемнәр белән беррәттән, дөньяви белем алу өчен дә мөмкинлекләр зур булган. 1910нчы елларда анда Истанбул дарелфөнүне[2], педагогия, тыйббия (медицина) мәктәпләре, дәүләт түрәләре һәм хәрбиләр әзерли торган уку йортлары, Галата-Сарайда Император лицее, Сәнгать академиясе һ.б. – җәмгысе 20 тирәсе югары мәктәп булган[3]. 1911 елда дарелфөнүндә тыйббия, хокук, илаһият, әдәбият, табигыять, хисап шөгъбәләре булган, аларда 7000 шәкерт белем алган[4]. Моннан тыш, илаһият бүлегендә дә белем алырга мөмкин булган[5]. 1912 елда алар уку йорты составында аерым мәктәпләр итеп үзгәртеләләр, ә 1924 елда уку йорты дәүләти статус ала[6].

[1] Хайрутдинов А.Г. Последний татарский богослов. Жизнь и наследие Мусы Джаруллаха Бигиева. Казань: Иман, 1999. С. 33–35.

[2] 1933 елдан Истанбул университеты.

[3] Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 286.

[4] Истанбул дарелфөнүне // Вакыт. 1911. 9 июнь.

[5] Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 286.

[6] URL: https://study-con.com/stambulskij-universitet-istanbul-university/#:~:text=Стамбульский%20университет%20был%20основан%20в,%2C%20философии%2C%20филологии%20и%20литературе (дата обращения: 12.11.2022).

Истанбул мәктәпләрендә төрекләр, башка мөселман илләреннән килгән яшьләр белән бергә татарлар да белем алган. Университетның тулы курсын тәмамлап диплом алган кеше урта уку йортларында укыту хокукы алган[7].

Истанбул бу чорда күбрәк дөньяви белем бирү үзәге буларак татарларны җәлеп иткән. Шуңа да, белем артыннан Истанбулга килгән яшьләргә, әгәр алар төпле дини белем алырга тели икән, башка ислам мәгарифе үзәкләрен сайларга, ә инде дөньяви белем, һөнәр үзләштерергә теләк белдергәннәргә, Истанбулда калып, төрек уку йортларына керергә киңәш биргәннәр. Дини белем артыннан яшьләр Каһирә, Мәдинә, Мәккә кебек шәһәрләрдәге уку йортларына юл алганнар[8].

Истанбулда чит телләргә, аеруча европа телләренә өйрәтү яхшы каралган була. Француз, инглиз телләренең башлангычларын үзләштергәннән соң, татар яшьләре Европа, Америка һ.б. илләргә барып, төрле урта-һөнәри уку йортларына, университетларга укырга керә алганнар. Күпчелек татарлар өчен Европа университетларына юл Төркия аша булган. Мәсәлән, Истанбулда белем алган Йосыф Акчура 1899–1903 елларда Парижда «Ирекле сәясәт гыйлеме мәктәбе»ндә укый, Сорбонна университетының «Гамәли фәннәр югары мәктәбе» лекцияләренә йөри[9]. Шушы ук фикерне С.Максуди, Г.Идриси һ.б. мисалында да расларга мөмкин.

Моннан тыш, игъдади сыйныфларында[10] укып, шәһадәтнамә алырга һәм белем алуны югары уку йортларында дәвам итәргә мөмкин булган. Әлеге сыйныфларда укыган яисә ватанында гимназия тәмамлаган, шул ук вакытта төрек телен белгән чит ил яшьләре дә, беренчеләре кебек, имтиханнарсыз гали мәктәпләргә кабул ителгән[11]. Күп кенә татарлар Төркиядә игъдади сыйныфларны үтеп, алга таба белем алуларын дәвам иткәннәр. Татар мәдрәсәләрен тәмамлап килгән, кулларында белем турында рәсми документ булмаганнар өчен бу рәвештә белем алу уңайлы булган.

1890 нчы елларда Истанбулда башлангыч, рөшди (урта) уку йортлары шактый булса да, югары мәктәпкә әзерли торганнары күп булмый – бары тик 3 игъдади мәктәп. Аның берсе – хәрби, калган икесе – мөлкия игъдадия (дәүләт түрәләре мәктәбенә әзерләүче). Соңгылары үзләре ике төрле – берсе ләйли (кичке, пансион тибындагы), икенчесе – нәһари (көндезге, пансионсыз) була[12]. Фатих Кәрими Әхмәт Мидхәт ярдәме белән пансионда түләүсез укып

---

[7] Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 286.

[8] Миннуллин З. Землячества и благотворительные общества татарских учащихся в мусульманских странах (начало XX века) // Мир ислама. 1999. №1/2. С. 142.

[9] Татар энциклопедиясе. 6 томда. Т. 1. Казан: ТЭИ, 2008. Б. 104.

[10] Игъдади сыйныфлар – урта белем алган шәкертләрне югары уку йортларына әзерләүче баскыч.

[11] Истанбул мәктәпләре // Вакыт. 1908. 11 декабрь.

[12] Фәйзи Х. Башымнан узган эшләр // Безнең мирас. 2024. №3. Б. 41.

чыкса, Гобәйдулла Бубига (Төркиядә ул Фәез әфәнде булып йөри) түләп укырга туры килә. Пансионда укыр өчен елына 300 сум акча таләп ителгән. Харис Фәйзи, аның кадәр акчасы булырына ышанычы булмаганга, пансионга керми, нәһари игъдадигә укырга керә[13].

Истанбул югары уку йортларына керүнең, беренче карашка җиңел генә тоелса да, үз таләпләре булган. «Мөлкия» мәктәбенә, мәсәлән, игъдади мәктәпне тәмамлау турында шәһадәтнамә таләп ителгән. Моннан тыш, укыган мәктәп идарәсеннән рәсми кәгазь, «госманча тәзкирә», ягъни төрек паспорты, чәчәк эшләтү (прививка) хакында документ, игъдади мәктәпне тәмамлаганнан соңгы шөгыле турында шәһадәтнамә, хокук бозмавы һәм суд эшләренә тартылмавы турында белешмә кирәк булган. Мәктәпкә ел саен барлыгы 40 шәкерт кабул ителгән, һәм абитуриентларның саны әлеге күрсәткечтән артып киткән очракта, кабул итү имтиханнары уздырылган. Имтиханнар вакытында булачак студентларның хисап белеме, гомуми химия, табигать, француз теле кебек фәннәр буенча белемнәре тикшерелгән[14].

Истанбул дарелфөнүненә кабул ителер өчен тиҗарәт (сәүдә) мәктәбе яисә башка берәр урта уку йортын, игъдади мәктәпне тәмамлау хакындагы шәһадәтнамә соралган. Шулай ук укырга керергә теләүченең хөкемгә тартылмавы хакында кәгазь дә таләп ителгән. Моңа кадәрге баскычны тәмамлау турында документы булмаганнар гарәп, фарсы һәм француз телләре (грамматика, тәрҗемә), госманлы әдәбияты, математика (хисап гыйлеме, алгебра, геометрия), космография, механика, табигать фәннәре (физика, химия, биология, зоология), төрек тарихы, хөсне хат буенча керү имтиханнары тапшырганнар. Дини белем алырга теләүчеләр, болардан тыш, махсус фәннәрдән белемнәрен расларга тиеш булганнар[15].

Татарлар арасында Истанбулда укып, алга таба башка илләргә китеп белем алучылар да шактый була. Галимҗан Идриси, мәсәлән, Истанбул университетында фәлсәфә һәм илаһият буенча белем алганнан соң, бик аз вакыт аралыгында «Хөсәения» мәдрәсәсендә укытып ала, 1913 елда Европага китеп, Льеж, Лозанна университетларында укый, телләр һәм фәлсәфә фәнен өйрәнә[16]. 1918–1919 елларда Германиядә дөнья күргән «Татар иле» газетасының мөхәррире Бәдретдин Сәйфелмөлеков, Льеж университетының медицина бүлегенә кергәнче, Төркиядәге «Солтания» мәктәбен тәмамлый[17] һ.б.

Төркия хөкүмәте үзенең иң яхшы, сәләтле шәкертләренә Европа яисә башка мәгариф алга киткән илләрнең уку йортларына барып уку мөмкинлеге

---

13 Фәйзи Х. Башымнан узган эшләр // Безнең мирас. 2024. №3. Б. 40.

14 Истанбулда гали мәктәпләр // Вакыт. 1906. 20 июнь.

15 Шунда ук.

16 Гилязов И.А. Судьба Алимджана Идриси // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1999. № 3/4. С 158–159.

17 Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. Б. 364.

тудырган. 1905 елда, мәсәлән, Солтан Габделхәмид хан хәзрәтләре акчасына 40 кеше Европа мәктәпләренә җибәрелсә, 1906 елда укучылар саны 64 кешене тәшкил иткән. Алар арасыннан 18 кеше Германия, 13 – Франция, 14 – Англия, 4 – Америка, 6 кеше – Бельгия, 8 студент Япония, 2 се Австрия уку йортларына юллама алган[18]. Бу эш рәвеше алдагы елларда да дәвам иткән. Моннан тыш, кайбер илләрдә чит ил студентларын чакырып, аларга югары яисә урта һөнәри белем алу мөмкинлеген тудыра торган аерым җәмгыятьләр, шәхесләр аша да эшләү механизмнары булган. Мәсәлән, Әхмәтмөнир Ибраһимовның Япониядәге «Азия Гикай» җәмгыяте акчасына Япониягә барып югары белем алуы хакында мәгълүмат очрый[19].

Үз ватанында күренекле җәмәгать эшлеклесе, журналист, татарлардан беренче физика-математика фәннәре кандидаты[20] буларак танылу алган Гаяз Максудов (1891–1942) та шушы юллар белән Европага барып белем ала. Кышкар, «Хөсәения», «Буби» мәдрәсәләрендә укыганнан соң, 1910–1912 елларда ул Төркиянең Салоники шәһәрендәге лицейда белем ала. 1913 елда әлеге уку йортының иң яхшы укучыларыннан берсе буларак, укуын дәвам итү өчен Бельгиягә, Льеж университетының физика-математика факультетына җибәрелә. 1914 елда, Беренче бөтендөнья сугышы башлану белән, Төркиягә әйләнеп кайтырга мәҗбүр була, Сарай һәм Бурса шәһәрләрендәге уку йортларында математика укытучысы булып эшли. 1917–1919 елларда Истанбул университетының физика-математика факультетында белем ала. Укуын тәмамлаганнан соң, Россиягә кайта һәм башта педагогик, аннан фәнни-оештыру, җәмәгать эшләре белән шөгыльләнә[21]. Мондый мисаллар шактый.

Истанбулга барып гыйлем эстәүнең максаты һәм уңай яклары нидән гыйбарәт булган соң? Әлбәттә, беренче чиратта ул татарларны дин берлеге, тел һәм гореф-гадәтләр охшашлыгы белән җәлеп иткән. Бер белмәгән, ишетмәгән чит мәмләкәткә барып ирешүгә караганда Истанбулда җайлашу (адаптация) җиңелрәк барган. Тел ягыннан киртәләр дә аз, һәм аларны берничә ай эчендә җиңәргә мөмкин булган. Истанбул татарлар өчен чит дөнья түгел, аның бигрәк тә һәр мөселман өчен изге булган җирләрдә – хаҗ юлында урнашуы да үз ролен уйнаган. Биредә чит илләрдән килгән студентларга ачык мөгамәлә булган: «Читтән килгән бер кешегә безем Русия дарелфөнүннәренә барып, бар җирләрен күрү бераз читенрәк булыр иде. Истанбулда алай түгел. Госманлылар мөсафирларга хөрмәт күрсәтү юлында үзләренә башка бер урын тоталар. Читтән, бигрәк тә Русия мөселманнарыннан килгән кешеләргә һәммә ишек ачык...»[22]. Истанбул – «бөек бер музаханә, кызыклы бер театр,

---

[18] [Дәр сәгадәт мәктәп галиясендә ...] // Өлфәт. 1906. 13 апрель.

[19] Бу хакта алдагы бүлектә җентекләбрәк сөйләнәчәк.

[20] Валеев Р., Сулима Л. Трагедия сторонника «латинизации» (Дело Гаяза Максудова) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1998. № 1/2. С. 126.

[21] Татарская энциклопедия. В 6 т. Т. 4. Казань: ИТЭ, 2008. С. 35.

[22] М.-Х. Тыйббия мәктәбе // Кояш. 1914. 17 август

авыррак тел берлә язылган бер роман» булуы белән дә үзенә җәлеп иткән. Ләкин ул, татарлар өчен никадәр генә якын булса да, бер үк вакытта ят дөнья – «манаралары зәңгәр күккә ашып торган искиткеч зур бөек җамигъләреннән алып, урамдагы ширбәтчеләренә кадәр...»[23]. Моңарчы таныш булмаган, әмма танырга теләгән, ислам, төркилек рухы белән сугарылган бу шәһәр татар яшьләрен үзенә тарткан.

Билгеле булганча, Истанбул һәм Казан XX гасыр башында төрки дөньяның китапчылык һәм галимлек, милли һәм төрки үзаң үзәкләре булганнар. Россия татарлары һәм Истанбул арасында фикри һәм мәдәни бәйләнешләр нык булган. Бу бәйләнеш кешеләрнең үзара аралашуларында, вакытлы матбугатта фикер һәм мәгълүмат алмашуларында, әдәби әсәрләр аша алып барылган[24]. Моннан тыш, Идел-Урал буе мәдрәсәләрендә Истанбулдан кайтарылган дәреслекләр кулланылуы, татарларның төрек телендә дөнья күргән тәрҗемәләр аша Европа, аерым алганда француз романнары белән танышуларын да әйтеп узарга кирәктер. Истанбулда 1911 елда чыгып килгән «Төрек йорты» (мөхәррире Й.Акчура) журналы да төрки дөньяны туплауга хезмәт иткән. Бу елларда Истанбулда татарны таныткан шәхесләрнең яшәве зур әһәмияткә ия булган.

Төрекләрнең татарларга карата уңай мөнәсәбәттә булуы да үз ролен уйнагандыр, мөгаен. 1906 елда «Өлфәт» газетасының 25 санында истанбуллы Садретдин бәкнең хаты басылып чыга. Ул татар яшьләренең белем алуы, аларның тәрәккыяткә омтылышларын күреп шат булуы хакында хәбәр итә. Автор Истанбулда укучы татарларның киләчәктә үз мәмләкәтләренә кайтып мөгаллим булачагы, төрекләрнең татарларга ярдәм итәргә һәрчак әзер булулары турында яза. Чөнки, Садретдин бәк фикеренчә, «төрек вә татар бер милләттер»[25].

Шулай да татар яшьләренең Истанбулны сайлавының төп максаты заманча белем алу һәм аның эчтәлегендә булган: «Истанбулга килүдән һәр татар углының максаты да үзенә гыйльми, фәнни җәһәттәнме бер файда казанмак булу лязем»[26].

Бу чорда Истанбулга барып укучы татар яшьләренең гомуми саны төгәл билгеле булмаса да, аларның чагыштырмача күплеге турында әйтергә мөмкин. 1897 елда, мәсәлән, Истанбулда 15 татар шәкерте белем алган[27]. Кайбер чыганаклар буенча, 1906 елда Истанбулдагы һәрбер уку йортында 5–6 татар шәкерте белем алган, Мәрҗан лицеенда татар студентлары өчен хәтта махсус

[23] М.-Х. Тыйббия мәктәбе // Кояш. 1914. 11 июль.
[24] Мухаметдинов Р.Ф. Татары в общественно-политическом движении Османской империи // Тюркологические исследования. 2020, том 3, № 3. С. 12.
[25] Садретдин. Истанбулдан мәктүб // Өлфәт. 1906. 25 май.
[26] М.-Х. Истанбулдан мәктүб // Кояш. 1914. 11 июль.
[27] Давлетшин А. Отчет штабс-капитана Давлетшина о командировке в Хиджаз. СПб.: Военная типография, 1899. С. 62–63.

сыйныфлар оештырылган була[28]. «Әл-ислах» газетасы хәбәрләренә караганда, 1908 елда Истанбулның төрле мәктәпләрендә 27 ләп татар шәкерте укыган[29]. 1909 елда Истанбулдагы төрле дәрәҗә уку йортларында укучы татарларның саны 63 булган, аларның 14 е университетта, укытучылар әзерли торган уку йортында – 12, урта белем мәктәпләрендә 20, Солтан уку йортында – 4, шәһәр урта һөнәри белем мәктәпләрендә 10 кеше белем алган[30].

Гомумән алганда, XIX гасырның ахырларына таба Истанбулда татарларның аеруча күп яшәгән бистәләре булган. Бу – «мөселман катлавы яшәгән Фатих, Баязит, Солтанәхмәт, Нурыгосмания һәм Мәхмүтпаша районнары»[31]. Анда, мөһаҗирләр белән беррәттән, шәкертләр дә яшәгән. «XIX гасырның ахырларына таба Фатих Казаннан килүче мөһаҗирләр күпләп яшәгән районга әйләнә. Аеруча Фатих мәчетендә вазифа башкаручы һәм Фатих мәдрәсәсендә белем алучы Идел-Урал яшьләренең саны арта»[32].

Татар яшьләрен аеруча Истанбул университеты (дарелфөнүне), педагогия уку йорты (дарелмөгаллимин), Югары хәрби мәктәп («Ирадәэ сания», «Хәрбия мәктәбе») һәм дәүләт түрәләре әзерли торган югары дөньяви «Мөлкия» («Мәктәбе мөлкия-и шаһанә») мәктәпләре үзләренә җәлеп иткән[33]. Рәсми рәвештә әлеге уку йортлары чит ил студентларын бары тик 1905 елдан соң гына кабул итүгә карамастан[34], татарлар аңа кадәр үк әлеге уку йортларында гыйлем туплаганнар. Мәсәлән, «Мөлкия»дә татарлар арасында беренчеләрдән булып Муса Акъегетзадә (1891 елда тәмамлый) һәм Фатих Кәрими (1892–1894) укыган. «Мөлкия»нең урта (игъдадия) бүлеген шулай ук Гобәйдулла Буби тәмамлый[35]. Йосыф Акчура, 1888–1896 елларда Истанбулда махсус мәктәптә һәм «Хәрбия мәктәбе»ндә югары белем алганнан соң, штаб офицерлары курсларына укырга керә[36]. Истанбулда укыган татарлардан шулай ук Закир Рәмиевне, Галимҗан Идрисине (ул Истанбул университетында фәлсәфә һәм дин гыйлемнәрен өйрәнә)[37], Истанбулда гимназия тәмамлаган Габделкадыйр Зәйнулла улы Рәсүлевне атарга мөмкин[38].

---

[28] Фәйзи Х. Садретдин бәйгә мөрәҗәгать // Өлфәт. 1906. 26 июнь.

[29] [Шәрык, гарәп галәме ...] // Әл-ислах. 1908. № 39. Б. 8.

[30] ТР ДА, 1 ф., 4 тасв., 4485 эш, 7 кгз.

[31] Кылынч А. Идел-Урал татарларының Госманлы җирләренә XIX гасырның 70 нче елларына кадәрге күчешләре // Чын мирас. 2012. № 5–6. Б. 50.

[32] Шунда ук.

[33] Сибгатуллина А., Тюркоглу. Татары и Османское государство // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань, 2013. С. 348.

[34] Шунда ук.

[35] Шунда ук. С. 349.

[36] Татар энциклопедиясе. 6 томда. Т. 1. Казан: ТЭИ, 2008. Б. 104.

[37] Гилязов И. Судьба Алимджана Идриси // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1999. № 3/4. С 158.

[38] Расих А. Внук ишана. Казань: Татар.кн.изд-во, 2016. С. 45, 143.



*Гобәйдулла Бубый Истанбулдагы татар шәкертләре арасында. 1896 ел. (История татар с древнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань, 2013. С. 349).*

Истанбулда укыган татар студентлары турындагы мәгълүматларны XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты, аерым шәхесләрнең истәлек-хатирәләре аша барларга мөмкин. Мисал өчен, Габделкадыйр Рәсүлев турындагы кайбер мәгълүматлар язучы Атилла Расихның әнисе Зәйтүнә Мәүлүдова-Рәсүлева көндәлекләренә таянып язылган «Ишан оныгы» әсәрендә очрый. Ирле-хатынлы Кадыйр һәм Зәйтүнә 1914 елда хаҗ сәфәренә чыгалар, тик сугыш башлану белән кайта алмыйча, бүленеп калалар, Истанбулда тукталалар. Зәйтүнә көндәлекләрендә бу чорны бик яхшы тасвирлап барган. Анда бу чорда Истанбулда укыган башка татар студентлары да искә алына. Автор казанлы Зыя Насыйри белән танышуларын, Петербургта белем алган татар яшьләре Галимҗан һәм Ләбибне күрүләрен яза, Казаннан килгән университет студенты Гариф әфәнде белән аралашуларын тасвирлый[39]. Соңгысының Фатих Кәриминең бертуганы Гариф Кәрими булуы мөмкинлеген күздә тотарга мөмкин, чөнки, беренчедән, аның бу даирәдә үз кеше булуы күренә (автор фамилиясен дә күрсәтеп тормый), икенчедән, Гариф Кәриминең бу чорда Истанбул белән бәйләнешләре тыгыз була.

Төрек уку йортлары, аларның торышы турында шул чорда «Вакыт», «Йолдыз» газеталарында «Истанбул мәктүбләре» сәхифәсе астында басылган мәкаләләр сериясе дә мәгълүмати чыганакларның берсе булып тора.

[39] Расих А. Внук ишана. Казань: Татар.кн.изд-во, 2016. С. 328–229, 231.

Истанбулдагы татарлар белем алган уку йортларына килгәндә, иң беренче чиратта аларны педагогик белем алу кызыксындырган дисәк, ялгыш булмас. Чөнки мәгариф, тиешле дәрәҗәдә белем бирү милләт алгарышы өчен төп шартларның берсе булып саналган. Шуңа күрә милли, шул ук вакытта заманча нигезләргә таянып укытучы педагогларны әзерләүгә игътибар күп бирелгән. Мондый белемне Истанбул дарелмөгаллиминендә алырга мөмкин дип фаразланган. Троицкидагы татар приказчиклары җәмгыяте рәисе Камал Габитов[40] «Галия» мәдрәсәсе шәкерте, югары белем алырга теләк белдергән Хәбиб Зәйнигә: «Безгә тагын татарлар арасында яхшы мөгаллимнәр әзерли алырлык бик яхшы әзерлекле педагог кирәк. Россиядәге педагогик югары уку йортлары әзерләгән укытучылар безнең таләпләргә туры килми. Төркиядә укытучылар әзерләүгә бик зур игътибар бирелә. Әгәр Төркиягә барып, педагогик вузга укырга керсәң, без сиңа ай саен 25 сум күләмендә ярдәм итеп торачакбыз», – ди[41]. Шулай итеп, 1908 елда Х.Зәйни Истанбул шәһәренә барып, дарелмөгаллиминнең биогеография шөгъбәсенә укырга керә[42]. 1912 елда ул уку йортын «бишле» билгеләренә тәмамлап, Уфага кайта һәм «Галия» мәдрәсәсенә мөгаллим булып урнаша, ул үз белгечлеге – биология, географиядән генә түгел, ана теленнән һәм тарихтан да шәкертләргә белем бирә башлый. Моның өстенә, шәкертләрнең үтенече буенча, «Галия» тарихында беренче тапкыр буларак, ул физик тәрбия дәресләрен (ул вакытта аны «гимнастика» дип



*Хәбиб Зәйни (Әнвәр Терегуловның шәхси архивыннан)*

---

[40] Габитов Камал. Тәхәллүсләре: Габитов Камал, Г. Камал. Революциягә кадәр Троицк шәһәрендә Яушевларда хезмәт иткән укымышлы кеше, «Акмулла» көлке журналында редактор да булып торды. Троицкидагы приказчиклар оешмасының председателе, демократ (Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Псевдонимы в татарской литературе / төз.: Л.Ш.Гарипова, Г.Н.Зәйниева. Казан: ТӘһСИ, 2021. Б. 77).

[41] Зайни Х. Автобиография // ОРРК КФУ, 2390-т, IV.

[42] Х.Зәйни үзенең автобиографиясендә Истанбулда педагогия институтының биогеография факультетында белем алуы хакында яза (Зайни Х. Автобиография // ОРРК КФУ, 2390-т, IV). «Тәхәллүсләр сүзлеге» авторы М.Бөдәйли исә аны Төркиядә физкультура институтында укый дип белдерә (Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Псевдонимы в татарской литературе / төз.: Л.Ш.Гарипова, Г.Н.Зәйниева. Казан: ТӘһСИ, 2021. Б. 80).

атыйлар) укыта башлый, соңрак татар балаларына физик тәрбия бирү буенча методик әсбаплар язып бастыра[43].



*Габдулла Шнаси (Татар педагогик фикере антологиясе. Т. 2. Казан, 2016. Б. 161)*

Чыннан да, Истанбул мәктәпләре Европа дәрәҗәсендә педагоглар әзерләүче уку йортлары саналган. Шул сәбәпле татарлар яхшы, милли нигезләргә корылган педагогик белем артыннан Истанбулга юнәлгәннәр. Троицк шәһәрендәге 1 нче мәчет имамы, «Әхмәдия» мәдрәсәсе җитәкчесе ахун Әхмәтхаҗи Рахманколов, яңа җәдит ысулын тормышка ашыру нияте белән үз хәлфәләреннән берсе Мөхәммәтзакир Ваһаповны белем алыр өчен Истанбулга җибәргән[44]. Төркиядә алган белемнәр һәм тәҗрибә яшь педагогка Троицк шәһәрендә җәдит мәктәпләре ачарга мөмкинлек биргән.

Истанбулда югары педагогик белем үзләштергән татарлар арасында Габдулла Сабир улы Ибраһимов (Шнаси) да бар. Троицк шәһәрендә мәдрәсәдә белем алганнан соң, ул югары белем алу өчен Истанбулга юл тота һәм башта гимназия тәмамлап, урта белем турында шәһадәтнамә ала, ахырдан Истанбул университетының табигать фәннәре шөгъбәсенә[45] укырга керә[46].

Х.Зәйни билгеләп үтүенчә, Төркия уку йортларында, аерым алганда, Истанбул педагогия институтында[47], белем бирү француз һәм төрек телләрендә алып барылган. Бу исә анда укыган татар шәкертләренең төрек һәм француз телләрен яхшы үзләштерүләренә ярдәм иткән. Нәтиҗәдә, алар ватаннарына кайтканнан соң да әлеге белемнәреннән файдалана алганнар.

[43] Мортазина Л.Р. Хәбиб Зәйни хезмәтләрендә татар мәгарифе мәсьәләләре // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2020. № 1. Б. 148–149.

[44] Баттал Г. Троицк байларындан вә хәйратларындан Габделвәли Яушев. Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1912. Б. 14.

[45] «Татар энциклопедиясе»ндә Г.Шнаси «әл-Әзһәр» университетында укыган дип күрсәтелә (Татарская энциклопедия. В 6 т. Т. 6. Казань: ИТЭ, 2014. С. 423.). Г. Шнасиның тормыш юлын җентекләп өйрәнгән М.Рәхимкулова аны Истанбул университетында белем ала дип яза (Рахимкулова М. Медресе «Хусаиния» в Оренбурга. Оренбург, 1997. С.50).

[46] Муртазина Л.Р. Научно-педагогическая деятельность Габдуллы Сабировича Шнаси (1885–1938) // Вестник Томского государственного педагогического университета (Tomsk State Pedagogical University Bulletin). 2016. Вып. 8 (173). С. 121.

[47] Х.Зәйни совет чорында язылган документларда уку йортын шулай күрсәтә. Дарелмөгаллимин турында сүз бара дип аңлыйбыз.

Мәсәлән, Г.Шнаси татар мәдрәсәләре тарихында беренче тапкыр татар телендә химия дәреслеге язып бастыра[48] (бу дәреслек 1929 елга кадәр мәктәп системасында кулланыла[49]) һәм, автор билгеләп үткәнчә, әлеге әсбапны язуда ул рус авторларының китаплары белән беррәттән, француз авторларының дәреслекләреннән һәм төрек теленә тәрҗемә ителгән хезмәтләрдән файдалана[50]. Моннан тыш, ул факультатив рәвешендә «Хөсәения»[51], «Госмания» мәдрәсәләрендә[52] француз телен укыта. М.Рәхимкулова билгеләп үтүенчә, «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллимнәренең күбесе (ә алар арасында чит ил уку йортларында, шул исәптән Истанбулда укыганнар шактый була) гарәп, фарсы, төрек, француз, инглиз һәм немец телләреннән тәрҗемәләр башкарганнар, шулай ук үзләре дә әлеге телләрдә хезмәтләр язганнар[53].



*Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллимнәре. 1911 ел (Г.Шнаси – сулдан икенче) (Мортазина Л.Р. Шенас – кызыксынучан акыл // Безнең мирас. 2016. № 6. Б. 14)*

[48] Мифтахова Н.Ш. Химия буенча татар телендәге беренче китаплар турында // Фәнни Татарстан. 2005. № 3/4. Б. 10.

[49] Рахимкулова М.Ф. Преподавание естественных наук в татарских школах дореволюционной России: страницы истории татарских школ в России. Оренбург, 1998. С. 113.

[50] Шнаси Г.С. Мохтасар кимия. 1 кис. Казан: «Юл» көтепханәсе, 1910. Б. 3.

[51] Рахимкулова М. Медресе «Хусаиния» в Оренбурга. Оренбург, 1997. С. 50.

[52] Рахимкулова М.Ф. Педагог и общественный деятель // Совет мәктәбе. 1985. № 2. Б. 58.

[53] Рахимкулова М. Медресе «Хусаиния» в Оренбурга. Оренбург, 1997. С. 28–29.

Хәбиб Зәйнине исә, төрек телен яхшы белүен искә алып, 1917 елда Одессага тәрҗемәче офицерлар курсларына төрек теле терминологиясен үзләштерергә җибәрәләр[54]. Шулай итеп, Истанбул уку йортлары татар яшьләренә Европа мәдәнияте белән танышырга һәм Көнбатыш мәгълүмати кырына якынаерга мөмкинлек биргәннәр.

Төрек галәмендә бердәнбер дияргә мөмкин булган[55], ләкин чагыштырмача яшь («15–20 еллар элек салынган») Тыйббия[56] мәктәбе Истанбулның иң яхшы уку йортлары арасында саналган. Үзен «М.-Х.» дип күрсәткән автор язуынча, «Хәйдар пашада[57] булган тыйббия мәктәбе ерактан ук бинасының гүзәллеге, биеклеге белән күзгә ташланып тора. Барып кергән вакыт зур, биек ишекләр, югары менеп киткән киң баскычлар, мәктәпнең алдында тезелеп киткән матур агачлар – һәммәсе бу мәктәпнең гади бернәрсә дә булмый, күп акча тотылган, күп көч вә гайрәт сарыф ителгән бер нәрсә икәнен белгертеп торалар»[58]. Истанбулдагы «Гөлханә» хастаханәсендә яралы солдатларга ярдәм итүче самаралы татар егете Шәһидулла әфәнденең[59] әлеге уку йортында белем алуы мөмкин. Биредә укыган студентлар арасында русияле Сибгатулла әфәндене күрсәтергә мөмкин[60]. Шулай ук Уфа губернасы Бөре өязе Өчбүлә авылы[61] имамы Фәйзрахман хәзрәтнең улы Исмәгыйль Тупеевның да (1887 елда туган) Истанбулда укыганлыгы, һәм, табиб һөнәрен үзләштереп, Уфа шәһәрендә эшләгәнлеге мәгълүм[62].

Студентлар үзләре укыган белем йортларын, ихтыярсыз, ватаннарындагы мәктәпләр белән чагыштыралар һәм җиһазлар, фәнни әсбаплар белән тәэмин ителеш ягыннан төрек уку йортларының алга китүләрен ассызыклыйлар. «Тыйббия мәктәбе» мәкаләсе авторы әлеге мәктәпнең анатомия театрында, лабораторияләрендә булып, соклануын белдерә, мондый базаның бары тик Мәскәү университетында гына булу мөмкинлеген әйтә[63]. Шулай итеп, әлеге уку йортларында белем алуның татарларның белем дәрәҗәсенә, һәм, әлбәттә, гомумән, мәгариф үсешенә дә уңай йогынты ясаганлыгы күренә.

---

[54] Зайни Х. Автобиография // КФУ КСКБ. 2390-т, IV.

[55] М.-Х. Тыйббия мәктәбе // Кояш. 1914. 17 август.

[56] Тыйббия – медицина.

[57] Хәйдәр паша урамы хакында сүз бара.

[58] М.-Х. Тыйббия мәктәбе // Кояш. 1914. 17 август.

[59] Әлеге студент хакында Гм.-ның «Истанбул хатирәләре» дигән мәкаләсендә әйтелә (Кояш. 1913. 15 гыйнвар).

[60] Камал Г. Төркия мәктүбләре // Казан утлары. 1999. № 4. Б. 175.

[61] Өчбүлә авылы – хәзерге Башкортстан Республикасының Дүртөйле районында урнашкан.

[62] Габдрафикова Л. Его звали Ахметзия Тупеев, и он был... URL: https://dzen.ru/media/liliyagabdrafikova/ego-zvali-ahmetziia-tupeev-i-on-byl-631e01487e6c9644e0e1e9d7 (дата обращения: 13.04.2023).

[63] М.-Х. Тыйббия мәктәбе // Кояш. 1914. 17 август.

Күпчелек очракта татарлар, тиешле дәрәҗәдә белемнәр туплагач, ватаннарына кайтып, мәгариф, медицина, җитештерү өлкәләрендә ил һәм милләт файдасына хезмәт иткәннәр. Төркиягә килеп белем алып, төрле сәбәпләр белән шунда төпләнеп калучылар да булган.



*Исмәгыйль Тупеев тормыш иптәше белән (https://dzen.ru/a/Yx4BSH5slkTg4enX)*

Тикшеренүче, Истанбулдагы Мигъмар Синан Нәфис сәнгать университеты укытучысы Арзу Кылынч хәбәр итүенчә, Истанбул һәм башка шәһәрләрдәге белем бирү йортларына кабул ителү бер үк вакытта ватандашлыкка күчүнең бер юлы да булган[64]. Шул сәбәпле, теләгән очракта, татар яшьләре укыган җирләрендә яшәп тә кала алганнар. Төркиядә калган татарларның күпчелеге Төркия дәүләтендә билгеле шәхесләр булып, илнең икътисади, мәдәни үсешенә өлеш кертәләр. Алар арасында Муса Акъегетзадә, Хәлим Сабит Шибай, Әхмәт Таҗетдин һ.б. бар[65].

XX гасыр башында Төркиядә яшәп, җаваплы урыннарда эшләгән татарлар мөхәррирлек, мөгаллимлек иткәннәр. 1912–1913 елларда «Йолдыз» газетасының Төркиядәге мөхбире булган Галиәсгар Камалның билгеләп үтүенчә, «Истанбулда иң яхшы хатиб саналган кеше – татардыр. Гәзитә идарәләрендә иң яхшы мөхәррирләр – татарлардыр. Төркиянең әркане хәрб (хәрби штаб) әгъзалары арасында да татарлар бар. Төркиянең игъдади мәктәпләреннән

[64] Кылынч А. Идел-Урал татарларының Госманлы җирләренә XIX гасырның 70нче елларына кадәрге күчешләре // Чын мирас. 2012. № 5–6. Б. 50.

[65] Сибгатуллина А., Тюркоглу. Татары и Османское государство // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань, 2013. С. 349.

берсендә бер татар – мөгаллимдер»[66], «Малия вәзире Габдрахман паша – татардыр, зарбханәнең (монетный дворның) мөдире Габдрахман бәк – татардыр»[67]. Ләкин биредә шуны истә тотарга кирәк, «татар» атамасы белән ул вакытта Казан татарлары белән беррәттән, Кырым һәм Кавказ татарларын (әзәрбайҗаннарны) атаганнар. Шул сәбәпле, бу очракта искә алынган затларның барысы да Казан татары булмавы мөмкин.

Төркиядә яшәп, татар милләтен танытуга өлеш керткән берничә күренекле татар кешесен искә алып узыйк. Исеме Россиядә генә түгел, төрекләр арасында да яхшы билгеле шәхесләрнең берсе, киң татар җәмәгатьчелегенә татар телендә язылган беренче роман авторы буларак таныш булган Муса Акъегетзадә (1864–1923), мәсәлән, 1888–1891 елларда Истанбулда дәүләт оешмалары өчен югары белемле хезмәткәрләр әзерли торган «Мәктәбе мөлкия-и шахане» мәктәбендә укыганнан соң, шәһәрдәге Югары хәрби мәктәптә һәм Хәрби академиядә рус теле һәм икътисад буенча дәресләр бирә, «Мәтен» («Асыл нөсхә»), «Өч кардәш» исемле газеталар нәшер итә, Н.Ф.Катанов китапханәсен өйрәнү белән шөгыльләнә[68]. Ул шулай ук «Сөләймания» китапханәсенең беренче мөдире дә була. Моннан тыш, галимнәрнең бик дөрес билгеләвенчә, бөтен дөнья икътисади фикер тарихында да аның үз урыны бар. Ул дөнья һәм Россия икътисад фәненең иң алдынгы казанышларын һәм ислам традицияләрен берләштергән икътисади системаны нәзари яктан төзү белән бергә, Госманлы дәүләтендә икътисад фәненә нигез салучыларның берсе, бу өлкәдәге яңалыкларны таратучы буларак та яхшы билгеле[69].

Икенче бер татар егете Хәлим Сабит Шибай (1883–1946), мәдрәсә тәмамлагач, рус мәктәбендә имтихан тота һәм 1904 елда, белемен арттыру максаты белән, Истанбулга юл ала. Башта «Фатих» мәчетендә заманының атаклы галиме Габделфәттах Дагыстанлыда укып, иҗазәтнамә ала, аннан соң «Мәрҗан» мәктәбендә имтиханнар тапшырып, шәһадәтнамәгә ия була. 1910 елда Истанбул университетының илаһият бүлеген тәмамлый, бер үк вакытта, мәктәпләрдә педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукына ия булыр өчен шул ук университетта имтихан бирә. 1912 елда Геленбәви мәктәбендә укыта башлый, 1914–1919 елларда Истанбул университетында ислам тарихы һәм диннәр тарихыннан дәресләр бирә[70].

Чыгышы белән Минзәлә өязе Теләнче Тамак авылыннан булган Хәмит Зөбәер Кошай (1897–1984) да, Истанбулда белем алып, төрки халыклар фай-

---

[66] Камал Г. Истанбул мәктүпләре // Йолдыз. 1912. 16 декабрь.
[67] Камал Г. Истанбул мәктүпләре // Йолдыз. 1912. 29 декабрь.
[68] Татар энциклопедиясе: 6 томда. 1 т. Казан: ТЭИ, 2008. Б. 108.
[69] Хадиуллина Г.Н. Экономические воззрения Мусы Акъегетзаде (1864–1923) и их влияние в эпоху младотурков // Социально-экономические явления и процессы. 2008. № 4. С. 83.
[70] Бириндже А. Халим Сабит Шибай // Научный Татарстан. 2012. №4. С. 51–52.

дасына хезмәт иткән татарларның берсе. Ул 9 яшендә Р.Фәхретдин ярдәме белән Истанбулга укырга китә һәм Галатасарайда урнаша. 1912 елда укуын тәмамлап, лицей сыйныфына укырга керә. Сугыш башлану белән, укулар тукталып тора, һәм Хәмит, башка шәкертләр белән бергә, хәрби госпитальдә яралы сугышчыларга ярдәм күрсәтә.

1914 елда Хәмит Солоникидагы Мидхәт паша мәктәбенә укырга керә. Истанбулда ике ел укып, мөгаллимлек шәһадәтнамәсе ала һәм Кадикой бистәсе мәктәбендә физик тәрбия укытучысы булып эшкә урнаша.

1917 елда Венгриягә китә һәм Будапешт университетына укырга керә. 1925 елда докторлык дәрәҗәсе алып, кабат Төркиягә кайта. Хәмит Зөбәер Кошай китапханәләр буенча инспектор булып эшли, моннан тыш ул – Әнкара этнографик музееn оештыручы буларак Төркия тарихына кереп калган татар кешесе[71].

Төркиянең бу чорда дөньяви белем бирү буенча татар яшьләре арасында дан-шөһрәте зур булган, әлбәттә. Шулай да, ул элеккечә исламны өйрәнү үзәге буларак та үзенең әһәмиятен югалтмаган. Истанбул университетындагы илаһият (теология) факультеты бу яктан караганда алдынгы саналган. Биредә белем алган татарлар арасында Россиядә һәм Төркиядә билгеле шәхес – «Хөсәения» һәм «Галия» мәдрәсәләрендә фикъһ, фәлсәфә, хәдис һәм гарәп телен укыткан педагог, дәреслекләр авторы, «Тормыш» газетасы мөхәррире Закир Кадыйри бар. Ул әлеге уку йортына шактый әзерлекле булып килгән.

Закир Мөхәммәтхәлим улы Кадыйри (1878–1954), Сембер шәһәрендә 1нче мәчет каршындагы мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, 1894 елда әтисе киңәше белән Бохарада 5 ел дәвамында дин белеме ала, гарәп, фарсы әдәбиятын өйрәнә, Мәдинәдә укый[72]. 1899 елда хаҗ сәфәрендә вакытта Мәккәдә ике ел буе шәех Исхак Һиндидә гыйлем ала. Хиҗаздан кайтканнан соң, Истанбул университетының илаһият бүлегенә укырга керә. Остазы Җәмил Сидки Зәхавизадә киңәше белән Мисырга бара, «әл-Әзһәр» университетында һәм Әл-Һидивия мәдрәсәсендә шөгыльләнә, Тантави Җәүһәри әл-Мисридан дәресләр ала[73]. Бу чорда ул «Әл-Лива» газетасында «Гыйльмел-Ислам» журналында мәкаләләр дә бастырган[74].

Истанбулда белем алган татарлар арасында «Идел-йортка, гавамга, хәтта гуманитар өлкәдә эшләүче зыялыларга да билгеле булмаган», «халык хадим-

[71] Гаффарова Ф. Хәмит Зөбәер Кошай (1897–1984) // Безнең мирас. 2016. №8. Б. 48–49.

[72] Тимер А. Закир Кадири Уган. Ахмет Тимер: Возвращение / авт.-сост. Р. Абзалова-Сальманова. Казань: Яз, 2012. С.41–42.

[73] Тантави Җәүһәри әл-Мисри Россия мөселманнарына түләүсез дәресләр биргән (Исмаил Тюркоглу. Новые штрихи к творческой биографии Закира Кадыри-Угана // Tatarica. 2019. №1. С. 129).

[74] Тюркоглу И. Новые штрихи к творческой биографии Закира Кадыри-Угана // Tatarica. 2019. №1. С. 129.

нәре» арасында танылган табиб (медицина докторы), дистәләгән әдәби һәм гыйльми китаплар авторы, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Әхмәт Ләбиб Каранны (1878–1964) күрсәтергә мөмкин[75]. Чыгышы белән Каран (?) авылыннан булган, 1909 елда Истанбулда Вафа лицеен тәмамлаган Әхмәт Ләбиб 1912 елдан соң Истанбул университетының медицина факультетында укый. 1919–1923 елларда Төркиянең Мостафа Кәмал Ататөрек җитәкчелегендәге бәйсезлек өчен көрәшендә хәрби табиб буларак катнаша. Алга таба Измир һәм кайбер башка шәһәрләрдәге хастаханәләрдә эшли[76]. Соңрак Төркиядә оешкан «Идел-Урал», «Сөембикә...», «Тукай» җәмгыятьләренең җитәкчеләреннән берсе була, татар тематикасына бәйле мәкаләләре белән вакытлы матбугатта чыгыш ясый[77], татар телендә берничә китап бастырып чыгара.

Болар – Төркиядә хезмәт итеп, төрек дөньясына билгеле булган шәхесләр. Ләкин күпчелекне Истанбул уку йортларында белем алып, ватанына кайткан һәм алган гыйлемнәрен милләте һәм туган иле файдасына кулланган зыялылар тәшкил итә. Алар әдәбият, мәдәният, сәнәгатьнең төрле өлкәләрендә эшләп, гомерләрен туган кавеменә багышлаганнар. Әлбәттә, илдә барган кискен үзгәрешләр аларның язмышларына да хәлиткеч тәэсир иткән, күп очракта бу тәэсирләр аянычлы булган. Ләкин бу башка мәсьәлә, һәм әлеге тикшеренү кысаларында проблеманы карауны максат итмәдек.

Истанбул уку йортларында белем алу күпчелек тарафыннан уңай кабул ителсә дә, аерым затлар бу күренештә татар җәмгыятенең традицион тормыш кагыйдәләреннән тайпылуына китерә дип уйланылган төрек тәэсирен күргәннәр. Әлбәттә, шактый гомерен Төркиядә уздырып, төрекчә сөйләшергә өйрәнгән, төрек гадәтләренә күнегеп беткән яшьләрнең ватаннарына кайтканнан соң да әлеге традицияне дәвам итүләре аңлашыла да. Гомумән алганда, бу хәл чит мәмләкәтләрдә укыган татарларның күбесенә хас булган һәм ул аларның киенүләрендә, үз-үзләрен тотышларында, сөйләшүләрендә – кайбер очракта аңлы рәвештә, кайчак гадәт буенча – чагылыш тапкан. Галиәсгар Камал үзенең «Тел берләштерәләр» дип исемләнгән бер фельетонында[78] Төркиядә укып кайтучыларның сөйләшү рәвешләреннән көлеп яза. Икенче бер автор Тимербай «Йолдыз» газетасында: «Минем берничә төрле эшкә эчем поша, – дип яза, – җөмләдән берсе – яшьләр бик киемнәрен үзгәртә башладылар. Күбесе пальто-мальто кияләр. [...] Төркия вә Кырымдагы картлар бу хосуста бик тырышып бактылар вә мәга залик (шул) яшьләрен тыя алмадылар. Ахырында картлар үзләре дә а-ля-франка киенә башладылар», –

[75] Миңнегулов Х. Татар сүзен олылаган Каран. URL: https://madanizhomga.ru/news/shheslrebez/tatar-szen-olylagan-karan (дата обращения: 21.04.2024).

[76] Шунда ук.

[77] Ә.Каранның берничә шундый мәкаләсе «Милли юл» журналында дөнья күрә.

[78] Камал Г. Тел берләштерәләр // Яшен. 1908. 3 август (№1).

дип яза[79]. Әлбәттә, бу мәкалә юмор аша, көлеп язылган. Әмма аның асылында җәмгыятьтәге бу күренешнең чагылышы ачык күренә.

Гомумән алганда, Төркия уку йортлары татарлар өчен иң якын һәм абруйлы мәктәпләрнең берсе булып тора. Дин берлеге, тел, гореф-гадәтләр охшашлыгы, тарихи, этник һәм мәдәни тамырларның якынлыгы үзенең ролен уйнаган. Моннан тыш, Истанбул уку йортлары татарларны үзләренең чагыштырмача заманчалыгы, Европа тәҗрибәсенә якынлыгы, үзгәрешләргә ачык булуы белән дә тартканнар. Чөнки бу вакытта биредә шактый алдынгы дөньяви мәктәпләр булган, педагогика һәм укытучылык, телләр һәм әдәбият өйрәнүгә зур игътибар бирелгән. Истанбул бу чорда телләр өйрәнү буенча бик көчле үзәкләрнең берсе саналган. Андагы уку йортларында төрек теле белән беррәттән, француз, инглиз һ.б. телләрне бик камил үзләштерергә мөмкин булган. Шуңа да Европа университетларында дөньяви белем алырга теләгән яшьләр, шул илләрнең телләрен өйрәнү өчен Истанбул уку йортларына кергәннәр, җитәрлек дәрәҗәдә телне үзләштергәннән соң, үзләре сайлаган уку йортларына юл алганнар.

## *Фатих Кәрими*

Фатих Кәриминең тормыш юлы һәм эшчәнлеге тирәнтен өйрәнелгән. Истанбул чоры буенча да шактый мәгълүматлар билгеле. Аның Закир ишан (Мөхәммәтзакир Камалов) мәдрәсәсеннән «яшерен рәвештә бер рустан русча укый башлаган, шул рус аркылы «Тәрҗеман» дигән бер газета һәм шушы шәһәрдә чыга торган бер рус газетасы алып, шуны шәкертләргә укый һәм коткы сала башлавы» сәбәпле мәдрәсәдән китәргә мәҗбүр булуы, Уфада берничә кыш укыганнан соң, әтисенең улын Гарәбстанга укырга җибәрергә теләве («Фатихка күп белем кирәк») турындагы мәгълүматларны бертуганы Закирә Шәрәф язып калдырган[80]. Әнисенең Гарәбстанга җибәрергә теләмәве сәбәпле, Фатихны Төркиягә җибәрергә карар кылалар[81]. Бу урында аның әтисе Гыйльман хәзрәтнең улын Истанбулга озатыр алдыннан аңа тапшырган хатын гына кабат искә аласы килә.

«Углым! Мин сине кеше булырга, гыйлем алыр өчен ерак җирләргә җибәрәм. Киләчәктә милләткә файдалы булуыңны телим, сине җибәрүем байлыгым артыктан түгел. [...] Дөньяда яшәргә гыйлем, төзек әхлак, тырышлык кирәк. Бер сәгать гомереңне бушка үткәрмә. [...] Онытма: укырга, өйрәнергә ялкауланма. Атаң-анаңның синең өчен бөтен көчләрен кызганмый иткән хезмәтләренә каршы эштә булсаң, көфране нигъмәт (кадерен белмәү)

[79] Тимербай. Вак-төяк тырышу // Йолдыз. 1906. 1 октябрь.

[80] Шәрәф З. Фатыйх Кәрими // Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык= Фатих Карими: Научно-биографический сборник. Казан: Рухият, 2000. Б. 76–77.

[81] Шунда ук. Б. 77.

булыр. Безне шатландырырлык, киләчәктә илгә йолдыз төсле якты биреп торырлык угыл булып кайтуыңны телибез. Гыйльман Ибраһим углы. Миңлебай, 1892 сәнә»[82].



*Фатих Кәрими 1890 нчы еллар. (https://ru.wikipedia.org /wiki/Карими,_Фатих)*

1892 елда, Истанбул уку йортына керер алдыннан, Ф.Кәрими төрек язучысы Әхмәт Мидхәт белән киңәшләшә. Ул аның «Мөлкия»не сайлавы белән килешә, ләкин укып бетергәч, һичшиксез, ватанына кайтып үз милләтенә хезмәт итәргә тиешлеген әйтә. Соңыннан, хат алышуларда Ә. Мидхәт Ф.Кәримигә сәясәт белән түгел, ә мәгариф мәсьәләләре белән шөгыльләнергә, И.Гаспралы белән якыннан аралашырга киңәш итә[83].

Фатих Кәриминең Истанбулны сайлавында әтисе Гыйльман хәзрәтнең Әхмәт Мидхәт белән яхшы таныш булуы дә сәбәпче булгандыр. Алар электән хатлар алышып торганнар. Шуңа да Әхмәт Мидхәт әфәнде егетне бик якын дустының улы кебек кабул итә. Аның ярдәме белән Фатих игъдадинең ләйли кыйсеменә, ягъни пансионга түләүсез кабул ителә[84].

Шул рәвешле Фатих Кәрими Истанбулда «ул заманның иң алдынгы, гыйлем чишмәсе дип саналган «Гали мәктәбе мөлкия»гә[85] имтихан белән кабул ителә[86]. Истанбулда ул 1892–1896 елларда белем алган.

Кәрими биографиясендәге бу чор турында сакланган кайбер мәгълүматларга килгәндә, әтисенә язган бер хатында аның исеменең Фатих булуы сискәндерүе, хатларны тикшерүләре, монда бу исемне атауның тыелган булуы, үзен укуда «34» номеры белән атаулары

[82] Шәрәф З. Фатыйх Кәрими // Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык= Фатих Карими: Научно-биографический сборник. Казан: Рухият, 2000. Б. 79.

[83] Сибгатуллина А., Тюркоглу. Татары и Османское государство // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань, 2013. С. 349.

[84] Фәйзи Х. Башымнан узган эшләр // Безнең мирас. 2024. №3. Б. 40.

[85] «Әлмәт энициклопедиясе» мәгълүматларына караганда, дәүләт түрәләре әзерли торган бу мәктәпнең тулы исеме «Мәктәбе мөлкия-и шаһанә» була // Альметьевская энциклопедия. URL: https://almet-history.tatneft.ru/personalii/z-l/k/kan-kar/karimi-fatih-gilmanovich?lang=ru (дата обращения: 12.04.2023).

[86] Б.Солтанбәков исә Ф.Кәримине Истанбул университетында укыган дип күрсәтә (Солтанбәков Б. Тапланмас исем // Казан утлары. 1996. № 5. Б. 160).

турында язуы билгеле. Гыйльман хәзрәт аңа хатларда үзен «Сәгыйть» дип атарга тәкъдим итә, үзе исә исемен «Мәсгуть» дип күрсәтә башлый[87].

Истанбулда уку чорында Фатих әдәбият, тарих, филология һәм икътисад буенча алган белемнәрен эзлекле тирәнәйтә, татар һәм төрек телләренә өстәп, гарәпчә, фарсыча һәм французча иркен сөйләшергә һәм язарга өйрәнә[88]. Гыйльман хәзрәт улының укуын дәвам итүенә каршы булмый: «Төркиянең гали мәктәбен яхшы итеп бетереп, имтихан бирсәң, бәлки Яурупаның берәр мәмләкәтенә барып гыйлем алырга теләрсең, Германиягә яки Франциягә, үзең уйлап язарсың. Минемчә, әгәр һөнәр-техник эшләре белән кызыксынсаң, Германиягә, әгәр матур күренеш, әдәбият, көтебханәләр белән кызыксынсаң, Парижга барып. Күбрәк чит телләрне яхшы белеп кайтуың тиеш булыр дип уйлыйм. Сиңа вәгъдә биргәнемчә, расходлык барыр»[89]. Тик Фатих укуын тәмам иткәннән соң зур байлык – ике сандык китап төяп ватанына әйләнеп кайта[90]. Истанбулда үзләштергән гыйлемнәрен татар балаларына белем һәм тәрбия бирүдә, наширлек эшен оештыруда, татар матбагачылыгын оештыруда файдалана.

### *Зыя Насыйри*

Истанбулда югары белем алган татар шәкертләренең тагын берсе – мөгаллим Зыя Насыйри (Зыя Насрый, 1886–1933)[91]. Чыгышы белән Уфа губернасы Корманайбаш авылыннан булган Зыя Троицк, «Галия» мәдрәсәләрендә укыганнан соң, Төркиядә белемен арттыра (1912 елдан соң). Татар матбугатында басылып чыккан мәкаләләрендә чит илләрдә, аерым алганда Төркиядә белем эстәгән татар яшьләренең тормышын, яшәешен тасвирлый. Зыя Насыйри үзенең «Йолдыз» газетасында дөнья күргән «Истанбул мәктүбе» дигән мәкаләсендә татар студентлары тормышының кайбер сәхифәләрен яктырта. Казаннан Истанбулга килгән татар сәүдәгәре хаҗи Галәметдин әфәнде Ибраһимовның русияле фәкыйрь таләбәләр файдасына иганә ясавы турында хәбәр итә[92].

---

[87] Шәрәф З. Фатыйх Кәрими // Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык= Фатих Карими: Научно-биографический сборник. Казан: Рухият, 2000. Б. 81–82.

[88] Солтанбәков Б. Тапланмас исем // Казан утлары. 1996. № 5. Б. 160.

[89] Шәрәф З. Фатыйх Кәрими // Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык= Фатих Карими: Научно-биографический сборник. Казан: Рухият, 2000. Б. 79.

[90] Шунда ук. Б. 84.

[91] Зыя Насыйровның туган һәм вафат булган еллары төрле чыганакларда төрлечә күрсәтелгән: И.Рәмиев мәгълүматлары буенча, ул 1886–1933 еллар булса (Рәмиев И., Даутов Р. Б. 187), «Татар педагогик фикере антологиясе»ндә 1889–1937 еллар искә алына (Б. 111).

[92] Насыйри З. Истанбул мәктүбе // Йолдыз. 1914. 23 май.

Автор хәтта бай гаиләдән чыккан шәкертләрнең дә авырлыклар белән очрашуы, ватаннан акча килеп җитмәү сәбәпле укуларына зыян килү, дәреслекләр ала алмавы турында борчылып яза: «Ватанга, милләткә хезмәт өчен горбәт җирендә бу кадәр агырлыкларны күтәреп, тәхсил итәләр, милләт тә алардан хезмәт көтә». Шуңа да, җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итеп, «химаять ияләре (ярдәм итә алучылар) дә, акча күндерәчәк кешесе булмаган фәкыйрь таләбәләремезне хәтердән чыгармасалар, бик зур инсаният кылган булачакларына һич шөбһә юктыр», – дип яза. «Мәмләкәткә кайтып, Ватанга вә милләткә файдалы хезмәтләр күрсәтәчәкләре бик өмидле» булган татар яшьләренә ярдәм итәргә чакыра[93].

Ватанга кайтканнан соң, Зыя Төркестанда, Уфа губернасы авылларында балаларга белем бирә, революциядән соң Оренбургта сәяси курслар җитәкчесе булып эшли, Мәскәү үзәк халык мәгарифен оештыручылар институтында, Казан көнчыгыш педагогия институтында белем ала, Институт каршында оештырылган рабфакның директоры була[94]. Аның мәктәп укучылары өчен язылган дәреслекләре[95] татар балаларына белем һәм тәрбия бирүдә файдаланылган. Зыя Насыйри милләтенең өметен аклый, авырлык белән чит-ят җирләрдә алган белемнәрен тулаем халкына багышлый.

## *Харис Фәйзи-Чистапули*

Харис Зариф улы Фәйзуллин 1871 елда Чистай өязе Шахмай авылында туа. Яшьли ятим кала. Чистай мәдрәсәсендә укый, рус гимназиясенә керә алмый. 1891 елда Төркиядә белем алу нияте белән, паспорт алып, ватаныннан чыгып китә[96].

Истанбулда Казаннан килгән шәкертләр һәм фәкыйрь юлчылар өчен бер Казан бае салдырган махсус йортка – Казанлы тәкиясенә урнаша. Бу бик уңайлы булган, чөнки матди мөмкинлекләре чикле булган шәкертләр анда үзләре теләгән кадәр түләүсез яши алганнар. Икенче көнне Г.Барудиның шәкерте – ысул җәдит белән танышу өчен килгән Җиһангир хәлфә фатирына барып урнаша. Бу йортта шулай ук Галимҗан хәзрәтнең туганы Габдрахман Пороховый (Галиев), Нургали хәзрәт улы Мөхәммәт һәм Күгәрчен Габдрахман яшәгән.

[93] Насыйри З. Истанбулдан. Читтә укучы шәкертләремез ни хәлдә? // Вакыт. 1914. 4 апрель.

[94] Татар педагогик фикере антологиясе. Ике томда. Т. 2. Казан: Татар.кит.нәшр., 2016. Б. 111.

[95] Насыйри З. Мәктәп кызларына уку. Кыз балаларына махсус ибтидаи сыйныфлар өчен тәртип ителде. Казан: Кәримов, 1911. 56 б.; Насыйри З. Хисап мөгаллиме. 1 кис. Ибтидаи мәктәпләрнең 1 сыйныфлары өчен. Казан: Кәримов, 1908. 39 б. һ.б.

[96] КФУның Н.Лобачевский ис.Фәнни китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 2т ф., бәйл. 1–4.




*Харис Фәйзи-Чистапулинең шәкерт вакыты (https://faizy.ru/haris-fayzi/)*



*Харис Фәйзи Истанбулда. 1895 ел*[97]

Истанбулда Харис «Дареттәгълим» дигән мәктәпкә[98] йөри башлаган. Аның фатирдашлары исә «Дареттәдрис» дип исемләнгән уку йортына йөргәннәр һәм уку өчен 10 грош 80 тиен акча түләп торганнар. «Дареттәгълим»дә уку хакы арзанрак була – 5 грош 60 тиен[99]. Сарыф, мантыйк, нәхүне Чистай мәдрәсәсендә яхшы гына үзләштерүенә карамастан, егетне 1 нче сыйныфка кына алалар. Бу мәктәптә төрекчә язылган гарәп сарыфы белән хисап фәне генә укытылган. Хисап курсын Харис рус мәктәбендә укыганда узган була[100]. Ләкин анда дөньяви фәннәр укытыла торган хөкүмәт мәктәбенә кереп уку теләге зуррак булган. Чөнки, үзе язуынча, «Истанбулга барудан максатым – урыс мәктәпләре кебек төрле фәннәр укытыла торган низамлы хөкүмәт мәктәбендә уку», тик «ул вакытта хөкүмәт мәктәбенә шәкерт кабул ителмәгәнлектән, бер ай кадәр чарасыз йөрергә» мәҗбүр була[101]. Кырым татары мөгаллим Хаҗи Ногман егетне үзе идарә иткән рөшди[102] мәктәпнең 2 нче сыйныфына урнаштыра. Бу мәктәп, Х.Фәйзи язуынча, Истанбулның Даут паша

[97] КФУ КСКБ, 2т ф., бәйл. 46.
[98] Фаразлавыбызча, бу мәктәп кечерәк кенә шәхси белем йорты булган.
[99] Фәйзи Х. Башымнан узган эшләр // Безнең мирас. 2024. №3. Б. 38.
[100] Шунда ук. Б. 39.
[101] Шунда ук.
[102] Рөшди мәктәп, рөшдия – урта мәктәп.


دولت علیهٔ عثمانیه

شهادتنامه‌سی

*Харис Фәйзинең Истанбулдагы «Госмания» мәдрәсәсен тәмамлавы турындагы шәһадәтнамәсе*[103]

[103] КФУ КСКБ, 2т ф., бәйл. 13.

мәхәлләсендә урнашкан була, һәм ул эчтәлеге белән Россия гимназиясенең 4 сыйныфы дәрәҗәсенә туры килә. Мәктәп гомумән алганда егетне канәгатьләндерми, әмма ул шулай да, программада үзе белмәгән әйберләр булу сәбәпле, язга кадәр анда укуын дәвам итә[104]. 1891 елда Истанбулга укыр өчен Гобәйдулла Буби белән Фатих Кәрими килә, алар бергәләп имтиханнарга әзерләнеп[105], игъдади[106] мәктәпнең 1 сыйныфына керәләр[107]. Харис, пансионга керү өчен елына 300 сум кирәк булу, ватаныннан аның кадәр акчаны җибәрүләренә ышанычы булмау сәбәпле, нәһаре игъдадине[108] сайлый[109].

Укуга түләү мәсьәләсен хәл итү өчен Харис Фәйзи укытучыга ярдәмче булып эшли. Имтиханда бер сыйныфтан икенче сыйныфка гына күчеп калмый, тырышлыгы аркасында сыйныфтагы иң алдынгы 4 шәкертнең берсе була, мөкяфәткә[110] ия була – Солтан Гаидел Хәмиттән бүләккә алтын сәгать алуга ирешә. Игъдадине тәмамлап, «гали әл-әгълә» (иң югары) дәрәҗәдә шәһадәтнамә ала[111].

Төркиядә уку чорында Х.Фәйзи милли-сәяси мәсьәләләр белән дә кызыксына башлый, язучы Әхмәт Мидхәт, фәлсәфәче Җамалетдин әфәнде белән таныша, төрек телендә басылган китапларны һәм газеталарны укый. Үз алдына бәлки шунда калырмын, дигән уйны кертә. Ләкин Әхмәт Мидхәтнең сүзләрен истә тотып, ватанына кайтырга карар кыла: «Ул безгә һәрвакыт Төркиядә калмаска, Русиягә кайтып, татар халкына, татар милләтенә хезмәт итү турында киңәшләр бирә иде»[112]. 1897 елда «Хөсәения» мәдрәсәсеннән чакыру алганнан соң, Харис Фәйзи Россиягә кайта һәм педагогик эшчәнлеген башлап җибәрә, математика, физика, геометрия, география, тарих кебек фәннәрне укыта башлый. Белемен арттыру максатыннан, 1899 елда Мәскәүгә барып бухгалтерлык курсларын тәмамлый[113].

Х.Фәйзи, Төркиядә белем алган, 6 ел яшәгән кеше һәм беренче чиратта педагог буларак, Төркиядә татар балаларының белем алулары, дәреслек һәм уку китаплары, уку теле кебек мәсьәләләр буенча фикерләрен татар матбугатында белдереп барган. «Садретдин бәккә хитап» дигән мәкаләсендә ул Истанбулда басылган китаплар буенча дәрес бирү, Истанбулда татарлар өчен адаптацияләнгән махсус уку йорты ачу, бу мәсьәләләрне хәл итү буенча

---

[104] Фәйзи Х. Башымнан узган эшләр // Безнең мирас. 2024. №3. Б. 39–40.
[105] 2 ай дәвамында Сәедкый әфәнде исемендәге мәдрәсә шәкертеннән хосусый рәвештә дәресләр алалар (Фәйзи Х. Башымнан узган эшләр // Безнең мирас. 2024. №3. Б.40).
[106] Игъдади мәктәп, игъдадия – югары мәктәпкә әзерлек бүлеге.
[107] КФУ КСКБ, 2т ф., бәйл. 1–4.
[108] Нәһаре игъдади – югары белем алуга әзерли торган көндезге мәктәп.
[109] Фәйзи Х. Башымнан узган эшләр // Безнең мирас. 2024. №3. Б. 40.
[110] Мөкяфәт – бүләкләү, эшне бәяләү.
[111] Фәйзи Х. Башымнан узган эшләр // Безнең мирас. 2024. №3. Б. 41.
[112] Шунда ук. Б. 42.
[113] КФУ КСКБ, 2т ф., бәйл. 15.

Мәгариф министрлыгында махсус кеше билгеләү кебек проблемаларга туктала. Башлангыч мәктәптә ана телендә белем биреп, рөшдидән соң һәм галия мәдрәсәләрдә генә төрек телендә язылган дәреслекләрне файдалану уңышлы булачак дигән фикерне җиткерә. Аның фикеренчә, башлангыч чорда татар балалары өчен һәм татар, һәм төрек сүзләреннән гыйбарәт булган махсус шивә булу мөһим[114].

Харис Фәйзи-Чистапули татар мәгарифе тарихына туган телдә язылган[115] дәреслекләр авторы буларак кереп калды. Аның «Тәгьлим җәгърафия» (Казан, 1903), «Ысул җәгърафия» (Казан, 1911), «Рәһбәре имля» (Казан, 1914), «Мәдхәле җәгърәфия» (Казан, 1908), «Хөласа-и тарих гомуми. Беренче кыйсем» (Казан, 1903), «Гыйльме әшья» (1910) кебек әсбаплары мәдрәсәләрдә кулланылган[116].

[114] Фәйзи Х. Садретдин бәккә хитаб // Өлфәт. 1906. 26 июнь.

[115] Араларында рус теленнән тәрҗемә ителгәннәре дә бар.

[116] Татар педагогик фикере антологиясе. Ике томда. Т. 2. Казан: Татар.кит. нәшр., 2016. Б. 146.

## Бәйруттагы Америка көллияте

*«... монда да*
*татар әдәбияты вә татар матбугаты барлыгын*
*исбат кыласымыз килә...»*
(«Вакыт»)

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында Истанбул, Бәйрут, Каһирә кебек шәһәрләрдә мөселман яшьләре өчен Америка уку йортлары ачыла башлый[1]. Бәйруттагы Америка көллияте (колледжы) – бу чорда татарлар арасында иң популяр уку йортларының берсе була. 1866 елда Америка миссионерлары тарафыннан ачылган әлеге хосусый уку йорты[2] 1920 елда университет статусын ала. Белем бирү философиясе Америка университетларына тәңгәл килсә дә, программасы Якын Көнчыгыш ихтыяҗларына юнәлтелгән бу уку йортының теге яки бу дини оешма белән рәсми бәйләнешләре булмый[3]. Уку йортының төп идеологиясе – барлык кешеләргә, аларның социаль чыгышлары, тән төсе (расасы), милләте һәм диненнән бәйсез рәвештә белем бирүдән гыйбарәт була. Укучылар, нинди диндә булуларына карамастан, барысы бергә «әчке кыяфәте белән театрны хәтерләткән христиан гыйбадәтханәсендә лекцияләр тыңлаганнар»[4].

Америка көллиятендә белем алган татар яшьләре арасында Борһан Хәбиб[5], Троицкидан Закир Бакиров[6], Оренбург якларыннан Габдулла Газизов (матбугатта Сакмарый тәхәллүсе белән билгеле), күренекле татар мәгърифәтчесе Фәхрелбәнат Сөләйманиянең улы Габдулла Сөләйманов (1886–1937), Закир Габдуллин, Фазыл Бәкер, Фатих Әмирханның бертуган энесе Ибраһим Әмирханов (1889–1938) һ.б. бар. Моннан тыш, татар яшьләре Бәйруттагы башка уку йортларында да укыганнар. 1908 елда Бәйрут шәһәрендә укучы татарлар арасында «Америка миссионерларының тәрбиясендә булган «Мәдрәсәи көллият»тә 3, Франция миссионерлары тарафыннан ачылмыш «гимназия»дә 1 татар шәкерте» була[7]. 1909–1910 еллар тирәсендә, мәсәлән, көллият-

---

[1] Кәримуллин Ә. Америка татарлары тарихыннан // Казан утлары. 1990. №1. Б. 168.

[2] Ачылган вакыттагы исеме «Сүрия протестант көллияте».

[3] URL: https://propedia.org/ru/topic/2309414-pamerikanskii-universitet-beiruta-universitet-beirut-livan (дата обращения: 12.11.2022).

[4] Расих А. Внук ишана. Казань: Татар.кн.изд-во, 2016. С. 183.

[5] «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Б.Хәбиб Бәйрутта укый, «Мөхәммәдия»дә физика, химия фәннәреннән шәкертләргә белем бирә. 1917 елда И.Габитов, Г.Баруди һәм Г.Баттал белән бергә Ташкент шәһәрендә татар һәм үзбәк телләрендә «Шураи Ислам» газетасын оештыруда катнаша, шунда ук мәгариф институтында укыта (Урманче Б. «Мөхәммәдия» // Безнең мирас. 2022. № 9. Б. 34).

[6] Расих А. Внук ишана. Казань: Татар.кн.изд-во, 2016. С. 183.

[7] [Шәрык, гарәп галәме ...] // Әл-ислах. 1908. №39. Б. 8.

тә барлыгы 8 татар кешесе белем алган[8]. Ә 1913 елда укучылар саны 11 булган[9].

Көллияттә рәсми укыту теле инглиз теле булу сәбәпле, анда кереп укыр өчен иң беренче чиратта татар мәдрәсәләрендә гыйлем туплаган яшьләр өчен бөтенләй чит булган әлеге телне тирәнтен өйрәнү кирәк булган. Гарәп телен дә яхшы белү таләп ителгән, чөнки укытучыларның күпчелегенең аралашу теле гарәп теле булган[10]. Габдулла Газизовның[11] «Вакыт» газетасына юллаган бер мәкаләсендә Бәйрут колледжында уку шартлары турында сүз бара. Биредә уку өчен телләр, аеруча Ливандагы гарәп телен (ягъни шул сөйләшне) белүнең әһәмиятен ассызыклап, ул: «Безнең Русия мәдрәсәләрендә икән ун ел кадәр гарәпчә дип укыган нәрсәләребез мондагы гарәпчә берлән, икенче төрле әйткәндә, гарәпләр сөйләшкән тел берлән һич алыш-белеше юктыр»[12], – ди.

Көллияттә укучы студентлар – алар арасында төрле милләт вәкилләре: яһүдләр, әрмәннәр, руслар һ.б.лар булган – һәрберсе үз телләрендә язылган китапханәләрен яисә китап киштәләрен булдырганнар. 1914 елда татар студентлары да шундый бер «татар китапханәсе» ачарга карар кылалар. Бу эшнең төп максаты, шәкертләр фикеренчә, «милли әдәбият вә милли әфкяр (фикерләр) гомумидән хәбәрдар булып тору өчен хезмәт итә, икенче җәһәттән дә шул милләтләрнең әдәбиятлары барлыгын белдереп торадыр»[13]. Ягъни, беренчедән, әлеге китапханә аша милләт һәм ватан хәбәрләре белән танышып торылса, шул ук вакытта ул татарларны башка милләт вәкилләре арасында да үзләрен күрсәтергә, танытырга мөмкинлек бирәчәк. «Вакыт» газетасында дөнья күргән мәкаләнең авторы – Бәйрут көллияте студенты (исемен атамый) болай дип яза: «Моннан алты ел элек (ул вакыт көллияттә минем беренче елым иде) көллият профессорларыннан берсе миннән: «Сезнең матбугатыгыз бармы? Татарлар нинди хоруфат (хәрефләр) белән язалар?» – дип сорар иде. Мин гарәп хоруфаты белән дигәч, бик гаҗәпсенде. Ул да, күрәсең, шул көнгә кадәр татар әдәбияты барлыгын белмәгән. Инде без бу китапханәбез белән монда да татар әдәбияты вә татар матбугаты барлыгын исбат кыласымыз килә»[14].

[8] Бәйруттан. Бер мәктүб // Вакыт. 1911. 22 июль.
[9] Бәйрутта татар таләбәсе // Вакыт. 1914. 22 гыйнвар.
[10] Көллият ачылган вакытта анда укыту теле күпчелек укучылар өчен туган тел булган гарәп теле булган. Шәкертләр шулай ук госманлы төрек, француз һәм инглиз телләрен дә белергә тиеш булганнар. 1887 елдан инглиз телендә укытыла башлый.
[11] Язмада ул Сакмарлы дип искә алына. Сакмарый буларак та билгеле.
[12] Бәйруттан. Бер мәктүб // Вакыт. 1911. 22 июль.
[13] Бәйрутта татар таләбәсе // Вакыт. 1914. 22 гыйнвар.
[14] Шунда ук.

Көллият төрле милләт, төрле дин вәкилләренең бер-берләрен тану, күрсәтү, аралашулары өчен дә мөмкинлекләр тудырган. Төрле бәйрәм вакытларында башка милләт вәкилләренең үз туган телләрендә нотыклар сөйләгәнен күреп, татарлар да татар телендә китап һәм матбугат чараларын файдаланып, чыгыш ясауны максат итәләр. Моннан тыш, бу көллиятнең миссионерлар тарафыннан ачылуы сәбәпле, анда төп игътибар христиан диненә бирелгән, һәм әлбәттә, шул темаларга чаралар үткәрелгән. Татарлар, моңа җавап итеп, ислам диненә багышланган төрле кичәләр үткәргәннәр: «Киләчәктә дә бу хакта һәм дә татар милләтенең ни рәвеш тәрәккый итүе хакында үземездә бер-ике мәртәбә конференция бирергә уйлыйбыз»[15]. Шул рәвешле, читтә яшәгән хәлдә алар татар булып калганнар, ислам диненә һәм ватанына тугрылык саклаганнар, милләтен үстерергә, аны башкалар арасында танытырга тырышканнар.



*Ибраһим Әмирханов Бәйрутта укыган чорда. 1911 ел (ТР ФА Г.Ибраһимов ис. тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге)*

Көллияттә бик күп юнәлешләр – медицина, эшмәкәрлек нигезләре, авыл хуҗалыгы, төзелеш, архитектура һ.б. буенча белем алырга мөмкин булган. Телләр өйрәтүгә аеруча зур игътибар бирелгән. Шуңа күрә дә анда укып кайткан татар шәкертләре чит илләрдә дә яхшы гына эшли алганнар. 1908–1914 елларда Бәйрут көллиятендә белем алган[16], татарлар арасында беренче совет дипломатларының берсе Ибраһим Әмирханов, мәсәлән, бу уку йортында алган белемнәре – гарәп, инглиз, төрек телләрен яхшы үзләштерүе нәтиҗәсендә 1924–1926 елларда Согуд Гарәбстанында СССР консуллыгында уңышлы гына хезмәт куя[17].

Икенче бер татар шәкерте – Әхмәтзыя Тупеев (1885–1946), чыгышы белән Уфа губернасының Бөре өязе Өчбүлә авылыннан, мәдрәсә тәмамлаганнан соң, яхшы дөньяви белем алу максаты белән Госманлы дәүләтенә китә һәм Бәйрут көллиятенә укырга керә. Биредә ул табигать фәннәре факульте-

[15] Бәйрутта татар таләбәсе // Вакыт. 1914. 22 гыйнвар.

[16] Багаутдинов Ф.Н. Младший брат Фатиха Амирхана // Научный Татарстан. 2013. № 1. С. 88.

[17] Ахметова Д.И. Фатих Амирхан в фотографиях. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 21.

тында укый. Россиягә кайткannan соң, күп кенә чит мәмләкәтләрдә белем алган студентлар кебек, белем турындагы таныклыгын (дипломын) якларга туры килә. Революциягә кадәр аз гына вакыт аралыгында мулла булып ала, совет чорында укытучылык итә, Уфадагы 15 нче татар мәктәбенең директоры була[18].



*Әхмәтзыя Тупеев – Бәйруттагы Америка көллияте шәкерте (https://dzen.ru/a/Yx4BSH5slkTg4enX)*

Чит ил уку йортларына татар яшьләрен җибәрүдән төп максат – заманча белемнәргә ия булган, милләтнең алга таба үсешен тәэмин итәрлек белгечләр әзерләү була. Бу эшнең матди ягын татар байлары, иганәчеләр күтәргән. Алар Бәйрут көллиятендә укып кайткан яшьләрне күп очракта яхшы әзерлекле дин эшлекләре буларак күрергә теләгәннәр. Троицк шәһәрендәге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллиме Нияз Максудовны да (Нияз Мөхәммәтхаҗи улы Вилданов) сәүдәгәр Яушевлар, «муллалыкка укырга җибәрәбез дип», Бәйрутка юллыйлар. Ләкин Максудов Бәйруттан, алар күзаллаганча, «мулла булып кайтмый, Аляфранкка (Европага) китеп[19], чалма урынына, эшләпә киеп кайта. Футбол уйнарга өйрәнгән була. Шәкертләрне футбол уйнарга өйрәтә»[20]. Билгеле булганча, ул татар яшьләренә дөньяви белемнәр бирүне алга сөрә, 1915 елда Троицкида ачылган дарелмөгаллиминнең (башта «Вазифа» исеме белән йөртелә) оештыручысы да Нияз Максудов була[21]. 1918 елда Н.Максудов, укуын дәвам иттерү нияте белән, Владивосток

[18] Габдрафикова Л. Его звали Ахметзия Тупеев, и он был... URL: https://dzen.ru/media/liliyagabdrafikova/ego-zvali-ahmetziia-tupeev-i-on-byl-631e01487e6c9644e0e1e9d7 (дата обращения: 13.04.2023).

[19] «Аляфранкка (Европага) китеп» – мөгаен, бу урында текстны укуда ялгышлык киткән, фаразлавыбызча, дөресе «а-ля франка киеп» (ягъни европача киенеп) булырга тиеш.

[20] Мөхәммәтшин З. Көньяк Урал татарлары XX гасыр башы матбугатында, шәҗәрәләрдә // Милли-мәдәни мирасыбыз: Чиләбе өлкәсе татарлары. 2 нче басма. Казан, 2021. Б. 394.

[21] Денисов Д.Н., Хабутдинов А.Ю. Формирование и эволюция мусульманских общин Троицка и Челябинска в конце XVIII – начале XX века // Tatarica. 2021. Вып. 17. С. 98.

аркылы Америкага китә. Ләкин ватанына кире әйләнеп кайтырга насыйп булмый. Укуын тәмамлаганнан соң[22], Максудов Нью-Йоркта Шәрык факультетында декан булып эшли[23]. Аның исеме Нью-Йоркта 1927 елда оешкан «Мөселман берлеге» базасында ачылган «Америка татарлары ассоциациясе»н оештыручылар арасында очрый[24].

Әйтеп кителгәнчә, Бәйрут көллияте татар яшьләрен иң күп җәлеп иткән уку йортларының берсе булган. Анда укырга күпләр омтылыш ясаган. Күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм галим Зәки Вәлидинең дә әлеге Америка көллиятенә керергә теләге булганлыгы мәгълүм, тик ул, ни сәбәп беләндер, Бәйрутка бармый кала[25].

## *Габдулла Газизов (Сакмарый)*

XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында чит мәмләкәтләр һәм милләтләр, татар студентларының тормышына багышланган күп санлы мәкаләләр – юлъязмалар белән чыгыш ясаган яшьләр арасында Сакмарый (Сакмарлы) тәхәллүсе белән билгеле булган Габдулла Газизовны аерып күрсәтергә мөмкин.

Габдулла Кәлимулла улы Газизов турында мәгълүматлар күп түгел. Шулай да, булган чыганакларга таянып, аның атаклы татар педагогы, киң җәмәгатьчелек арасында «Лотфулла учитель» исеме белән билгеле булган Лотфулла Газизовның бертуган энесе икәнлеген фаразларга мөмкин. Мәхмүт Бөдәйли үзенең «Псевдонимнар сүзлеге»ндә[26] Габдулланың Сарыкташ[27] авылында тууын искәртә. Ливанның башкаласы Бәйруттагы Америка көллиятендә укып кайтканнан соң, Габдулла Газизов Троицк шәһәрендә миллионер Яушевларның кызына өйләнә һәм Яушевлар мәдрәсәсенә мөгаллим булып урнаша. Революциядән соң Россиядән күченеп китә, Харбин шәһәрендә «Мең

---

[22] Нью-Йорк университетының педагогика факультетында укыганлыгы хакында мәгълүмат очрый.

[23] Мөхәммәтшин З. Көньяк Урал татарлары XX гасыр башы матбугатында, шәҗәрәләрдә // Милли-мәдәни мирасыбыз: Чиләбе өлкәсе татарлары. 2 нче басма. Казан, 2021. Б. 395.

[24] Садыкова Л.Р. Сохранение и трансформация этнокультурной идентичности в условиях эмиграции: на примере «Тюрко-татарской» диаспоры США. Автореф. ... канд. ист. наук. Ижевск, 2012. С. 20.

[25] Габдрафикова Л. Его звали Ахметзия Тупеев и он был... URL: https://dzen.ru/media/liliyagabdrafikova/ego-zvali-ahmetziia-tupeev-i-on-byl-631e01487e6c9644e0e1e9d7 (дата обращения: 13.04.2023).

[26] КФУ КСКБ, 2501 т.

[27] Татар Сарыкташы – Сакмар елгасы буендагы татар авылы, Оренбург өлкәсенең Сарыкташ районында урнашкан.

ел» дигән бер көнлек газета чыгаруда катнаша[28]. Кызганычка каршы, шуннан соңгы тормышы һәм эшчәнлеге турында әлегә мәгълүматлар табылмады.

Габдулла Газизов, шул заман рухына тугры калып, Бәйрутта белем алган чорында үзе укыган уку йорты, Бәйрут, якын-тирәдәге башка гарәп илләре һәм анда яшәгән халыклар турында мәкаләләр язып, аларны татар вакытлы матбугатында бастырып чыгара. Шундый бер мәкаләсе «Вакыт»та дөнья күрә[29].

Әлеге язмада автор үзенең Бәйрутка ни рәвешле барып чыгуын тәфсилләп сөйли. Алдан ук шушы уку йортына кереп укуны максат итүе турында яза. Шуның өчен ул Казанда торганда бер кыш кадәр «аттестат зрелости» курсларында укый, учительлек шәһадәтнамәсен ала. Хисап кебек фәннәрне яхшы белүе сәбәпле, алардан азат ителеп, төп игътибарны инглиз телен өйрәнүгә бирә. 8 ай эчендә инглизчә газета-журналлар укый алырлык дәрәҗәгә җитә.

Бу кадәр җентекләп язуның максатын башка чыганаклардан мәгълүмат алу мөмкинлеге чикле булган заманда татар яшьләренә белем алуда юл күрсәтү, милләтнең киләчәге өчен борчылу дип карарга кирәк. XX гасыр башында татар вакытлы матбугаты шундый зур миссияне үтәгән.

Сакмарый Истанбулда бер атнага тукталып, өйдән чыгуына 35 көн дигәндә Бәйрутка барып җитүе турында яза. Бу вакытта көллияттә укулар башланган була, шулай да аны кабул итәләр, чөнки уку йорты уку елы дәвамында яңа укучылар белән тулыланып торган. Бу яктан ул, Г.Газизов билгеләвенчә, татар мәдрәсәләрен хәтерләтә. Казанда алган учительлек шәһадәтнамәсе аңа көллияткә укырга керергә мөмкинлек бирә. Әлеге мәктәпнең уңай якларын тасвирлап, ул аның беркайда да язылмаган, әмма һәр студентның күңеленә уелган девизын китерә: «Эшлә яки үл! Хәзер эшлә! Кулыңнан килгәннең иң яхшысын эшлә! Тырышып кара!» Шуңа күрә дә ул, автор фикеренчә, «безнең өчен истикъбаль (киләчәк) кояшлары шушы мәктәптән чыкса, гаҗәп түгел», «бу мәктәп һәр мәктәптән файдалы, безнең милләтне аякка бастыру өчен шушы мәктәп кешеләре күбрәк кирәк», дип саный.

Көллиятнең татарлар өчен файдалы булган тагын бер ягы, автор фикеренчә, аның дини белем бирүгә үзенчәлекле, фәлсәфи якын килүендә. «Боларның (дин мөгаллимнәренең) дәресләреннән соң дин хакында шундый бер фикер хасыйл була ки, динне кешене һәрбер рәхәтеннән, хөрриятеннән манигъ (киртә) итә торган бер вәһми (хыялга бәйләнешле) нәрсә дип карамый, бәлки аны кешенең сәгадәт вә рәхәте өчен лязем булган бер практический нәрсә дип карый башлыйсың. [...] Дәлилләр турыдан-туры хәяттан вә дөньяви

---

[28] Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Псевдонимы в татарской литературе / төз.: Л.Ш.Гарипова, Г.Н.Зәйниева. Казан: ТӘһСИ, 2021. Б. 57–58.

[29] Бәйруттан. Бер мәктүб // Вакыт. 1911. 22 июль.

шәйләрдән китерелә. Боларның динне реальный бер нәрсә итеп тануга вә дини фикернең галиләнүенә күп файдасы барлыгында шөбһә юк. Бу вакытта инсанның күз алдына дин берлән дөнья дигән бер-берсенә дад (зар) ике нәрсә урынына сәгадәт дигән бер генә нәрсә килә башлый». Ләкин көллиятнең мөселман уку йорты булмыйча, миссионерлар тарафыннан нигезләнгән булуын да искәртеп узу кирәк. Г.Газизов бу хакта үзе дә искә ала, Бәйруттагы Америка көллияте турында сүз чыкканда, беренче чиратта аның миссионерлар тарафыннан ачылуын игътибарга алып, шикләнебрәк карыйлар, ди. Ләкин чынлыкта аның максаты – кешене теге я бу дингә чыгару түгел, ә «бәлки һәркемгә хакыйкатьне эзләргә бер куәт салмактыр».

Автор көллият тормышына бәйле берничә мисалны китереп уза. Уку йортының «гыйльмия шөгъбәсен» тәмамлап шәһадәтнамә алган бер татар егете[30] турында сөйләгәндә, ул аның бирегә килгәнче өч-дүрт ел мөгаллимлек иткән булуы, көллиятне биш ел эчендә тәмам итүе турында гаҗәпләнеп һәм бер үк вакытта сокланып хәбәр итә. Чөнки ул шул арада көллияттә укырлык дәрәҗәдә чит телне үзләштергән. Һәм иң мөһиме – шушы тырышлыгы белән ул «көллият идарәсенә татарларны иҗтиһадлы вә фигъли (эшчән, эшлекле) бер милләт танытмыш». Шуңа да, Газизов фикеренчә, «хәзер көллият һәйәт идарәсе татар шәкертләрен бик яхшы күз берлән карый. Алар хакында һәрбер мөмкин булган җиңеллекне эшләргә тырыша». Шул рәвешле, тырышып укыганда үзеңне генә түгел, милләтне дә күрсәтергә мөмкин дигән фикерне үткәрә. Истигъдадны тәмамлап документ алган татар егетләренең берсе сәүдә, икенчесе гыйльми яки мөгаллимнәр курсына китергә уйлыйлар, ди. Г.Газизов кыш буе истигъдадиядә инглизчә укып, тиешле фәннәрне әзерләп, язын гыйльмия бүлегенә керергә тели, әмма инглизчәне биреп тә, җәбер (алгебра) буенча имтиханын бирә алмый. Шул сәбәпле җәй буе әзерләнеп, көзен алгебрадан кабат имтихан тапшырырга уйлавын җиткерә.

Көллияттә укучы татар шәкертләре моңа кадәр татар газета-журналлары булмау сәбәпле, татар дөньясы хәбәрләре белән танышып бара алмаганнар. 1911 елда көллият аларга махсус урын биреп, Россия мөселманнарының матбугатын урнаштыру мөмкинлеген тудырган[31].

Америка көллиятендә белем алган чорда Сакмарый Госманлы дәүләте шәһәрләрендә, аерым алганда Шамда (Димәшкъ), Бәгальбәктә сәяхәттә була һәм әлеге сәяхәт вакытында күзәткәннәрен татар укучысы белән уртаклаша. Аның әлеге уй-фикерләре вакытлы матбугатта басылган язмаларында чагылыш таба.

Г.Сакмарыйның Сүриянең төрле шәһәрләрендә яшәүче халыкның мәдәни тормышын, аның борынгы тарихын, илдәге сәясәтне, уку-укытуның торышын яктыртып язган «Шам хатирәте», «Сүрия әхвале», «Шамнан Бәгальбәккә» дигән юлъязмалары 1913–1914 елларда «Шура» журналы битләрендә

[30] Кызганычка каршы, автор аның исемен күрсәтми.
[31] Бәйруттан. Бер мәктүб // Вакыт. 1911. 22 июль.

басылып чыккан. Әлеге язмалары аша ул чын мәгънәсендә «гаҗәеп кызыксынучан, киң эрудицияле, кешеләр белән тиз уртак тел таба алучы зыялы шәхес буларак күз алдына килә»[32]. Авторның язмаларыннан аңлашылганча, ул татар, рус телләреннән тыш, инглиз, төрек, гарәп, француз телләрен белгән, тарих буенча киң мәгълүматларга ия булган. Сүриянең бик борынгы тарихына караган сәхифәләрне тасвирлауда гаять бай һәм кызыклы, документаль характердагы материаллардан файдалануы шуны раслый.

Сакмарыйның «Шам хатирәте» исемле язмасы «Шура» журналының 1913 елгы 18–24нче; 1914 елгы 1–3 нче саннарында басылып чыга. Дөньяның иң борынгы, мәшһүр шәһәрләреннән берсе булган Шам (аны зурлап Шамшәриф дип тә атаганнар) тарихын сурәтләгәндә атаклы Көнчыгыш гыйлем ияләре, шулай ук Америка, Европа язучылары (мәсәлән, Марк Твен) фикерләренә таяна. Үзе дә әлеге гүзәллекләргә соклануын күрсәтә, әмма, шул ук вакытта, «безнең Сакмар, Агыйдел вә Дим буйларыннан матуррак түгел», – дип белдерә[33]. Автор шәһәрдә сәүдә һәм сәнәгать үсеше, мәктәп-мәдрәсәләр һәм китапханәләр тарихына бик җентекле туктала. Аның фикеренчә, Шамның элеккеге мәктәп-мәдрәсәләре мәшһүр Багдад уку йортларыннан гына калышканнар[34]. Сакмарый мәгълүматлары буенча, андагы иң билгеле уку йортларыннан «Мәдрәсәи Госмания»дә бер татар шәкерте укырга кергән булган, ләкин тәмам итмәгән[35]. Сакмарый «хәлифәләр заманыннан ук билгеле булган тарихи шәхесләрнең, исламда изге саналган затларның каберләрен зиярәт итеп, хәзер инде үткәндәге бөеклек, дан белән генә яшәргә ярамый, яшәеш, тормыш башканы таләп итә, аның өчен дөньяви белемнәр, фәннәрне үзләштерергә кирәк дип искәртә. Алга киткән Европа илләрен үрнәк итеп китерә, андагы цивилизациянең үсешен, уку-укыту системасының югары дәрәҗәдә куелышын ассызыклый»[36].

«Шам», «Шамда мөһаҗирләр» дип исемләнгән бүлекләрдә тәкъдим ителгән мәгълүматлар безнең өчен аеруча зур кызыксыну тудыра. Биредә Шамның Салихия дип аталган өлешендә яшәгән татарлар, аларның яшәеше, Россиядән килгән хаҗиларны каршы алучы Талип ага, аның тормышы, гаиләсе турында үтә кызыклы фактлар искә алына. Нәкъ шушы ук мәгълүматлар үзен «Камал» дип күрсәткән авторның 1914 елның 1 июнендә «Вакыт» газетасында басылып чыккан «Гарәп мохитендә татар туе» мәка-

---

[32] Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Сәяхәтнамәләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Путешествия / төз.: А.Х.Алиева, Г.М.Ханнанова; текст., иск. һәм аңл. әзерл.: А.Х.Алиева, Г.М.Ханнанова; кереш сүз авт. А.Х.Алиева. Казан: ТӘһСИ, 2022. Б. 13.

[33] Сакмарый. Шам хатирәте // Шура. 1913. № 18. Б. 552.

[34] Сакмарый. Шам хатирәте // Шура. 1913. № 20. Б. 612.

[35] Шунда ук.

[36] Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Сәяхәтнамәләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Путешествия / төз.: А.Х.Алиева, Г.М.Ханнанова; текст., иск. һәм аңл. әзерл.: А.Х.Алиева, Г.М.Ханнанова; кереш сүз авт. А.Х.Алиева. Казан: ТӘһСИ, 2021. Б. 9.

ләсендә[37], Атилла Расихның «Ямашев» романында һәм аның әнисе Зәйтүнә Мәүлүдованың көндәлекләренә таянып язылган «Ишан оныгы» китабында да искә алына[38]. З.Мәүлүдова гаиләсенең Истанбулда 1914–1918 елларда яшәгәнлеген искә алганда (димәк язмалар да шушы чорга карый), Сакмарый мәкаләсенең башка искә алынган чыганакларга караганда алданрак дөнья күргәнлеге бәхәссез.

«Шура» журналында Г.Газизовның моннан тыш «Сүрия әхвале»[39] һәм «Җәмил бәк илә мөсахәбә»[40], «Хәлеб хатирәләре»[41], «Шамнан Бәгальбәккә»[42] дигән язмалары басылып чыккан. Аларда автор Сүрия тормышының бик күп якларын яктырта. «Хәлеб хатирәләре»ндә җылы хатирәләр белән кабат Талип ага искә алына, автор якташлары – «Мәктәп Солтани» таләбәләре Камал[43] вә Галимҗан әфәнделәр турында хәбәр итә[44].

Сакмарый әлеге сәфәрләрендә гади сәяхәтче булып кына йөрмәгән, үз алдына фәнни максатларны да куйган. Мәсәлән, Шамга бу юлы килүендә (мәкалә 1916 елда басылып чыга) ул дин галиме Ибн Тәймия (1263–1328) һәм Коръән тәфсирен язучы, хәдисләр белгече Ибн әл-Каййим әл-Җәүзийя (1292–1350) язуларының фотокопияләрен ясатып ала.

«Шамда мөһаҗирләр» дигән бүлектә автор бирегә килеп урнашкан татарлар белән очрашуын, аларның тормыш-көнкүрешен, милләттәшләребезнең чит-ят җирләрдә дә югалып калмавын, тырыш хезмәтләре белән матур яшәүләрен яза. Сакмарыйның Бәйрутның гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре турындагы мәкаләләре дә шул заман укучыларында кызыксыну уяткан[45]. Бу язмалар булачак татар шәкертләренә уку йортын сайларга, киләчәкләрен күз алдына китерергә, максатлар һәм бурычлар билгеләргә ярдәм иткән.

---

[37] Камал. Гарәп мохитендә татар туе // Вакыт. 1914. 1 июнь.

[38] Бу хакта тулырак Л.Мортазинаның «Шам татарлары» мәкаләсендә танышырга мөмкин («Безнең мирас. 2018. № 11. Б. 34–39).

[39] Сәйях. Сүрия әхвәле // Шура. 1913. №2. Б. 36–37.

[40] Сакмарый. Җәмил бәк илә мөсахәбәт // Шура. 1913. № 22. Б. 690–692.

[41] Сакмарый. Хәлеб хәтирәләре // Шура. 1915. №№ 6–10, 21–23, 1916. №1–3, 5–10.

[42] Сакмарый. Шамнан Бәгальбәккә // Шура. 1914. № 20. Б. 612–615, №21. Б. 644–647.

[43] Уебызча, әлеге мәкаләдә искә алынган Камал әфәнде «Гарәп мохитендә татар туе» мәкаләсенең авторы булырга тиеш.

[44] Сакмарый. Хәлеб хатирәләре // Шура. 1916. № 9. Б. 215–217.

[45] Сакмарый. Бәйрутта беренче июль бәйрәме // Вакыт. 1911. 5 август.

## Европа уку йортларында татарлар

*«Бу кеби мәгарифле яшьләремезнең Аурупа*
*дарелфөнүннәрендә укыярак икмаль*
*тәхсил итдекләренә вә әгъла сурәттә*
*шәһадәтнамә алдыкларына милләтемез*
*ифтихар итмәгә хаклыдыр»*
(«Вакыт»)

Күренгәнчә, гасырлар чигендә татар зыялылары арасында Истанбулда яки Каһирәдә белем алырга теләүчеләрнең саны шактый була. Язучы Атилла Расих Европада укырга теләүчеләр, алар белән чагыштырганда, азрак булган дигән фикерне әйтә[1]. Бу очракта ике моментны истә тотарга кирәктер, мөгаен. Беренчедән, Европа уку йортлары дөньяви белем бирүгә юнәлдерелгән, илаһият бүлекләрендә исә христиан яки католик дине нигезләре буенча белем бирелгән; икенчедән, Европага барып, югары уку йортларына керү өчен, европа телләрен белү мәҗбүри булган. Моннан тыш, Россиядән килеп укырга теләүчеләргә кайбер аерым таләпләр дә куелган[2]. Укучыларның чагыштырмача азрак булуы шуның белән дә бәйле.

Гомумән алганда, XX гасыр башында татар егетләре арасында Европа илләренә барып белем алучылар күренгәли башлый. Алай гына да түгел, хәтта хатын-кызлар да Европа уку йортларының бусагасын атлап керергә җөрьәт итәләр. Иң атаклы татар студентлары арасында Гаяз Максудов, Садри Максуди, Йосыф Акчура, Сара Шакулова һ.б.ны атарга мөмкин.

«Вакыт», Парижда чыгып килүче «Матэн» газетасында[3] дөнья күргән язмага таянып, хәбәр итә: «Садретдин Максудов җәнабләренең Париждагы голүм хокук дарелфөнүнендә мөкәммәл сурәттә икмаль итеп, фаикыятьлек (өстенлек) шәһадәтнамәсе алдыгы һәм башка фөнүн галия мәктәпләреннән вә мәшһүр Сорбонна дарелфөнүненнән шәһадәтнамә алмак итдеге бәян ителмешдер»[4]. Татар җәмәгатьчеле бу күренешне бик зур мәртәбә белән кабул иткән: «Бу кеби мәгарифле яшьләремезнең Аурупа дарелфөнүннәрендә укыярак икмаль (камил) тәхсил итдекләренә (белем алуларына) вә әгъла (бик югары, дәрәҗәле) сурәттә шәһадәтнамә алдыкларына милләтемез ифтихар итмәгә (горурланырга) хаклыдыр»[5].

---

[1] Расих А. Внук ишана. Казань: Татар.кн.изд-во, 2016. С. 232.

[2] Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 22.

[3] «Le Matin» – 1884–1944 елларда Париж шәһәрендә чыгарылган көндәлек газета.

[4] Парижда татар шәкерте // Вакыт. 1906. 20 июль.

[5] Шунда ук.

XX гасыр башында Европа уку йортларында мөселман укучыларының гыйлем эстәве гайре табигый хәл булмый инде. Парижда 1910 елда, мәсәлән, барлыгы 600 мөселман студенты белем алган. Шуларның 400е – төрек, 50се – мисырлы, 120се – гаҗәм[6], 6 сы русияле мөселман була. Бельгиянең Льеж шәһәрендә Россиядән килеп укучыларның саны 1914 елда 4 кә җитә[7]. 1911 елда Женевада белем алган 40 мөселман студентының 5се Россиядән була (чагыштыру өчен: 12се – Төркиядән, 2се – Ираннан, 15е – Гарәбстаннан һ.б.)[8]. Мөселман кызлары арасында иң беренче Европага барып белем алган кеше Ләйлә Шахтахтинская[9] булса, 1910 елда Парижда Сорбонна университетында Сара Шакулова укый[10].

Кайбер илләр, әйтик, Госманлы дәүләте, үз яшьләренең Европада белем алуын милләтнең һәм илнең алгарышы өчен төп шартларның берсе күреп, бу эштә һәртөрле булышлык итәргә тырышкан. 1909 елда Сәгыйть Хәлим паша[11] тарафыннан Мисырдан Европага дүрт шәкерт җибәрелә, һәрберсенә еллык 6–7 мең сум акча бүлеп бирелә[12]. 1910 елда Төркия хөкүмәте үзенең казна хисабыннан иң сәләтле, кабилиятле 100 ир-егеткә Париж югары уку йортларына барып уку мөмкинлеген тудырган, аларның 80е мөселманнар булган. Бу студентларга, моннан тыш, аена 110 сум стипендия дә бирелгән. Хокук бүлегендә укучыларга шулай ук җәйге ял көннәрендә Европа мәмләкәтләрендә йөреп, хокук гыйлеменә караган мәгълүмат җыю максаты белән һәр кеше башына өстәмә рәвештә 250 сум акча түләнгән. Хөкүмәт техник, инженерлык, хәрби белем бирүдә Европа уку йортларының тәҗрибәсенә таянуны мәгъкуль күргән, шул сәбәпле максатчан рәвештә үз яшьләрен Европага җибәрү буенча махсус карарлар кабул иткән, программалар әзерләгән[13]. Шул программа нигезендә Германия югары уку йортларына 20, Швейцария мәктәпләренә 7 шәкерт җибәрелгән[14]. Татар яшьләре исә аерым дәүләт программалары нигезендә түгел, ә шәхси акчаларга яисә хәйриячеләрнең матди ярдәме белән белем алганнар. Бу хәл матди кыенлыклар алдында калган татар яшьләренә укуларын дәвам итү мөмкинлеген чикләгән. Чит мәмләкәтләрдә генә түгел, Россия уку йортларында укучыларның кайберләре дә,

[6] Гаҗәм – гарәп булмаган халыклар, фарсылар, иранлылар.

[7] Бәлҗика // Вакыт. 1914. 14 февраль.

[8] Чәләби С.Я. Эсвичрәдә тәхсил // Вакыт. 1911. 23 сентябрь.

[9] Ләйлә Исасолтан кызы Шахтахтинская (1886–1908) – Европада белем алган беренче азәрбайҗан кызы. Г.З.Тагиев акчасында Швейцариягә бара, 1904–1907 елларда югары медицина белеме ала. URL: https://birlik16.ru/2023/01/urozhenka-irevana-lejla-shahtahtinskaya-pervaya-azerbajdzhanskaya-devushka-poluchivshaya-obrazovanie-v-evrope (мөрәҗәгать итү датасы: 12.10.2023).

[10] Ислам галәменнән // Йолдыз. 1910. 19 гыйнвар.

[11] Сәгыйд Хәлим паша (1863–1921) – Госманлы дәүләтенең бөек вәзире.

[12] Яурупага шәкертләр йибәрү // Вакыт. 1909. 29 гыйнвар.

[13] Ислам галәменнән // Йолдыз. 1910. 19 гыйнвар.

[14] Парижда мөселман укучылары // Вакыт. 1910. 14 гыйнвар.

акчалары җитмәү аркасында, үзләре укыган мәктәпләрен ташлап, эшкә урнашырга мәҗбүр булганнар[15]. Ләкин, шулай да, аерым Европа илләрендә чит илләрдән килеп укучы мөселман студентлары, димәк ки, татарлар өчен дә, кайбер уңайлыклар булган. Мәсәлән, 1911 елда Женева шәһәрендә «Мөселман таләбәләре көтепханәсе» төзелә һәм ул чит илләрдән җыелган барлык мөселман яшьләренә ярдәм күрсәтүне үзенең максаты итә. Мөгаен, күпчелекне төрекләр тәшкил иткәндер. Шул ук вакытта бу хактагы хәбәрнең «Вакыт» газетасында урнаштырылуы китапханәнең Россиядән килгән укучыларны да күздә тотуын күрсәтә. Язмада хәбәр ителгәнчә (аның авторы юридик факультет студенты С.Я.Чәләби, милләте буенча Кырым татары), «Мөселман таләбәләре көтепханәсе» читтән килгәннәргә университетка укырга керү шартлары, яшәү, фатир эзләү һ.б. хосусларда мәгълүмати ярдәм итүне максат итә[16]. Льежда исә төрле илләрдән килгән төрки-мөселман шәкертләренең үзара ярдәм итешүләре өчен «Мөселман шәкертләр җәмгыяте» төзелә[17].

Гомумән алганда, бу чорда Европада Россиядән килгән студентлар чагыштырмача күп була. 1911 елда, мәсәлән, чит илләрдән килеп, Париж университетының хокук факультетында белем алган 976 ир-ат студентларның 255-е, 89 хатын-кызның 88-е россияле була. Шул ук хәл башка факультетларда да күзәтелгән. Шулай итеп, университетта укучы 3565 чит ил студентының 1861ен, ягъни яртысыннан артыграгын руслар[18] тәшкил иткән[19].

Европаның төрле илләрендә вазгыять гомумән алганда охшаш булса да, россиялеләргә карата караш төрлерәк булган. Бу яктан караганда, иң консерватив илләрнең берсе Германия була, моңарчы рус шәкертләрен бик теләп кабул иткән Швейцариядә дә 1914 нче елларда укырга керү шартлары катгыйлана төшә; Бельгиядә исә, киресенчә, Россиядән килгән егет һәм кызларны яхшы каршы алганнар. Соңгысында хәтта белешмәләр, паспортлар да таләп итмәгәннәр. Чит ил студентлары дәүләт хисабына эшләп килүче Льеж һәм Гент университетларында укый алганнар[20].

Вазгыятькә беркадәр ачыклык кертергә теләп, 1907 елда «Вакыт» газетасы болай дип яза: «Боңа кадәр Русиядә бөек мәктәпләр, хосусан сәнәгать мәктәпләре аз, вә булганнары да начар улдыгыннан, Русиянең үзендә фабрика, завод, мәгъдән (руда) учаклары кеби нәрсәләрне идарә кылырлык мәгълүматлы кешеләр җитешми иде. Шул сәбәпле бу урыннарга мәгълүматлы адәм-

---

[15] Камал Г. Мөселман студентларымыз // Йолдыз. 1910. 10 март.
[16] Гыйлем һәвәслеләрнең дикъкатенә // Вакыт. 1911. 19 август.
[17] Бәлҗика // Вакыт. 1914. 14 февраль.
[18] Бу очракта гомумән Россиядән килеп укучылар күздә тотыла.
[19] Париж дарелфөнүнендә укучы әҗнәбиләр // Вакыт. 1911. 6 март.
[20] Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 13, 123, 158, 154.

нәр пакъ бөек вазифалар илә Аурупадан чакырыла иделәр. [...] аурупалылар өчен Русиягә кереп эш башына менү бик файдалы иде»[21]. Инде Россиядән килгән яшьләргә Европада белем алу мөмкинлеге туу белән, автор уенча, бу вазгыять беркадәр тискәре гәүдәләнеш ала: европача белем алган россиялеләрне алар, ягъни европалылар, үзләренә конкурент итеп күрәләр, шул сәбәпле аларга алдынгы уку йортларына кереп укуда беркадәр киртәләр хасыйл итәләр. Россиядән килгән студентларның активлык күрсәтеп, укыган илләрендә сәяси хәрәкәттә катнашулары да аларда канәгатьсезлек тудыра[22].

Европа уку йортларына керүнең төп шартларына килгәндә, иң беренче чиратта, бу – чит телләрне белү. Махсус курсларда белем алып, яшьләр укырга кирәрлек дәрәҗәдә телне үзләштерә алганнар. Әйтик, Лозанна университеты каршында шундый курс эшләп килгән – чит илдән килгән абитуриентлар 2 семестр дәвамында 150 франк түләп француз телен өйрәнгәннәр. Моннан тыш, әлбәттә, чит ил паспорты таләп ителгән. Тагын да иң мөһим моментларның берсе – белем турындагы шәһадәтнамәнең булуы. Шәһәр училищеларын тәмамлау турындагы документлар югары уку йортларына керү хокукын бирмәгәннәр. Германия уку йортларына керү өчен классик гимназия яисә югары (өстенлекле) дәрәҗәдәге реаль училище дипломы таләп ителгән[23]. Проблеманы шул илләрнең үзләрендә үк хәл итәргә дә мөмкин булган. Лозанна уку йортларына керергә теләүчеләр «Ecole Lemania» дип аталган хәзерлек мәктәбендә укып, керү имтиханнарына әзерләнә, Швейцария өлгергәнлек аттестатын ала алганнар. Бу документ Көнбатыш Европадагы барлык уку йортларына керергә мөмкинлек биргән[24].

Европада белем алучы шәкертләр аралашу, төрле мәсьәләләрне хәл итү максатында аерым чаралар уздырганнар. Швейцариянең Берн шәһәрендә 1914 елда Европа мәктәпләрендә укучы россияле студентларның съезды була. Бу чорда Европада аларның саны 15 мең тирәсе була. Шуларның 2 меңе – яһүди, һәм аларның үз партияләре булу сәбәпле, әлеге съездда катнашмаганнар. Ә калган милләтләр исә һәр шәһәрдән 50 шәкерткә бер вәкил сайлап җибәргәннәр. Шулай ук мәгарифпәрвәр байлар да катнашкан. Съездда Европада укучы Россия студентларының хокуклары, хосусый рус дарелфөнүне ачу, барлык студентларны берләштерү, аларга милли ихтыяҗларын үтәү юлында ярдәм итү кебек мәсьәләләр каралган[25]. Моннан тыш, кайбер шәһәрләрдә укучыларның махсус оешмалары да булган. Әйтик, Берлинда «Н.И.Пирогов исемендәге Россия студентлары җәмгыяте» эшләп килгән.

---

[21] Заграницада рус шәкертләре // Вакыт. 1907. 20 февраль.

[22] Шунда ук.

[23] Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 129, 2, 18.

[24] Шунда ук. С. 15.

[25] Бернда русияле студентлар съезды // Вакыт. 1914. 17 май.

Женевада, Лозаннада, Берндә рус китапханәләре һәм рус милли ризыкларын тәкъдим итүче ашханәләр булган[26].

Татарлар арасында иң популяр булган Европа уку йортлары булып Франция, Германия, Швейцария, Бельгия университетлары саналган. Швейцария уку йортлары, гомумән алганда, чит ил студентларын теләп кабул иткәннәр. Моның сәбәпләре арасында, шунда белем алган Г.Идриси фикеренчә, матди як беренче урында торган. Тагын бер сәбәп – илдә хосусый дарелфөнүннәрнең гаять дәрәҗәдә күп (барлыгы 7) булуы. Шуңа алар читтән килгән шәкертләрне, күпме булуларына карамыйча, кабул итәргә әзер булганнар[27].

Г.Идриси мәгълүматлары буенча, Бельгиядәге Льеж шәһәрендә 1914 елда ике татар шәкерте була[28]. Аның берсе – ул үзе, икенчесе – Бәдретдин Сәйфелмөлеков. Алар Льежга икесе берьюлы киләләр. Г.Идриси 1914 елда Төркиядә «Солтания» мәктәбендә укып яткан Баһаветдин Бәкер атлы шәкертне дә Льежга китерү өчен Россиядәге милләттәшләренә мөрәҗәгать итеп, акча җыюны оештыра[29]. Ләкин әлеге шәкертнең бу уку йортына килү-килмәвен раслаучы төгәл мәгълүмат әлегә табылмады.

«Вакыт» газетасының хәбәр итүенә караганда, 1914 елда Льежда укучы татар шәкертләренең саны икәү генә түгел, ә дүртәү булган[30]. Саннарның төрлелеге, мөгаен, татарларның чит илдә тупланып, бер-берсен белешеп бетмәве белән билгеләнәдер. Чагыштырмача соңрак, ягъни август аенда дөнья күргән икенче бер материалга таянып, бу чорда анда биш татар егете укыган дигән нәтиҗәгә килдек.

1914 елда «Вакыт» газетасында «Льеж шәһәрендә бер мөселман гөруһы» дигән исем астында фотосурәт басылып чыга[31]. Анда Европа сәяхәтендә вакытта Льеж шәһәренә килеп чыккан Садри Максуди һәм Европа уку йортларында укучы бер төркем татар студентлары сурәтләнгән. Сурәт астындагы кыска язмада хәбәр ителгәнчә, әлеге фото Садри әфәнденең килүе хөрмәтенә алынган. Льежда «дөньяның иң яхшы мәктәпләреннән саналган гали бер сәнәгать мәктәбендә» укучы татар яшьләре (утырып торалар): Галимҗан Идриси, Германиянең Фрайбург гали мәгъдәнчелек (тау эшләре) гали мәктәбе[32] студенты Искәндәр Рәмиев, Льеж университеты студентлары Салих

---

[26] Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 24, 124.

[27] Әл-Идриси Г. Эсвичрәдә чит мәмләкәт шәкертләре // Вакыт. 1914. 20 март.

[28] Әл-Идриси Г. Эсвичрәдә чит мәмләкәт шәкертләре // Вакыт. 1914. 20 март. Бу сан, уебызча, дөреслеккә бик үк туры килеп бетми, чөнки 1914 елда биредә бу ике шәкерттән тыш, тагын берничә татар баласы белем алган.

[29] Шунда ук.

[30] Бәлҗика // Вакыт. 1914. 14 февраль.

[31] Льеж шәһәрендә бер мөселман гөруһы // Вакыт. 1914. 1 август.

[32] Фрайбергтагы Король тау академиясе – Саксониядәге иң борынгы югары уку йортларының берсе, 1765 елда нигез салына. Анда Россиядән килеп укучылар шактый була. Мисал өчен, 1909 елда 129 россияле укучы булса, 1911 елда барлык 439 студентның

әфәнде[33], (басканнар): оренбурглы Бәдретдин Сәйфелмөлеков, Гариф Рәмиев һәм Мидхәт Рәмиев. Садри Максуди алгы рәттә уртада утырып тора.

Искәндәр Рәмиевтән кала башка студентлар барысы да Льежның үзендә укыйлар. Искәндәр Рәмиев исә, мөгаен, туганнары белән күрешү хөрмәтенә Германиядән махсус килгәндер. Билгеле булганча, әлеге студентлар тарафыннан «Мөселман таләбәләре җәмгыяте» оештырыла, аның әгъзалары лекцияләр һәм әдәби кичәләр оештыру, үзара ярдәм эше белән шөгыльләнә[34].



*Льеж шәһәрендә татар студентлары Садри Максуди белән. 1914 ел («Вакыт», 1914, 1 август)*

223-сен чит ил укучылары, шуның яртысын россиялеләр тәшкил иткән. Диплом яклауга үткәрелү өчен, студентлар 150 көн дәвамында шахтада кара эшче булып эшләргә, ягъни практика үтәргә тиеш булалар (Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 49–50, 94).

[33] Әлеге шәхеснең фамилиясе билгеле түгел, бары тик «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлавы һәм Льеж электротехника мәктәбендә укуы, Беренче бөтендөнья сугышы башланганнан соң Льежда бүленеп калуы хакында билгеле (Оренбургские студенты за границей // Оренбургская газета. 1914. 29 августа).

[34] Муртазина Л.Р. Садри Максуди с татарскими студентами в Льеже: история одной фотографии // Историческая этнология. 2018. Т. 3, № 2. С. 305.

Инде әлеге чыганактан күренгәнчә, Европада белем алган татарлар арасында атаклы сәнәгатьчеләр һәм хәйриячеләр бертуган Рәмиевләрнең балалары да була. Мөхәммәтсадыйк Рәмиев балаларына европача, ләкин татарлыкка (миллилеккә) юнәлдерелгән белем бирергә кирәк дип санаган[35]. М.Рәхимкулова аның уллары Закир һәм Шакир Рәмиевләрнең заманы өчен яхшы белем алулары – Шакирның Европада, Закирның Төркиядә белем алулары хакында яза[36]. Чынлап та, Закир Рәмиевнең беркадәр вакыт Төркиядә яшәп, телләр, әдәбият мәсьәләләрен һәм типография эшен өйрәнүе билгеле, әмма кайсы уку йортында укыганлыгы турында мәгълүмат юк. Шакир Рәмиевнең 1902 елда Европада алтын табу һәм эшкәртүнең заманча ысулларын өйрәнүе, яңа техника сатып алуы хакындагы информация сакланган, тик, шулай ук, теге яки бу уку йорты турында сүз алып барылмый, мөгаен, ул әлеге белемнәрен шәхси рәвештә, аерым сәнәгать предприятиеләрендә алгандыр.

Закир Рәмиевнең олы улы Искәндәр (1886–1943) Оренбург губернасы Юлык авылында дөньяга килгән. 1901 елда «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң[37], Петербургта гимназиядә укыган. Сәнәгатьче улы буларак, ул тау эшләрен үзләштерү үзәге булган Германиягә барып укуны үз алдына максат итеп куйган, шул сәбәпле немец гаиләсендә яшәп телне өйрәнгән. Үзенең теләге һәм әти-әнисенең киңәше һәм ярдәме белән Искәндәр Фрайбургтагы атаклы тау академиясенә укырга керә[38]. 1914 елда ул әлеге уку йортын тәмамлап, тау инженеры дипломын ала һәм Россиягә кайта, приискка урнашып, гаилә эшен дәвам итә. Революциядән соңгы вакыйгалар, барлык башка сәнәгатьчеләр кебек үк, аның тормышына да зур үзгәрешләр кертә, приисклар дәүләткә тапшырыла, ә Искәндәр Рәмиев Баймак бакыр кою заводында баш инженер булып эшли башлый, әмма, күп зыялылар кебек, репрессияләргә эләгә, Гулаг лагерьларына җибәрелә, шунда вафат була[39].

Закир Рәмиевнең икенче улы – Гариф (1893–1971) «Хөсәения» мәдрәсәсен һәм Оренбургта реаль училище тәмамлаганнан соң, Льеж электротехника югары мәктәбенә укырга керә. Әмма ул абыйсы Искәндәр кебек ватанына кайта алмый, башта Франциядә, башка Европа илләрендә яши. Соңыннан Гариф Рәмиев Финляндиягә барып урнаша һәм Терийоки шәһәрендә Финляндия ислам җәмгыяте чакыруы буенча 1930 нчы елларда татар

[35] Фонотов М. Родная старина. Очерки истории Южного Урала. Челябинск: 2013. С. 80.

[36] Рахимкулова М. Рамеевы. Оренбург, 1995. 140 с.

[37] Рахимкулова М. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. Оренбург, 1997. С. 108, 218.

[38] Бадрутдинова М.Ш. Башир Рамеев – видный представитель династии Рамеевых // Дәрдемәнд мирасы һәм хәзерге заман. Казан, 2009. Б. 131.

[39] Хәмидуллин Л. Тарихта үз эзләре бар // Бертуган Рәмиевләр: Фәннибиографик җыентык. Казан: Рухият, 2002. Б. 63.

балалары өчен махсус оештырылган туган телне һәм ислам нигезләрен өйрәтү курсларында укыта[40].

Шакир Рәмиевнең улы Мидхәт тә 1912 елдан Льеж электротехника югары мәктәбендә белем ала[41]. Сугыш башлану белән, ул да бүленеп Европада кала. 1918–1925 елларда Мидхәт Германиядә, Шарлоттенбургта Югары техник мәктәп студенты[42]. Бөек Ватан сугышыннан соң, Америкага күченеп китә[43].

Чит илләргә барып белем алучылар арасында сәүдәгәр балалары күп булуы аңлашыла, чөнки юл, яшәү һәм уку өчен шактый акча таләп ителгән. Алар арасында Рәмиевләр, Агафуровлар кебек атаклы сәүдәгәр, сәнәгатьче балалары бар. Екатеринбург байлары Агафуровларның уллары мисалында бу аеруча ачык күренә. Урта Уралдагы иң мәшһүр сәүдә оешмаларының берсе булган[44] «Бертуган Агафуровларның сәүдә йорты» әгъзасы, актив җәмәгать эшлеклесе, Екатеринбург шәһәре мөселман хәйрия җәмгыятенең беренче рәисе, Шәһәр думасы гласные Зәйнетдин Агафуровның улы Нуретдин (1890–1923) 1910 елларда Лейпциг шәһәрендә (Германия) югары уку йортында укый, немец телен һәм сәүдә эшләрен өйрәнә.

1913 елда «Сибирия» газетасында басылып чыккан язмада Германиянең Лейпциг шәһәрендә өч зыялы татар сәүдәгәре (берсе кавказлы) һәм университет тәмамлаган мөселман (әфганлы) егетенең фотосурәте басылып чыга. Бу егетләрнең берсе – Лейпцигта югары белем алучы[45] Нуретдин Агафуров, ә икенчесе – Әхмәтсәлим Мусин, Семипалат шәһәрендәге мәшһүр байлардан Мөхәммәтфатих әфәнде Мусинның улы була. Ул да туган шәһәрендә гимназия тәмамлаганнан соң, Лейпцигта югары сәүдә мәктәбендә укый, немец телен бик яхшы белә. «Сәүдә эшендә тәҗрибәсе бик яхшы булганга, бик шәп сәүдә итә. Пушнина сәүдәсенең мәркәзе Лейпцигта булганга, анда

[40] Беляев Р. Татарская диаспора Финляндии: вопросы интеграции и сохранения идентичности. Хельсинки, 2017. С. 90, 180, 181.

[41] Хәмидуллин Л. Тарихта үз эзләре бар // Бертуган Рәмиевләр: Фәнни-биографик җыентык. Казан: Рухият, 2002. С. 61.


[42] Гилязов И. Общество поддержки российско-мусульманских студентов в Берлине (1918–1925) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1996. №3/4. С. 194.

[43] Хәмидуллин Л. Тарихта үз эзләре бар // Бертуган Рәмиевләр: Фәнни-биографик җыентык. Казан: Рухият, 2002. С. 61–62.

[44] Старостин А.Н. Новые страницы из истории екатеринбургских купцов и меценатов Агафуровых // Minbar. Islamic Studies. 2018. № 11(2). С. 248.

[45] Лейпцигтагы коммерция академиясе хакында сүз бара дип фаразлыйбыз. Биредә 5 семестр дәвамында укып, диплом алырга мөмкин булган. Укырга керү өчен аттестат яисә немец классик гимназияләре программасы нигезендә эшләүче уку йортлары дипломы, немец телен белү хакындагы белешмә таләп ителгән (Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 5).

барып, Заһид әфәнде[46] белән шәрик булып, контор ачкан. Сәлим әфәнде хөр фикерле, күркәм холыклы, тәрәкъкыйпәрвәр яшь бер сәүдәгәрдер»[47]. Икенче бер язмага караганда, Сәлим Мусин, Германиягә укырга киткәнгә кадәр, ватанында хокук белеме дә алган[48].




*Рәсемдәге әфәнделәр («Сибирия», 1913, 26 июнь)*
*(1се – Нуретдин Агафуров, 4се – Сәлим Мусин)*

Нуретдин Агафуров 1915 елдан Екатеринбург мөселман хәйрия җәмгыяте идарәсе әгъзасы буларак билгеле[49]. Ул да, туганнары кебек, хәйриячелек белән шөгыльләнгән, Екатеринбург мөселман хәйрия җәмгыяте идарәсе әгъзасы һәм Хәрбиләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү буенча вакытлы мөселман комитетының Екатеринбург бүлеге әгъзасы итеп сайланган. Революциядән соң Агафуровларның күпчелеге мөһаҗирлектә гомер итә. Нуретдин Агафуров та гаиләсе белән башта Харбинга, аннан Япониягә күченә.

Агафуровларның тагын бер вәкиле – Кашшафетдин бай улы Бәдретдин Агафуров та (1901 елда туган, үлгән елы билгесез), Томск университетының хокук факультетында белем алганнан соң, Берлин сәүдә институтында укый. Тик ул Германиягә Россиядән түгел, ә 1921 елда Япониядән килә. Бу вакытта

[46] Сурәттә 3 нче сан белән күрсәтелгән.
[47] Рәсемдәге әфәнделәр // Сибирия. 1913. 26 июнь.
[48] Лейпцигта мөселман тиҗарәт конторы // Вакыт. 1912. 27 апрель.
[49] Ислам на Урале: энциклопедический словарь / коллект. авторов, отв. редактор – Д.З. Хайретдинов. М.: Издат. дом «Медина», 2009. С. 25.

аның гаиләсе дә Йокогама шәһәренә күченгән була. 1924–1932 елларда Маньчжуриядә «Бертуган Агафуровлар» фирмасында эшли, Харбин шәһәрендәге мөселман җәмгыяте әгъзасы итеп сайлана[50].

Европада белем алган татар яшьләре арасында исеме татар матбугатында иң еш яңгыраган кешеләрнең берсе – Галимҗан Идриси (1887–1959) дисәк, һич тә ялгыш булмас. Аның төрле темаларга язылган язмалары «Шура», «Вакыт» кебек басмаларда бик еш чыгып торган.

Г.Идрисинең гаять каршылыклы эшчәнлек алып барганлыгы билгеле. Бу очракта без аны тик ватаннан читтә укыган студент буларак искә алабыз. Ул чыгышы белән Петропавел шәһәреннән була. Бохарада белем алганнан соң, Истанбул университетына укырга керә (1912 елда тәмамлый), 1913 елдан Лозанна һәм Льеж уку йортларында телләр һәм фәлсәфә гыйлемен өйрәнә[51], тугыз телдә сөйләшкән[52]. Әле Төркиядә яшәгән чорда ук татар вакытлы матбугатында язышa башлый, «Вакыт» газетасының чит илләрдәге хәбәрчесе булып тора[53]. 1911 елда «Вакыт»та дөнья күргән мәкаләсендә Истанбул дарелфөнүнендә узган кичә (конферанс), уку йортының таләбәләр җәмгыяте һәм аның эшчәнлеге һ.б. турында язып чыга[54]. 1914–1915 елларда ул Төркиядә «Төрек йорты» журналының икенче мөхәррире булып тора, 1915 елдан Германиядә яши[55]. 1916–1922 елларда Г. Идриси мөселман хәрби әсирләренең Вюнсдорфтагы лагеренда имам булып хезмәт итә[56].

1914 елда Г.Идрисинең «Вакыт» газетасында «Эсвичрә мәктүбләре», Европага бару юлын тасвирлаган «Истанбулдан Лозанга» дигән күләмле мәкаләләре басылып чыга[57]. Шул ук елда аның Лозаннадагы «Төрек йорты» шөгъбәсе бинасында әлеге шәһәрдә булган барлык татар һәм төрек студентлары каршында лекция укуы турында билгеле[58].

1918 елда Г.Идриси Берлин шәһәрендә татар студентларының үзәге булган «Россия мөселман студентларына ярдәм җәмгыяте»н оештыра[59]. Әле-

[50] Старостин А.Н. Новые страницы из истории екатеринбургских купцов и меценатов Агафуровых // Minbar. Islamic Studies. 2018. № 11(2). С. 253–254.

[51] Гилязов И. Судьба Алимджана Идриси // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1999. № 3/4. С. 158–159.

[52] Насыйров Т. Татар мөһаҗирләре матбугаты // Казан утлары. 2001. №7. Б. 156.

[53] Шунда ук. Б. 155–156.

[54] Әл-Идриси Г. Мәрхүм солтан Габделгазизнең углы шаһзадә Габделмәҗид әфәнде илә мөлякәт // Вакыт. 1911. 20 гыйнвар.

[55] Гилязов И. Судьба Алимджана Идриси // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1999. № 3/4. С. 158–159.

[56] Насыйров Т. Татар мөһаҗирләре матбугаты // Казан утлары. 2001. №7. Б. 156.

[57] Әл-Идриси Г. Истанбулдан Лозанга // Вакыт. 1914. 23, 25 гыйнвар; Әл-Идриси Г. Эсвичрә мәктүбләре // Вакыт. 1914. 30 гыйнвар.

[58] Мөхбир. Европада төрек-татар таләбәсе // Вакыт. 1914. 14 февраль.

[59] Гилязов И. Судьба Алимджана Идриси // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1993. № 3/4. С. 158.

ге оешманың эшендә, җәмгыятьнең рәисе Г.Идрисидән тыш, Б.Сәйфелмөлеков (делегат), М.Рәмиев (казначы) һәм Дрезденда Югары техник мәктәп студенты Ибраһим Акчура (сәркатип) катнаша[60].



*Европада укучы татар студентлары ял вакытында*
*(Хамидуллин Л. Дәрдемәнд = Дердменд. Казан, 2019)*

Революциягә кадәр татар студентлары, кайсы гына мәмләкәттә белем алсалар да, укудан тыш, әлеге илләрнең тарихы, үзенчәлекләре, традицияләре белән якыннан танышырга тырышканнар. Шул максат белән алар төрле шәһәрләргә сәфәр кылганнар, үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап эзләгәннәр. Бәйрутта укыган Габдулла Газизовның (Сакмарый) Шамда, башка шәһәрләрдә фәнни күзәтүләр алып баруы хакында билгеле. Истанбулда укучы татар шәкертләре дә, берничә кеше үзара җыелышып, алдан әзерләнеп, һәр җомга көнне Босфор култыгының ярларына җәяүле сәяхәтләр оештырганнар. Бу традицияне күпчелек очракта Истанбул аша килгән Льеж студентлары дәвам иткән. Алар һәр атнаның якшәмбесендә 5–6 кеше берләшеп, иртүк сәгать 3тә торып, Льеж шәһәрендә һәм тирә-юнендә тамаша кылып йөрергә яратканнар, аның табигатен күзәткәннәр, архитектура һәйкәлләрен өйрәнгәннәр, ял иткәннәр: «чәйнек вә чынаякларымызга кадәр махсус капчыклар белән аркаларыбызга күтәреп, шул гүзәл манзаралы җирләргә барып, чәй хәзерләп эчәбез. Уйныйбыз, йөгерәбез, суда коенабыз, рәсемнәр чыга-

[60] Гилязов И. Общество поддержки российско-мусульманских студентов в Берлине (1918–1925) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1996. №3/4. С. 194.

рамыз[61]. Шулай итеп, өзлексез уку сәбәпле, арыган фикерләрне яңартып, хәл җыйдырып кайтамыз»[62]. Моннан тыш, татар студентлары Европаның башка илләренә – Бельгия, Голландия, Германиянең тарихи, иң мәшһүр шәһәрләренә дә сәяхәткә чыкканнар. Бу чараның төп оештыручысы – Льежда икенче елын яшәүче, димәк башкаларга караганда шәһәрне яхшырак белүче Мидхәт Рәмиев була. Ул 1914 елда Льеж университетының инженерлык факультетының икенче курс студенты була: «Ул бер кулына хаританы (картаны), икенче кулына юл таягын ала да, безгә юлбашчылык итә»[63]. Шул рәвешле алар үзләре укыган илләрнең табигатен, тарихын, мәдәниятен өйрәнгәннәр, нәзари белемнәрен гамәли яктан ныгытканнар.

Беренче бөтендөнья сугышы башлану белән, чит мәмләкәтләрдә, шул исәптән Төркиядә һәм Европа илләрендә белем алуны дәвам итү мөмкинлекләре чикләнә. Күпчелек яшьләр, укып бетерү-бетермәүгә карамастан, ватаннарына кире әйләнеп кайтырга мәҗбүр булалар. Шәкертләрнең бер өлеше исә бүленеп кала һәм беркадәр вакыттан соң укуларын дәвам итә алалар. Октябрь революциясеннән соң чит мәмләкәт уку йортларында укучы татар студентларының саны нигездә мөһаҗирләр исәбенә тулыландырылган. Бу елларда заманча белемле яшьләргә мохтаҗлык кичергән Бохара Халык Совет Җөмһүрияте үзенең укучыларына Германиягә юллама биргән. Алар өчен хәтта Берлин шәһәрендә аерым йорт та булдырылган. 1923 елда, мәсәлән, 43 студент Германиягә килә. Бу мәсьәләне җайга салуда Бохара республикасының Германиядәге вәкиле Г.Идриси катнашкан. 20нче еллар азагына таба бу эшкә чик куелган[64].

Революциядән соң Европа уку йортларында белем алган татар яшьләре хакында кайбер мәгълүматлар сакланган. Ләкин алар, кагыйдә буларак, турыдан-туры Россиядән түгел, ә башка мәмләкәтләр аша килгәннәр. Шундыйларның берсе – Кәмал Локман (1899–1976) – Төркиянең беренче нефть инженеры, озак еллар илнең энергетика министры булып торган[65]. Ул чыгышы белән Казакъстанның Казалы шәһәреннән була (Әтисе заманында бирегә Оренбург шәһәреннән күченеп килә). Истанбулда башта «Хадыкыят-ы Мәшверете» башлангыч мәктәбендә 5нче сыйныфта укый, урта белем алганнан соң, хөкүмәт хисабына Шам шәһәрендә белем ала. Үзенә сүз бирә: «Кайда эшләп булса да, барыбер И.Гаспралы кебек Франциядә укыячакмын!»[66].

---

[61] Фотога төшү хакында сүз бара.

[62] Идриси Г. Льеж тирәсендә җәяү сәяхәт // Вакыт. 1914. 6 июль.

[63] Шунда ук.

[64] Алиханов М.М. Из истории отправки студентов за рубеж из Туркестана в начале XX века // Universum: общественные науки. 2023. №10. С. 9.

[65] Искәрмәләр һәм аңлатмалар // Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. Т. 14. Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. Б. 428.

[66] Гәрәева-Акчура А. Төркиянең беренче нефтьчесе – татар // Казан утлары. 2008. №10. Б. 154–155.

Франциядә Политехник уку йортында, Гренобльдә һәм Страсбургтагы Югары милли нефть мәктәбендә белем ала. 1927 елда, укуын тәмамлап, Төркиягә кайта, төрле нефть компанияләрендә эшли[67]. К.Локман Әнкарада татар мәхәлләсен җитәкләүчеләрнең берсе буларак та яхшы билгеле була.

XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында Европада белем алган татар шәкертләренең төгәл саны билгеле түгел. Аларның күбесе татар мәдрәсәләрен тәмамлап, нигездә төрек уку йортларында әзерлек узган дип фаразларга тулы мөмкинлек бар. Инде искә алынганнардан тыш, Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлаган Габдулла Мостакаев белән Зыя Мөҗавировны атарга мөмкин. М.Мәһдиев мәгълүматларына караганда, Мостакаев Бельгиядәге энергетика институтына укырга керә. Соңыннан ул, ватанына кайтып, күпчелек татар шәкертләре кебек, ил сәнәгатен үстерүгә өлеш кертә[68].

Европада белем алу – татар яшьләре, мөселманнар өчен зур, шактый мәшәкатьле, әмма нәтиҗәле, милләтнең алгарышы өчен гаять әһәмиятле эшләрнең берсе саналган. Белем алуны милләт һәм ватан алдында торган иң зур бурычлары дип инанган татарлар, кайда, нинди уку йортында гына укысалар да, «истикъбалемез ялгыз голүм вә мәгариф саясендә улачагын» бер мизгелгә дә хәтердән чыгармаганнар[69].

## *Бәдретдин Сәйфелмөлеков*

Бәдретдин Сәйфелмөлеков (1886 – ?), чыгышы белән Оренбург шәһәреннән[70] (икенче бер чыганакта аның Казалыдан булуы хәбәр ителә[71]), сәүдәгәр Камалетдин Сәйфелмөлеков гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне Оренбург шәһәрендә ала, соңыннан 1907 елда (кайбер чыганаклар буенча 1910 елда) Г.Идриси белән бергә Истанбулга килә[72]. Истанбулда «Солтания» мәктәбен тәмамлаганнан соң, Льеж университетына укырга керә[73]. Аннан соңгы тормышы Германия белән бәйле. 1914 елда «Кояш» газетасының хәбәр итүенә караганда, сугыш башланганнан соң Льежда укучы 300 тирәсе Россия студентлары әсир итеп Германиянең Аахен каласына китерелә. Алар арасын-

[67] Ryosuke Ono. Muhacerattakı bır özbek türkü'nün mektuplarina göre türk dünyasi – Abdülvahap Oktay ve mektupları // Ankara Üniversitesi Dil ve Tarih-Coğrafya Fakültesi Dergisi 53, 2 (2013). 572.

[68] Мәһдиев М. Сызып ак нур белән. Казан: Татар.кит.нәшр., 2014. Б. 109.

[69] Чәләби С.Я. Эсвичрәдә тәхсил // Вакыт. 1911. 23 сентябрь.

[70] Льеждагы мөселман студентлары // Вакыт. 1914. 27 август.

[71] Насыров Т. Татарская эмигрантская пресса // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2004. №2. С. 120.

[72] Гайнетдинов Р.Б. Тюрко-татарская политическая эмиграция: начало XX века – 30-е годы: Ист. Очерк. Набережные Челны: Камский издат. дом, 1997. С. 57.

[73] Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. Б. 364.

да Оренбургтан килеп укыган татар яшьләре дә була[74]. «Йолдыз» газетасы да бу хәлне тасвирлап, русияле студентларның ата-аналарының, Испания короленә мөрәҗәгать итеп, балаларының язмышын ачыклавын үтенүләре хакында яза[75]. Бәдретдин Сәйфелмөлековның да шул юл белән Германиягә китү ихтималын күздә тотабыз.

1916 елда Б.Сәйфелмөлеков Берлин университетының медицина факультетына укырга керә[76]. 1919–1920 нче елларда алар Г.Идриси белән берлектә «Татар иле» газетасын чыгаралар. Студент Б.Сәйфелмөлеков, газетаның мөхәррире һәм мөдире буларак, татарлар турында туры, дөрес мәгълүмат бирүне максат иткән. Газетаның мәсләге дә шуның белән билгеләнгән: «Татар иле» бигрәк тә татарларга үзләрен танытырга, һәрнәрсәдә татар вә мөселман булып, тагы бер мәртәбә әйтәм, татар булып алга барырга вә һәр нәрсәләрендә: теле, гадәт, йөреш-торыш, хәтта киемнәрендә татар гына булып калырга бар көче белән булышачак»[77].

Б.Сәйфелмөлеков Германиядә Камалетдин Бәдри буларак та билгеле була. 1921 елда, укуын тәмамлап, теш табибы белгечлеген алганнан соң, ул «Татарларның теше. Одентологик һәм краниологик тикшеренү» дигән темага диссертация яза. Әлеге хезмәтендә автор Вюнсдорф лагерендәге татар әсирләренең тешләре торышы хакында гына түгел, гомумән татарларның тарихы, этнографиясе һәм тормыш-көнкүреше хакында да шактый җентекле мәгълүмат биргән. Диссертация беренче тапкыр 1921 елда немец телендә Германиядә дөнья күрә, 2013 елда Себастьян Цвиклински тарафыннан кабат бастырып чыгарыла[78].

Б.Сәйфелмөлековның фәнни эшчәнлеге медицина өлкәсе белән генә чикләнми. 1916 елның мартыннан башлап ул «Шәрык телләре семинары» эшендә катнаша, атаклы шәркыятьче галим Готтхольд Вайльгә ярдәм йөзеннән Вюнсдорфтагы татар әсирләренең хатларын тәрҗемә итә, өйрәнә[79]. Эшнең нәтиҗәсе буларак, 1930 елда Г.Вайльнең 1917–1918 елларда татар әсирләреннән җыеп тупланган җырлар җыентыгы дөнья күрә[80]. Аның чыгуында Б.Сәйфелмөлековның да өлеше булганлыгын чамалау кыен түгел. Шул ук вакытта ул үзен педагог буларак та таныта алган: 1918 елның апреленнән

---

[74] Оренбурглы мөселман студентлары кайда? // Кояш. 1914. 28 август.

[75] Льеж студентлары // Йолдыз. 1914. 3 сентябрь.

[76] Гайнетдинов Р.Б. Тюрко-татарская политическая эмиграция: начало XX века – 30-е годы: Ист. Очерк. Набережные Челны: Камский издат. дом, 1997. С. 57.

[77] Гарифуллин Д. Алман җирендә «Татар иле» // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1996. № 1/2. С. 221–225.

[78] Цвиклински С. Из истории татарской прессы и книгоиздательской деятельности татар в Германии (XX – начало XXI вв.) // TATARICA. 2013. №1. С. 177.

[79] Насыров Т. Татарская эмигрантская пресса // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2004. №2. С. 120.

[80] Цвиклински С. Из истории татарской прессы и книгоиздательской деятельности татар в Германии (XX – начало XXI вв.) // TATARICA. 2013. №1. С. 177.

алып, әле үзе дә студент хәлендә, Вайль җитәкчелегендә Берлин университетында татар теле укыта башлый[81].

Университетта дәресләр саны кимегәннән соң, ул укытуын тәмамлый һәм эштән китә[82]. Ә 1924 елда немец ориенталистлары өчен татар теле курслары оештыра. 1925 елның башларында Б.Сәйфелмөлеков укытучылык эше белән шөгыльләнү өчен Ташкент шәһәренә китәргә теләк белдерә. Аңа рөхсәт бирелә, ләкин шуннан соңгы язмышы хакында билгеле түгел[83].

## *Габдулла Тимер*

Габдулла Гыйззәтулла улы Тимер Казан губернасы Спас өязе Иске Салман авылында дөньяга килгән. Шул авылның Гыйззәтулла хәзрәт улы. Уральск шәһәрендә белем алганнан соң, сугышка кадәр белем алу максаты белән Мисырга бара һәм анда «әл-Әзһәр» дарелфөнүнендә укый, Коръән хафиз була, аннан соң Кодеста югары укытучылар мәктәбен тәмамлый. Яшьтән үк спорт белән кызыксына, шуңа да махсус рәвештә укып, Лондонга барып, андагы тәрбия вә эзчелек институтыннан эзчелек (скаутлык) шәһадәтнамәсен ала[84]. Сугыш башлану белән, ватанына кайта алмый бүленеп кала. Фәләстыйнда урнашып, Хайфа шәһәрендә яши, мөгаллимлек итә башлый. Анда «Әмирия» мәдрәсәсендә гарәп балаларына Коръән, тәфсир, голүме шәргыя һәм тән тәрбиясе фәннәрен укыта. Бик күп телләрне – инглиз, француз, гарәп, фарсы телләрен камил рәвештә белә.

Г.Тимер Фәләстыйнда эзчелек хәрәкәтенә нигез салучы булып санала[85]. Бу хәрәкәттә катнашучы яшьләр, сәясәткә керми генә, физик, рухи һәм акыл үсеше мәсьәләләре белән шөгыльләнгәннәр.

Габдулла Тимер Гаяз Исхакый белән яхшы таныш булган. Бу хакта язучы үзенең «Ислам мәмләкәтләрендә» дигән юл истәлекләрендә искә ала, Фәләстыйнда ни рәвешле Габдулла Тимер белән очрашуы хакында бәян итә[86]. Г.Исхакый Габдулла әфәнде укыткан гарәп мәдрәсәсендә булып, мөгаллимнәр һәм шәкертләр белән күрешә, «Бу Идел буе төрек-татарының

---

[81] Гилязов И.А. Готтхольд Вайль как исследователь татар и татарского языка // Филология и культура: Philology and culture. 2015. №1(39). С. 272–273.

[82] Гилязов И.А., Гатауллина Л.Р. Российские солдаты-мусульмане в германском плену в годы Первой мировой войны (1914–1920). Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. С. 144.

[83] Гилязов И. Общество поддержки российско-мусульманских студентов в Берлине (1918–1925) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1996. № 3/4. С. 199.

[84] Исхакый Г. Ислам мәмләкәтләрендә // Гаяз Исхакый. Сайланма әсәрләр. 15 томда. Т. 10. Б. 323.

[85] Тимер Г. Эзчелек (бер-ике сүз) // Яңа милли юл. 1932. №9. Б. 25.

[86] Исхакый Г. Ислам мәмләкәтләрендә // Гаяз Исхакый. Сайланма әсәрләр. 15 томда. Т. 10. Б. 323–326.

пәйгамбәрләрнең туган йире булган Фәләстыйнда гарәп балаларына Коръән өйрәтүе тагын гаҗәп төсле булып китте», – дип яза ул зур гаҗәпләнү белән.

Г.Исхакыйның эзчелек хәрәкәте турындагы кызыксынуларына җавап итеп, Г.Тимер «Яңа милли юл» журналында скаутлык хәрәкәтенә багышланган «Эзчелек (бер-ике сүз)» дигән мәкаләсен бастырып чыгара[87]. Шул ук санда Габдулла Тимернең фотосурәте урын ала. Автор 1908 елда Англиядә барлыкка килгән әлеге хәрәкәтнең, татарлар арасында таралган очракта, милләтнең рухи һәм җисми сәламәтлеге өчен файдасы зур булачагы турында яза: «татар балаларын да шундый бер учакка җыеп тәрбия итү һәм спортны халык эченә күбрәк таратып, яшьләрнең тән тәрбияләренә зуррак әһәмият бирүнең ничаклы мөһим булганлыгы билгеле»[88]. Эзчелекнең нигезләрен аңлатып, ул: «Эзчелек – ул балаларга тормышта кирәк булган нәрсәләрне табигатьнең үзеннән өйрәнә. Эзче – егет һәм намуслы кеше дигән сүз», – дип яза. Туган иленнән читтә яшәргә мәҗбүр булган татар кешесенең, инде, мөгаен, кире әйләнеп кайтачагына өмете аз булса да, һаман үз милләте, аның тормышы һәм киләчәге хакында уйлавы аның милли хисләренең нык булуы, милли үзаңының югары булуы турында сөйли. «Балаларның бик кечкенәдән үк чыдамлы, намуслы һәм ачык зиһенле булып үсүләре өчен бөтен милләтләрдә булган бу учакның бездә дә корылуы кирәк иде», – дип яза ул, татар балаларына физик тәрбия бирүнең әһәмиятенә басым ясап[89].




*Габдулла Тимер*
*(«Яңа милли юл», 1932, №9, б. 25)*

[87] Тимер Г. Эзчелек (бер-ике сүз) // Яңа милли юл. 1932. №9. Б. 23–25.
[88] Шунда ук. Б. 23.
[89] Шунда ук.

## Америка уку йортларында татар шәкертләре

XX гасыр башында, бигрәк тә Беренче рус революциясеннән соң, белемгә сусаган, үз милләтен үстерү, башкаларга таныту теләге белән янган татар егетләре ерак Америкага омтыла башлыйлар. Татар җәмгыятендә шактый зур яңгыраш алган әлеге күренешне татар газеталары, аерым алганда, «Вакыт» газетасы шактый тулы һәм җентекле яктырта. Әлеге газетаның 1911 елгы 11 сентябрь санында Сан-Францискода белем алучы татар егете Хәбибулла Байбулатовның «Америкадан мәктүб» дигән мәкаләсе басылып чыга. Химия мәктәбенә укырга кергән татар егете яшьләрне андагы уку һәм яшәү шартлары белән таныштыра[1]. Кызыксынучылардан бик күп хатлар килә. Газетаның 1912 елгы 9 март санында Х.Байбулатовның җавап хаты урнаштырыла[2]. Әлеге мәкаләдән күренгәнчә, Америка мәктәпләрендә белем алырга теләүче татар яшьләре арасында «Галия» мәдрәсәсе шәкертләре, Бәйрут көллиятендә укучы (Габдрахман Рәми), шулай ук Томск губернасында, Омск, Петербург, Оренбург һ.б. шәһәрләрдә яшәүче егетләр була.

Шул ук «Вакыт» газетасының 1915 елгы 23 сентябрь санында Американың Индиана штатындагы Вальпараисо университетында белем алучы ике татар егете – чыгышы белән Себердән булган Фуад Әнвәров һәм Ташкент шәһәреннән килгән Галимҗан Сәйфелмөлековның фоторәсеме басылып чыга[3]. 1914–1915 елларда «Шура» журналында укучылар игътибарына Ф.Әнвәровның «Вальпараисо университеты (Америкада)» дигән мәкаләсе тәкъдим ителә[4].

Болардан тыш, 1914–1923 еллар аралыгында Индиана шатында урнашкан Вальпараисо университетында белем алган Зыя Мөҗавировны, Фазыл Бәкерне, Айовада белем алган Закир Габдулиннарны күрсәтергә мөмкин.

Әлеге шәкертләр турында төп мәгълүмати чыганак XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты булса да, кайбер шәхесләр, әйтик Вальпараисо университетында укучы татарлар турында әлеге уку йортының архивларыннан да кайбер документлар табылды.

Вакытлы матбугат язмаларына таянып, студентларның кайберләре турында аерым фактларны (исем-фамилияләре, чыгышы, кайсы уку йортында укуы, кайсы елларда һ.б.) ачыкларга мөмкин. Аларның үзләренең мәкаләләре нигезендә гомумән ватаннан читтә белем алуның үзенчәлекләре, уңай яклары һәм җитешсезлекләре, авырлыклар, уку йортларының тәртипләре, керү һәм уку шартлары һ.б. турында белергә мөмкин.

---

[1] Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1911. 11 сентябрь.

[2] Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1912. 9 март.

[3] Америкада татар шәкертләре // Вакыт. 1915. 23 сентябрь.

[4] Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1914. №22. Б. 697–699; Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1915. №2. Б. 54–56.

Чит мәмләкәтләрдә, аерым алганда Америка уку йортларында белем алу белән бәйле рәвештә берничә үзенчәлекне аерып күрсәтергә була. Беренчедән, татарлар, кая гына, кайсы кыйтгага гына барып чыксалар да, белем һәм мәгарифнең төп максаты итеп милләтенә, ватанына хезмәт итүне санаганнар. Шуңа күрә алар мөмкинлектән файдаланып, күбрәк белем тупларга тырышканнар, чөнки милләтнең алгарышы, киләчәге өчен аның белемле яшьләре җаваплы икәнен аңлаганнар, дөньякүләм киңлеккә чыгып, заманча гыйлемнәр үзләштерергә тырышканнар. Европа, Америка уку йортлары, аларның фикеренчә, татар милләтенең алга китешенә ярдәм итәргә мөмкин, моның өчен күбрәк татар баласына шунда барып уку мөмкинлеген тудырырга кирәк.

Икенчедән, әлеге уку йортларында укуның аерым нюанслары булган, һәм аларны алдан ук белеп бару хәерле саналган. Әйтик, Америка уку йортларында уку теле – инглиз теле, шуңа күрә әлеге телне өйрәнүгә зур әһәмият бирергә тиешле. Моның өчен Мәскәү я Петербургта 6 айлык тел курсларында укырга мөмкин[5]. Ә инде андый мөмкинлек юк икән, уку йорты урнашкан шәһәрдә төрле тел өйрәнү, хәзерлек курсларында да инглиз телен үзләштерергә мөмкин. Тагын бер мөһим таләп – сәламәтлекнең нык булуы. Берәр әгъзасы сәламәт булмаган, бигрәк тә күзләре зәгыйфь булган кешене хәтта Америкага бара торган пароходларга да утыртмыйлар[6]. Әлбәттә, күпмедер күләмдә акча булу кирәк. Шулай да, иң төп шарт, ул, әлбәттә, сәләт, зиһен һәм тырышлык. Татар яшьләре әлеге таләпләрне истә тотып, уку йортына керү өчен алдан ук хәзерлек күргәннәр. Татар милләтен ватаннарында гына түгел, чит кыйтгаларда да танытуны максат иткәннәр.

## *Хәбибулла Байбулатов*

*«Максудым – үз ватандаш вә милләттәшләремә*
*хезмәт итмәк вә файда китермәктер»*

Инде алда әйтеп узылганча, чит мәмләкәтләрдә белем алган татар яшьләре һәм беренчеләрдән булып гыйлем артыннан ерак Америка кыйтгасына барып чыккан Хәбибулла Байбулатов турындагы мәгълүмат беренче тапкыр «Вакыт» газетасында дөнья күрә. 1911 елдан химия мәктәбендә укучы татар егете милләттәшләрен Сан-Франциско уку йортлары, андагы уку һәм яшәү шартлары белән таныштыра. Әлеге ерак кыйтгага барып чыгуының сәбәбен аңлатып, ул болай дип яза: «Максудым – һәр ни кадәр җәфа чигеп булса да,

[5] Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1912. 9 март.
[6] Шунда ук.

бер һөнәр үгрәнгәннең соңында үз ватандаш вә милләттәшләремә хезмәт итмәк вә файда китермәктер»[7]. Хатның ахырында ул хәбәрләшү өчен үзенең адресын урнаштыра. Чыннан да, уку йорты белән кызыксынучылар бик күп булып чыга, һәм автор аларның барысына да аерым-аерым җавап бирү мөмкинлеге булмау сәбәпле, редакциягә тагын бер хат юллый һәм татар яшьләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар бирә. Бу язма газетаның 1912 елгы 9 март санында басылып чыга[8]. Әлеге ил һәм уку йорты турында белергә теләүчеләр бик күп булгандыр, мөгаен, шул сәбәпле Х.Байбулатов бу темага караган мәкаләләрне моннан соң да шактый бастыра: «Америка мәктүбләре», «Америкадан» исеме белән «Вакыт», «Сибирия», «Тормыш» газеталарында байтак язмалары дөнья күрә.



*Хәбибулла Байбулатов*
*(«Вакыт», 1912, 27 май)*

Хәбибулла Байбулатов хакында мәгълүматлар юк дәрәҗәсендә. «Вакыт» газетасында дөнья күргән «Америкада бер татар шәкерте» дигән кыска хәбәрдә аның «Американың Сан-Франциско шәһәрендә тәхсил гыйлемдә булуы» хакында әйтелә, фотосурәте бирелә[9]. «Йолдыз» газетасы хәбәренә караганда, Америкада белем алган беренче татар егете Хәбибулла Акбулатов була[10]. И.Рәми, мөгаен әлеге мәгълүматка таянып, Х.Акбулатовның 1911 елда Америкага китеп, Сан-Францискодагы Химия институтында укуы хакында яза. Билгесез чыганакка нигезләнеп, «Укуын тәмам иткәч, Америкада сәүдә конторасы ачып, Россиядән пушнина товарын үткәрүдә арадашлык итә башлый. Вафатыннан соң, бу кәсепне улы Фатих дәвам иттерә», – дип яза[11]. Кызганычка каршы, әлеге тикшеренү кысаларында Акбулатов хакында башка бер дәлилле мәгълүматка тап булмадык. Шул сәбәпле, әлеге ике очракта бер үк шәхес хакында сүз баруы мөмкинлеген дә күздә тотабыз.

---

[7] Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1911. 11 сентябрь.
[8] Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1912. 9 март.
[9] Америкада бер татар шәкерте // Вакыт. 1912. 27 май.
[10] Дахили хәбәрләр // Йолдыз. 1913. 1 август.
[11] Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. Б. 361.

Мәкаләләрендә Х.Байбулатов үзен «олуг яшьтәге шәкерт» дип атый, Россиядә туып-үсүен хәбәр итә, тик төгәл урынын атамый[12]. Тайга станциясендә Мулланур әфәнде Магазовта дүрт ел дәвамында хезмәт итеп, белем алу өчен беркадәр акча туплавы хакында яза[13]. И.Рәмиев тә аның 1911 елдан Сан-Франциско шәһәрендә Химия институтында укуыннан тыш, башка информация бирми[14].

Язмаларында Байбулатов татар яшьләренә Америка тарихыннан мәгълүмат бирүне кирәк таба, аның Колумбтан башланган сәхифәләрен кыскача бәян итә[15]. Америкада яшәүче төрле кыйтгалардан җыелган милләтләргә тукталып, алар төрле булса да, һәрберсе үз динен, телен һәм гореф-гадәтләрен саклыйлар, «америкалашмыйлар», «Американың гомум һөнәреннән, байлыгыннан гына файда итәләр», ди. Шул ук вакытта ул биредә мөселманнарның бик аз булуын искәртә. Россиядәге татарларның укуга карата һаман да «җиңелчә» карауларына ризасызлык белдерә: бай балалары, аталарының байлыгына ышанып, гыйлем, һөнәр өйрәнмиләр; фәкыйрьләр читкә китеп укый алмыйлар, чөнки акчалары юк һәм аларга ярдәм итәргә ашкынып торган байлар да күп түгел, ди. Белем алу юлына баскан татар балаларының акчалары бик авырлык белән табылса да, бик тиз су кебек агып бетәләр. «Бу ялган сыйфатларны[16] бетереп чын мөселман улмак өчен [...] Америка, Европага китеп укырга, бик күп гыйлем-һөнәр әһеле хәзерләргә форсаттыр. Тәрәкъкыйның юлы шулдыр»[17]. «Сибирия» газетасын укучылар арасында Себердә яшәүче мөселманнарның күп булуын истә тотып, ул беренче чиратта аларга мөрәҗәгать итә: «Себер мәмләкәте байлык ягыннан үзе икенче Америкадыр. Кулыңыздагы форсатны качырмаңыз. Дөньяның һәр ягына таралып, гыйлем-һөнәр өйрәник!»[18].

«Америка мәмләкәте яңа ачылган, яңа дөнья булса да, гыйлем-һөнәр җәһәтеннән барысыннан да алда, барысыннан да югары дәрәҗәдә торадыр», ди, бу хәлнең сәбәбен ул техниканың гаять алга китүендә һәм халыкның тырышлыгында, байлыгында күрә. Һөнәри белем бирүнең асылына тукталып, Х.Байбулатов андагы мәктәпләрнең чынлыкта үзенчәлекле фабрикалар булуы, ягъни белем бирүнең гамәли нигезләрдә алып барылуы турында яза. Татарлар өчен бу мәктәпләрдә укуның әһәмияте, нәтиҗәләре гаять зур булачагына инанып, ул: «100 татар баласын Американың һөнәр мәктәпләрендә

[12] Байбулатов Х. Америка мәктүбләре // Сибирия. 1912. 10 март.

[13] Шунда ук. 18 февраль.

[14] Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. Б. 361.

[15] Байбулатов Х. Америка мәктүбләре // Сибирия. 1912. 10 март.

[16] Автор татар җәмгыятендә күзәтелгән ялкаулык, үзара дошманлык, фәкыйрьлек кебек сыйфатлар турында сүз алып бара.

[17] Байбулатов Х. Америка мәктүбләре // Сибирия. 1912. 13 май.

[18] Шунда ук.

укытса идек. Безнең халык арасында тизлек илә һөнәр таралырга сәбәп булыр иде», – ди, бу эшнең барып чыгуы өчен хәмитле татар байларының булышлык итүләрен үтенә[19].

Х.Байбулатов хәбәр итүенчә, бу мәктәптә укулар кичен алып барылган һәм түләүсез булган. Укучыларны, кайсы илдән яки шәһәрдән булуына карамастан, кабул иткәннәр[20]. Шуңа да, теләк һәм омтылышлар көчле булганда, бирегә килеп белем алу һәр татар кешесе өчен дә мөмкин эш. Чыннан да, бу хатлар белән танышканнан соң, Американың мәгариф системасы, югары мәктәпләре белән кызыксынган, аларда белем алырга теләгән татар яшьләренең саны арта[21].

Сан-Францискода төрле кыйтгалардан килгән милләт вәкилләре белем ала. Алар арасында, Байбулатов билгеләвенчә, японнар аерылып тора. Аларның үз җәмгыятьләре бар, һәм алар укуда бер-берсенә ярдәм итеп торуны үзләренең бурычлары саныйлар. Бу хосустан караганда, Япониянең дәүләт сәясәте искиткеч: хөкүмәт һәм хосусый голүм тарату җәмгыятьләре ел саен Америкага гына 100ләп шәкертен җибәрә, аларны уку дәвамында матди яктан тәэмин итә. Нәтиҗәсе дә шатлыклы: һәр ел әллә никадәр белгеч, Япониягә кайтып китеп, илнең сәнәгатен һәм икътисадын үстерергә ярдәм итәләр, Америка ысулы белән һөнәр, мәгъдән эшләрен (руда эшкәртү) тәрәккъый иттерәләр. Төрекләрдә һәм татарларда, үз сәнәгатьләре тиешле дәрәҗәдә булмау сәбәпле, милләт акчасы җиһазлар, тукымалар һ.б. алу өчен читкә китә. Татарларга да японнар кебек тәрәккъыятьле милләтләрдән үрнәк алып, белемле, зыялы затларын булдырырга, милләтнең киләчәге, байлыгы өчен тырышырга кирәк, ди[22]. «Шул гали һөнәр илә мөлкәтемезне, ватанымызны, малымызны сакларлык хәлгә килермез икән? [...] Әгәр заманына күрә без дә голүм-һөнәр илә кораллanmасак, башкаларга да кол улачагымыз бик ачыктыр. Җитәр инде, күп йокладык...», – дип яза ул ачынып[23].

Һөнәри белем һәм тәрбия бирүнең әһәмиятен Х.Байбулатов башка мәкаләләрендә дә күтәреп чыга. Шундый язмаларның берсендә, мәсәлән, ул Америкада үткәрелә торган һөнәр бәйрәмен – һөнәр һәм гыйлемгә, сәнәгатькә, һөнәр ияләренә дан җырлаган чараны сурәтли[24].

Хәбибулла Байбулатов татар укучыларын Америка тормышы, аның мәгарифе, сәнәгать үсеше кебек мәсьәләләр белән таныштырып торган иң актив татар студентларының берсе дияргә мөмкин. 1914 елда ул «Тормыш» газетасының үз мөхбире (хәбәрчесе) вазифасын башкара[25]. Аның язмалары аша


---

[19] Байбулатов Х. Америка мәктүбләре // Сибирия. 1912. 10 март.
[20] Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1911. 11 сентябрь
[21] Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1912. 9 март.
[22] Байбулатов Х. Америка мәктүбләре // Сибирия. 1913. 6 гыйнвар.
[23] Шунда ук.
[24] Шунда ук. 6 февраль.
[25] Байбулатов Х. Америкадан // Тормыш. 1914. 18 гыйнвар, 21 гыйнвар.

Америка уку йортлары һәм анда уку шартлары турында гына түгел, чит мәмләкәткә китеп гыйлем алган татар яшьләренең уй-фикерләре, кичерешләре, хыяллары турында да мәгълүмат алырга мөмкин.

## *Закир Габдуллин*

1913 елда «Вакыт» газетасында Америкада белем алучы тагын бер татар егете[26] Закир Габдуллинның[27] «Америка мәктүбләре» дигән исем астында берничә мәкаләсе басылып чыга[28]. Соңрак шул ук газетада аның фотосурәте[29] һәм «Америкада әҗнәби мәмләкәт таләбәләре» дигән тагын бер язмасы дөнья күрә[30].



*Закир Габдуллин*
*(«Вакыт», 1914, 11 февраль)*

Закир Габдуллин турындагы мәгълүматлар белән аның үз мәкаләләре аша беркадәр танышырга мөмкин. Әлеге мәкаләләр нигезендә аның чыгышы белән Уфа губернасының Бәләбәй өязеннән булуы ачыклана. Шулай ук «Йолдыз» газетасында дөнья күргән, «Дахили хәбәрләр» сәхифәсенә караган язмада да күпмедер информация бар. Мәкалә авторы З.Габдуллинның Бәйруттагы Америка көллиятен тәмамлап, 1913 елның 1 июлендә Бәйруттан Америкага укырга чыгып китүе хакында хәбәр итә[31]. Татар матбугаты тарихы белгече И.Рәми аның әүвәл Истанбулда һәм Мисырда укыганнан соң, 1913 елда Америкага күчеп, авыл хуҗалыгы институтына[32]

[26] Закир Габдуллин Америкада укучы өченче татар егете була. Беренчесе – Хәбибулла Байбулатов, икенчесе – Екатеринбург имамы мәрхүм Хәким хәзрәтнең улы Хәбибулла әфәнде (?), Бәйруттагы Америка көллиятен тәмамлап, Америкага укырга киткән (Дахили хәбәрләр // Йолдыз. 1913. 1 август.)

[27] Кайбер чыганакларда аның фамилиясе Абдуллин дип күрсәтелгән.

[28] Габдуллин З. Америка мәктүбләре // Вакыт. 1913. 25 октябрь; Габдуллин З. Америка мәктүбләре (Америкада әҗнәби мәмләкәт таләбәләре) // Вакыт. 1914. 11 февраль.

[29] Америкада татар шәкерте. Закир Габдуллин // Вакыт. 1914. 11 февраль.

[30] Габдуллин З. Америкада әҗнәби мәмләкәт таләбәләре // Вакыт. 1914. 11 февраль.

[31] Дахили хәбәрләр // Йолдыз. 1913. 1 август.

[32] З.Габдуллин бу уку йортын үзе көллият дип күрсәтә – “Iowa State College”. Ул Айова университеты составындагы уку йорты була.

керүен язып калдырган[33]. Төгәлрәк итеп әйткәндә, бу Айова зирагать мөһәндислеге, бүгенге телгә күчергәндә, авыл хуҗалыгы өчен инженерлар әзерләүче уку йорты була. З.Габдуллинның нәкъ менә шушы юнәлешне сайлавына, «Йолдыз»дагы мәкалә авторы сүзләренә караганда, Бәләбәйдә үзләренең җир-сулары күп булуы сәбәп була[34].

Закир Габдуллин, шул заманда чит илләрдә белем алган башка татар яшьләре кебек үк, үзе өчен моңарчы бөтенләй таныш булмаган яңа дөнья, яңа илләр, милләтләр һәм мәгариф турындагы фикерләре белән уртаклаша, чит мәмләкәттә уку шартларын, мөмкинлекләрне моңарчы үзе белем алган мәктәп-мәдрәсәләр, гимназияләр белән чагыштыра, андагы кешеләр, төрле милләт вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләрне күзәтүдән туган кайбер уй-фикерләрен татар укучыларына җиткерә.

З.Габдуллин язган мәкаләләрнең төп максаты – татарларны инженерлар әзерләү буенча Америкада беренче, авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча икенче урында торган, бик күп күренекле шәхесләр-белгечләр тәрбияләп чыгарган, мәртәбәле[35] Айова университетына керү һәм уку шартлары, анда яшәүнең нечкәлекләре белән таныштыру. Шул ук вакытта, аның фикеренчә, Америкада белем алырга уйлаган һәр кеше, анда барып ирешкәнче, үзенең теләкләрен генә түгел, мөмкинлекләрен дә күздән кичерергә тиеш. Чөнки күп кенә очракта, яшьләр бер-берсеннән күреп-ишетеп, ул илләрнең үзенчәлекләрен һәм укытуның шартларын белеп бетермәстән, чит мәмләкәтләргә чыгып китәләр һәм авырлыклар алдында берүзләре калалар. Шуңа күрә мондый зур сәфәргә алдан ук өйрәнеп һәм әзерләнеп, мөмкин булган кыенлыкларны алдан ук күреп, истә тотып чыгарга кирәк.

З.Габдуллин хәбәр итүенчә, Айова университетындагы уку шартлары студентлар, шул исәптән чит илләрдән килеп укучы яшьләр өчен, гомумән алганда шактый уңайлы булса да, алар беренче караштагыча бик үк гади түгел. Иң беренче шарт – үзең укырга теләгән белгечлеккә караган фәннәр буенча билгеле бер дәрәҗәдә белемнәргә ия булу. Укырга сәләте булмаган яшьләрне биредә кабул итмиләр. Сәләтле, тырыш, әмма университет таләп иткән дәрәҗәдә белеме булмаганнарга әзерлек курслары үтеп укырга керү мөмкинлеге бар. Ләкин, авторның билгеләп үтүенчә, бу эш өстәмә вакыт һәм чыгымнар таләп итәчәк. Моннан тыш, Айова университетына, һәм, гомумән, Америкадагы башка барлык уку йортларына укырга керү өчен иң кирәкле, мәҗбүри шартларның берсе – уку теле булган инглиз телен белү. Шуңа күрә бу үзенчәлекләрне алдан ук белеп, ватанда чакта ук әзерләнеп киленсә, «эшне яртылай җиңеләйтү» булачак. Шуны да истә тоту мөһим – булачак студент

[33] Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. Б. 361.

[34] Дахили хәбәрләр // Йолдыз. 1913. 1 август.

[35] Габдуллин З. Америка мәктүбләре // Вакыт. 1913. 25 октябрь.

акча, укыган өчен түләү мәсьәләсенә дә алдан ук әзер булып торырга тиеш. Чөнки, гәрчә эшләп уку мөмкинлеге булса да, бигрәк тә беренче елны «профессорлар эшкә ышанып килүне муафыйкъ күрмиләр»[36].

Габдуллин Америкага килергә карар итүчеләрнең үз-үзләренә нык ышанган, тәртипле (уку мәсьәләсендә аеруча), сәләтле булуларын, уку эшенә бик җитди карауларын төп шартларның берсе итеп күрсәтә: «монда татар мәдрәсәләре, Истанбул җамигълары юк, мәктәпкә кергән вакытта шул мәктәптә укыла торган дәресләрне яхшы, монтазам (тәртип белән) алып барырлык булсаң гына кабул итәләр. Эш бик катгый. Икътидарың (мөмкинлегең, сәләтең) юк икән, туп-туры: кабул итә алмыйбыз, диләр. Затән (нигездә) бу хәл Европа мәктәпләрендә дә шулайдыр. Шуның өчен кабул булуына ышана алмаган кешеләр теләдекләре мәктәпкә кирәк өчен хәзерлек үтәргә кирәк булачагын да уйлап килергә тиешлеләрдер»[37].

Бу мәкаләләрнең төп максаты татар яшьләрен Америкада белем алуга әзерләү булганга, автор аларны башка илләрдән килеп белем алучы студентларның тормышы-яшәеше белән таныштыруны да максат итә. Америкадагы һәрбер уку йортында чит ил студентларының үз җәмгыятьләре, төрле оешмалары булган. З.Габдуллин укыган Айова мәктәбендә дә шундый җәмгыять – «идарәле пансион» ачыла. Анда һәрберсе 150шәр сум акча биреп кергән 18 кеше әгъза булып тора (шуларның берсе – З.Габдуллин). Әлеге җәмгыятьләр үзара аралашып торганнар, уртак җыелышлар, съездлар үткәргәннәр, һәр чит ил студентына хас булган проблемаларны билгеләгәннәр, аларны бергәләп чишәргә омтылганнар. Шул ук вакытта һәр ел саен елга бер мәртәбә Американың төрле шәһәрләрендәге уку йортларында белем алучы чит ил студентларының бердәм, уртак җыелышлары да булган. 1914 елда ул Айова университетында узган[38]. 1915 елда исә Сан-Францискода шундый зур җыелыш үткәрергә карар кылына. Анда, автор билгеләвенчә, Америкадан гына түгел, дөньяның төрле кыйтгаларыннан студентлар җыелачак. Бу җыелышның «Космополитан» дип аталуы һәм «Бөтен милләтләр өстендә бер инсаният» дигән шигарь (лозунг) астында үткәрелүе аның гаять киң мәсләкле булачагы турында сөйли[39]. Шунысы кызык, «Вакыт» газетасында басылган шушы хатлардан Америкадагы шул берән-сәрән татар студентлары да татар дигән милләтне күрсәтә алган, дигән фикергә килергә мөмкин. Чөнки, Закир Габдуллин язуынча, әлеге җыелышларның берсендә җыелышның рәисе аңа:

[36] Габдуллин З. Америка мәктүбләре // Вакыт. 1913. 25 октябрь.

[37] Шунда ук.

[38] Икенче бер язмага караганда, әлеге җыелыш 1914 елда Айова штатындагы Де-Мойн шәһәрендә узган. «Вакыт» газетасы хәбәр иткәнчә, анда сайланган вәкилләр арасында Америкада укучы татар яшьләрен басманың мөхбире Закир әфәнде Габдуллин тәкъдим иткән (Америкада татар шәкертләре // Вакыт. 1914. 9 май).

[39] Габдуллин З. Америка мәктүбләре. Америкада әҗнәби мәмләкәт таләбәләре // Вакыт. 1914. 11 февраль.

«Татар мәктәпләреннән вәкил килсә, һич шөбһәсез, сезгә дә, безгә дә файдалы булыр иде», – дип белдергән. Татар шәкерте бу фикерне үзе дә бик мәслихәт дип кабул итә һәм «татар шәкертләре, я татар яшь зыялылары исеменнән һич булмаганда бер вәкил күндерелсә, бик яхшы булыр иде», дигән фикере белән газета укучыларына мөрәҗәгать итә һәм, әгәр татарлар арасыннан теләк белдерүче булса, алдан ук үзенә хәбәр итәргә кирәклеген искәртә[40].

Закир Габдуллин, Америкада ярлы балалары белән бергә миллионер балаларының бер табында ашап-эчеп, бергә укуларын күреп, гаҗәпкә калуы турында яза. Аны шулай ук Америкада укучы Кытай, Мексика, Филиппин, Япония кебек илләрдән килгән студентларның, нинди милләттән һәм диннән булуына карамастан, үзара дус һәм тату яшәүләре сокландыра. «Бик гариб вә бик гаҗиз бер вакытта бу чит мәмләкәт таләбәсе миңа зур бер ярдәм итте. Яныма киләләр, сораша, мотаябә кылалар (уен-көлкеле сүзләр белән күңелне күтәрәләр), йөрергә алып чыгалар, әлхасыйль, нинди булса бер юл табып, минем ялгызлыгымны оныттыралар иде. Болар арасында мин иң гариб булырга тиешле бер вакытымны да иң күңелле бер сурәттә уздырдым. Болар миңа шулкадәр рәхимле, шулкадәр шәфкатьле иделәр, болар арасында булган вакытта мин үземне Русиядә, туган гаиләм янында кебек хис итә идем», – дип яза ул бу хакта[41].

Никадәр генә яхшы шартлар тудырылса да, З. Габдуллин әлеге ерак кыйтгалар өчен билгесез бер өммәт кешесе. Америкалылар татарлар турында һични белмиләр, күп очракта аларны үзләренә бөтенләй охшамаган, кыргый халык дип күзаллыйлар. З.Габдуллинның Американың әлеге шәһәренә укырга килүе дә, мөгаен беренче очрак булу сәбәпледер, Айова җәмгыятендә «сенсация» буларак кабул ителә. Ул уку йортына керү белән, җирле газеталарның берсендә аның турында «Айова заригать мөһәндислеге мәктәбенә ерак Русиядән бер татар егете килде», – дип хәбәр иткән мәкалә басылып чыга[42]. Бу мәгълүмат белән танышкан америкалылар, татар кешесен күрергә теләп, мәктәпкә киләләр. «Шул татарны күрәсе иде, нинди кеше икән?» дип кызыксынучыларны күреп, Закир Габдуллин, мөгаен, татарларның чын мәгънәсендә кем икәнлеген күрсәтергә вакыт җитте, дип уйлап куйгандыр. Ул заманда татар яшьләре милләтен бөтен дөньяга күрсәтү, танытуның иң мөһим юлларыннан берсе итеп мәгърифәткә омтылу, башка милләтләр арасында югалып калмаслык белемнәргә ия булуны санаганнар, шуңа да чит мәмләкәтләрдә үзләрен татар милләтенең бер вәкиле буларак танытуны максат иткәннәр, моның өчен кулдан килгән кадәр тырышканнар.

[40] Габдуллин З. Америка мәктүбләре. Америкада әҗнәби мәмләкәт таләбәләре // Вакыт. 1914. 11 февраль.

[41] Шунда ук.

[42] Габдуллин З. Америка мәктүбләре // Вакыт. 1913. 25 октябрь.

## *Фуад Әнвәров, Галимҗан Сәйфелмөлеков*

Татар яшьләренә иң яхшы дип саналган чит ил университетларында укыту мөмкинлеген тудырып, белем һәм мәгърифәт аша гомумән милләтне күтәрү, татарларны башка милләтләр арасында лаеклы итеп күрсәтү – Америка, Европа университетларында укыган татар студентларының иң зур теләге була. Американың Индиана штатындагы Вальпараисо университетында[43] белем алган ике татар егете – Фуад Әнвәров һәм Галимҗан Сәйфелмөлековлар да, тиешле дәрәҗәдә белем алып, киләчәктә милләт мәнфәгатьләрен кайгыртуны максат иткәннәр. Фуад Әнвәров татарлар дөньяның иң яхшы, алдынгы уку йортларында укырга тиеш дип саный: «Без дә башка милләт яшьләре кебек барлыгыбызны күрсәтик, татарның нәрсә икәнлегеннән хәбәре булмаган америкалыларга аның Шәрыктан туып килә торган кояш шикелле төрле вә өметле бер милләт булганын белдерик. Үземездән гали булган башка милләтләр арасында таралыйк. Алардан дәрес алып бераз дөнья күрик»[44].



*Фуад Әнвәров*
*һәм Галимҗан Сәйфелмөлеков*
*(«Вакыт», 1915 ел, 23 сентябрь)*

1914–1915 елларда «Вакыт» газетасында һәм «Шура» журналында Фуад Әнвәровның Вальпараисо университеты һәм анда белем алу шартларына багышланган мәкаләләре басылып чыга[45]. Автор үзе укый торган «Вальпараисо университеты хакында милләтемезнең тәхсилгә (белем алуга) һәвәсле яшьләренә беркадәр мәгълүмат бирүне» үзенең максаты иткән[46]. «Вакыт» газетасының 1915 елгы 23 сентябрь санында «Америкада татар шәкертләре» дигән исем астында ике сабакташ – Фуад Әнвәров

---

[43] Вальпараисо университеты 1859 елда Кушма Штатлардагы ир һәм кыз балалар бергә укый торган беренче көллиятләрнең берсе буларак барлыкка килә. Гражданнар сугышы вакыйгалары белән бәйле рәвештә 1871 елда ул ябыла. Кабат 1873 елда эшли башлый. 1900 елда университет статусын ала.

[44] Әнвәров Ф.Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1915. №2. Б. 56.

[45] Әнвәров Ф. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1914. 8 ноябрь; Әнвәров Ф. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1914. 21 ноябрь; Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1914. №22. Б. 697–699; Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1915. №2. Б. 54–56.

[46] Әнвәров Ф. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1914. 8 ноябрь.

һәм Галимҗан Сәйфелмөлековның фоторәсеме һәм алар турында кыскача мәгълүмат дөнья күрә[47].

Бу ике егет турында да, кызганыч, аз билгеле. «Шура»дагы мәкаләгә карaганда, Фуад Әнвәров чыгышы белән Себердән, ә Галимҗан Сәйфелмөлеков Ташкент шәһәреннән була. Америкага алар авыр юллар үтеп, Истанбул аша килеп ирешәләр. Вальпараисо дип аталган шәһәрнең бер үк вакытта ике илдә – Чилида (Көньяк Америка) һәм Төньяк Американың Индиана штатында булуы сәбәпле, әлеге ике егет укыган белем йортын билгеләүдә төрлелек күзәтелә. Гәрчә ул үзенең мәкаләсендә Вальпараисо университетының Индиана штатында икәнлеген ассызыкласа да, И. Рәми һәм Р. Даутов белешмәлегендә ул, ялгышлык белән, Чилидагы Вальпараисо университетында укый дип күрсәтелә[48]. Соңгы фикернең хата икәнлеген раслаучы архив мәгълүматы – Ф. Әнвәровның Төньяк Америкадагы Вальпараисо университетында укыганлыгы турындагы документ табылды[49]. Һәм тикшеренүләр нәтиҗәсендә әлеге уку йортында укучы татар шәкертләренең әлеге ике заттан тыш та булуы ачыкланды.

Вальпараисо университетының 1915–1916 елгы бюллетенендә Россиядән укырга килгән Әнвәр Фуад (Анвер Фуад) турында кыскача белешмә бирелә[50]. Бу докумет нигезендә аның әлеге уку йортының әзерлек курсларында укуы билгеле булды.

Вальпараисо университетының 1914–1915 елгы студентларны исәпкә алу кенәгәсенең 6 битендәге мәгълүматларга караганда, Фуад Әнвәров чыгышы белән Себердән, Зайсаннан[51] дип күрсәтелгән. 1914–1915 елларда ул университетта авыл хуҗалыгы белгечлеге (агрокультура) буенча белем алган, чит телләр, геометрия, тарих, стереометрия, алгебра, борынгы тарих кебек предметларны үзләштергән. Әнвәровның укуда өлгергәнлеге югары – алда санап үтелгән предметлар буенча мөмкин булган 100 баллдан 70–95 балл җыйган[52]. Кызганычка каршы, мәгълүматлар 1915 елның март ае белән төгәлләнә.

---

[47] Америкада татар шәкертләре // Вакыт. 1915. 23 сентябрь.


[48] Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. Б. 364.

[49] Әлеге документны эзләп табуда безгә ярдәм иткән Казахстан университеты профессоры Розалия ханым Гариповага ихлас рәхмәтебезне белдерәбез.

[50] Valparaiso University Bulletin. Forty-Second Annual Catalog 1915–1916. P. 162.

[51] Хәзерге Казахстанның Зайсан шәһәре, XIX гасырның икенче яртысыннан Россиянең Кытай белән сәүдә капкасы ролен үтәгән.

[52] Student Credits book of Valparaiso University. 1914–1915. Old School Ledgers p. 6. URL: http://collections.valpo.edu/cdm/compoundobject/collection/ledgers/id/9399.



1914-1915 | Sept. 22 | Dec. 15 | March 9


| | 1st TERM | 2nd TERM | 3rd TERM |
|---|---|---|---|
| NAME. J.W. Andrews<br>POSTOFFICE. 188 Shelton ave Jamaica L.I.<br>COUNTY. Queens<br>STATE. N.Y.<br>COURSE. Eng<br>John Andrews | SUBJECTS Alg I<br>Geometry II<br>Gymn I<br>Grammar 1 wk. | | |
| NAME. Arthur A. Annis<br>POSTOFFICE. Bremen<br>COUNTY. Marshall<br>STATE. Ind<br>COURSE. M.T.<br>Chas. E. Annis | SUBJECTS Mech. Draw II 90<br>Solid Geom 93<br>Cabinet Making & Mach work 94 | | |
| NAME. Fuad Anweroff<br>POSTOFFICE. Zaysan<br>COUNTY. Siberia<br>STATE. Russia<br>COURSE. agriculture | SUBJECTS Read. + Lang., 12 wks | Grammar 80<br>Geometry I 90<br>Reading 85<br>Orthoepy 80<br>History 70 | Solid Geom. 85<br>Alg. III 95<br>Ancient Hist. 70 |

*Вальпараисо университеты бюллетене*
*(Valparaiso University Bulletin. Forty-Second Annual Catalog 1915–1916. P. 162)*

Шәкертләрнең икенчесе – Галимҗан Сәйфелмөлеков шәхесен ачыкларлык төгәл мәгълүматлар әлегә табылмады. Шулай да Үзбәкстан татарларының «tatar.uz» сайтында[53] әлеге шәхес хакында кыскача хәбәр һәм берничә фотосурәткә тап булдык.


[53] http://tatar.uz/?page_id=3655




*Вальпараисо университеты бинасы сурәтләнгән открытка һәм аның арткы ягында Г.Сәйфелмөлековның (А.С.Малекофф) якыннарына язган хаты. 1915 ел, 3 август (http://tatar.uz/?page_id=3655)*

Искә алынган мәкалә татар яшьләрен Вальпараисо университеты, анда керү шартлары белән таныштыру максатын күздә тотып язылган. Шул сәбәпле анда уку, яшәү шартлары бик тәфсилле рәвештә тасвирлана. Авторга бигрәк тә университетның «демократический әсасларга корылуы» ошый: «Монда нәсел, байлык, кибарлык, мәзһәб, милләт, табгалек (кемгәдер иярү) кебек нәрсәләр һичбер роль уйнамыйлар»[54]. Америкадагы мәгариф өлкәсендәге алга китешне Россиядә яшәүче мөселманнарның мәгарифе белән чагыштырып, ул аерманың бик зур икәнлеген ассызыклый. Әлбәттә бу очракта аерымлыкларга ике ил һәм ике мәгариф кенә түгел, ә дини һәм дөньяви белем арасындагы үзенчәлекләр буларак карарга кирәк.


162 *VALPARAISO UNIVERSITY.*

**REGISTER OF STUDENTS**

**PREPARATORY DEPARTMENT.**

Acosta, Jose A..Cuba, West Indies
Acosta, Jeronimo..............Cuba, West Indies
Adomaitis, P. W........Cook, Ill.
Aidman, Henrietta...............New York, N. Y.
Aiken, Bertram.....Hawaiian Is.
Alarcon, Frank....Spain, Europe
Alderson, Anthony.....Cook, Ill.
Allen, Walter S......Fayette, Pa.
Alvarez, Thomas..Cent. America
Ambuehl, Geo.......Fayette, Ill.
Anderson, Rubie..Franklin, Miss.
Anderson, Samuel M. LaPorte, Ind.
Anderson, Severin......Cook, Ill.
Angel, Ray........St. Louis, Mo.
Anver, Fuad.....Russia, Europe
Bianski, Andrew I......Cook, Ill.
Biderman, Stanley......Cook, Ill.
Biderman, Peter........Cook, Ill.
Bitant, William........Cook, Ill.
Bittman, Alice L...Dickey, N. D.
Blachourak, John......Cook, Ill.
Blackwell, Sidney...Oregon, Mo.
Blanchard, Stephen.....Cook, Ill.
Bonnstetter, Martin.Palo Alto, Ia.
Borguding, Herman W.................Muskegon, Mich.
Borggren, John...Kankakee, Ill.
Bowers, Beatrice...DeKalb, Ind.
Bowling, Raymond...Scott, Iowa
Brand, Frederick...............Philadelphia, Pa.
Brasted, Elie.................

*Вальпараисо университеты студентларын исәпкә алу кенәгәсе (Student Credits book of Valparaiso University. 1914–1915. Old School Ledgers p. 6. http://collections.valpo.edu/cdm/compoundobject/collection/ledgers/id/9399)*

Ф.Әнвәровның язуынча, бу чорда әлеге университетта дөньяның төрле кыйтгаларыннан җыелган милләт вәкилләре зирагать (агрономия, авыл хуҗалыгы), тиҗарәт (сәүдә), тыйбб (медицина), хокук, ташчылык, голүме табигыя (табигать белемнәре), мәгариф, музыка һ.б. белгечлекләр буенча белем ала. Билгеле булганча, Индианадагы Вальпараисо университеты Америкадагы ир һәм кыз балалар бергә укый торган иң зур тарихлы уку йортларының берсе була. XX гасыр башында ул яхшы белем бирә торган, шул ук вакытта чагыштырмача арзанлы университет буларак дөнья күләм танылу ала. Халык телендә аның «ярлылар өчен Гарвард» дип атап йөртелүе дә шуңа ишарәли[55]. Гамәли белем, тормыш өчен кирәкле һөнәрләр бирү, белемнең хезмәткә, тор-

[54] Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1914. №22. Б. 697.

[55] Муртазина Л., Гибатдинов М. Документальные следы двух татарских студентов в Америке // «Beyond the TARTAROS». A Muslim World in the Heart of Europe between Elbe, Bug and Kama = «По ту сторону ТАРТАРА». Мусульманский мир в сердце Европы между Эльбой, Бугом и Камой. Сборник научных трудов / Отв. ред. М. Гибатдинов, М. Хотопп-Рике, Ш. Тайлиг. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. С. 134.

мышка якынлыгы принципларына корылган әлеге университетның татарлар арасында зур шөһрәт казануы да, беренче чиратта, шуның белән бәйледер дип карарга кирәк.

Студентлар арасында Россиядән, Англия, Испания, Италия кебек Европа илләреннән килгән студентлар, шулай уку башка милләт вәкилләре була. Автор хәбәр итүенә караганда, университетта бигрәк тә рус телендә сөйләшүчеләр күп, беренче карашка «бу җирне Русия инородецларының колониясе дип әйтергә мөмкиндер»[56]. Шул ук вакытта Ф.Әнвәров мөселманнарның саны бик аз – бары тик җиде генә кеше – ике татар кешесе, ике иранлы, ике гарәп, бер һиндлы ди[57].

Студент Әнвәров, Россиядән килгән кеше булу сәбәпле, ирексездән үз ватанындагы һәм биредәге уку йортларын, андагы уку-укыту тәртипләрен, яшәү шартларын чагыштыра һәм Америкада бу яктан эшнең куелышы шактый югары дәрәҗәдә дип билгели. Аны бигрәк тә университет җитәкчелегенең укучыларга карата булган мөнәсәбәте сокландыра. Автор билгеләвенчә, нинди милләттән булуына һәм нинди динне тотуына, матди хәленә карамастан, әлеге уку йортында һәр студентка бер үк төрле караш булдырылган. Үз илендә милли һәм дини үзенчәлекләрнең кеше тормышында нинди хәлиткеч роль уйнавын күреп белгән, үз җилкәләрендә татыган яшьләргә бу хәл бик нык тәэсир иткән. Мәктәп идарәсе тарафыннан билгеләнгән тәртипләр һәр студентның кызыксынуларын, теләкләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алып эшләнгән. Шуңа күрә уку йорты шәкертләр арасында зур хөрмәт казанган. Автор университет җитәкчелегенең бирегә уку нияте белән килгән кешеләрнең берсен дә кире борып җибәрмәве, белем һәвәсе булганнарның барысын да кабул итәргә әзер торуы сокландырган. Ул Америкада гыйлем йортына килгән кешене кире кагу, өметен өзү зур гөнаһ саналуы хакында хәбәр итә[58]. Шәкертнең укырлык, яшәрлек мөмкинлеге чикле булган очракта, мәктәп идарәсе үзе җаен табып, аны укыта, эш бирә, фатирга урнаштыра, вакытлыча аны көндәлек тормышта кирәкле һәрнәрсә белән тәэмин итә. Шул ук вакытта, монда укырга килергә җыенучы яшьләр белеп торырга тиеш: болар берсе дә бушка эшләнми, чөнки Америкада «буш», «сәдака» дигән нәрсәләр юк, монда һәр нәрсә эш белән үлчәнә һәм билгеләнә[59].

Аеруча мохтаҗлык кичерүче шәкертләрне яклау механизмы эшләнгән: мәктәп идарәсе әлеге студентның укуы һәм яшәве өчен киткән чыгымны соңыннан түләү шарты белән кредит биреп, аннан расписка ала, каникул вакытларында үзенә туры килгән эш белән тәэмин итә. Эшләп акча тапканнан соң, студент мәктәп идарәсе алдындагы бурычын түли, укуын дәвам итә

---

[56] Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1914. №22. Б. 697.
[57] Шунда ук. Б. 697.
[58] Шунда ук. Б. 698.
[59] Шунда ук.

алган. Шул рәвешле матди ягы бик үк җитеш булмаган студент та укып һәм бер үк вакытта һөнәр үзләштереп, университетны тәмамлап чыга алган. Әлеге мөмкинлекнең тудырылуы, Ф.Әнвәров билгеләп үткәнчә, «бик бәрәкәтле хәрәкәт». Ләкин шул ук вакытта кайбер укучылар каникуллар вакытында гына укуга түләрлек акчаны табып бетерә алмаганнар, алар, укуларын туктатып торып, эшләп алырга мәҗбүр булганнар. Язмадан билгеле булганча, әлеге ике татар студенты да нәкъ шул рәвешле укырга мәҗбүрләр. Алар укуларын 2 ел ярымга кичектереп торып, шул вакыт аралыгында алга таба укуларын дәвам итәрлек мая туплауны максат итәләр[60].

Ф.Әнвәров Вальпараисо университетындагы уку-укыту тәртипләренең студентларның укуда уңышка ирешүләренә бер адым дип саный. Ләкин автор шуны кисәтә: бу тәртипләрнең дөрес эшләве өчен студентлар үзләре җаваплы, чөнки мәктәп идарәсе – ул шәкертләр үзләре. Алар киңәшләшеп, фикерләшеп, укуга һәм яшәүгә кагылышлы һәр мәсьәләне үзләре хәл итәләр. Мәктәп мөдире аларның эшенә күзәтчелек итә, кирәк вакытта аларга туры юлны күрсәтә[61].

Ф.Әнвәровның билгеләп үтүенчә, Америка һәм Россия мәктәпләре арасында гыйлем һәм мәгарифкә караштта аерма бар. Биредә гыйлем дип эшли белүгә, хезмәт эшчәнлегенә, аз гына булса да акча китерерлек һәрбер эшкә әйтәләр[62]. Ике илнең мәгарифе арасындагы аерманы автор эшкә булган мөнәсәбәттә дә күрә. Америкалылар иң зур гөнаһларның берсе итеп эшләмәүне, эштән тартынуны саныйлар[63]. Шуңа күрә, Әнвәровның ышануынча, биредә Россиядәге күп кенә тәртипләрне, аерым алганда, эшкәртелми яткан җирләрнең булуын, ул җирләрнең хуҗаларының җир эшкәртү алымнарын өйрәнмәүләрен, начар яшәүләрен һич кенә дә башларына сыйдыра алмаячаклар[64].

Вальпараисо университетында дәрес бирү ысуллары да ватандагы мәктәпләрдән шактый аерыла. Биредә дәреснең эчтәлеген һәм күләмен билгеләүне шәкертләр үзләре хәл итәләр. Һәрбер укучы, үзенең көче җитүенә карап, көненә 4,5 яки 6 сәгать укырга мөмкин, дәрес санына карата чикләүләр куелмаган. Һәр дәрес өчен бер мөгаллим тәгаенләнгән, һәр мөгаллимгә бер сыйныф бирелгән. Кабинет системасы нигезендә студентлар үзләре төрле сыйныф бүлмәләренә кереп, үзләренә кирәкле дәресләрне тыңлыйлар, белем алалар[65].

Шунысын да әйтеп узарга кирәк. Ф.Әнвәровның бу язмасы үзе белем алган уку йортының тәртипләрен, андагы уку һәм яшәү шартларын идеал-

[60] Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1914. №22. Б. 698.
[61] Шунда ук. Б. 698.
[62] Шунда ук. Б. 698.
[63] Шунда ук. Б. 699.
[64] Шунда ук. Б. 699.
[65] Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1915. №2. Б. 54.

лаштырып язылган. Әлбәттә, уку йортының җитешсезлекләре, кимчелекле яклары була, әмма автор аларны күрми, бары тик үзе уңай дип тапкан үзенчәлекләргә генә туктала. Бу билге әлеге мәкаләгә һәм аның авторына гына хас түгел, «Америка мәктүбләре» башы астында дөнья күргән мәкаләләрнең дә барысында да шул рух сизелә. Үзләре өчен бөтенләй яңа, ят булган җирлектә, моңарчы күрелмәгән яңа шартларда, бөтенләй үзгә булган вазгыятьтә яшәү бигрәк тә беренче елларда аларда эйфория тудырган, мөгаен. Һәм инде, алар, ихтыярсыз, бу тирәлекне үзләре өчен гадәти булган мохит белән чагыштырганнар. Ф.Әнвәровның «Вальпараисо университеты (Америкада)» мәкаләсенә Галимҗан Ибраһимов та игътибар итә. Ул үзенең 1915 елда «Йолдыз» газетасында басылып чыккан «Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр» дигән язмасында Ф.Әнвәровның фикерләрен М.Горькийның Америка турындагы сүзләре белән чагыштыра. «Горький Американың матди хәятенең куәтләренә хәйран булып яза. Ләкин аның алдында табынмый», – дип яза ул, Ф.Әнвәровның бу илгә мөкиббән китүенең сәбәпләрен эзләп[66].

Ләкин Ф.Әнвәров, әлеге уку йорты һәм андагы тәртипләргә сокланса да, беренче чиратта үз милләте турында уйлый, аларының татар яшьләрен тәрбияләүгә кертәчәк өлешләре турында фикер йөртә: «Бездә дә тырыш, гыйлем-мәгърифәт гыйшкы булган, шуның илә бәрабәр зиһен вә фикерләре башка милләт балаларыннан бер дә ким булмаган татар балалары аз түгел. Шушындый җирләрдә укысалар, боларның да башка милләт балалары шикелле үк кеше булачаклары, болар арасында да зур кешеләр, гыйлем-мәгърифәт әһелләре, һөнәр вә сәнәгать әрбабы җитешәчәге кояш кебек заһирдыр (ачык)», – дип чын күңелдән ышанып яза[67].

Татар яшьләрен Вальпараисо университетына чакырып, автор һичшиксез үтәлергә тиешле шартларны күрсәтә. Болар: инглиз телен белү, билгеле бер күләмдә укуга түләрлек акчага ия булу. Россия урта мәктәпләренең шәһадәтнамәсен алган кешеләрне биредә югары бүлеккә (университетка) имтихансыз кабул итәләр, булмаган очракта монда килгәч, ике елда урта мәктәпне тәмамлап, университетка керергә мөмкин, ди. Ф.Әнвәров та, Сан-Франциско студенты Х.Байбулатов кебек үк, Вальпараисо университетына укырга керергә теләүчеләргә күзләренең сәламәт булуына игътибар итәргә, сәфәргә чыкканчы ук күзләрен яхшы докторга күрсәтеп, сәламәтлекләре турында белешмә алырга киңәш итә. Чөнки, аның язуынча, күзләре сәламәт булмаган кешеләрне монда кертмиләр, аеруча Нью-Йоркта юлчыларның күзләрен үтә дикъкать белән тикшерәләр[68]. Тагын да күбрәк мәгълүмат алырга теләгән кеше булса, үзенә мөрәҗәгать итәргә кушып, автор үзенең адресын күрсәтә[69].

---

[66] Ибраһимов Г. Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр // Йолдыз. 1915. 29 апрель.
[67] Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1915. №2. Б. 55.
[68] Шунда ук.
[69] Шунда ук.




*Г.Сәйфелмөлеков Вальпараисо университеты студентлары арасында (уңнан икенче, утыра) (http://tatar.uz/?page_id=3655)*

Кызганычка каршы, Америкада белем алган ике татар студентының моннан соңгы язмышы турындагы мәгълүматларны табу әлегә мөмкин булмады. Ватаннарына әйләнеп кайтып, үз алларына куйган максатларын тормышка ашыра алганнармы-юкмы – билгесез. Алда искә алынган язмалардан тыш, бу шәхесләр белән бәйле мәгълүматлар вакытлы матбугат битләрендә дә башка очрамады. Ерак Америка кыйтгасына барып белем эстәгән, үзләрен туган кавеменә, газиз милләтенә хезмәткә багышлауны максат иткән Фуад Әнвәров белән Галимҗан Сәйфелмөлеков, зур авырлыклар кичеп, әмма мәсләкләрен югалтмый гомер кичергәннәрдер дип ышанырга гына кала.

Әлеге китапны укучылар арасында бәлки искә алынган шәхесләр турында мәгълүматы булган, аларның гаиләләре, варислары, якыннары турында ишетеп-күреп белгән белгән кешеләр очрар. Ф.Әнвәров белән Г.Сәйфелмөлековның туган җирләре – хәзерге Казахстанның Зайсан өлкәсендә, Үзбәкстанда яшәүче милләттәшләребездән хәбәргә чыгучылар булса, рәхмәтле булыр идек.

Ләкин, булган кадәр материалларга таянып та, милләтебезнең бу ике фидакарь улының халкыбызны мәгърифәтле итү, ватаннарын һәм татарларны дөнья күләмендә таныту өчен шактый хезмәт итүләрен күреп була. XX гасыр башында Америка, Европаның атаклы университетларында белем алган татар егет-кызларының саны артуда, мөгаен, аларның да роле булгандыр.

## *Зыя Мөҗавир*

Америкада белем алган тагын бер татар егете – Мөҗавиров Зыя Хәмит улы хакында да мәгълүматлар күп түгел. Аның исем-фамилиясе «Буби» мәдрәсәсе шәкертләре исемлегендә урын алган[70]. Галим Мөхәммәт Мәһдиев тә үзенең язмаларында Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлап, Америкадагы Тау төзелешен өйрәнү иниситутына укырга кергән Мөҗавировны искә ала. Соңыннан аның, ватанына кайтып, ил сәнәгатен үстерүгә өлеш кертүе хакында искәртә[71]. Моннан тыш, И.Рәминең «Әдәби сүзлеге»ндә дә Зыя Мөҗавир турында кыскача гына информация бирелә[72].

Беркадәр материаллар белән галим, техник фәннәр кандидаты Якуб Әхтәмовның 1997 елда Чиләбе шәһәрендә басылып чыккан «Наперекор ударам судьбы» дигән китабы аша танышырга мөмкин. Автор Чикагода инженерлар көллиятен тәмамлаган Зыя Хәмит улы Мөҗавиров хакында кайбер мәгълүматларын җиткерә. «Вакыт» газетасы аша безгә таныш булган Зыя Мөҗавиров белән әлеге китапта искә алынган шәхес арасында шактый охшашлыклар очрау сәбәпле, ике чыганакта бер үк зат хакында сөйләнелә дип уйларга тулы җирлек бар.

Я.Әхтәмов үзенең гаилә әгъзасы – бертуган апасы Әсманың ире Зыя Мөҗавировның яшәгән елларын күрсәтә – 1875–1937[73]. Чикагода инженерлар көллиятен тәмамлагач, 1921 елда Зыя СССР хөкүмәте чакыруы буенча Россиягә кайта һәм Ташкентта проектлар конторасына инженер булып урнаша, дип хәбәр итә[74]. Аның Америкада укыган еллары 1915 еллар тирәсендә булуын татар вакытлы матбугатында басылган язмалары раслый.

Әлеге китапта искә алынганча, Зыя революциягә кадәр үзенең иптәше белән дини гыйлем алу максаты белән Гыйракка баралар. Биредә Шәрык яшьләренә Америкага барып югары техник уку йортларында бушлай белем мөмкинлеге хакында ишетеп беләләр һәм үзләренең уку теләге булуы хакында АКШ консулына мөрәҗәгать итәләр. Әлеге затның ярдәме белән, ике дус пароходта Чикагога килеп җитәләр. Я.Әхтәмов хәбәр итүенчә, Мөҗавир җиде ел дәвамында Чикагода укып, югары белем ала, өч ел инженер булып эшләп, уку буенча булган бурычын түли[75].

---

[70] Гимазова Р.А. Мугаллимы и шакирды медресе «Буби» // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2003. № ¾. С. 315.

[71] Мәһдиев М. Сызып ак нур белән. Казан: Татар.кит.нәшр., 2014. Б. 109.

[72] Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. Б. 362.

[73] Ахтямов Я.А. Наперекор ударам судьбы. Челябинск, 1997. С. 15.

[74] Шунда ук. С. 22.

[75] Шунда ук.

Бу мәгълүматларның төгәллегенә, нигездә истәлекләргә нигезләнеп язылулары сәбәпле, шигебез бар. Бу очракта без Зыя Мөҗавирның үз язмаларына таяну дөресрәк дип саныйбыз.

Татар вакытлы матбугатында З.Мөҗавирнең Американың Индиана штатында урнашкан Вальпараисо университетында[76] укыган чорда әлеге уку йорты, анда уку шартлары, үзенең әлеге илгә барып чыгуы, андагы тәртипләр һ.б. мәсьәләләрне яктырткан мәкаләләре дөнья күрә. Авторның хәбәр итүенә караганда, ул чыгышы белән Пржевальск[77] шәһәреннән була[78]. 1914 елның июнь азакларында ул, Америкага барып белем алу нияте белән, Россиядән китә[79].

«Европадан Америкага» дигән беренче язмасында Зыя Мөҗавир Америкага бару юлын бөтен нечкәлекләре белән сурәтли. Башта Румания[80], аннан соң Болгария, Юнанстан[81], Италия аша сузылган авыр, зур юл була бу. Юлчылар зур авырлыклар үтеп (пароходта барганда «биш көн эчендә һәр көн салкын таш өстенә бастырып коендырдылар. Коенган көнне барлык юлчылар хаста булалар»), Нью-Йорк шәһәренә барып җитәләр. Автор пароходта бары тик итальян телендә генә сөйләшү мөмкинлеге булуы («кешеләрне итальянча үгрәнергә мәҗбүр итеп, үз телләрен таратырга хезмәт итмәкче булалар имеш»), бары тик Америкага барып җиткәндә генә кешеләрнең әз-мәз инглиз теленә күчә барулары, 14 көнгә сузылган бу сәяхәтнең ахырына таба күпләрнең тәмам инглиз теленә күчеп бетүләре турында бәян итә. Наполи[82] шәһәрендәге «пычраклык һәм тәртипсезлек», эчкечелекнең таралуы да авторның игътибарыннан читтә калмаган[83].

Зыя Мөҗавирнең икенче бер язмасы Америка тормышын, анда мәгариф эшенең куелышын, студентлар яшәешен тасвирлауга багышланган. Читтән килгән шәкертләргә уку да, тормыш итү дә бик җиңелләрдән булмаган, әлбәттә. Ләкин белем алу, үзенең һәм милләтенең киләчәге турында уйлаган яшьләр авырлыклар алдында баш имәскә тырышканнар: «уку фикеренә бирелгән бер таләбә һәрвакыт истикъбале (киләчәге) хакында төшенә һәм үз мохитенең мөмтаз (аерылып торган, өстен) бер фәрде (аерым шәхесе)

---

[76] И.Рәми, бераз ялгышлык җибәреп, Зыя Мөҗавирне Чилидагы Вальпараисо университетында укый дип хәбәр итә (Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. Б. 362).

[77] Хәзерге Кыргызстандагы Каракол шәһәренең 1889–1922 һәм 1939–1992 еллардагы исеме.

[78] Мөҗавир З. Америка хәяты (Шимали Америкада, Вальпараисода) // Вакыт. 1915. 4 апрель.

[79] Мөҗавир З. Европадан Америкага // Вакыт. 1915. 11 март.

[80] Румыния турында сүз бара.

[81] Греция.

[82] Неаполь, Италиядәге шәһәр.

[83] Мөҗавир З. Европадан Америкага // Вакыт. 1915. 11 март.

булырга тырыша, шуның өчен дә гомеренең газиз бер кыйсемен парлак (данлы, күркәм) истикъбальга малик булу өчен хыялланып уздыра, ул сәгатьләрчә хыял диңгезендә чума, дөньяның әллә нинди караңгы почмакларына кадәр китеп булса да укуга разый була»[84].

З.Мөҗавир да, Ф.Әнвәров кебек үк, Америкада укуга карата булган мөнәсәбәткә соклануын белдерә: «Мондагы хәятнең әсасе (нигезе) уку белән эшләүгә бинаән ителгән, уку юлына кергәннәре үлгәнчегә кадәр укыйлар, чөнки мондагы укуның чиге юк, дәрәҗә-дәрәҗәгә бүленеп тәгали итә бара (үсә, югарырак баскычка күчә), университет бетергән бер taләбә бер-ике сәнә профессорлык итә, я башка бер эш белән шөгыльләнә дә, соңра мәктәпкә килеп бер сәнә укып бер фәндә ихтисас (берәр эшнең яхшы белгече) кәсеп итә. Тагын да дөньяга чыгып бер-ике сәнә эшләгәч, кире килеп бер сәнә тагын да укый, икенче бер фәндә ихтисас кәсеп итә. Һәр сәнә укыган саен жалованьесы да, дәрәҗәсе дә арта бара. Шулай итеп, үлгәнгә кадәр укуны дәвам итәдер»[85].

Автор язганча, моңа кадәр Америкага килгән татарның һич ишетелгәне юк[86]. Инде күренгәнчә, автор бераз ялгыша, 1911 елда Сан-Францискода татар егете Хәбибулла Байбулатов, Американың Айова шәһәрендә Закир Габдуллин белем алуы, ә 1914 елда З.Мөҗавир укыган Вальпараисо университетында Фуад Әнвәров белән Галимҗан Сәйфелмөлековларның гыйлем эстәве хакында аның хәбәре булмый.

Мөҗавир, башка татар егетләре кебек үк, телләр өйрәнү мәсьәләсенә җентекләп туктала, чөнки Америка уку йортларында төп белем бирү теле инглиз теле булу сәбәпле, аны яхшы белү сорала. Ә татарлар өчен, автор раславынча, бу бер дә кыен эш түгел, һәм аны тиз арада өйрәнү мөмкин: «Галәлхосус (бигрәк тә) татарлар шикелле һәртөрле кәлимәне (сүзне) тәләффыз итүгә (әйтүгә) мөсагыйд (мөмкинлек бирүче) лисанга (телгә) малик (ия) булган бер милләт өчен инглизчә үгрәнү бер дә кыен түгел. Инглиз лисанының тәләффызы бераз зәхмәт чидекерә, юкса грамматикасы бик җөзьи (авыр түгел), никадәр лөгать (сүз) ятланса, шулкадәр белән сөйли башларга мөмкин»[87].

Зыя Мөҗавир татар яшьләренең укуда зирәк, зиһенле, үткен булуларын, шул сәбәпле кайларга гына барсалар да, нинди уку йортына керсәләр дә, югалып калмаулары турында горурланып яза: «Өч йөз миллионнан гыйбарәт, мөхтәлиф (төрле-төрле) милләтләргә мәнсуб мөселманнарның иң мөтәрәкъкыйсе (зирәкләре, тырышлары), шөбһәсез, татарлардыр. Шуңа күрә һәртөрле фидаилекне (фидакарьлекне) илтизам итү (үзеңә тиешле дип санау,

[84] Мөҗавир З. Америка хәяты (Шимали Америкада, Вальпараисода) // Вакыт. 1915. 4 апрель.
[85] Шунда ук.
[86] Шунда ук.
[87] Шунда ук.

кабул итү) безгә тәртип итә. Һәр изгелек хосусында үрнәк булу безнең бурычымыз булып күренә»[88]. Шул ук вакытта, әлегәчә «Америкада русиялеләрдән башка татарларны белүче милләт юк дип әйтерлек». Шуңа күрә дә татар студентлары милләтне танытыр өчен бар тырышлыкларын куеп, үзләрен бары тик яхшы яктан гына күрсәтергә, укуда алдынгы булырга тиешләр.

«Америкага барып уку юллары» дигән икенче бер мәкаләсендә З.Мөҗавир татар яшьләрен әлеге уку йортларына бару, анда уку шартлары белән таныштыруны максат итә. Үзенә килгән күп санлы хатларга нәтиҗә ясап, ул: «Бу мәктүбләрдән татар яшьләре арасында уку һәвәсенең фәүкыльгадә бербер тизлек белән алга китмәктән идекен аңлап, өмид итдекемдән артык мәмнүн булдым», – дип хәбәр итә[89]. Җавабында ул Америкага кайчан (сугыштан соңмы яисә хәзер) китүнең муафыйкъ булуы, кайсы юл аша бару, күпме акча кирәк булу, анда яшәү өчен эш табу мөмкинлеге булу-булмау, укырга керү шартлары, кабул итмәгән очракта нинди эш-гамәлләр күрү дөрес булу хакындагы сорауларга бик тәфсилле җавап бирә. Авторның фикеренчә, Европа сугышы сәбәпле Американың икътисады бик җимерек хәлдә, эш табу кыен, юлга да ике өлеш акча сарыф ителәчәк, шуңа күрә укырга килү мәсьәләсен сугыш тәмамланганнан соң гына хәл итү дөрес булачак. Килгән очракта, үзең белән акча, лөгать китабы (сүзлек) һәм бераз кием-салым алу мәҗбүри. Эш табу мәсьәләсен хәл итүдә дә кыенлыклар бар, моның өчен мәҗбүри рәвештә инглиз телен өйрәнү кирәк («аның өчен Вальпараисо мәктәбендә 9 ай тел үгрәнергә кирәк»), шуңа да үзең белән 9 ай буе яшәү өчен җитәрлек акчаның булуы шарт. Шул ук вакытта Американың парадокслар иле булуы («2 сум 50 тиен белән килгән бер ярлы француз уңайлы эшкә очрап (балта остасы), әкренләп үзенең осталыгы аркасында эшкә яңалыклар кертеп, тора-бара миллионер булып әверелгән») хакында бәян итә[90].

Зыя Мөҗавирның әлеге язмалары, яшьләрне Вальпараисо университеты белән таныштырудан тыш, татар укучыларында моңарчы таныш булмаган кыйтга, андагы тәртипләр, гореф-гадәтләр турында күзаллаулар формалашуга да ярдәм иткән.

Алда искә алынган китаптан алынган мәгълүмаларга караганда, З.Мөҗавир, Ташкентка кайтканнан соң, гаилә корып, беркадәр вакыт эшли, соңыннан Уфага күченә һәм «Башзолото» оешмасында инженер булып урнаша. 1936 елда ул кулга алына һәм берничә ай тоткынлыкта торганнан соң, азат ителә. 1937 елда кабат кулга алына һәм «халык дошманы» дип табыла, шук елны атып үтерелә. Тормыш иптәше, баласын алып, Ташкентка


[88] Мөҗавир З. Америка хәяты (Шимали Америкада, Вальпараисода) // Вакыт. 1915. 4 апрель.

[89] Мөҗавир З. Америкага барып уку юллары // Вакыт. 1915. 3 сентябрь.

[90] Шунда ук.

әнисе янына кайтып китәргә мәҗбүр була[91]. Милләте, ватаны турында зур хыяллар белән янган татар шәкертенең тормышы шулай аянычлы тәмамлана.

## *Фазыл Бәкер*



*Фазыл Бәкер (Record Yearbook (Valparaiso, IN) – Class of 1923. P. 16)*

Вальпараисо университетында белем алган тагын бер татар кешесе – Фазыл Бәкер хакында әлеге уку йортына караган материалларга нигезләнеп фикер йөртә алабыз. Аларда татар студенты турында шактый җентекле сөйләнелә.

Вальпараисо университеты документлары арасында Ф.Бәкергә бәйләнеше булган өч документ табылды: «The Torch»[92] газетасының ике саны һәм Вальпараисо университетының «Еллык язмалары». Аларның икесе Фазыл Бәкернең вафатыннан соң язылган. «The Torch» газетасының 1923 елгы 2 гыйнвар санында 1922–1923 елда укыган һәм уку елы азагында сертификат алу өчен гариза биргән студентларның гомуми исемлеге бирелгән. Анда Фазыл Бәкернең исеме дә бар. Бу исемлек әлеге мәсьәләне хәл итәчәк комиссиягә тәкъдим итү өчен студентларның шәхси эшләренә беркетелгән[93]. Шул ук газетаның 1923 елгы 9 гыйнвар саны Вальпараисо университетының көллиятендә соңгы курста белем алган татар студенты Ф.Бәкернең 8 гыйнварда вафат булуы хакында хәбәр итә[94]. Университетның «Еллык язмалары» мәҗмугасында Ф.Бәкернең фотосурәте һәм вафатына багышланган кайгынамә урнаштырылган[95]. «Истәлек өчен» дип аталган әлеге текстта Бәкер турында шактый тулы белешмә бирелә. Ул 1896 елның 22 гыйнварында Троицк шәһәрендә дөньяга килә. Аңа ун яшь тулгач, әтиәниләре яшүсмерне Истанбулга укырга җибәрәләр. Биредә ике ел башлангыч

[91] Ахтямов Я.А. Наперекор ударам судьбы. Челябинск, 1997. С. 78.
[92] «Torch» инглиз теленнән «факел» дип тәрҗемә ителә.
[93] The Torch. January 2, 1923.
[94] The Torch. January 9, 1923. № 15.
[95] Record Yearbook (Valparaiso, IN) – Class of 1923. P. 16–17.



RECORD

# In Memorium

FAZL BEKR
1896-1923

Fazl Bekr was born at Troysky, Russia, on January 22, 1896. When he became ten years of age his parents sent him to Constantinople to begin his school work. After completing the elementary school at Constantinople, he studied for two years in an American college at Bayroat. Later he returned to his home and taught school for three years.

Fazl Bekr came to Valparaiso from Harbier, Siberia. Entering Valparaiso University in the fall of 1919, he aimed at a firm foundation before attempting college work. His aim was attained for his work in high school proved him to be above the average student. He enrolled in the arts and science department from which he would have graduated at the end of the summer quarter.

Early in November he became aware of his illness which proved to be leakage of the heart. In the latter part of December he was taken to the Christian Hospital where he remained for a short time. He died in the West End Hospital in Chicago, January 2, 1923.

He was a student of unusual ability, especially in mathematics and chemistry. His interest was ever in his work. He would have been a credit not only to himself and his faculty, but to his college as well.

His friends could not have lost a better friend, nor the University a better student.

Thirteen

1923

*«Record Yearbook (Valparaiso, IN)» мәҗмугасында (1923 ел, 17 бит)*
*Фазыл Бәкер хакындагы язма*

мәктәптә белем алганнан соң, Бәкер Бәйруттагы Америка колледжына укырга керә. Соңыннан ул ватанына кайта һәм өч ел дәвамында мәктәптә белем ала. Вальпараисо шәһәренә ул Себердән, Харбьердан[96] килә һәм 1919 елда университетка укырга керә. Әлеге документта әйтелгәнчә, Фазыл Бәкернең белеме ныклы, тырышлыгы көчле, ул һәрвакыт эш белән мәшгуль студентларның берсе була. Сәнгать һәм фәннәр факультетында укый, 1924 елда уку йортын тәмамларга җыенган була. Ноябрь башында ул авырып китә, декабрьнең икенче яртысында егетне Кристин госпиталенә салалар, ләкин аңа биредә озак дәваланырга туры килми, 1923 елның 2 гыйнварында Чикагодагы Вест-Энд госпиталендә йөрәк өянәгеннән вафат була. «Ул бик зур сәләткә ия студент иде, бигрәк тә математика һәм химия өлкәсендә. Ул һәрвакыт эш белән кызыксына иде. Ул үзе һәм факультеты өчен генә түгел, көллияте өчен дә зур хөрмәткә ия зат иде. Аның иптәшләре иң якын дусларын, ә университет иң яхшы студентын югалтты», – диелә әлеге документта[97].

Фазыл Бәкер – атаклы Троицк байлары Бакировлар гаиләсеннән дип фаразлыйбыз. Әлеге байлар[98] һәм аларның улы Фазыл турында күренекле рәссам Бакый Урманченың Татарстан Сынлы сәнгать музеенда сакланган шәхси архивындагы кулъязмалары аша беркадәр мәгълүмат алырга мөмкин[99]. Б.Урманче язуына караганда, Фазыл Бәкер 1918 елда Нияз Максудов белән бергә Владивосток аша Америкага китә. Автор аның бер елдан вафат булуы хакында яза[100]. Соңгы хәбәрнең төгәл булмавын Вальпараисо университеты документлары раслый.

Ф.Бәкернең эшчәнлеге, эш-гамәлләре турында әлегә башка мәгълүматлар табылмады. Ничек кенә булса да, ерак Америкага китеп, татар милләтенең бер вәкиле булып, аны чит кыйтгаларда танытыр өчен көч куйган милләттәшебезне, ватаны һәм халкы алдында зур мәртәбәләр күрсәтергә өлгермәсә дә, ихтирам белән искә алырга тиешбез.

---

[96] Фаразлавыбызча, әлеге торак пунктның Харбин шәһәре булу ихтималы бар.

[97] Record Yearbook (Valparaiso, IN) – Class of 1923. P. 17.

[98] Кызганычка каршы, аларның төгәл исемнәрен ачыклау мөмкин булмады. А.Расих Бакировларны Троицк төбәгенең миллионерлары дип атый. Революциядән соң бу байлар чит илдә мөһаҗирлектә, ди. Әлеге нәселдән билгеле шәхес – Александр Александрович Бакиров (чын исеме Габделхәмит Габделлатыйф улы) Төмән нефтен беренче ачучы геолог-галим (Расих А. Тыныч еллар күләгәсендә // Казан утлары. 1997. №1. Б. 60). Троицк тарихына караган икенче бер китапта сәүдәгәр Бакировларның Казан артындагы Мәңгәр авылыннан булулары хакында әйтелә (Абубакирова М., Шамсутдинов И., Хасанжанова Р. Историю оставить народу своему. Троицк, 2002. 176 с.).

[99] Әлеге кулъязмалар З.Мөхәммәтшин тарафыннан өйрәнелеп, матбугатта бастырылып чыгарылган.

[100] Мөхәммәтшин З. Көньяк Урал татарлары XX гасыр башы матбугатында, шәҗәрәләрдә // Милли-мәдәни мирасыбыз: Чиләбе өлкәсе татарлары. 2 нче басма. Казан, 2021. Б. 395.

# Японийдә белем алган татар егете

XX гасыр башында татарлар арасында Япония уку йортлары бик популяр булган дип әйтеп булмый. Шулай да, анда барып белем алган яшьләр, күп булмаса да, очрый. Шулар арасында иң билгелесе – танылган дин һәм җәмәгать эшлеклесе Габдрәшит Ибраһимовның улы Әхмәтмөнир Ибраһимов («1303 нче ел 26 нчы Зөлкагъдәдә (1886 елның 13 августында) Тара шәһәрендә туган»[1]). Ул, Россия татарларыннан беренчеләрдән булып, Японийдә югары белем алуга ирешә. Аның белем алу өчен нәкъ менә шушы илне сайлавында, мөгаен, әтисенең йогынтысы булгандыр.

Билгеле булганча, XX гасыр башында татар җәмгыятендә Япония белән кызыксыну шактый югары була. Бу, беренче чиратта, әлеге илдә ислам дине таралу, ислам диненә карата уңай мөнәсәбәт урнаша башлау белән бәйле. Шулай ук бу чорда Япония тарафыннан да Россия һәм башка илләрдә яшәүче мөселманнар белән элемтә корырга омтылышлар күренә. Габдрәшит Ибраһимов 1909 елда, Японийдәге чираттагы сәяхәтендә, Токиодагы мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында – хосусый Васэда университетында һәм Император университетында була[2]. 1906 елдан ук таныш булган Акаси Мотодзиро[3] соңыннан Г. Ибраһимовка улы Мөнирне «Кокурюкай»[4] җәмгыяте акчасына Васэда университетына укырга кертергә ярдәм итә[5]. Икенче бер чыганак буенча, яңа гына Истанбулдагы «Мөлкия» мәктәбен тәмамлап, Токиога белем артыннан юнәлгән бер төркем яшьләрнең укуын үзенең исемен атарга теләмәгән Мисыр пашасы тәэмин иткән[6].

Төрек тикшеренүчесе Исмәгыйль Төркуглы Мөнир Ибраһимовның Япониягә барып студент булуында «Азия Ги-Кай» җәмгыяте җитәкчесе, япон дипломаты Охара әфәнденең роле булуы хакында яза. Ислам динен кабул иткәннән соң исемен Әбүбәкер дип үзгәрткән әлеге дипломат Габдрәшит Ибраһимов тәкъдиме белән шәйхелислам Муса Казим әфәндегә һәм Мәккә шәһәренең иң мәшһүр галимнәреннән берсе булган әс-Сәет Габдулла әфәндегә Япониягә белем алырга теләүче яшьләрне җибәрүләрен сорап хатлар яза. Күп тә үтми, Төркиядән өч егетне җибәрергә хәл ителә: Мәхмүт Тәүфикъ, Хә-

---

[1] Ибраһим Г. Бөгрәделек көндәлеге. Казан, 2013. Б. 169, 171.

[2] Усманова Л. Габдерәшит Ибраһим Японийдә // Габдрәшит Ибраһим: фәнни-библиографик җыентык / Төз. М. Госманов, Ф. Галимуллин. Казан: «Җыен», 2011. Б.334.

[3] Акаси Мотодзиро (1864–1919) – япон генералы, 1902–1905 елларда Россиядә хәрби атташе, Европадагы япон разведкасы агенты.

[4] «Кокурюкай» җәмгыяте Көнбатыш илләрне яклаучылар режимы белән көрәшә.

[5] Усманова Л. Габдерәшит Ибраһим Японийдә // Габдрәшит Ибраһим: фәнни-биографик җыентык / төз. М. Госманов, Ф. Галимуллин. Казан: «Җыен», 2011. Б. 338–340.

[6] Ислам в Японии // В мире мусульманства. 1911. №17 (19 август).



*Габдрәшит Ибраһимов улы Әхмәтмөнир белән. 1895нче еллар (И. Төркуглының шәхси архивыннан)*




*Габдрәшит Ибраһимов уллары белән (уңнан беренче – Әхмәтмөнир). Истанбул шәһ., 1912 ел (Исмәгыйль Төркуглының шәхси архивыннан)*

сән Фәһми һәм Ибраһим Әдһәм. Соңгысы авырып китә, һәм аның урынына Әхмәтмөнир Ибраһимов билгеләнә[7].

XX гасыр башында Япония үзенең уку йортлары белән дан казанган була инде. Бигрәк тә инглиз системасы үрнәгендә эшләүче Токио һәм Киото университетлары студентларны җәлеп иткән. Аларның үзенчәлеге – югары гомуми фәнни һәм югары гамәли белемне берләштерүләрендә. Ягъни, япон уку йортларында нәзари белемнәр белән бер үк дәрәҗәдә гамәли өлешкә дә зур игътибар бирелгән[8]. Шуңа да Япония, Япониядә ислам динен тарату мәсьәләләре белән кызыксынган Г.Ибраһимовның улы өчен шушы уку йортын сайлавы аңлашыла да кебек.

[7] Тюркоглу И. Татары в Японии: Хасан Фехми и Габдерашит Ибрагимов // Тюрко-мусульманский мир: идентичность, наследие и перспективы. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2015. С. 333–334.

[8] Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 289.



*Әхмәдмөнир Ибраһимов (сулда) Төркиядән Япониягә укырга килгән ике студент белән. Токио шәһәре, 1911 ел (И. Төркуглының шәхси архивыннан)*

Әхмәтмөнир Ибраһимов XX гасыр башы татар җәмгыятендә шактый билгеле, хәтта мәшһүр шагыйребез Тукайның игътибарына лаек булган шәхес[9]. И.Рәми мәгълүматларына караганда, ул Япониядәге Васэда университетына 1913 елда укырга керә[10]. Икенче бер чыганак буенча ул биредә 1910–1913 елларда белем алган[11]. Чынлыкта Мөнир әфәнде Токио шәһәренә 1910 елда икенче бер татар егете Хәсән Фәһми[12] белән килеп төшә. Аңа кадәр ул Истанбулдагы «Солтания» мәктәбендә белем ала, укып бетергәч ватаны Россиягә кайтып, Петербург университетының хокук шөгъбәсенә укырга керә. Тик әлеге уку йортын тәмамларга насыйп булмый – ул әтисенең киңәше белән кабат Төркиягә кайта[13]. Бу елларда ул Япония университеты шәкерте буларак вакытлы матбугатта бик күп мәкаләләрен бастыра[14], иптәше һәм фикердәше Хәсән Фәһми белән икәүләп Истанбулда чыгучы «Сыйрател-мөслимиен»

---

[9] 1912 елда «Ялт-Йолт» журналында басылып чыккан «Бик зур кешеләребез» дигән фельетонында Г. Тукай Габдрәшит һәм Әхмәтмөнир Ибраһимовларны искә ала (кара: Г. Тукай. Бик зур кешеләребез // Габдулла Тукай. Әсәрләр. Алты томда: 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 232–233).

[10] Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. Б. 362.

[11] Искәрмә һәм аңлатмалар // Габдулла Тукай. Әсәрләр. Алты томда: 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 393.

[12] Хәсән Фәһми (1886–1920) Казанда туса да, Истанбул шәһәрендә үсә. Әтисе Мәхмүт Кәрим «Йолдыз» сараенда хезмәт итә. Хәсән «Мәрҗан» лицеенда, «Солтания мәктәбе»ндә (Галатасарай лицее) белем ала. 1911–1916 елларда Токио император университетының хокук шөгъбәсендә укый (Тюркоглу И. Татары в Японии: Хасан Фехми и Габдерашит Ибрагимов // Тюрко-мусульманский мир: идентичность, наследие и перспективы. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2015. С. 334).

[13] Turkoglu I. Japonyada Üniversite Tahsile Gören Bir Tatar: Hasan Fehmi // Proceedings of the Fifth International Symposium on Islamic Civilization in Volga – Ural Region. Istanbul, 2015. P. 127.

[14] Әхмәтмөнир Ибраһимовның «Япониядәге университет студентыннан Госманлы университеты студентына хат» дип исемләнгән, «Сәбилүррешад» журналында басылып чыккан (1328 (2). 2–9 т. № 52–234. Б. 450–451) мәкаләсе хакында төрек тикшеренүчесе И.Төркуглы хәбәр итә (Карагыз: Төркуглы И. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы төрек-татар багланышлары // Чын мирас. 2013. № 2. Б. 15).

журналына язмаларын җибәреп тора, Япония тормышына караган тәэссоратлары белән уртаклаша[15]. Татар матбугатында ул Әхмәтмөнир Ибраһим, Әхмәтмөнир Рәшит исемнәре белән билгеле була. Японидә укыган чорда Ә. Ибраһимовның япон матбугатында да язышуы турында мәгълүматлар очрый[16].

Мөхәммәт Мәһдиев билгеләвенчә, 1920 елда, Рәшит казый Япониягә килгәндә, Әхмәтмөнир Ибраһимов университетны тәмамлаган була инде[17]. Дипломлы белгечнең моннан соңгы тормышы тулаем Төркия мәмләкәте белән бәйле – Япониядән ул Беренче бөтендөнья сугышы башланганнан соң күченеп китә. Биредә ул төрле өлкәләрдә хезмәт куя – Әнкарадагы хатын-кыз укытучылар мәктәбендә укыта, «Сумарбанк»та, авыл хуҗалыгын механикалаштыру өлкәсендә эшли[18].

Шәхси тормышына килгәндә, Әхмәтмөнирнең бертуганы Фәүзия Ибраһимованың[19] Европа һәм Россия халыклары ашларына багышланган, яңа гына кабат басылып чыккан китабында[20] теркәлгән мәгълүматларга караганда, Төркиядә Ә.-М. Ибраһим (Искер) Җәмилә Бихтерин атлы кызга өйләнгән, бу никахтан өч баласы: Ходаяр Искер, Хөсәен Искер һәм Нилүфәр Искер туган. Бүгенге көндә (2017 елгы мәгълүматлар буенча) уллары инде вафат, ә кызы Нилүфәр Искер Фламм Германиядә яши, улы бар. Ходаяр Искернең өч баласы хәзерге көндә Төркиянең Измир, Әнкара шәһәрләрендә гомер итәләр. Хөсәен Искернең дүрт баласыннан өчесе исән, Измирда яшиләр[21]. Г. Ибраһимовның тормыш юлын һәм эшчәнлеген өйрәнгән немец галиме Себастьян Цвиклински мәгълүматларына караганда, Әхмәтмөнир Габдрәшит улы үзе Әнкара шәһәрендә, этисеннән алдарак вафат була[22].

---

[15] Тюркоглу И. Татары в Японии: Хасан Фехми и Габдерашит Ибрагимов // Тюрко-мусульманский мир: идентичность, наследие и перспективы. Казань: Изд-во Казанского университета, 2015. С. 335.

[16] Искәрмә һәм аңлатмалар // Габдулла Тукай. Әсәрләр. Алты томда: 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 393.

[17] Мәһдиев М. Тарихи кыңгыравык (Бер гаҗәеп шәхес турында) // Мирас. 1992. № 8. Б. 81.

[18] Төркуглы И. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы төрек-татар багланышлары // Чын мирас. 2013. №2. Б.15.

[19] Фәүзия Ибраһимова – Габдрәшит Ибраһимовның беренче хатыны Мөнирәдән туган баласы, Әхмәтмөнир, Кадрия белән бертуган. Татар милли ашларына багышланган китабы 1909 елда басылып чыга. Аның турында тулырак Ф.Ибраһимовага багышланган махсус бүлекчәдә укыгыз.

[20] Ибрагимова Ф. Мастер кулинарии: подарок для дам = Аш остасы: ханымнарга һәдия. Казань: Изд-во «Познание» Казан. инновац. ун-та, 2017. 234 с.

[21] Ибрагимова Ф. Мастер кулинарии: подарок для дам = Аш остасы: ханымнарга һәдия. Казань: Изд-во «Познание» Казанского инновационного университета, 2017. Б. 26.

[22] Искәрмә һәм аңлатмалар // Габдулла Тукай. Әсәрләр. Алты томда: 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 393.

Ә.-М. Ибраһимовның «Япониядә таләбә тормышы» дигән мәкаләсе[23] 1914 елның май аенда «Вакыт» газетасында басылып чыга[24]. Аның дөнья күрүе татар вакытлы матбугатында чит илләрдә укучы татар студентларының язмалары басылган чорга туры килә.

Мәкаләнең төп максаты – татар яшьләрен Япониядәге иң эре һәм алдынгы хосусый университетларның берсе булган Васэда университеты белән таныштыру була. 1882 елда мәктәп форматында нигез салынган бу уку йорты 1902 елда университет итеп үзгәртелә. Сәясәт өлкәсендә югары белем алырга теләүчеләр өчен (ә татар яшьләре өчен XX гасыр башында сәясәт, хокук белеме өлкәләре, милләт мәнфәгатьләрен кайгырту ягыннан чыгып караганда, иң әһәмиятле һәм кирәкле юнәлешләрнең берсе санала), Әхмәтмөнир Ибраһимов карашынча, Васэда университеты иң кулай уку йортларының берсе саналырга хаклы. Шуңа күрә ул милләттәшләребезне әлеге уку йорты белән тулы итеп таныштыру максатын үз алдына куя. Моннан тыш, автор Япониядәге башка университетлар һәм фәнни юнәлешләр буенча да кайбер мәгълүматларны бирә.

Әхмәтмөнир Ибраһимов фикеренчә, Япониядә иң алга киткән тармакларның берсе – технология. Токиодагы Технология университетында, мәсәлән, барлыгы 28 факультет, һәм аларда гади балта остасы һәм чүлмәкчедән алып, технологик яктан иң катлаулы һәм чагыштырмача яңа булган, фәнни алгарышка нигезләнгән һөнәрләр, әйтик, кинематография белгечлегенә кадәр өйрәнергә мөмкин. Бу мисал белән ул уку йортларының киңкырлылыгын, тормышчанлыгын раслый, аларда кеше эшчәнлеге өчен кирәк булган һәр төрле һөнәрне үзләштерү мөмкинлеге булуын ассызыклый.

Автор билгеләвенчә, Япониядә иң актуаль саналган фәнни юнәлешләр арасында полиция, медицина һәм лингвистика да бар. Токиодагы югары уку йортларында әлеге белгечлекләрне үзләштерергә мөмкин. Моның өчен тырышлык, зур теләк һәм, әлбәттә, уку теле булган инглиз телен белү шарт.

Ә.-М. Ибраһимов фикеренчә, Япониянең югары белем бирү системасы алга киткән киткән илләрнең (Америка һәм Европа илләренең) мәгарифеннән һич кенә дә калышмый. Фикерен раслау өчен, ул Америкада дөнья күргән «The American review of reviews» журналында 1914 елда басылып чыккан мәкаләдән[25] алынган өзекне тәрҗемә итеп китерә. Анда Васэда университеты эшчәнлегенә, гомумән Япониядәге югары белем бирү системасына зур бәя бирелгән. Ибраһимов япон университетларының башка илләрдәге кебек тар, аерым белгечлекләр буенча гына белем бирмичә, киң карашлы һәм күп-

[23] Газетада мәкалә авторы Әхмәтмөнир Рәшит дип күрсәтелгән.

[24] Рәшит Ә.-М. Япониядә таләбә тормышы // Вакыт. 1914. 21 май.

[25] Waseda, Japan`s Modern University // The American review of reviews. 1914. February. P. 231–233. URL: https://babel.hathitrust.org/cgi/pt?id=njp.32101076870607;view=1up;seq=247 (дата обращения: 11.03.2020).

кырлы, төрле өлкәләр буенча хәбәрдар шәхесләр әзерләвенә игътибарны юнәлтә. Бу юл, аның фикеренчә, иң дөрес һәм иң уңышлы ысулларның берсе.

Мәкаләдә университетта уку шартлары, белем алуның матди ягы кебек әһәмиятле проблемалар чагылыш таба. Күп кенә мәсьәләләрне ачыклаганда, автор японнарның да бу мәсьәләгә карашын чагылдыруны кирәк дип таба. Шул рәвешле ике милләт, ике мәдәният, ике менталитет, ике төрле гореф-гадәтләр системасы үзара чагыштырыла. Уку, мәгариф, эшне оештыру ягыннан японнар алда барса, ашау-эчү, милли гореф-гадәтләр мәсьәләләрендә татар рухының автор өчен аеруча якын икәнлеге күренә.

Булачак татар студентлары өчен иң әһәмиятле моментларның берсе булган уку өчен түләү проблемасын яктыртканда Ибраһимов Япониядә укуның беренче урында торуын, башка илләрдәгечә, әйтик, Америкадагы кебек, эшләп уку мөмкинлегенең булмавын ассызыклый.

Әлеге мәкалә Япониядә укырга теләгән яшьләр өчен генә түгел, ә гомумән киң татар җәмәгатьчелеген кызыксындырган сорауларга җавап йөзеннән дә язылган. Чөнки татар җәмгыятендә Япония белән кызыксыну бу чорда шактый күзәтелә. Япониядә ислам дине таралуга, японнар арасында мөселманнар арту һәм башка мәсьәләләргә багышланган мәкаләләрнең чагыштырмача күп булуы да шуны раслый[26].

Ә.-М. Ибраһимов күрсәтеп узганча, бу бик мөһим, ләкин шул ук вакытта шактый катлаулы мәсьәләләрнең берсе. Шуның өстенә японнарның гомумән дингә карата мөнәсәбәтләре дә татарларныкыннан аерыла. Татар җәмгыятендә мөселманлык беренче урынга куелса («татар» һәм «мөселман» атамалары тәңгәлләштерелеп карала), японнар милләтне өстенрәк саныйлар. Исламга килгәндә, татарлар карашы белән тулаем туры килгән мөнәсәбәт күзәтелми. Автор моны Япониядә ислам дине буенча төпле белем бирерлек укытучыларның һәм гыйбадәтханәнең булмавы белән аңлата.

Ике милләт арасындагы аерма сәүдәгә мөнәсәбәттә дә чагылыш таба. Татарлар өчен сәүдә – иң беренче урында торган, каннарына сеңгән, буыннан-буынга, ата-бабалардан мирас булып килгән шөгыль төре булса, японнарда ул фән дәрәҗәсенә күтәрелгән юнәлеш: аңа махсус укыйлар, сәүдә нигезләрен мәктәпләрдә өйрәтәләр һ. б.

Әлбәттә, татарлар өчен әһәмиятле сорауларның тагын берсе – ул японнарның татарларга мөнәсәбәте. Билгеле булганча, бу чорда чит илләрдә татарларны белмиләр, аларга карата булган караш та үзенчәлекле. Закир Габдуллинның Айова университетына килеп укый башлавы җирле халыкта әлеге моңарчы билгеле булмаган милләтнең бер вәкиле һәм татарлар белән кызыксыну тудырган кебек[27], японнар да кайсыдыр яклары белән үзләренә ох-

[26] Мөхәммәд Бәркәтулла әфәнде // Вакыт. 1914. 19 август; Япониядә инородецлар мәсьәләсе // Вакыт. 1914. 17 июнь.

[27] Габдуллин З. Америка мәктүбләре // Вакыт. 1913. 25 октябрь.

шашлыгы булган татарларга игътибар иткәннәр. Гомумән алганда, татарларга, аларның гореф-гадәтләренә, телләренә, мәгарифенә карата төрле илләрдәге мөнәсәбәтне чагылдырган мәкаләләр татар вакытлы матбугатында еш күзәтелгән. Шуңа күрә дә, мөгаен, Әхмәтмөнир Ибраһимов та аңа җентекләбрәк тукталырга карар кылгандыр.

Япон җәмгыятенә килгәндә, биредә дә, Америкадагы кебек, татарларны начар беләләр, еш кына кыргызлар (бу очракта: казахлар) белән бутыйлар. Шулай да, мәкаләдән күренгәнчә, Япониядә татарларга мөнәсәбәт, башка илләр белән чагыштырганда, чагыштырмача яхшы. Бу бигрәк тә Рус-япон сугышында әсирлеккә төшкән татарлар белән бәйле: алар, автор фикеренчә, татарларның нинди тырыш һәм булдыклы халык икәнлекләрен исбатлаганнар инде. Шуңа бәйле рәвештә галимнәр арасында да татарлар белән кызыксыну барлыкка килгән. Японнар татарларның этнографиясен, тарихын, үзләренең теленә шактый охшаш булган телләрен өйрәнүне максат иткәннәр, сәүдә мөнәсәбәтләрен җайга салу уе белән япон фирмаларындагы хезмәткәрләргә татар телен өйрәтә башлаганнар һ.б.

Бу кызыксыну, әлбәттә, ике яклы булган. Япониядәге татар мөһаҗирләре дә ике тел арасындагы уртаклыкларны тойганнар: «Юк, фәкать ниппон теле[28] безгә бик җиңел бирелгәнлектән, ниппончаны өйрәнү өчен лөгать (сүзлек) китаплары тотып утырып, үз ана телебезнең сарыф-нәхүенә (морфология-синтаксис) ят булган җөмлә төзелешләрен күңелгә бикләргә тырышырга кирәкмәгәнлектән генәме? Ниппон теле дә Урал-алтай телләре агачының бер ботагыдыр. Ниппон телендәге җөмләнең, нәхү буенча, төзелеше безнекенә бик якын булганлыктан, һәм безнең телдәге тавышлар ниппон телендә дә шулай ук әйтелгәнлектәндер»[29].

Ибраһимов Япония югары уку йортларында студентларны ораторлык сәләтенә, үз сүзләрен, фикерләрен әйтә белергә өйрәтүгә игътибар иткән. Фикерләү сәләтләрен үстерү өчен студентларның үзләренең парламент мәҗлесе ясап, сәяси мәсьәләләр буенча нотыклар сөйләүләрен уңай гамәл буларак тасвирлаган[30]. Авторның фикеренчә, бу шул заман шартларында бик кирәкле эш ысулы булып танылырга хаклы, татар яшьләре дә, гыйлем алу белән беррәттән, сәяси яктан әзерлекле, киң карашлы булырга тиешләр.

Әхмәтмөнир Ибраһимовның әлеге мәкаләсендә аның Япония һәм мәгариф системасына карата фикерләренең гомумән алганда уңай икәнлеге күренә. Автор карашынча, бу дәүләттә, башка кайбер илләр белән чагыштырганда, татарларга һәм мөселманнарга, татар мәдәниятенә (япон телендә татар спектакле күрсәтелә һ.б.) мөнәсәбәт уңай; шуңа күрә белемгә сусаган татар яшьләре, һичшиксез, Япония уку йортларын сайларга тиешләр. Шул ук

[28] Ниппон теле – япон теле.
[29] Телебез белән ниппон арасындагы якынлык // Милли байрак. 1943. 20 май.
[30] Япония // Йолдыз. 1906. 5 апрель.

вакытта, әлеге мәкаләдән авторның мондагы тәртипләрне, студентларга булган мөнәсәбәтне, укыту өлкәсендәге яңалыкларның кайберләрен татар милли мәгарифендә дә күрәсе килгәнлеге ачык сизелә.

Мөнир Ибраһимов татар газеталары белән һәрчак тыгыз элемтәдә була. 1914 елда ул «Вакыт» газетасының үз мөхбире буларак, Япония, аның икътисады, ислам дине белән бәйле темаларга язмалары белән чыгыш ясый[31], «Вакыт», «Сибирия», «Бәянелхак» укучыларын Япониянең вазгыяте, мәдәнияте һәм мәгарифе, Ислам җәмгыятенең эшчәнлеге, студентлар тормышы белән таныштырып бара[32]. 1912 елда аның Англия һәм Һиндыстан арасындагы мөнәсәбәтләргә багышланган «Ингелтерә вә галәм ислам яки куркулы төш» дигән мәкаләсе «Сибирия» газетасында басылып чыга[33]. Шул ук елны «Икътисад» журналында «Япониядә сәүдә эшләре»[34], «Япониядә исламиятне кабул вә Мәшрукъ хәбәрләре»[35] мәкаләләре дөнья күрә[36]. 1917 елда «Солтан Фатих» дигән пьесасы буенча «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан спектакль әзерләнә.

* * *

XIX гасыр ахырында Россия, Көнбатыш Европа уку йортларында белем алучы татар студентларының саны арта. Яңа индустриаль үсеш чорына керү татарлар арасында да дөньяви белемнәргә ия булган белгечләргә ихтыяҗ тудыра. Татар яшьләре, үзләренең милли нигезләргә корылган дөньяви белем бирү системасы булмау, ә рус уку йортларына керү юллары чикле булу сәбәпле[37], Истанбул, Европа университетларына, XX гасыр башында Америка, Япония уку йортларына юл алганнар.

---

[31] Муртазина Л.Р. Ахмедмунир Ибрагимов о системе высшего образования Японии // Культурные, экономические, технологические контакты и взаимодействие Японии и Татарского мира: история и современность: сборник научных трудов. Вып. 3. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2021. С. 137.

[32] Ибраһимов Ә.-М. Япония җәмгыяте исламиядән // Вакыт. 1914. 10 июль.

[33] Ибраһим М. Ингелтерә вә галәм ислам яки куркулы төш // Сибирия. 1912. 28 ноябрь.

[34] Рәшит Ә.-М. Япониядә сәүдә эшләре // Икътисад. 1912. №1. Б. 10–13.

[35] Рәшит Ә.-М. Япониядә исламиятне кабул вә Мәшрукъ хәбәрләре // Икътисад. 1912. №1. Б. 31–32.

[36] 1911 елда бу мәкаләләр «Бәянелхак» газетасында басылып чыга. «Икътисад» журналына күчереп басыла.

[37] Амирханов Р.У. Некоторые особенности развития народного образования у татар в дооктябрьский период // Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. Казань, 1992. С. 33.

Моңа кадәр дини белем алуда әһәмиятле шәһәрләрнең берсе булган Истанбул дөньяви белем үзләштерергә теләүчеләрне дә үзенә кабул иткән. Педагогик, медицина белеме белән кызыксынучылар Истанбул университетын, Тыйббия мәктәбен сайлаганнар. Ә югары техник, технологик, сәяси белемнәргә өстенлек бирүчеләр, Истанбулда тел буенча әзерлек үтеп, кайбер очракта урта мәктәпләрне тәмамлап, шәһадәтнамәләр алып, Европа уку йортларына юнәлгәннәр.

XX гасыр башында татарлар арасында моңарчы күзәтелмәгән хәл – Америка уку йортларына барып укырга теләүчеләр күренә башлый. Төп аргумент буларак, Америкада сәнәгатьнең, авыл хуҗалыгының төрле тармаклары буенча төпле, нигезле белем бирә торган уку йортларының булуы, ә ватанда мондый мөмкинлекнең чикле булуы күрсәтелә. Моннан тыш, аларны бу кыйтгада чагыштырмача иркенлеккә ия булу – шәкертләрне милләте, дине, матди хәле буенча аерып карау кебек күренешләрнең күзәтелмәве дә кызыксындыра. Татар студентлары, яшьлек ялкыны белән, яхшы белем алып, ул белемнәрне ватан, милләт мәнфәгатьләре өчен файдалануны гына түгел, татар милләтен ерак кыйтгаларда таныту, башка милләтләр арасында югалып калмау, татарлыкны ныгытуны да максат итәләр.

Бу чорда ватаннан читтә дөньяви белемнәр үзләштереп, чит телләрне һөнәри дәрәҗәдә өйрәнеп, ватаннарына кайткан татар яшьләре фән, мәгариф, мәдәният һәм сәнәгатьнең төрле өлкәләрендә җаваплы урыннарда хезмәт иткәннәр, милләте һәм иленең алгарышына өлеш керткәннәр.

# ВАТАННАН ЧИТТӘ БЕЛЕМ АЛУНЫҢ МАТДИ ҺӘМ БАШКА ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

## Чит мәмләкәтләрдәге татар шәкертләренә иганәләр һәм ярдәм җәмгыятьләре

Чит илләргә белем артыннан баручыларның шактый өлеше хәлле гаиләләрдән булган. Бу шәкертләр артык кыенлыклар күрми генә уртача шартларда укый һәм яши алган. Ләкин укучылар арасында матди мөмкинлекләре чикле, әмма белем алуга дәрте һәм сәләте булган татар яшьләре дә күп булган. Алар, аеруча XIX–XX гасырлар чигендә, иганәчеләр ярдәме белән чит мәмләкәтләргә барып укый алганнар.

Бу очракта татар шәкертләренә матди ярдәм күрсәтүне оештыру һәм аны җайлау механизмы турында сөйләү дөрес булыр. Татар җәмгыятендә күзәтелгән әлеге күренеш хәйриячелек дип атала һәм аның, билгеле булганча, зур тарихы бар. XIX гасыр ахырларында әлеге хәрәкәт тагын да активлаша һәм мәгариф өлкәсендә аеруча нык чагылыш таба. Татар яшьләрен дөньяның танылган мөселман белем бирү үзәкләренә җибәреп укыту белән аерым хәйриячеләр дә, шулай ук хәйрия җәмгыятьләре дә шөгыльләнгән. Әлбәттә, беренче чиратта милли мәнфәгатьләр күздә тотылган – шул рәвешле аерым шәхесләр һәм җәмгыятьләр татар милләтенең киләчәген кайгыртуны, аны белемле яшьләр белән тәэмин итүне максат иткәннәр.

Шунысын да искәртеп китү мөһим, хәйриячелек җәдитчелек хәрәкәте җәелү белән үзгә төсмер ала. Ул традицион мөселман хәйриячелегеннән аермалы буларак, җәмәгатьчелек хәйриячелеге рәвешен ала һәм аерым җәмгыятьләр эшчәнлегендә чагылыш таба. Урта Азиядә җәдитчеләр тарафыннан оештырылган хәйрия җәмгыятьләре, мәсәлән, сәләтле яшьләрне чит илләргә җибәреп укытуга зур әһәмият бирәләр[1]. Җәдитчеләрнең бу хәрәкәтен хәлле кешеләр күтәреп ала һәм нәтиҗәдә дистәләрчә яшьләргә җәмгыятьләр һәм аерым шәхесләр акчасына Германия, Төркия уку йортларында белем алырга мөмкинлек ачыла[2].

---

[1] Гафаров Н.У. Джадидизм в Средней Азии в конце XIX в. – начале XX в. Автореф. дисс. на соискание ученой степени д.ист. н. Душанбе, 2013. С. 34–35.

[2] Гаффоров Н.У. Деятельность благотворительных обществ среднеазиатских джадидов в сфере народного образования // Ученые записки Худжандского государственного университета им. академика Б. Гафурова. Гуманитарные науки. 2013. №. 1. С. 112, 114–115.

Бу урында Россия күләмендә танылган хәйриячеләр – Әхмәт (1837–1906) һәм Мәхмүт (1839–1910) Хөсәеновларны искә алу хаклы булыр. Алар ил эчендә генә түгел, чит мәмләкәтләрдә белем алучы шәкертләргә дә ярдәм иткәннәр. Мисал өчен, 1906 елда Мәхмүт Хөсәенов акчасына «Хөсәения» мәдрәсәсе җитәкчелеге берничә шәкертне Каһирәгә укырга җибәрә[3]. Татарларда хәйриячелек тарихын өйрәнгән галим Җ.С. Миңнуллин билгеләп узуынча, алар арасында татарның танылган мәгърифәтчесе, дин эшлеклесе һәм педагог Сөнгатулла Бикбулатов та була[4]. Икенче бер тикшеренүче Д.Н. Денисов С.Бикбулатовны Әхмәт бай акчасына укыган дип күрсәтә. Аның исәпләүләренчә, Әхмәт байның вафаты алдыннан татар мәгарифе мәнфәгатьләре өчен васыять итеп калдырган ярты миллион акчасына З.Аюханов, Г.Батталов, С.Бикбулатов, Ш.Вахитов, Л.Зәитов, Ә.Сәйфетдинов, Г.Фәйрушин «әл-Әзһәр» университетында, Г.Кәрими һәм Г.Максудов Истанбул университетында, Ш.Фәйрушин Бәйрут университетында белем алалар[5]. Ничек кенә булса да, бертуган Хөсәеновларның татар яшьләренең ватаннарында һәм мәмләкәттән читтә югары белем алуларына зур өлеш керткәнлекләре бәхәссез. Сәнәгатьчеләр бертуган Рәмиевләр шулай ук сәләтле татар яшьләрен Истанбул уку йортларына җибәреп укытканнар. Зыя Камалига исә Төркиягә укырга китәр өчен мөфти Мөхәммәтьяр Солтанов (35 сум) һәм Кырым мөселманнары ярдәм иткән. 1896 елда Кырымда чит ил паспорты алган вакытта, аның белемгә омтылышы зур, әмма матди мөмкинлекләре бик аз икәнен күргән Бакчасарай мөселманнары, үзара җыелышып, З.Камалига 60 сум тирәсе акча җыеп биргәннәр. 1900 елда Каһирәдәге «әл-Әзһәр» университетына укырга кергәннән соң, аңа Уфа хәйриячесе Садретдин Назыйров 200 сум акча җибәрә[6].

Троицк мулласы ахун Әхмәтхаҗи Рахманколов, җәдиди мәдрәсәләренә мөгаллимнәр әзерләү максатыннан татар яшьләрен Төркиягә җибәреп укыту өчен матди ярдәм күрсәтүен сорап, Габделвәли Яушевка[7] мөрәҗәгать итә[8].

---

[3] Миннуллин З. Землячества и благотворительные общества татарских учащихся в мусульманских странах (начало XX века) // Мир ислама. 1999. №1/2. С. 146.

[4] Татар энциклопедиясе: 6 томда. Т. 1. Казан: ТЭИ, 2008. Б. 484.

[5] Денисов Д.Н. Роль Оренбургского медресе «Хусаиния» в развитии мусульманского образования // Ученые записки Казанского государственного университета. Гуманитарные науки. 2010. Том 152. Кн. 3, ч. 2. С. 70.

[6] Ергин Ю.В. Зия Камали – основатель медресе «Галия»: трагические 30-е годы. URL: https://cyberleninka.ru/article/n/ziya-kamali-osnovatel-medrese-galiya-tragicheskie-30-e-gody/viewer (дата обращения: 11.11.2022).

[7] Габделвәли Яушев (1840–1906) – Троицк шәһәренең һиммәтле байларыннан берсе, хәйрияче; яңа ысул нигезендә ачылган мәктәпләрне матди яктан тәэмин иткән, мөгаллимнәргә хезмәт хакы түләп торган.

[8] Гизатуллин Р.Н. 1 января 1846 г. основано медресе «Мухаммадия» (Троицк, город). URL: https://chelreglib.ru/ru/cid/detail/50/ (дата обращения: 10.04.2021).

«Әхмәдия» мәдрәсәсе хәлфәсе Мөхәммәтзакир Ваһаповка Истанбулда укыр өчен акчаның иң күп өлешен Яушев биргән[9].

Россиянең аерым шәһәрләрендә оештырылган иҗтимагый һәм һөнәри оешмалар шулай ук укучы мөселман яшьләренә ярдәм итүне максат иткәннәр. Мисал өчен, 1905–1907 елларда барлыкка килгән «Троицк приказчиклар җәмгыяте» дөньяви белем алырга теләүчеләргә булышлык күрсәткән. Җәмгыятьнең җитәкчесе Камал Габитов Россия уку йортларында гына түгел, чит илләрдә укучы татар студентларына да «татар милләте үсеше өчен иң әһәмиятле» булган һөнәрләрне үзләштерергә матди ярдәм иткән – әлеге җәмгыять акчасына өч татар егете табиб, хокук белгече һәм педагог һөнәренә ия булган. Атаклы Троицк мөгаллиме Хәлил Зәйнетдинов улы Хәбибулла Зәйни, шушы мәсьәлә буенча «Троицк приказчиклар җәмгыяте»нә ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән. Нәтиҗәдә Истанбул дарелмөгаллиминенең биогеография факультетына җибәрелгән. Җәмгыять аңа ел саен 25 сум түләп барырга вәгъдә итә. 1910 елның көзендә әлеге оешма эшчәнлеген туктатканнан соң, ике ел дәвамында матди ярдәм алган Х.Зәйни, алга таба укуын дәвам итү өчен, типографиягә хәреф җыючы булып эшкә урнашырга мәҗбүр була. Авырлыкларга карамастан, 1912 елда укуын бик яхшы билгеләренә тәмамлап, диплом ала һәм Уфага кайта[10].

Кайбер булачак студентларга аерым шәхесләр, халык ярдәм иткән. Күп очракта әлеге акчаның күләме зур булмаган, һәм ул теге яки бу илгә барып җитәргә, ягъни юл чыгымнарын капларга гына җиткән. Хәбибулла Байбулатовка, мәсәлән, шул рәвешле җыелган акча – барлыгы 78 сум – Америкага барып җитеп, Сан-Франциско шәһәрендә уку йортына урнашырга мөмкинлек биргән[11].

Алга таба яшьләргә яшәү һәм белем алу өчен матди мөмкинлекләрне үзләренә эзләргә туры килгән. Җәмәгатьчелек бу мәсьәләне хәл итү юлларының берсе буларак татарлар өчен махсус уку йорты ачуны күргән. Мәдинә шәһәрендә барлыкка килгән «Казанлы» мәдрәсәсе шуның ачык мисалы.

Проблеманы хәл итүнең икенче, шулай ук әһәмиятле, ләкин беренчесе белән чагыштырганда беркадәр җиңелрәк булган икенче бер юлы – аерым шәһәрләрдә яисә мәмләкәтләрдә яшәп укучы татар шәкертләре яисә Россия мөселманнары өчен җәмгыятьләр оештырудан гыйбарәт булган. Бу проблема тикшеренүчеләр Ж.Миңнуллин, Ф.Шәкүров хезмәтләрендә яктыртыла[12].

---

[9] Габделбари Баттал. Троицк байларындан вә хәйратларындан Габделвәли Яушев. Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1912. Б. 14.

[10] КФУ КСКБ, 2390-т, IV, б 1.

[11] Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1911. 11 сентябрь.

[12] Миннуллин З. Землячества и благотворительные общества татарских учащихся в мусульманских странах (начало XX века) // Мир ислама. 1999. №1/2. С. 129–148; Фазлиев А.М., Шакуров Ф.Н., Ибрагимов Р.Р., Нафиков И.З. Общественные организации татарских учащихся в Оттоманской империи в начале XX в. // Современная наука:

Чынлап та, бу җәмгыятьтләрне ачу шәкертләрнең бик күп кенә проблемаларын, беренче чиратта, матди мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек биргән. Моннан тыш, башка мәмләкәтләрдә оештырылган кайбер гомуми хәйрия җәмгыятьләре дә шул ук максатларга юнәлдерелгән була. Мисал өчен, 1909 елда Истанбулда оештырылган «Бохара мәгарифне тарату җәмгыяте» шундыйлардан була. Күп тә үтми, Төркестанның төрле шәһәрләрендә аның филиаллары барлыкка килә. Җәмгыятьнең максаты – мөселман яшьләрен Истанбул уку йортларына укырга җибәрү. Устав буенча уку тәмамланганнан соң, әлеге яшьләрнең эшчәнлек даирәсен билгеләү җәмгыять карамагында кала[13].

Мөселман илләрендә, бигрәк тә Хиҗазда, хаҗ юлында урнашкан шәһәрләрдәге уку йортларында укучы шәкертләр матди хәлләрен хаҗилар исәбенә хәл иткәннәр. Хаҗиларны йөртү, урнаштыру, аларның проблемаларын хәл итүдә ярдәм итеп, алар үзләренең матди хәлләрен яхшыртканнар һәм ел дәвамында, икенче Зөлхиҗҗә аена кадәр яшәү өчен беркадәр мая туплаганнар. Күп очракта бу аларның бердәнбер керем чыганагы булып хезмәт иткән. Ләкин кайбер елларда төрле сәбәпләр белән хаҗга килүчеләрнең саны көтелгәннән ким булган, бу исә татар яшьләренең кесәләренә дә суккан. 1914 елда мәсәлән, сугыш башлану белән бәйле рәвештә, хаҗга килүчеләрнең саны бик аз була, һәм шул сәбәпле күп кенә шәкертләр матди яктан авырлыклар кичерәләр[14].

Шулай итеп, төрле җирләрдә шәкертләрнең үз җәмгыятьләре ачыла башлый.

Бу чорда кайбер башка халыкларның мондый төрдәге җәмгыятьләре була инде. Мәсәлән, Төркиядә яшәүче әрмәннәрнең төгәл эшли торган шундый механизмнары булган: бер-ике студент җәмгыять исәбенә төрек уку йортларында европа телләрен өйрәнгән, соңыннан алар шул ук җәмгыять тарафыннан Европа яисә Америка уку йортларына җибәрелгән, белем алып, әзерлекле белгечләр булып илләренә кире әйләнеп кайтканнар, алган гыйлемнәрен милләтне алга җибәрү өчен сарыф иткәннәр. Шулай итеп, әкрен-әкрен генә милләтне үстерегә, аның иң алдынгы милләтләр сафына басуына ирешергә мөмкин дип санаганнар[15]. Татар җәмәгатьчелеге әлеге үрнәкне, аның кайбер элементларын файдаланып, татарлар өчен дә кулланырга мөмкин дип санаганнар.

Соңрак, 1920 елда «Мисырдагы рус студентлары берлеге» оеша, аның максаты «рус студентларын берләштерү һәм аларның мәнфәгатьләрен як-

актуальные проблемы теории и практики. Серия «Гуманитарные науки». 2023. № 9/2. С. 38–42.

[13] Гаффоров Н.У. Деятельность благотворительных обществ среднеазиатских джадидов в сфере народного образования // Ученые записки Худжандского государственного университета им. академика Б. Гафурова. Гуманитарные науки. 2013. № 1. С. 112, 114–115.

[14] Хаҗилар вә татар таләбәләре // Вакыт. 1914. 4 октябрь.

[15] Укучыларга ярдәм җәмгыяте // Вакыт. 1910. 6 март.

лаудан» гыйбарәт була[16]. Әлеге җәмгыять ярдәме белән Европа илләренә барып, андагы уку йортларына керү мөмкин булган. 1944 елда исә Каһирәдә «Төркестан хәйрия җәмгыяте» оеша, ул үз сафларына Төркестан мөһаҗирләрен туплый, аның Уставы да була[17].

Нигездә шушы ук максатларны хәл итү өчен чит мәмләкәтләрдә укучы татар студентлары да үзләренең җәмгыятьләрен оештырганнар. 1906 елда Каһирәдә шәкертләрнең «Татар таләбәсе җәмгыяте» дип исемләнгән оешмалары була[18]. Аның максаты – «Мисырда укымакта булган шәкертләргә матди вә мәгънәви ярдәм бирмәк вә милләткә дә әдәби сурәттә хезмәт итмәк»тән гыйбарәт була[19]. Әлеге җәмгыятьнең эшчәнлегенә тукталып, «Казан мөхбире» газетасы: «Мисырда да Русиянең төрле урыннарыннан җыелган таләбәләр үзләре махсус җәмгыять ясап, үзләренең мәгърифәтләрен арттыру вә ватаннарына ни тарика (юл) хезмәт итү яки килгән мохтаҗ ватандашларына мәгунәт (ярдәм) итәргә сәгый (тырышлык) вә иҗтиһад итмәктәләрдер (тырышалар)», – дип хәбәр итә[20].

1908 елда Истанбулда «Рәсәй мөселман укучылары җәмгыяте» оеша, ул үз эченә Кырым һәм Казан татарларын туплый[21]. Шул ук елның азагында тагын бер җәмгыять барлыкка килә – ул Россиядән килеп белем алучы яшьләргә ярдәм итүне максат итә[22]. Әлеге җәмгыять татар байлары, сәүдәгәрләре һәм дин әһелләре тарафыннан оештырыла һәм финанслана. Аның үз программасы була, 70 тән артык әгъзаны берләштергән әлеге оешма яшьләргә яшәү һәм белем алу өчен уңайлы шартлар тудыру белән беррәттән, аларны татар китаплары һәм вакытлы матбугат басмаларыннан гыйбарәт булган китапханә белән тәэмин итү мәсьәләсен дә хәл итә. Озакламый әлеге ике җәмгыять берләшә[23]. Бу – татар укучылары җәмгыятьләренең иң эреләреннән берсе була, аның үз клубы, кыйраәтханәсе ачыла, музыкаль һәм әдәби кичәләр оештырыла, лекцияләр укыла[24]. Әлеге оешманы мөселман илләрендә дини белем алган барлык татарларны берләштерүче үзәк дияргә дә мөмкиндер, чөнки аның идарә әгъзалары Истанбулга укырга килгән татар яшьләрен, аларның максатларыннан һәм теләкләреннән чыгып, тиешле илләргә һәм уку йортларына җибәрүне хәл иткән.

---

[16] Москалец О.В. Об организации «Союз русских студентов в Египте» (1920–1922 гг.) // Minbar. Islamic Studies. 2019. №12(4). С. 948.

[17] Хайрутдинов А.Г. Из истории туркестанской эмиграции: «Туркестанское благотворительное общество» в Каире // Minbar. Islamic Studies.2020. №13(4). С. 824–844.

[18] Каһирә. Татар таләбәсе җәмгыяте // Өлфәт. 1906. 26 июнь.

[19] Мөхбирләребездән // Вакыт. 1906. 20 июнь.

[20] Мисырда. Татар таләбәсе җәмгыяте // Казан мөхбире. 1906. 9 апрель.

[21] Истанбулда татар шәкертләре // Әл-Ислах. 1908. №43. Б. 9.

[22] Истанбулда русияле татар шәкертләре // Йолдыз. 1908. 7 декабрь

[23] Миннуллин З. Землячества и благотворительные общества татарских учащихся в мусульманских странах (начало ХХ века) // Мир ислама. 1999. №1/2. С. 142.

[24] Кәрими Ф. Истанбул мәктүбләре. Оренбург, 1914. Б. 413–414.

Бу вакытта Истанбулда казанлы, кырымлы, төркестанлы, кавказлы һәм кыргыз яшьләрен берләштергән «Русияле таләбә җәмгыяте» эшләп килә. Аның төп максаты – яңа килгән яшьләргә яшәргә урын табу, укырга керергә әзерләнергә, юнәлеш сайларга ярдәм итүдән гыйбарәт була. Баштагы чорда Казан татарлары җәмгыяте буларак төзелгән әлеге оешма Кырымнан килгән студентларны да үз эченә алган. 1908–1912 елларда аның матди ярдәме белән 50 тирәсе шәкерт төрле уку йортларына кергәннәр. 1912 елда анда барлыгы 150 әгъза исәпләнелә[25]. Җәмгыятьнең үзенең уку залы (кыйраәтханәсе), конференцияләр үткәрү өчен махсус бүлмәсе була. Студентлар 2–3 атнага бер җыелышып, төрле кичәләр, «әдәбият ахшамнары» үткәргәннәр. 1914 елның 24 апрелендә булып узган шундый кичәләрнең берсендә Зыя Насыйри да катнашкан. Ул, үзе дә төрек уку йортында укыган кеше буларак, мондагы шәкертләргә нинди мәгълүматлар кирәген, кызыклы булуын яхшы белгән һәм шуңа да иң беренче Россиядәге хәлләрне бәян иткән. Лекциягә бер көн кала «Икъдам» газетасында бу турыда игълан бирелә, шуңа күрә аны тыңларга күп кеше җыела. З.Насыйри чит илләрдә белем алучы яшьләр өчен «ватанымызны, милләтемезне оныту, милли рух вә тәрбиямезне гаеп итү, тәхсилне (укуны) икмаль (камил) иткәннән соң мәмләкәткә кайтмыйча читтә калу тиеш булмауны» аңлаткан, мөмкин кадәр аларга рух бирергә тырышкан. Лекция тәмам булганнан соң, әдәбият кичәсе башланган. «Иң элек скрипка, гармун, мандолинада кечек, әмма рухлы вә әһәмиятле, оркестр тарафыннан берничә милли көйләремез уйналды. Соңра мәрхүм Тукаевның, Мәҗит Гафуриның шигырьләре, башка берничә мәшһүр парчалар хор илә дә, аерым бер кеше тарафыннан да җырланды, укылды. Кырымлы вә кыргыз кардәшләремездән дә берәр кеше үз тарафларыннан милли лисан вә шивәләрендә мәнзум (тезелгән) парчалар укыдылар. [...] Хосусан, скрипка вә гармунда уйналган милли көйләремез яшьләремезгә бөтенләй башка бер тәэсир, бер рух бирде»[26].

Моннан тыш, Истанбулда 1908 елда ачылган «Нәшре мәгариф җәмгыять хәйриясе»нең максаты да «чит мәмләкәтләрдән килгән мөселман шәкертләренең укуларына, мәгыйшәтләренә, голүм вә мәгърифәтендә алга китүләренә ярдәм кылмак вә аларны тәэмин мәгыйшәт итә торган зирагать (авыл хуҗалыгы), тиҗарәт (сәүдә), һөнәр вә сәнәгать юлларына кертмәктә»н гыйбарәт булган[27]. Җәмгыятьнең әгъзалары булып, Казан татарлары белән беррәттән, Кырым татарлары да торган.

Әлеге җәмгыятләр студентларга матди ярдәм күрсәтү белән беррәттән, авырлыкларга очраган ватандашларына чит мәмләкәттә югалып калмаска, үз юлларын табарга булышлык иткәннәр. Баһаветдин Бәкер атлы 15 яшьлек

[25] Камал Г. Истанбул мәктүпләре // Йолдыз. 1912. 18 декабрь.
[26] Насрый З. Истанбул мәктүбе // Йолдыз. 1914. 23 май.
[27] Истанбулда «Нәшре мәгариф җәмгыять хәйриясе» // Вакыт. 1908. 11 декабрь.

татар егете нинди юллар беләндер Истанбулга килеп чыга. «Русияле ислам таләбә җәмгыяте»нә мөрәҗәгать итә, аның әгъзалары аша бер вакытлы матбагага эшкә урнаша. Өч ай дәвамында бик тырышып эшләп, «китап бөкләргә вә төпләргә вә бераз хәреф төзәтергә өйрәнә». Өйләдән соң ял өчен бирелгән вакытын Казалы шәһәреннән килеп мөгаллимлек иткән Габдрахман агадан дәресләр алуга сарыф итә. Һәр көнне газета сатып алып укуны гадәткә кертә, шулай итеп, алган белемнәрен ныгыта, алга таба укуын дәвам итү өчен 3–4 ай эчендә беркадәр акча туплый ала. Аннан соң Хәлим Сабит әфәнденең[28] киңәше һәм ярдәме белән бушлай Солтания мәктәбенә укырга керә. Укуга сәләтле һәм тырыш егет җиде еллык курсны өч елда тәмам итә. Моның өстенә, белемен Европада дәвам итәргә хыяллана[29].

1909 елда Мәккәдә укучы Россия мөселман шәкертләре «Ислам таләбәсенең җәмгыять гыйльмиясе» дип исемләнгән оешмаларын булдыралар. Аның программасы җирле хөкүмәт тарафыннан 1909 елның 15 декабрендә раслана. Ул ике өлештән һәм 20 маддәдән гыйбарәт була. Программада күрсәтелгәнчә, җәмгыятьнең максаты – «Русиядән тәхсил гыйлем (гыйлем алу) өчен килгән һәр таләбәнең голүм гарәбия вә голүм динияи заманымызга мотабикъ (туры килгән, заманча) сурәттә тәхсиленә сәгый (тырышлык) вә гайрәт (тырышлык) итеп, мәгарифтән хәбәрдар итмәк»[30]тән гыйбарәт була. Моннан тыш, шәкертләрне «мәмләкәткә кайтдыкта кавем вә кабиләсенә муафикъ хәрәкәттә булынмага тәргыйбь итмәк (кызыксындыру)» мәсьәләсе күтәрелә. Ягъни, әлеге уку йортларында белем алганнар ватанга кайткач алган белемнәрен милләт мәнфәгатьләре өчен файдаланырга тиешләр. Программада җәмгыятьнең оештыру өлешләре – рәис, мөгавин, сәркатиб сайлау, атнага бер тапкыр эшчәнлегенә анализ, нәтиҗә ясау, һәр әгъзаның әдәп вә инсаф ягыннан тәнкыйтькә ия булу мөмкинлеге, керем-чыгымнар турында матбугат аша хәбәр итеп тору, башка җирләрдә урнашкан русияле таләбә җәмгыятьләре белән бәйләнештә тору һ.б. бик күп мәсьәләләр каралган[31].

Гомумән алганда, җәмгыять составында Казаннан, Әстерханнан, Кырымнан, Себердән һәм Россиянең башка җирләреннән килгән яшьләр була. Җәмгыять әгъзалары даими рәвештә ватандашлар, хаҗилар белән очрашулар оештырганнар. Баштагы чорда хаҗиларны чакырып, аларга җәмгыятьнең максатларын аңлатканнар, бүгенге хәле белән таныштырганнар[32]. Мөгаен,

[28] Хәлим Сабит (1883–1946) – Россиядән килгән татар укытучысы, аның хакында тулырак «Истанбул – тәрәкъкыйпәрвәрлеккә бер күпер» бүлегендә сөйләнелә.

[29] Әл-Идриси Г. Эсвичрәдә чит мәмләкәт шәкертләре // Вакыт. 1914. 20 март.

[30] Мәккәи Мөкәррәмәдә («Русияле ислам таләбәсенең җәмгыять гыйльмиясе») // Шура. 1910. №6. Б. 191 (191–192).

[31] Шунда ук. Б. 191–192.

[32] Җанкүз Х. Мәккәи Мөкәррәмәдән мәктүб // Йолдыз. 1910. 17 гыйнвар.

шул рәвешле, аларның игътибарын җәлеп итеп, җәмгыять файдасына беркадәр табыш алырга теләгәннәрдер.

Татар студентлары үзләре Мәккәдә укуны матди яктан караганда файдалырак дип санаганнар. Ләкин биредә икенче бер проблема килеп туган – хаҗ вакытында яшәү урыннары табу кыенлык тудырган. Чөнки студентларның үз мәдрәсәләре, димәк, укытучылары, аерым билгеләнгән махсус яшәү урыннары булмаган. Шул сәбәпле алар теге яки бу мәдрәсәгә җирле студентлардан бушаган арада гына йөри алганнар, үзләренә махсус педагог табып, аның хезмәтен түләргә тиеш булганнар. «Русияле ислам таләбәләре җәмгыяте»нең программасында алар өчен махсус мәдрәсә ачу, аерым укытучы билгеләү, китапханә булдыру кебек мәсьәләләр билгеләнә. Әлеге җәмгыятьнең казнасын татар яшьләре Истанбулдагы арадашчы Риза бәк һәм хаҗилар ярдәмендә тупларга кирәк дип саныйлар[33].

1909 елда шундый ук җәмгыять Мәдинәдә дә барлыкка килә, ул үзенең максат-бурычлары белән Мәккә оешмасына охшаш була.

1914 елда Россия империясе чикләреннән читтә татар шәкертләренең тагын ике җәмгыяте – беренчесе Бәйрутта, ә икенчесе Һиндыстандагы Деобанд җирлегендә (Сахаранпур шәһәрендә) барлыкка килә[34].

Әлеге җәмгыятьләрнең эше белән татар җәмәгатьчелеге кызыксынып торган. Сәүдәгәрләр, хаҗилар шәкертләр белән очрашулар оештырганнар, аларга матди яктан ярдәм итәргә тырышканнар. Әйтик, 1906 елда Мисырда булып, татар таләбәсе җәмгыятендә булган Бөгелмә өязе мулласы Зәкиҗан Шаһгәрәев һәм Минзәлә өязе сәүдәгәре Нурмөхәммәтовның, җәмгыять эшчәнлегеннән канәгать калып, аның алга таба да тәрәккъкыйлеген теләп, бер Англия алтынын бүләк итүләре билгеле[35].

Ислам мәмләкәтләрендә укучы Россия мөселманнары өчен иганә җыю мәсьәләләре вакытлы матбугатта да яктыртылып барган. Мәдинәдәге «Русияле ислам таләбәләренең җәмгыять гыйльмиясе» әгъзалары үзләренә матди ярдәм иткән затларга рәхмәтләрен белдергән язмаларын «Йолдыз» битләрендә бастырганнар. Бу керемнәр җәмгыятьнең рәсми иганә дәфтәрендә язылып барылган һәм бу турыда җәмәгатьчелеккә хәбәр ителгән. Шундый хатларның берсендә 1909 елның маенда җәмгыять файдасына акча күчергән кешеләр – Бөгелмә өязе Баланкүл авылы имамы Зәкиҗан хәзрәт[36] (иганә дәфтәрендә 14 нче номер белән теркәлгән) һәм шул ук елда әлеге хәзрәтнең ты-

[33] Мәккәи Мөкәррәмәдә русияле ислам таләбәсенең җәмгыять гыйльмиясе тарафыннан игъланнамә // Вакыт. 1910. 28 август.

[34] Миннуллин З.С. Татарские благотворительные общества: от общины к обществу // Миңнуллин Җ.С. Мәкаләләр җыентыгы. Казан: Татар.кит.нәшр., 2023. Б. 344.

[35] Мисырда. Татар таләбәсе җәмгыяте // Казан мөхбире. 1906. 9 апрель.

[36] Алда искә алынган Зәкиҗан мулла Шаһгәрәев турында сүз барса кирәк.

рышлыгы белән башкалардан җыеп тапшырылган 20 сум акча турында хәбәр ителә[37].

Матди якны тәэмин итү әһәмиятле булган, әлбәттә. Тик татар шәкертләре, аерым җәмгыятьләр төзегәндә гыйльми якны, ягъни уку барышын җайга салу, дәреслек һәм башка методик әсбаплар, программалар нигезендә белем бирү кебек уку-укытуның эчтәлегенә караган мәсьәләләрне хәл итүне дә бер үк дәрәҗәдә кирәкле санаганнар. Мәдинә шәһәрендәге «Казанлы» мәдрәсәсе шәкертләре, мәсәлән, үзләренең 1909 елның 9 февралендә төзелгән «Казанлы таләбәсе җәмгыять гыйльмиясен»ә беренче чиратта нәкъ менә уку-укыту проблемаларын хәл итү бурычын куйганнар. Мәдинә шәһәрендәге атаклы остазларны тартып, тәртип нигезендә укыту турындагы карарны да әлеге җәмгыять әгъзалары кабул итә[38].

Бу җәмгыятьнең программасы матбугатта басылып чыга[39]. Әлеге программага караганда, җәмгыятьнең максаты «Мәдинәи Мөнәүвәрәгә килгән һәр талибны голүм диния вә голүм гарәбия тәхсиленә сәгый вә гайрәт (тырышлык) иттермәгә бәрабәр, мәгариф вә мәдәнияттә хасса баб (үзенчәлекле капка) итеп бәгъдәл тәхсил (белем алганнан соң) мәмләкәттә кайтдыктан соңра голүм диния вә голүм гарәбия тәгълиме илә милләт исламиягә вә шәригать горрәгә хезмәткә багыс улмак»тан гыйбарәт була[40]. Бу максатны тормышка ашыруда иң беренче бурыч итеп, җәмгыять әгъзалары укыту тәртибе һәм программаларны җайга салу, яхшы мөдәррисләр билгеләүне күрәләр. Нәтиҗә буларак, «Казанлы» мәдрәсәсен тәмамлаган татар яшьләре «мәмләкәткә кайтдыкта кавем-кабиләсенә муафикъ хәрәкәттә булышып, хәсән тәүҗиһләрен (биредә: игътибарларын) казанмага тәргыйбь вә тәшвикъ итмәк (өнди, кызыксындыра)». Шәкертләр ватаннарына кайтканнан соң, ислам һәм милләт файдасына хезмәт итү белән, үзләренең гыйлемлелеге белән башкаларны да җәлеп итәргә, белем алырга кызыксыну тудырырга тиешләр. Мәдрәсә тәмамлаучыларга шәһадәтнамә бирү, хәлләренә күрә эш белән тәэмин итү мәсьәләсе дә каралырга һәм хәл ителергә тиеш. Программа шулай ук оештыру моментларын – өч айга бер тапкыр хисап тоту, Русиядән килгән һәр таләбәне әгъза итеп алу, тәртибе яисә башка гамәлләре белән җәмгыять низамына туры килмәгән очракта әгъзалыктан чыгару, тәртип һәм инсаф мәсьәләсен һәрчак тикшереп тору һ.б. бик күп моментларны бик ачык тасвирлаган.

Таләбә җәмгыятьләре әгъзалары вакытлы матбугатта чыгыш ясап, киң җәмәгатьчелеккә үзләренең проблемаларын бәян иткәннәр, кызыксынучылар өчен әлеге илләрдә белем алу шартларын аңлатканнар, игъланнар биргәннәр. Татар газеталары аларны туган илләре белән бәйләп торучы механизм ролен

[37] Тәшәккер // Йолдыз. 1910. 13 апрель.
[38] Идарәгә мәктүб // Йолдыз. 1909. 6 сентябрь
[39] Мәдинәи Мөнәүвәрәдә казанлы таләбәсенең гыйльмиясе // Йолдыз. 1909. 7 сентябрь.
[40] Шунда ук.

үтәгәннәр. 1910 елда «Йолдыз» газетасында «Истанбул русияле ислам таләбәсе җәмгыяте» әгъзаларының язмасы басылып чыга. Анда бер төркем «хаиннәрнең» Россиядә җәмгыять исеменнән акча җыеп йөрүләре турында хәбәр ителә. Акча җыю өчен җәмгыятьнең рәсми мөһере белән расланган дәфтәрләре була, шуңа күрә авторлар, ватандашларын кисәтеп, аларның теләсә кемгә акча бирмәүләрен үтенәләр, «Без мәмләкәттә парә тупламак өчен кемсә күндермәдек», – дип язалар[41]. Икенче бер игъланда җәмгыять әгъзалары үзләренең китапханәләрен ачу сәбәпле, шул китапханәне газета-журналлар белән тулыландыру, мөмкин булган кадәр мөхәррир һәм наширләрнең ярдәм итүләрен үтенеп мөрәҗәгать итәләр[42].

Ватаннан читтә белем алган татар шәкертләренең үзара ярдәм җәмгыятьләре аларга чит мохиттә яшәргә һәм белем алырга мөмкинлекләр тудырган, әлеге оешмалар эшчәнлегеннән алар һәм матди, һәм рухи таяныч алганнар. Бу җәмгыятьләр шәкертләргә ватаннары белән элемтәләрне югалтмаска, милли мәдәнияттән читләшмәскә булышкан. Әлеге оешмалар ярдәмендә шәкертләр татарларны һәм татар мәдәниятен башка милләтләр алдында таныта алганнар.

Шулай итеп, XIX–XX гасырлар чигендә чит мәмләкәтләрдә укучы татар студентларының ватаннан читтә яшәү һәм белем алуның күп якларын искә алган үзенчәлекле механизмнары эшләп килгән. Анда матди як белән беррәттән, ислам дине, янәшәдә яшәгән мөселман халыкларының традицияләрен хөрмәт итү дә күздә тотылган. Беренче урында татарларга гына хас булган үзенчәлекләр, милләтнең менталитеты мәсьәләләре чагылыш тапкан. Һәм, әлбәттә, тәрәкъкыятьнең төп юлы булган белемлелеккә ирешүдә ватандагы милләтпәрвар татар байларының һәм хәйрия оешмаларының роле зур булган.

---

[41] Идарәгә килгән мәктүбләр // Йолдыз. 1910. 17 гыйнвар.

[42] Идарәгә хат // Йолдыз. 1910. 2 май.

# Татар хатын-кызлары югары белем юлында

*«Болар, ватаннарына кайтып,*
*милләттәшләре арасында хезмәт итәчәкләр»*
(«Вакыт»)

Югары уку йортларында белем алган студентлар турында сүз алып барганда, нигездә ир-егетләр искә алына. Бу аңлашыла да. Җәмгыятьтә ир-атларга һәм хатын-кызларга карашның һәм мөмкинлекләрнең төрлелеге, хокукларда аерма булуы һ.б. үз ролен үтәгән. Университетларның уставлары ир-атларны гына укытуны караган. Хатын-кызларга белем алу өчен дә мөмкинлекләр, ир-атлар белән чагыштырганда, чикле булган. Бик сирәк очракта гына кызлар университетларга йөреп лекцияләр тыңлый алган. XIX гасырның 60нчы елларында илдә югары белем алып булмагач, Россия хатын-кызлары чит илләргә укырга китә башлаган[1]. XIX–XX гасырлар чигендә исә мөселман кызлары арасында да, татар мәктәпләре белән генә чикләнмичә, рус уку йортларына кереп белем алу күренеше күзәтелә башлый. Соңрак кайберләре югары белем артыннан чит мәмләкәтләргә юнәлә.

Россиядә хатын-кыз мәгарифе үсешенең үзенчәлекләре бар. Әлеге тикшеренү кысаларында гомумән белем алуның барлык баскычларына да тукталмыйча, махсус һөнәри һәм югары белем алу мәсьәләләрен генә карарбыз. Гасырлар чигендә хатын-кызларның махсус югары курсларга кереп белем үзләштерүләре шактый киң таралса да, университет дипломнары алу өчен юллар ябык була. Моны Россия җәмгыятендә хатын-кызның югары белем алуына карашның, сәясәтнең бер чагылышы дип карарга кирәк[2]. Билгеле булганча, кызлар югары белемне бары тик башкала шәһәрләрендә генә (Мәскәү, Петербург) ала алганнар. Мәскәү галимнәренең күпчелеге хатын-кызга югары белем бирү мәсьәләсенә карата катгый рәвештә тискәре караштa торганнар, шул сәбәпле ханымнар күбесе Петербургта укыганнар[3]. Дәүләт югары белем бирү системасы тарафыннан кире кагылган хатын-кызлар белем артыннан чит илләргә – Швейцариягә, Франциягә, Германиягә юнәлергә мәҗбүр булганнар[4]. Цюрихта, мәсәлән, 1871 елда 17, 1872 елда 104

---

[1] Мәхмүтова А. Вакыт инде: без дә торыйк... (Җәдидчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. Казан: Татар. кит.нәшр., 2012. Б. 78.

[2] Соловей А.П. К вопросу о включенности женщин в научную деятельность // Роль женщины в развитии современной науки и образования. Минск: БГУ, 2016. С. 837.

[3] Биктимирова Т.Ә. Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. Казан: Печатный двор, 2002. Б. 65.

[4] Иванов А.Е. Российское студенческое зарубежье: конец XIX – начало XX вв. URL: http://vivovoco.astronet.ru/VV/PAPERS/HISTORY/IVANOV.HTM (дата обращения: 10.10.2022)

Россиядән килеп белем алучы хатын-кыз булган[5]. Тырышып укуның нәтиҗәләре дә куанычлы булган – алар дипломнар алганнар. Ләкин, шуңа да карамастан, аларның күбесе Россиягә кайткач әлеге документлары нигезендә фәнни һәм педагогик эшчәнлекләрен дәвам итә алмаган. Моның өчен ханымнарга белемнәрен раслап, кабат имтиханнар тапшырырга һәм Россия уку йортларының дипломнарын алырга туры килгән. Атаклы Сорбонна университетын тәмамлап кайткан Сара Шакулова, 1914 елда Мәскәү университетының математика фәннәре бүлегендә имтихан тапшырып, II дәрәҗә дипломга лаек була, тик ул әлеге документын бары тик 1915 елның 23 июлендә генә ала алган[6].



*Сара Шакулова*

XX гасыр башында татар кызлары арасында да чит мәмләкәтләргә барып белем алу күренеше гайре табигый хәл саналмый башлый. 1912 елда «Вакыт» газетасы шушы елда Эсвичрәдә (Швейцариядә) университетның медицина факультетын тәмамлап, докторлык шәһадәтнамәсе алган татар кызы Габдрахманова турында язып чыга. Анда шулай ук берничә айдан шушы ук уку йортын тәмамлап, имтиханнар бирергә әзерләнгән Сыртланова[7] турында да хәбәр ителә. Язма авторы шундый белемле ханымнарыбызның барлыкка килүе милләтебезнең яшәүгә лаек булуын раслаучы күренеш дип саный: «Болар ватаннарына кайтып, милләттәшләре арасында хезмәт итәчәкләр. Болар кебек мөнәүвәр (нурлы, якты) калебле, мәгариф вә тәрбияле һәмширәләрен (кыз кардәшләрен) күргәндә никадәр татар кызларының йөрәкләре тибәчәк вә үзләре дә шулай булырга теләячәкләр»[8].

Европага барып укуның үз үзенчәлекләре һәм кыенлыклары була. Бу яктан караганда, Истанбул уку йортлары татар кызлары өчен уңайлырак була, шуңа да күпләрне җәлеп итә. Ташкент шәһәрендә яшәүче Мәликә Ибраһимованың «Вакыт» газетасына юлланган хатына караганда, татар кызлары

[5] Иванов А.Е. Студенчество России к. XIX – нач. XX в. Социально-историческая судьба. М.: РОССПЭН, 1999. С. 369.

[6] Мәхмүтова А. Вакыт инде: без дә торыйк... (Җәдидчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. Казан: Татар. кит.нәшр., 2012. Б. 117–118.

[7] Сүз Суфия Сыртланова һәм Мәрьям Габдрахманова хакында бара (Женевада мөселман шәкертләре // Вакыт. 1912. 24 август).

[8] Кырымлы С.Я. Чәләби. [Быел Эсвичрә дарелфөнүнендә...] // Вакыт. 1912. 6 март.

Истанбулда югары медицина, педагогик белем алу мөмкинлекләре, аларда телләр укытылу мәсьәләләре белән кызыксынганнар. Истанбулдагы дарелмөгаллимат идарәсеннән алынган җавапларга нигезләнеп, 1910 елда Истанбулда кызлар өчен махсус тыйббия һәм педагогик курслар булмый, ләкин дарелмөгаллимат һәм кул эшләренә өйрәтү өчен сәнәгать мәктәпләре эшләп килә дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Димәк, әлеге уку йортларына укырга керү мәсьәләсен карарга мөмкин булачак[9].

Бу чорда хатын-кызлар өчен Истанбул университетына керү мөмкинлеге булган. Т.Биктимерова мәгълүматларына караганда, танылган педагог һәм дин эшлеклесе Салихҗан хәзрәт Галиевнең кызы 15 яшьлек Әминә (1893–1918), олыларның хуплап бетермәүләренә дә карамастан, әтисе артыннан Вологдага сөргенгә китә. Россия мөселманнарының бердәм таләбе нәтиҗәсендә, хөкүмәт шул ук елны сәяси тоткыннарга ташлама ясый һәм чит илгә китәргә рөхсәт бирә. 1908 елның сентябрендә Салихҗан хәзрәткә Истанбулга китәргә мөмкинлек тугач, аның кызы Әминә дә әтисе белән барырга карар кыла. Төркиядә кыз атаклы шәйхелислам Касыйм хәзрәтнең кызы Хөсния ханымнан хәзерлек дәресләре алып, университет каршында оештырылган «Аналар мәктәбе»ндә укый, алай гына да түгел, югары белем алу максаты белән Истанбул дарелфөнүненә дә керә. Әминә Галиева гуманитар фәннәрне, аеруча борынгы тарихны өйрәнүгә зур басым ясый, Кубрат хан хәзинәләре белән кызыксына, туган илгә кайткач, музей ачу уе белән яна. Тик, кызганыч, кызга укуын тәмамларга насыйп булмый, Балкан сугышы башлангач, Истанбулга юллар ябыла һәм туган шәһәренә каникулга кайткан Әминә кабат Төркиягә китә алмый. Ул Казандагы Шумкова гимназиясенә йөреп, ашчылык курсларын тәмамлый. 1914 елда шәһәрдә кызлар өчен коммерция мәктәбе ачылгач, Әминә анда дин дәресләре алып бара[10], Л.Хөсәения мәктәбендә ана теле укыта.

Тагын бер татар кызы – Зәйтүнә Мәүлүдова (Рәсүлева) әле Буби мәктәбендә укыганда ук Истанбулда белем алу турында хыяллана. 1914 елда хаҗ сәфәрендә вакытта гаиләсе белән Истанбулда бүленеп калгач, ул укырга керү турындагы хыялларын тормышка ашыру өчен тырыша башлый: андагы уку йортлары, уку программалары, укыту ысуллары белән таныша. Аңа Йосыф Акчура булыша. Ләкин, кызганыч, акча булмау сәбәпле бу хыял тормышка ашмый кала. Шулай да ул 1915 елда университетта ирекле тыңлаучы буларак лекцияләргә йөри. Соңыннан аңа Сатигъ бәк мәктәбенә керергә мөмкинлек туа (бу вакытта анда икенче бер татар кызы Гадилә ханым да укый), ләкин Зәйтүнә ханым аның хыялларына туры килгән мәктәптән ераклыгын күрә: бу бөтенләй дә Европа тибындагы мәктәп булмый һәм анда табигать фәннәрен укытуга игътибар бирелми. Чыгарылыш имтиханнарын тапшырганнан соң,

[9] Укучыларның сөальләренә җаваплар // Вакыт. 1910. 24 октябрь.
[10] Биктимирова Т. Әминә туташ // Сөембикә. 2006. №7. Б. 10–11.

аны Бәйрутка мөгаллимә итеп билгелиләр. Тик Россиягә кире кайту мөмкинлеге туа, һәм алар гаиләләре белән кайтып китәләр[11]. Гайшә Рәсүлева исә Истанбулдагы Солтания мәктәбендә укый, ахырдан хатын-кыз укытучылар мәктәбенең бишенче курсына күчә[12].

Революциядән соңгы чорда чит илләрдә укучы хатын-кызларның сафын нигездә мөһаҗирләр тәшкил итә. Шулай ук аерым программалар нигезендә укырга җибәрелгәннәр дә була. Шундыйларның берсе Зөһрә Кошай 20нче елларда Дрезденда педагогия факультетын тәмамлаган[13], ә Фәүзия Ибраһимова Берлин университетында белем алган[14].

XX гасыр башында чит мәмләкәтләрдә гыйлем алган татар кызлары үзләренең алган белемнәрен халыкка хезмәткә багышлаганнар, ватан, милләт мәнфәгатьләрен кайгыртып, иҗтимагый тормыш эчендә кайнаганнар, һөнәри төрле өлкәләрдә үзләрен танытканнар.



*Зәйтүнә Мәүлүдова*

## *Сара Шакулова*

Франциядәге атаклы Сорбонна университетының механика-математика факультетында белем алган татар кызы Сара Шакулова хакында фәнни әдәбиятта шактый сөйләнелсә дә, бу урында аны аерым искә алып үтмәү дөрес булмас, мөгаен. Чөнки ул чит мәмләкәтләрдә белем алган иң тырыш һәм сәләтле татар кызларының берсе һәм беренчесе була.

Сара Шакулова 1887 елның 3 июлендә Рязань губернасы Касыйм шәһәрендә тамырлары белән Мөхәммәд пәйгамбәргә барып тоташкан сәед Шакуловлар гаиләсендә дөньяга килә. Татарбай (Торбаево) авылында җәдиди

[11] Расих А. Внук ишана. Казань: Татар.кн.изд-во, 2016. С. 233–234, 240, 244.
[12] Шунда ук. Б. 240.
[13] Искәрмәләр һәм аңлатмалар // Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. Казан: Татар. кит.нәшр., 2013. Т. 14. Б. 428.
[14] Ибраһимова Ф. Мастер кулинарии: подарок для дам = Аш остасы: ханымнарга һәдия. Казан: Изд-во «Познание» Казанского инновационного университета, 2017. Б. 7.

мәктәптә укыган чорда ул туган телен бик яхшы өйрәнә һәм ислам дине нигезләре буенча тирәнтен тәрбия ала. 1897 елда Касыйм шәһәрендәге хатын-кызлар гимназиясенә укырга керә, 1905 елда аны алтын медаль белән тәмамлап укуын дәвам итү теләге белән Петербургга килә. П.Лесгафт тарафыннан оештырылган югары физик тәрбия курсларына кереп укый башлый[15]. Тик 1907 елда курслар рәсми рәвештә ябыла, анда укучылар «ышанычсыз» дип табыла, шулай да кызлар 1909 елга кадәр белем алуларын дәвам итәләр әле[16]. Сара Шакулова башка югары курсларга керергә тырышып караса да, бу мөмкин булмый. Шул сәбәпле кыз белем алуын чит илдә дәвам итәргә карар кыла һәм Париж шәһәренә юл ала. Максаты – дөньядагы иң мәртәбәле уку йортларының берсе булган Сорбонна университетына керү була.

Бу вакытта Франциядә хатын-кызларны ир-атлар белән бер үк дәрәҗәдә ирекле тыңлаучылар буларак университетларга алганнар. Алар арасында чит илләрдән, аеруча Россиядән килгән хатын-кызлар күп була. Парижда 1910 нчы елларда 1200 россияле югары белем үзләштергән. Биш факультетны берләштергән Париж университетының табигать фәннәре-математика һәм тел (филология) факультетлары Сорбоннада урнашкан була[17].

Россиялеләр үз иткән Сорбонна университетында ир-атлар белән бергә хатын-кызлар да укыган. Укырга керү өчен урта белем мәктәпләре аттестаты (бакалавр дипломы яки гимназия тәмамлау хакындагы документ) һәм туу турында таныклык (метрика кәгазе) таләп ителгән. Университетның бер факультетына кергән студент, теләге булган очракта, башка факультетка да язылa алган[18]. Физика-математика факультетын тәмамлаучыларга магистр яисә доктор дәрәҗәсе бирелгән[19].

1913 елда Сара Шакулова укуын тәмам итеп, 19 мартта әлеге уку йортын тәмамлау турында Француз республикасының мәгариф министры тарафыннан бирелгән 1098 номерлы дипломына ия була. Ләкин ул Париждан, әлеге төп дипломыннан тыш, тагын берничә документ алып кайта: 1911 елның 30 октябрендә Париж фәннәр факультетының Югары белем турындагы шәһадәтнамәсен (физика факультетының (анализ һәм механика) сынау комиссиясе-тарафыннан бирелә), шулай ук Париж университетының эксперименталь физика факультеты каршындагы махсус комиссиянең 1912 елның 31 октябрендә

---

[15] Татар педагогик фикере антологиясе. Ике томда. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 160.

[16] Мәхмүтова А.Х. Вакыт инде: без дә торыйк... (Җәдтдчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу). Казан: Татар.кит.нәшр., 2012. Б. 115.

[17] Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 182–183, 193.

[18] Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915. С. 189, 193.

[19] Шунда ук. С. 185.

биргән Югары белем турындагы дипломын, 1912 елның 26 июнендә математика фәннәре факультетының рациональ механика буенча зачетны «бик яхшы» билгесенә бирүе хакындагы таныклыгын алуга ирешә[20]. Бу документларга нигезләнеп, 1913 елның 10 мартында Сара Шакуловага «механика профессоры» дигән гыйльми дәрәҗә бирелә[21].



*С.Шакулова Лесгафт курсларында укыган иптәш кызлары белән. 1908 ел*

Шулай итеп, Франциядә укуын тәмамлап, С.Шакулова Россиягә кайта. Тик аның Европаның иң абруйлы уку йортларының берсендә алган бу документлары зур көчкә ия була алмый. Ватанында эшне башлап җибәрер өчен ул үзенең белем дәрәҗәсен Россиядәге югары уку йортларының берсендә расларга тиеш була. 1913 елда Шакулова Мәскәү университеты каршындагы физика-математика имтиханнар комиссиясенә кертүләрен сорап, Халык мәгарифе министрлыгына мөрәҗәгать итә. Рөхсәт 1914 елның язында гына бирелә. Ә диплом алу бәхетенә фәннәр докторы 1915 елда ия була.

[20] Абзалина Р. Первая татарская женщина математик. URL: https://dzen.ru/a/Yy2du5jbkAUxQsw9?sid=138152194910081923 (дата обращения: 05.04.2023).

[21] Мәхмүтова А. Вакыт инде без дә торыйк... (Җәдидчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 117.


RÉPUBLIQUE FRANÇAISE.

Diplôme de Licencié ès Sciences.

Le Ministre de l'Instruction publique,

Vu les trois Certificats d'études supérieures accordés au Sieur Mlle Chacouloff, Sarah née à Kassimov, département d' (Russie), le 3 Juillet 1887,

Savoir : 1er Certificat de ..., obtenu le 23 octobre 1911, devant la Faculté de Paris,
2e Certificat de ..., obtenu le 26 Juin 1912, devant la Faculté de Paris,
3e Certificat de ..., obtenu le 29 octobre 1912, devant la Faculté de Paris,

Vu le visa donné à ces certificats par l'Autorité académique,

Donne, par les présentes, audit Sieur Mlle Chacouloff le Diplôme de Licencié ès Sciences, pour en jouir avec les droits et prérogatives qui y sont attachés par les lois, décrets et règlements.

Le Ministre de l'Instruction publique,

Fait à Paris, le 10 Mars 1913

*Сара Шакулованың дипломы*

Шуңа да карамастан, хәтта Мәскәү университеты дипломы да яшь белгечкә фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирми. Аның хатын-кыз өммәтеннән («Фән белән шөгыльләнү ир-атлар эше») һәм мөселман динендә булуы эшендә каршылыклар тудыра. С.Шакулова туган төбәгенә кайтып, Зарайск реаль училищесына эшкә урнаша[22]. 1916 елда ул Казанга килә, Парижда танышкан дусты, Казан кызы Надежда Сапожникованың танышы рәссам Николай Фешин аша Казан сәнгать училищесына геометрия һәм сызым укытучысы булып эшкә урнаша. Шул ук елны Шакулова Ф.Аитованың кызлар гимназиясендә һәм Л.Хөсәениянең кызлар мәктәбендә геометрия укыта башлый.

1917 елда педагог урта мәктәпләрдә математика укытучысы таныклыгына ия була. Ни гомер вакытын Франция университетларында уздырып алган профессор дипломының бер дә кирәге чыкмый. Аннан соңгы эшчәнлеге урта һәм югары мәктәпләр, Башкортстан АССР халык мәгариф коми-

[22] Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. Б. 365.

теты, РСФСР халык мәгарифе комитетының милли мәктәпләр бүлеге белән бәйле була. Моннан тыш, ул методик эш белән дә шөгыльләнә – татар мәктәпләре өчен кулланмалар, мәкаләләр язып бастыра. Шулай итеп, Сорбоннада югары белем алган беренче татар кызы милләте һәм ватаны алдындагы бурычын тулаем үтәгән.

## *Фәүзия Ибраһим*

Фәүзия Ибраһимова 1309 ел һиҗри 2 нче мөхәррәм аенда (1891 елның 26 июлендә) Тара шәһәрендә танылган дин галиме, җәмәгать эшлеклесе Габдрәшит Ибраһимов гаиләсендә дөньяга килә[23]. Гаиләсе белән бергә, Петербургны калдырып, чит илгә китәргә мәҗбүр була[24]. Шуннан соңгы тормышы нигездә Төркия мәмләкәте белән бәйле булса да, үз гомерендә дөньяның күп илләрендә була. Кайбер мәгълүматларга караганда, Фәүзия Берлин университетында белем алган[25]. 1917 елда ул Берлин шәһәреннән Төркиягә күченеп килә, 1920 елда Топкапыда әтисе төзегән мәктәптә укыта һәм озак еллар дәвамында мөдирлек итә[26]. Татар вакытлы матбугат язмаларына нигезләнеп, Ф.Ибраһимованың 1913 елда Истанбулда кызлар өчен мәктәп ачуын күрергә мөмкин[27]. Үзенең билгеләвенчә, башлангыч, урта һәм хәзерлек сыйныфларыннан гыйбарәт булган әлеге мәктәпнең программасында, гомуми белемнән тыш, балалар тәрбиясе, мөгаллимәлек һәм хуҗалык эшләре, аш әзерләү, тегү һәм чигү кебек дәресләр каралган була[28].

Фәүзия Ибраһимова мөһаҗирлеккә кадәр үк үз ватанында ханымнар өчен атап язылган китаплар авторы буларак билгеле була. Аның 1909 елда Казан шәһәрендә дөнья күргән «Аш остасы. Ханымнарга һәдия» китабы[29] татарларны XX гасыр башы рус һәм Европа халыкларының аш пешерү

---

[23] Ибраһим Г. Бөгрәделек көндәлеге. Казан, 2013. Б. 169.

[24] Арул Аксой Н. Точка пересечения народов: Урало-Поволжье и пример изучения исторической судьбы урало-волжских народов с точки зрения интеллигенции: Абдуррашид Ибрагим, его семья и тоска по Родине // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2017. № 7. С. 224.

[25] Ибраһимова Ф. Мастер кулинарии: подарок для дам = Аш остасы: ханымнарга һәдия. Казан: Изд-во «Познание» Казанского инновационного университета, 2017. Б. 7; Хайрутдинов А.Г. Общественная деятельность Фаузии Ибрагимовой. Minbar. Islamic Studies. 2022. №15(2). С. 306–307.

[26] Arul Aksoy N. Abdürreşit İbrahim'in Kızı FevziyeAbdürreşit ve Asar-ı Nisvan Mecmuası // Japonya Seyyahı Abdürreşit İbrahim'in İzinde. İstanbul: Doğu Kütüphanesi, 2020. S. 128.

[27] Истанбулда кызлар мәктәбе // Мәктәп. 1913. №8. Б. 211.

[28] Габдрәшит Ф. Мөслимәләр өчен мәктәп // Шура. 1913. №15. Б. 3.

[29] Ибраһимова Ф. Аш остасы. Ханымнарга һәдия. Казан: Әхмәтгәрәй Хәсәни вә ширкәсе, 1909. 246 б.

традицияләре белән таныштыручы, ханымнарга тәгаенләнгән беренче татар китабы булып тора. Авторның 1911 басылып чыккан «Кер юу һәм аларны саклау» дигән китабы да[30] киң җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алына. Бу басмалар татар ханымнарының көндәлек тормышын җиңеләйтү, аларны хуҗалык эшләренең нечкәлекләре белән таныштыру максатыннан язылган[31]. Моннан тыш, ул дәреслек авторы да: 1918 елда Берлинда Фәүзия ханымның татарларны гарәп графикасы нигезендә укырга өйрәтү өчен «Әлифба» китабы басылып чыга[32], Төркиядә «Мәкятиб ибтидаиядә хисабның усулы тәгълим вә тәдрисе» дәреслеге дөнья күрә[33].

Фәүзия Ибраһимованың Төркиядәге эшчәнлеге журналистика белән бәйле. Ул беренчеләрдән булып төрек ханымнары өчен «Asar-i Nisvan» («Kadın Yazıları») журналын чыгара башлый. Басманың төп максаты хатын-кызларны укуга, белем алырга әзерләү һәм мәгърифәтле итүдән гыйбарәт була. Журналның дөньяга килүендә XX гасыр башы татар матбугатының йогынтысы булган дип уйларга тулы җирлек бар, чөнки Ф. Ибраһимова вакытлы матбугат белән яхшы таныш була, үзе дә «Сибирия», «Шура» кебек татар басмаларында хатын-кыз проблемаларын күтәргән саллы мәкаләләре белән чыгыш ясый. Нәтиҗәдә татар матбагачылык традицияләре, һәм, әлбәттә, гомумән төрки-мөселман ханымнары өчен уртак булган мәсьәләләр төрек журналларында да чагылыш таба. Фәүзия ханым татар җәмгыяте шартларында формалашкан матбагачылык моделен төрек мохитенә яраклаштырып кулланган, төрек хатын-кыз журналистикасын булдыруда татар халкының чагыштырмача яңа формалашкан гәзитчелек өлкәсендәге эш алымнарын файдаланган. Шуңа да төрек хатын-кыз басмала-




*Ф.Ибраһим, Шмельцер. Әлифба*

[30] Ибраһимова Ф. Кер юу һәм аларны саклау. Казан, 1911. 20 б.

[31] Бу хакта тулырак укыгыз: Мортазина Л.Р. Педагог, журналист һәм мәгърифәтче Фәүзия Габдрәшит кызы Ибраһим эшчәнлеге // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2022. № 1. С. 177–186.

[32] Ибраһим Ф.Г., Шмельцер. Әлифба. Берлин, 1918. 100 б.

[33] Хайрутдинов А.Г. Общественная деятельность Фаузии Ибрагимовой // Minbar. Islamic Studies. 2022. №15(2). С. 315.

рының барлыкка килүендә XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты һәм татар кызы Фәүзия Ибраһимова хәлиткеч роль уйнаган дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

Ф.Ибраһимова туган теленнән тыш, төрек, француз, рус һәм инглиз телләрен (һәм, мөгаен, гарәп телен дә, чөнки ике дистә елга якын Каһирәдә яши) бик яхшы белгән. Әлеге белемнәрен ул дини-мәдәни мирасны саклау һәм таныту максатында уңышлы файдаланган, инглиз һәм француз телләрендә балалар өчен Мөхәммәд пәйгамбәр тормышын сурәтләгән китапчыклар язган[34]. Ләкин нинди телдә язса һәм сөйләшсә дә, ул ватаннан читтә яшәп, югары белем алып, миллилекне, татар халкының гореф-гадәтләрен, тел һәм мәдәни традицияләрен саклап кала алган.

* * *

Ватаннан читтә белем алуның матди үзенчәлекләре татар шәкертләренә акчалата булышлык күрсәтүне максат иткән хәйрия җәмгыятьләре һәм аерым шәхесләр, шулай ук шәкертләрнең үзләре белем алган илләрдә, уку йортларында төзегән махсус оешмалары – шәкертләргә ярдәм җәмгыятьләре эшчәнлеге белән билгеләнә. Соңгылары вакытлыча чит кыйтгаларда яшәүче татар егетләренә рухи һәм мәгълүмати ярдәм итүне дә күздә тотканнар, яңа шартларга күнегергә булышлык иткәннәр. Бу очракта татар шәкертләренең чит мәмләкәтләрдә укуын, яшәвен тәэмин итүче, шактый җайлы эшләп килүче тулы механизм турында сүз алып барырга мөмкин.

Ватаннан читтә гыйлем эстәү, гомумән югары белем алу татар хатын-кызлары өчен гайре табигый хәл саналса да, XX гасыр башында чит кыйтгаларга чыгып белем эстәүчеләр күренгәли башлый. Алар гыйлем үзләштерүдә ир-атлардан калышмаганнар, фәнни эзләнүләр алып барганнар, ватаннарына югары уку йортларын тәмамлау турындагы шәһадәтнамәләр белән кайтканнар, авырлыкларга карамыйча, алга барырга, милләте һәм халкы алдындагы изге бурычларын үтәргә тырышканнар. Татар кызларының да төп максаты – нигезле, төпле гыйлемнәр үзләштереп, ил, милләт файдасына хезмәт итүдән гыйбарәт булган. Һәм бу максатны алар тулаем үти алганнар.

[34] Хайрутдинов А.Г. Общественная деятельность Фаузии Ибрагимовой // Minbar. Islamic Studies. 2022. №15(2). С. 319.

# ЙОМГАК

Ватаннан читтә белем алу – татар мәгарифе үсешенең иң әһәмиятле үзенчәлекләренең берсе дияргә мөмкин. Күп гасырлык тарихка ия булган әлеге күренеш татар иҗтимагый һәм педагогик фикер үсешенә йогынты ясаган, милләтнең үсеш, алгарыш юнәлешләрен билгеләргә мөмкинлек биргән. Дагыстан, Урта Азия мәмләкәтләрендәге белем йортларында укыган татар яшьләре белән белем һәм мәгърифәт, уку-укыту тәртипләре һәм ысуллары, язма мирас, китаплар, яңа фикерләр ияреп кайткан. Идел-Урал буйларында яңа мәктәп-мәдрәсәләр ачылган, аларда Урта Азия, Дагыстан уку йортлары үрнәгендә белем бирелгән. Шул рәвешле, бу системалар Россиянең үзәк төбәкләренә үтеп кергән һәм ныклап урнашкан. XX гасыр ахырларына таба татарлар белем бирүдә заманчалык принцибына ачык булган Госманлы дәүләте илләренә – Төркия, Мисыр, Сүрия уку йортларына юнәлгәннәр. Шулай итеп, аларда укып кайткан шәкертләр белән яңа укыту алымнары, яңалыклар татар мәдрәсәләренә дә үтеп кергән, татар мәгариф системасын үзгәртеп коруга күпмедер дәрәҗәдә йогынты ясаган.

XIX–XX гасырлар чиге, башка бик күп милләтләр кебек, татарлар өчен дә уяну, алгарыш чоры була. Илдәге сәнәгать, авыл хуҗалыгы һ.б. өлкәләрдәге үзгәрешләр мәгариф системасы алдына да зур бурычлар куя, чөнки заманча белемнәр белән коралланганда гына яңа таләпләргә җавап бирерлек, конкурентлыкка ия белгечләр булырга мөмкин. Татар яшьләре дөньяви белем артыннан Төркия, Франция, Швейцария, Германия, Америка, Япония кебек илләрдәге югары уку йортларына юнәләләр.

Төрек уку йортлары башка илләрдә дөньяви белем алырга теләгән яшьләр өчен телләр өйрәнү буенча база ролен үтәгәннәр, чөнки аларда европа телләренә өйрәтү яхшы каралган була. Француз, инглиз телләренең башлангычларын үзләштергәннән соң, Европа, Америка һ.б. илләргә барып университетларга укырга керү мөмкин булган. Күп кенә татар яшьләре шул юлны үткәннәр.

Нәтиҗәдә алдынгы технологияләр, фәнни белемнәр белән коралланган яшьләр, дипломнар алып, ватаннарына кайтканнар һәм җәмгыятьнең алгарышында катнаша башлаганнар. Мәмләкәттән читтә дөньяви белем алып, ил, ватан алдында зур казанышларга ирешкән шәхесләр арасында совет фәне, мәгарифе үсешенә зур өлеш керткән Гаяз Максудовны, галим, нашир һәм педагог Фатих Кәримине, тау инженеры Искәндәр Рәмиевне, педагоглар Харис Фәйзи-Чистапулины, Габдулла Шнасины, Хәбиб Зәйнине, инженер Зыя Мөҗавирны һ.б.ларны атарга була.

Бу чорда хатын-кызлар арасында да ватаннан читтә белем алучылар күзәтелә. Шулар арасында иң мәгълүме – Сара Шакулова. Моннан тыш, татар вакытлы матбугаты мәгълүматларына таянып, Женевада укыган Мәрьям Габдрахманова һәм Суфия Сыртланова турында әйтергә мөмкин. С. Шакулова Сорбоннада укып югары белем диломы гына түгел, механика профессоры дигән гыйльми дәрәҗә дә алган ханым буларак татар тарихына кереп калды. Алар барысы да, укуларын тәмамлап, зур белемнәргә ия булып, газиз халкын һәм туган илен алга җибәрү, татар җәмгыятен үзгәртү, милли мәгариф системасын тамырыннан үзгәртеп кору, милләтнең якты киләчәген тәэмин итү уе белән рухланып кайтканнар.

Тик, кызганычка каршы, күбесенең тормышлары сикәлтәсез генә бармаган, чөнки чит илләрдә белем алган шәкертләргә карата ватанга кайтканнан соң да таләпләр катгый була. Мәдрәсәләрдә, татар мәктәпләрендә чит ил дипломнары белән эшләү мөмкинлеге булса да (Истанбулда укып кайткан Г.Шнаси, Х.Зәйни, Каһирәдә белем алган З.Камали «Галия» мәдрәсәсендә укыталар һ.б.), дәүләт оешмаларына керү өчен әлеге документлар кабул ителмәгән. Шул сәбәпле ватаннан читтә белем алган татар яшьләре күп очракта үзләренең дипломнарын кабат якларга, Мәскәү уку йортларында имтиханнар бирергә мәҗбүр булганнар. Беренче бөтендөнья сугышы башлану белән укулары бүленеп, илгә әйләнеп кайтканнарга Россиядә укуларын дәвам итәргә мөмкинлек бирелмәгән.

Ватаннан читтә дини белем алган яшьләрнең, дөньяви белем эстәгән татар егет һәм кызларының күпчелеге туган илебезгә кайтып, иле һәм халкы файдасына хезмәт итә алганнар, үз алларына һәм милләте алдына куйган олуг бурычларын фидакарьләрчә үтәгәннәр.

# ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ ӘДӘБИЯТ

## Архив документлары

### Татарстан Республикасы Дәүләт архивы (ТР ДА)<br>Государственный архив Республики Татарстан (ГА РТ)

Ф. 1. Канцелярия казанского губернатора.
Ф. 92. Попечитель Казанского учебного округа.

### Россия дәүләт тарих архивы (РДТА)<br>Российский государственный исторический архив (РГИА)

Ф. 821. Департамент духовных дел иностранных исповеданий Министерства внутренних дел.

### КФУның Н.Лобачевский исем. фәнни китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге (КФУ КСКБ)<br>Отдел рукописей и редких книг Научной библиотеки им. Н.Лобачевского КФУ (ОРКК КФУ)

Фонд 2. Харис Фәйзи:
С.б. 1. Х.Фәйзи. тәрҗемәи хәл. 1927.
С.б. 2. Х.Фәйзи. «Тәрҗемәи хәлгә кагылышлы язмалар». [1914]–1919.
С.б. 3. Харис Фәйзи. Тормыш язмалары. 1924.
С.б. 4. Куен дәфтәре. 1899 – (?).
С.б. 13. Истанбулда «Госмания» мәдрәсәсен тәмамлау турында Әхмәдхарис Фәйзигә бирелгән шәһадәтнамә.
С.б. 15. 1899 елда Харис Фәйзинең Мәскәүдә бухгалтерлык курсын бетерүе турындагы таныклык.
С.б. 46. Х.Фәйзи. Истанбул. 1895 ел.

Фонд 6. Альберт Фәтхи:
38 с.б. Бохарадагы татар шәкертләре.
103т. Каюм Насыйри. Некролог яки кыскача сәйр.
2390-т. Хабиб Зайни. Автобиография.
2501 т. Һади Мәхмүт Бөдәйли. Татар әдәбиятында кулланылган псевдонимнар.
3598 т. Шам Шәрифнең истәлекле урыннарын күрсәтә торган рисалә (сәяхәтчеләргә юл күрсәткеч). 1900 еллар.
2392 т. Сабир Алимов. Каһирә. Якынча 1908 ел.

## БАСМА ЧЫГАНАКЛАР
### Татар телендә


1. Америкада бер татар шәкерте // Вакыт. 1912. 27 май.
2. Америкада татар шәкерте. Закир Габдуллин // Вакыт. 1914. 11 февраль.
3. Америкада татар шәкертләре // Вакыт. 1914. 9 май.
4. Америкада татар шәкертләре // Вакыт. 1915. 23 сентябрь.
5. Әл-Идриси Г. Мәрхүм солтан Габделгазизнең углы шаһзадә Габделмәҗид әфәнде илә мөлякәт // Вакыт. 1911. 20 гыйнвар.
6. Әл-Идриси Г. Эсвичрәдә чит мәмләкәт шәкертләре // Вакыт. 1914. 20 март.
7. Әл-Идриси. Истанбулдан Лозанга // Вакыт. 1914. 23 гыйнвар.
8. Әл-Идриси. Эсвичрә мәктүбләре // Вакыт. 1914. 30 гыйнвар.
9. Әл-Мәгади Г. Мәдинә Мөнәүвәрәдән мәктүб // Дин вә мәгыйшәт. 1911. № 7. С. 108.
10. Әнвәри Ф. Зайсаннан мәктүб // Йолдыз. 1906. 11 ноябрь.
11. Әнвәров Ф. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1914. 21 ноябрь.
12. Әнвәров Ф. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1914. 8 ноябрь
13. Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1914. №22. Б. 697–699.
14. Әнвәров Ф.Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1915. №2. Б. 54–56.
15. Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1911. 11 сентябрь.
16. Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1912. 9 март.
17. Байбулатов Х. Америка мәктүбләре // Сибирия. 1912. 10 март.
18. Байбулатов Х. Америка мәктүбләре // Сибирия. 1912. 13 май.
19. Байбулатов Х. Америка мәктүбләре // Сибирия. 1913. 6 гыйнвар.
20. Байбулатов Х. Америка мәктүбләре // Сибирия. 1913. 6 февраль.
21. Байбулатов Х. Америкадан // Тормыш. 1914. 18 гыйнвар.
22. Байбулатов Х. Америкадан // Тормыш. 1914. 21 гыйнвар.
23. Баруди Г. Иман шарты // Әд-дин вәл-әдәп. 1906. № 10. Б. 317–318.
24. Бәйрутта татар таләбәсе // Вакыт. 1914. 22 гыйнвар.
25. Бәкер М. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Йолдыз. 1910. 4 май.
26. Бәлҗика // Вакыт. 1914. 14 февраль.
27. Берндә русияле студентлар съезды // Вакыт. 1914. 17 май.
28. Бохараи шәрифтә дәрес ысулы // Өлфәт. 1906. 6 апрель.
29. Бубый Г. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Бәянелхак. 1906. 17 май.
30. Бубый Г. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Бәянелхак. 1906. 10 август.
31. Бубый Г. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Казан мөхбире. 1906. 6 март.
32. Бубый Г. Мәдинәдә Казан мәдрәсәсе // Казан мөхбире. 1906. 12 март.
33. Габдрәшит Ибраһим. Бөгрәделек көндәлеге. Казан, 2013. 190 б.
34. Габдрәшит Фәүзия. Мөслимәләр өчен мәктәп // Шура. 1913. №15. Б. 3.
35. Габдулла Тимер // Яңа милли юл. 1932. №9. Б. 25.
36. Габдуллин З. Америка мәктүбләре // Вакыт. 1913. 25 октябрь.
37. Габдуллин З. Америка мәктүбләре (Америкада әҗнәби мәмләкәт таләбәләре) // Вакыт. 1914. 11 февраль.
38. Гм. Истанбул хатирәләре // Кояш. 1913. 15 гыйнвар.

39. Гобәйдулла углы Габдулла. Олуг галимебез шәех әл-Мәрҗани хәзрәтләре хакында хатирәләрем // Мәрҗани: Шиһабетдин әл-Мәрҗанин хәзрәтләренең вилядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәте илә нәшер ителде. Казан: «Мәгариф» матб., 1915. Б. 528–530.

40. Гыйлем һәвәслеләрнең дикъкатенә // Вакыт. 1911. 19 август.

41. Давлетшин А. Отчет штабс-капитана Давлетшина о командировке в Хиджаз. СПб.: Военная типография, 1899. 145 с.

42. Дахили хәбәрләр // Йолдыз. 1913. 1 август.

43. [Дәр сәгадәт мәктәп галиясендә ...] // Өлфәт. 1906. 13 апрель.

44. Женевада мөселман шәкертләре // Вакыт. 1912. 24 август.

45. Җанкүз Х. Мәккәи Мөкәррәмәдән мәктүб // Йолдыз. 1910. 17 гыйнвар.

46. Заграницада рус шәкертләре // Вакыт. 1907. 20 февраль.

47. Ибраһим М. Ингелтерә вә галәм ислам яки куркулы төш // Сибирия. 1912. 28 ноябрь.

48. Ибраһим Ф.Г., Шмельцер. Әлифба. Берлин, 1918. 100 б.

49. Ибраһимов Ә.-М. Япония җәмгыяте исламиядән // Вакыт. 1914. 10 июль.

50. Ибраһимов Г. Ислам дөньясы // Безнең мирас. 2017. №3. Б. 52–53.

51. Ибраһимов Г. Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр // Йолдыз. 1915. 29 апрель.

52. Ибраһимова Ф. Аш остасы. Ханымнарга һәдия. Казан: Әхмәтгәрәй Хәсәни вә ширкәсе, 1909. 246 б.

53. Ибраһимова Ф. Кер юу һәм аларны саклау. Казан, 1911. 20 б.

54. Идарәгә килгән мәктүбләр // Йолдыз. 1910. 17 гыйнвар.

55. Идарәгә мәктүб // Йолдыз. 1909. 6 сентябрь.

56. Идарәгә мәктүб. Бохара шәрифтән // Бәянелхак. 1906. 8 май.

57. Идарәгә хат // Йолдыз. 1910. 2 май.

58. Идриси Г. Истанбулдан Лозанга // Вакыт. 1915. 25 гыйнвар.

59. Ислам галәменнән // Йолдыз. 1910. 19 гыйнвар.

60. Истанбул дарелфөнүне // Вакыт. 1911. 9 июнь.

61. Истанбул мәктәпләре // Вакыт. 1908. 11 декабрь.

62. Истанбулда «Нәшре мәгариф җәмгыять хәйриясе» // Вакыт. 1908. 11 декабрь.

63. Истанбулда гали мәктәпләр // Вакыт. 1906. 20 июнь.

64. Истанбулда кызлар мәктәбе // Мәктәп. 1913. №8. Б. 211.

65. Истанбулда русияле татар шәкертләре // Йолдыз. 1908. 7 декабрь.

66. Истанбулда татар шәкертләре // Әл-Ислах. 1908. №43. Б. 9.

67. Кадермәти М.Й. Хвалында мәдрәсәи галия // Вакыт. 1906. 21 ноябрь.

68. Казандагы гарәби хәрефле матбага // Шура. 1908. № 17. Б. 525–527.

69. Камал Г. Истанбул мәктүпләре // Йолдыз. 1912. 16 декабрь.

70. Камал Г. Истанбул мәктүпләре // Йолдыз. 1912. 18 декабрь.

71. Камал Г. Истанбул мәктүпләре // Йолдыз. 1912. 29 декабрь.

72. Камал Г. Мәдрәсәи Галия // Йолдыз. 1907. 26 август.

73. Камал Г. Мөселман студентларымыз // Йолдыз. 1910. 10 март.

74. Камал Г. Тел берләштерәләр // Яшен. 1908. 3 август.

75. Камал Г. Төркия мәктүбләре // Казан утлары. 1999. № 4. Б. 166–179.

76. Камал. Гарәп мохитендә татар туе // Вакыт. 1914. 1 июнь.

77. Камали З. Мәктүбләр // Нур. 1906. 13 апрель.

78. Каһирә. Татар таләбәсе җәмгыяте // Өлфәт. 1906. 26 июнь.

79. Кәрими Ф. Истанбул мәктүбләре. Оренбург, 1914. 450 б.

80. Кырымлы С.Я.Чәләби. [Быел Эсвичрә дарелфөнүнендә...] // Вакыт. 1912. 6 март.

81. Лейпцигта мөселман тиҗарәт конторы // Вакыт. 1912. 27 апрель.

82. Льеж студентлары // Йолдыз. 1914. 3 сентябрь.

83. Льеж шәһәрендә бер мөселман гөруһы // Вакыт. 1914. 1 август.

84. Льеждагы мөселман студентлары // Вакыт. 1914. 27 август.

85. М.-Х. Истанбулдан мәктүб // Кояш. 1914. 11 июль.

86. М.-Х. Тыйббия мәктәбе // Кояш. 1914. 17 август.

87. Мангушев Т. [«Казан мөхбире»нең ...] // Бәянелхак. 1906. 19 апрель.

88. Мәдинә шәһәрендәге «Казани» мәдрәсәсе шәкерте Мөхәммәдфатыйх Җиһангир улыннан Гариф муллага хат // Алдым каләм, яздым сәлам...: хатлар / төз. Р.Ф.Мәрданов. Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2018. 180 б.

89. Мәдинәи Мөнәүвәрә шәкертләре // Йолдыз. 1907. 15 март.

90. Мәдинәи Мөнәүвәрәдә казанлы таләбәсенең гыйльмиясе // Йолдыз. 1909. 7 сентябрь.

91. Мәдинәи Мөнәүвәрәдә татар мәдрәсәсе // Өлфәт. 1906. 25 октябрь.

92. Мәккәи Мөкәррәмәдә «Русияле ислам таләбәсенең җәмгыять гыйльмиясе» // Шура. 1910. №6. Б. 191 –192.

93. Мәккәи Мөкәррәмәдә русияле ислам таләбәсенең җәмгыять гыйльмиясе тарафыннан игъланнамә // Вакыт. 1910. 28 август.

94. Мәңгәрле Зыяэтдин әл-Камали. Мәдинәи Мөнәүвәрә вә мөҗавирлар // Нур. 1906. 17 апрель.

95. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 415 б.

96. Мәрҗани: Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вилаятенә йөз ел булу (1233–1333) мөнәсәбәте илә нәшер ителде. Казан: «Мәгариф», 1915. 639 б.

97. Мөхбир. Кабул ителмәү // Вакыт. 1914. 3 сентябрь.

98. Мисыр әл-Каһирәдә әл-Әзһәр // Шура. 1908. №4. Б. 114–116.

99. Мисыр әл-Каһирәдә әл-Әзһәр // Шура. 1908. №6. Б. 168–171.

100. Мисыр әл-Каһирәдә әл-Әзһәр // Шура. 1908. №7. Б. 200–202.

101. Мисырда. Татар таләбәсе җәмгыяте // Казан мөхбире. 1906. 9 апрель.

102. Мөҗавир З. Америкага барып уку юллары // Вакыт. 1915. 3 сентябрь.

103. Мөҗавир З. Америка хәяты (Шимали Америкада, Вальпараисода) // Вакыт. 1915. 4 апрель.

104. Мөҗавир З. Европадан Америкага // Вакыт. 1915. 11 март.

105. Мөхбир. Европада төрек-татар таләбәсе // Вакыт. 1914. 14 февраль.

106. Мөхбирләребездән // Вакыт. 1906. 20 июнь.

107. Мөхәммәд Бәркәтулла әфәнде // Вакыт. 1914. 19 август.

108. Насыйри З. Мәктәп кызларына уку. Кыз балаларына махсус ибтидаи сыйныфлар өчен тәртип ителде. Казан: Кәримов, 1911. 56 б.

109. Насыйри З. Хисап мөгаллиме. 1 кис. Ибтидаи мәктәпләрнең 1 сыйныфлары өчен. Казан:: Кәримов, 1908. 39 б.

110. Насыйри З. Истанбулдан. Читтә укучы шәкертләремез ни хәлдә? // Вакыт. 1914. 4 апрель.

111. Насыйри З. Истанбул мәктүбе // Йолдыз. 1914. 23 май.

112. Насыйри К. Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы // Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. 2 томда. Т.1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. Б. 48–58.

113. Оренбурглы мөселман студентлары кайда? // Кояш. 1914. 28 август.

114. Париж дарелфөнүнендә укучы әҗнәбиләр // Вакыт. 1911. 6 март.

115. Парижда мөселман укучылары // Вакыт. 1910. 14 гыйнвар.

116. Парижда татар шәкерте // Вакыт. 1906. 20 июль.

117. Рәсемдәге әфәнделәр // Сибирия. 1913. 26 июнь.

118. Рәшит Ә.-М. Японияда сәүдә эшләре // Икътисад. 1912. №1. Б. 10–13.

119. Рәшит Ә.-М. Японияда исламиятне кабул вә мәшрукъ хәбәрләре // Икътисад. 1912. №1. Б. 31–32.

120. Рәшит Ә.-М. Японияда таләбә тормышы // Вакыт. 1914. 21 май.

121. Русия вә Истанбул мәктәпләрендә укыту // Вакыт. 1909. 16 июнь.

122. Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Сәяхәтнамәләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Путешествия / төз.: А.Х.Алиева, Г.М.Ханнанова; текст., иск. һәм аңл. әзерл.: А.Х.Алиева, Г.М.Ханнанова; кереш сүз авт. А.Х.Алиева. Казан: ТӘһСИ, 2022. 300 б.

123. Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Псевдонимы в татарской литературе / редкол.: И.Г.Гомәров (проект җит. һәм җавап. мөх.), Ә.М.Закирҗанов, А.М. Ахунов; төз.: Л.Ш.Гарипова, Г.Н.Зәйниева. Казан: ТӘһСИ, 2021. 300 б.

124. Сакмарый. Бәйрутта беренче июль бәйрәме // Вакыт. 1911. 5 август.

125. Сакмарый. Җәмил бәк илә мөсахәбәт // Шура. 1913. № 22. Б. 690–692.

126. Сакмарый. Хәлеб хатирәләре // Шура. 1915. №№ 6–10, 21–23, 1916. №1–3, 5–10.

127. Сакмарый. Хәлеб хатирәләре // Шура. 1916. № 9. Б. 215–217.

128. Сакмарый. Шам хатирәте // Шура. 1913. № 18. Б. 551–553.

129. Сакмарый. Шам хатирәте // Шура. 1913. № 20. Б. 612–614.

130. Сакмарый. Шамнан Бәгальбәккә // Шура. 1914. № 20. Б. 612–615.

131. Сакмарый. Шамнан Бәгальбәккә // Шура. 1914. №21. Б. 644–647.

132. Сәйях. Сүрия әхвәле // Шура. 1913. №2. Б. 36–37.

133. Тәшәккер // Йолдыз. 1910. 13 апрель.

134. Тимербай. Вак-төяк тырышу // Йолдыз. 1906. 1 октябрь.

135. Тукаев М. Тарихы Эстәрлебаш // Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 2 нче кисәк. Казан, 2019. Б. 7–23.

136. Укучыларга ярдәм җәмгыяте // Вакыт. 1910. 6 март.

137. Укучыларның сөальләренә җаваплар // Вакыт. 1910. 24 октябрь.

138. Урманче Б. «Мөхәммәдия»// Безнең мирас. 2022. № 9. Б. 34–35.

139. Уфа хәбәрләре // Вакыт. 1910. 29 май.

140. Фәйзи Х. Садретдин бәйгә мөрәҗәгать // Өлфәт. 1906. 26 июнь.

141. Фәйзи Х. Башымнан узган эшләр (текстны басмага әзерләүче Р.Шәрәфиева) // Безнең мирас. 2024. №3. Б. 36–42; №5. Б. 20–24.

142. Фәхреддин Р. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. 360 б.

143. Фәхреддин Р. Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. 304 б.
144. Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. 638 б.
145. Фәхреддин Р. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре // Фәхреддин Ризаэддин. Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр: сайланма хезмәтләр. Казан: Рухият, 2011. Б. 153–207.
146. Фәхретдин Р. Без – шималь (Болгар) төрекләрендә гыйлем тәхсил итү рәвешләре // Фәхретдин Р. Болгар вә Казан төрекләре. Казан, 2021. Б. 296–303.
147. Фәхретдин Р. Гыйльми хәдистән көтебе ситтә вә мөәллифләре. Оренбург: Вакыт, 1910. 135 б.
148. Фәхретдин Р. Уфа шәһәрендә Губернский исполнительный комитетка сайланган котлуг татар егетләренә һәм, гомумән, бүген эш башында торучы иптәшкәләргә ачык мәктүб // Болгар вә Казан төрекләре. Казан: Татар.кит.нәшр., 2021. Б. 304–318.
149. Фәхретдин Р. Дини вә милли мәктәпләребез хакында // Шура. 1913. № 24. С. 737–740.
150. Фәхретдин Р. Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Гыйльме хәдистән / басмага әзерләүче А. Гайнетдинов. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019. 104 б.
151. Фәхретдин Р. Нәсихәт. Ялгыз кыз балалар өчен // Мәгариф. 1992. №6. Б. 53–54.
152. Хаҗилар вә татарталәбәләре // Вакыт. 1914. 4 октябрь.
153. Һиндыстанда татар таләбәсе җәмгыяте // Вакыт. 1914. 23 май.
154. Чәләби С.Я. Эсвичрәдә тәхсил // Вакыт. 1911. 23 сентябрь.
155. Чит мәмләкәтләрдә укыган студентлар // Вакыт. 1914. 1 октябрь.
156. Шәрекъ, гарәп галәме ...// Әл-ислах. 1908. № 39. Б. 8.
157. Шнаси Г.С. Мохтасар кимия.1 кис. Казан: «Юл» көтепханәсе, 1910. 170 б.
158. Юлдаш. Казанлы мәдрәсәсе // Вакыт. 1906. 17 октябрь.
159. Япония // Йолдыз. 1906. 5 апрель.
160. Япониядә инородецлар мәсьәләсе // Вакыт. 1914. 27 июнь.
161. Яурупага шәкертләр йибәрү // Вакыт. 1909. 29 гыйнвар.

## Рус телендә

1. Альмушев Х. Хадж-наме URL: https://idmedina.ru/books/history_culture/hadjj/1/almushev.htm (дата обращения: 11.11.2022).
2. Ахун Мансур ибн Абд ар-Рахман ибн Анас ал-Бурундуки. История Чингисхана / вступ. сл. Д. Мухетдинов; вст. ст., подготовка текста, указ. И.В. Зайцев. М.: Медина, 2018. 176 с.
3. Бустанов А.К. Библиотека Зайнап Максудовой = Зәйнәп Максудова китапханәсе. М., 2019. 463 с.
4. Ибрагимова Ф. Мастер кулинарии: подарок для дам = Аш остасы: ханымнарга һәдия. Казань: Изд-во «Познание» Казанского инновационного университета, 2017. 234 с.
5. Ислам в Японии // В мире мусульманства. 1911. №17 (19 августа).

6. Марджани Ш. Введение к библиографическому словарю «Верность предшественникам и приветствие потомкам» (Мукаддимат китаб Вафиййат аль-асляф ва тахиййат аль ахляф). Казань: Магариф-Вакыт, 2022. 360 с.

7. Марджани Ш. Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф-Вакыт, 2022. 856 с.

8. [Мы слышали, что...] // Тәрҗеман – Переводчик. 1901. 24 август.

9. Оренбургские студенты за границей // Оренбургская газета. 1914. 29 августа.

10. Расих А. Внук ишана. Казань: Татар.кн.изд-во, 2016. 271 с.

11. Рахманкулов А.В. Шейх Ахмат Хаджи Рахманкулов и его потомки // Хилял. 2011. №1.

12. Фахреддин Р. Кутуб ситта и их составители /Перевод, введение, примечания и комментарии Гатин Р.Н. М.: 2023. 311 с.

13. Хадж-наме. Книга о хадже. Путевые заметки /пер. со старотатарского А.М.Ахунова. Н.Новгород, 2006. 112 с.

## Чит телләрдә

1. Valparaiso University Bulletin. Forty-Second Annual Catalog 1915–1916. P.162.

2. Waseda, Japan`s Modern University // The American review of reviews. 1914. February. Pp. 231–233. URL: https://babel.hathitrust.org/cgi/pt?id=njp.32101076870607;view=1up;seq=247 (дата обращения: 11.03.2020).

3. Record Yearbook (Valparaiso, IN) – Class of 1923. P. 16–17.

4. Student Credits book of Valparaiso University. 1914–1915. Old School Ledgers p. 6. URL: collections.valpo.edu/cdm/compoundobject/collection/ledgers/id/9399

5. Torch. January 2, 1923.

6. Torch. January 9, 1923. № 15.

## СТАТИСТИК БАСМАЛАР ҺӘМ БЕЛЕШМӘЛЕКЛӘР

1. Альметьевская энциклопедия. URL: https://almet-history.tatneft.ru/personalii/z-l/k/kan-kar/karimi-fatih-gilmanovich?lang=ru (дата обращения: 12.04.2023).

2. Аюханов Закир Насырович // Энциклопедия Башкирии. URL: https://ufa-gid.com/encyclopedia/auhanov.html (дата обращения: 12.04. 2023)

3. Большой юридический словарь. Составители: А.Я. Сухарев, В.Е. Крутских, А.Я. Сухарева, 2003 год. URL: http://law.niv.ru/doc/dictionary/big-legal/index.htm (дата обращения: 13.05.2023).

4. Записки о Бухарском ханстве (Отчёты П.И. Демезона и И.В. Виткевича). М.: Наука, 1983. 143 с.

5. Ислам на Нижегородчине: энцикл. словарь / ред.-сост. Д.В. Мухетдинов. Н.Новгород: ИД «Медина», 2007. 207 с.

6. Ислам на Урале: энциклопедический словарь / Коллект. автор. Сост. и отв. редактор – Д.З. Хайретдинов. М.: Издательский дом «Медина», 2009. 404 с.

7. Марголин Д.С. Справочник по высшему образованию: руководство для поступающих в высшие учебные заведения за границей. Петроград; Киев, 1915.
8. Фархшатов Ф.М. Камали З. // Медресе Южного Урала и Приуралья: история и современность: Хрестоматия / сост. Т.М. Аминов Уфа: БГПУ; 2010. С. 293.
9. Татарская энциклопедия. В 6 т. Т. 4. Казань: ИТЭ, 2008. 768 с.
10. Татарская энциклопедия. В 6 т. Т. 6. Казань: ИТЭ, 2014. 720 с.
11. Татар энциклопедиясе. 6 томда. Т. 1. Казан: ТЭИ, 2008. 720 б.
12. Энциклопедический словарь «Ислам на Нижегородчине». URL: https://idmedina.ru/books/encyclopedia/?794 (дата обращения: 12.12. 2022).

## ӘДӘБИЯТ

### Татар телендә

1. Әмирхан Р. Иманга тугрылык. Казан: Татар.кит.нәшр., 1997. 384 б.
2. Әмирхан Р. Максатка тугры Максуди // Казан утлары. 1999. №5. Б. 151–156.
3. Әхмәтҗанов М. Әдип Ишнияз бине Ширнияз Хәрәзми (1725/(?)–1790/91) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2005. №1. Б. 79–87.
4. Батыршин Ф. Идел буенда тарикатьләр: тарихы һәм хәзерге заман. URL: https://dumrt.ru/help-info/theology/analytics_4709.html?curPos=20 (мөрәҗәгать итү датасы: 10.11.2022).
5. Баттал Г. Троицк байларындан вә хәйратларындан Габделвәли Яушев. Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1912. 17 б.
6. Биктимерова Т. Әминә туташ // Сөембикә. 2006. № 7. Б. 1011.
7. Биктимирова Т.Ә. Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. Казан: Печатный двор, 2002. 140 б.
8. Вәлиәхмәтов Х. Ислам галәменең казык йолдызы // Безнең мирас. 2017. № 3. Б. 16–20.
9. Габделбари Баттал Таймас. Мин бер яктылык эзләгән идем // Казан утлары. 1998. №5. Б. 144–169.
10. Гаффарова Ф.Ю. Садри Максуди (1906–1924 еллар). Казан: ДАС, 2001. 261 б.
11. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Алты томда: 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 431 б.
12. Габәши Х. Мәдрәсәләрдә дәрес укытылу тәртибе – программа хакында // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 607–616.
13. Гайнанова М. Низаметдин хәзрәт улы Садри Максуди: беренче адымнар // Садри Максуди: фәнни-популяр җыентык /Авт-төз. Гайнанова М.Р. Казан: «Җыен», 2023. Б. 19–24.
14. Гайнетдинов М. Г.Тукай һәм һинди Минһаҗ // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар: Г.Тукай тууына 125 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2011. Б.37–40.

15. Галләмова Ә.Г., Заһидуллин И.К., Фәхретдинов Р.Р. Татарстан һәм татар халкы тарихы. XIX гасыр–XX гасыр башы: 9 сыйныф: Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. Казан: Татар балалар нәшр., 2019. 96 б.

16. Гарифуллин Д. Алман җирендә «Татар иле» // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1996. № 1/2. Б. 221–225.

17. Гаффарова Ф. Хәмит Зөбәер Кошай (1897–1984) // Безнең мирас. 2016. №8. Б. 48–49.

18. Гаффарова Ф.Ю. Садри Максуди. Казан: ДАС, 2001. 261 б.

19. Гәрәева-Акчура А. Төркиянең беренче нефтьчесе – татар // Казан утлары. 2008. № 10. Б. 151–163.

20. Зиннәтуллина А.Ә. Дин һәм дәүләт эшлеклесе Мансур әл-Борындыкый // Фәнни Татарстан. 2020. №3. Б. 96–100.

21. Искәрмә һәм аңлатмалар // Габдулла Тукай. Әсәрләр. Алты томда: 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 291–429.

22. Искәрмәләр һәм аңлатмалар // Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. Казан: Татар.кит.нәшр., 2013.Т. 14. Б. 412–468.

23. Исхакый Г. Ислам мәмләкәтләрендә // Гаяз Исхакый. Сайланма әсәрләр. 15 томда. Т. 10. Б. 323–326.

24. Кәримуллин Ә. Америка татарлары тарихыннан // Казан утлары. 1990. №1. Б. 167–172.

25. Кылынч А. Идел-Урал татарларының Госманлы җирләренә XIX гасырның 70 нче елларына кадәрге күчешләре // Чын мирас. 2012. № 5–6. Б. 44–62.

26. Мәхмүтова А. Вакыт инде: без дә торыйк... (Җәдидчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2012. 365 б.

27. Мәһдиев М. Сызып ак нур белән. Казан: Татар.кит.нәшр., 2014. 583 б.

28. Мәһдиев М. Тарихи кыңгыравык (Бер гаҗәеп шәхес турында) // Мирас. 1992. № 8. Б. 80–83.

29. Миңнуллин Җ. Рухи мирасны барлаганда // Казан утлары. 1984. № 12. Б. 170–171.

30. Миңнуллин Җ.С. Аны Шәрык алкышлаган // Миңнуллин Җ.С. Мәкаләләр җыентыгы. Казан: Татар.кит.нәшр., 2023. Б. 197–199.

31. Мифтахова Н.Ш. Химия буенча татар телендәге беренче китаплар турында // Фәнни Татарстан. 2005. № 3/4. Б. 9–16.

32. Мортазина Л.Р. Педагог, журналист һәм мәгърифәтче Фәүзия Габдрәшит кызы Ибраһим эшчәнлеге // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2022. № 1. С. 177–186.

33. Мортазина Л. Татар шырпы заводлары // Безнең мирас. 2019. №9. Б. 20–23.

34. Мортазина Л. Шам татарлары // Безнең мирас. 2018. № 11. Б. 34–39.

35. Мортазина Л.Р. Хәбиб Зәйни хезмәтләрендә татар мәгарифе мәсьәләләре // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2020. № 1. Б. 146–158.

36. Мортазина Л.Р. Бәйрәкә авылында мәгариф тарихының кайбер сәхифәләре // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2021. №1. Б. 140–152.

37. Мөхәммәтшин З. Көньяк Урал татарлары XX гасыр башы матбугатында, шәҗәрәләрдә // Милли-мәдәни мирасыбыз: Чиләбе өлкәсе татарлары. 2 нче басма. Казан, 2021. Б. 388–405.

38. Расих А. Тыныч еллар күләгәсендә// Казан утлары. 1997. №1. Б. 9–86.

39. Рәми И. Мәдрәсәдән – университетка // Казан утлары. 1966. №3. Б. 131–135.

40. Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 399 б.
41. Согуд Гарәбстанындагы Пәйгамбәр мәчете янында татар җире табылды. URL: https://atnya-rt.ru/news/mgyiyat/sogud-garbstanyindagyi-pygambr-mchete-yanyinda-tat (мөрәҗәгать итү датасы: 12.11.2021)
42. Солтанбәков Б. Тапланмас исем // Казан утлары. 1996. № 5. Б. 159–164.
43. Татар педагогик фикере антологиясе. Ике томда. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 407 б.
44. Татар педагогик фикере антологиясе. Ике томда. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 486 б.
45. Татар педагогик фикере тарихы. Казан: ТФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты, 2017. 308 б.
46. Татар теле: үткәне һәм бүгенгесе / хезмәтне әзерләүчеләр: Р.Г. Галиуллин, Г.К. Һадиева. Казан, 2021. 72 б.
47. Тимергалин А.К. Миллият сүзлеге: өч томда. Т. 2. Казан: Татар.кит. нәшр., 2017. 684 б.
48. Төркуглы И. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы төрек-татар багланышлары // Чын мирас. 2013. № 2. Б. 5–19.
49. Хәмидуллин Л. Тарихта үз эзләре бар // Бертуган Рәмиевләр: Фәнни-биографик җыентык. Казан: Рухият, 2002. Б. 34–68.
50. Шәрәф З. Фатыйх Кәрими // Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык – Фатих Карими: Научно-биографический сборник. Казан: Рухият, 2000. Б. 74–111.
51. Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: «Җыен», 2010. Б. 16–194.
52. Яхин Ф.З. Татар дини китапларыннан – «Иман шарты» // Образование и право. 2022. № 8. С. 130–132.

### Рус телендә

1. Абзалина Р. Первая татарская женщина математик. URL: https://dzen.ru/a/Yy2du5jbkAUxQsw9?sid=67412101133068794 (дата обращения: 05.04.2023).
2. Абдуллин Я.Г. Татарская просветительская мысль (Социальная природа и основные проблемы). Казань: Татар.кн.изд-во, 1976. 320 с.
3. Абубакирова М., Шамсутдинов И., Хасанжанова Р. Историю оставить народу своему. Троицк, 2002. 176 с.
4. Алиханов М.М. Из истории отправки студентов за рубеж из Туркестана в начале XX века // Universum: общественные науки. 2023. №10. С. 8–10.
5. Алмазова Л.И. Зыяэтдин Камали – мыслитель, просветитель и религиозный деятель // Камали З.Д. Философия ислама: в 2 т. Казань: Татар. кн. изд-во, 2010. Т. 1. С. 9–57.
6. Амирханов Р.У. Некоторые особенности развития народного образования у татар в дооктябрьский период // Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. Казань, 1992. С. 22–60.
7. Амишов Р. Татарский богослов Нургали Хасанов. Казань: Изд-во «Магариф – Вакыт», 2022. 336 с.

8. Амишов Р.И. Паломничество в Мекку богослова Нургали Хасанова (1852–1919) // Minbar. Islamic Studies. 2022. №15(1). С. 33–49.

9. Ахметова Д.И. Фатих Амирхан в фотографиях. Казань: ИЯЛИ, 2016. 72 с.

10. Ахтямов Я.А. Наперекор ударам судьбы. Челябинск, 1997. 159 с.

11. Ахунов А. «Татарская недвижимость» на Востоке // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2002. № 3/4. С. 79–84.

12. Багаутдинов Ф.Н. Младший брат Фатиха Амирхана // Научный Татарстан. 2013. № 1. С. 87–94.

13. Бадрутдинова М.Ш. Башир Рамеев – видный представитель династии Рамеевых // Дәрдемәнд мирасы һәм хәзерге заман. Казан, 2009. Б. 127–134.

14. Бартольд В.В. История культурной жизни Туркестана. Л.: Изд-во АН СССР, 1927. 256 с.

15. Беляев Р. Татарская диаспора Финляндии: вопросы интеграции и сохранения идентичности. Хельсинки: 2017. 310 с.

16. Биринджи А. Халим Сабит Шибай // Научный Татарстан. 2012. №4. С. 51–56.

17. Бобровников Н.А. Русско-туземные училища, мектебы и медресы Средней Азии: Путевые заметки. СПб.: Сенат. тип., 1913. 90 с.

18. Валеев Р., Сулима Л. Трагедия сторонника «латинизации» (Дело Гаяза Максудова) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1998. № 1/2. С. 125–136.

19. Валиди Дж. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). М.-Пг., 1923. 106 с.

20. Габдрафикова Л.Р. Татарское буржуазное общество: стиль в эпоху перемен (вторая половина XIX – начало XX века). Казань: Татар.кн.изд-во, 2015. 367 с.

21. Габдрафикова Л.Р. Дореволюционное детство в текстах татарского педагога советского времени Хабиба Зайни. Вестник РУДН. Серия: История России. 2023. Том 22. № 2. С. 207–222.

22. Габдрафикова Л. Его звали Ахметзия Тупеев, и он был... URL: https://dzen.ru/a/Yx4BSH5slkTg4enX (дата обращения: 13.04. 2023).

23. Гаджиев аль-Инчхи М. Мухаммад Али бин Захир аль-Витри. URL: https://as-salam.ru/news/1505/ (дата обращения: 10.04.2023).

24. Гайнетдинов М. На пути истины. Литературная критика. Казань: Тат. кн. изд-во, 2001. 320 с.

25. Гатин Р. Особенности дореволюционного зарубежного образования мусульман Поволжья. URL: https://islamnews.ru/2023/5/29/osobennosti-dorevolyutsionnogo-zarubezhnogo-obrazovaniya-musulman-povolzhya (дата обращения: 12.06. 2023).

26. Гафаров Н.У. Джадидизм в Средней Азии в конце XIX в. – начале XX в. Автореф. дисс. на соискание ученой степени д.ист. н. Душанбе, 2013. 46 с.

27. Гаффоров Н.У. Деятельность благотворительных обществ среднеазиатских джадидов в сфере народного образования // Ученые записки Худжандского государственного университета им. академика Б. Гафурова. Гуманитарные науки. 2013. № 1. С. 110–121.

28. Гёрмез М. Муса Джаруллах Бигиев / перевод с турецкого: Хайрутдинов А.Г. Казань, 2010. 169 с.

29. Гибатдинов М., Муртазина Л., Биктимирова Т. Система национального образования татар: история и современность // Казанский федералист. 2006. №4. С. 23–45.

30. Гизатуллин Р.Н. 1 января 1846 г. основано медресе «Мухаммадия» (Троицк, город). URL: https://chelreglib.ru/ru/cid/detail/50/ (дата обращения: 10.04. 2023).

31. Гилязов И.А. Общество поддержки российско-мусульманских студентов в Берлине (1918–1925). История возникновения // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1996. № 3/4. С.193–199.

32. Гилязов И. Судьба Алимджана Идриси // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1999. № 3 / 4. С 158–171.

33. Гилязов И.А. Готтхольд Вайль как исследователь татар и татарского языка // Филология и культура: Philology and culture. 2015. №1(39). С. 269–274.

34. Гилязов И.А., Гатауллина Л.Р. Российские солдаты-мусульмане в германском плену в годы Первой мировой войны (1914–1920). Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. 303 с.

35. Гимазова Р.А. Мугаллимы и шакирды медресе «Буби» // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2003. № 3/4. С. 308–319.

36. Давлетшин Г. Духовная культура Казанского ханства // История татар с древнейших времен в семи томах. Том 4. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2014. С. 532–542.

37. Денисов Д.Н., Хабутдинов А.Ю. Формирование и эволюция мусульманских общин Троицка и Челябинска в конце XVIII – начале XX века // Tatarica. 2021. Вып. 17. С. 84–104.

38. Денисов Д.Н. Роль Оренбургского медресе «Хусаиния» в развитии мусульманского образования // Ученые записки Казанского государственного университета. Гуманитарные науки. 2010. Том 152. Кн. 3, ч. 2. С. 68–78.

39. Джурабаев Д. Х. Система мусульманского образования в Бухарском ханстве в конце XVIII — начале XIX в. (по материалам русских источников) // Вестник таджикского государственного университета права, бизнеса и политики. Серия: «Общественные науки». № 3(55). 2013. С. 209–216.

40. Ергин Ю.В. Зия Камали – основатель медресе «Галия»: трагические 30-е годы. URL: https://cyberleninka.ru/article/n/ziya-kamali-osnovatel-medrese-galiya-tragicheskie–30-e-gody/viewer (дата обращения: 11.11.2022).

41. Загидуллин И. Традиционные мусульманские общины // История татар в сдревнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань: 2013. С. 401–414.

42. Загидуллин И.К. Татарское национальное движение в 1860–1905 гг. Казань: Татар.кн.изд-во, 2014. 423 с.

43. Иванов А.Е. Российское студенческое зарубежье: конец XIX-начало XX вв. URL: http://vivovoco.astronet.ru/VV/PAPERS/HISTORY/IVANOV.HTM (дата обращения: 10.10.2022).

44. Иванов А.Е. Студенчество России к. XIX – нач. XX в. Социально-историческая судьба. М.: РОССПЭН, 1999. 414 с.

45. Иванов П.П. Очерки по истории Средней Азии (XVI – середина XIX вв.). М.: Изд. восточной лит-ры, 1958. 247 с.

46. Идиятуллина Г. Развитие богословской мысли в Волго-Уральском регионе во второй половине XVIII – начале XIX вв. // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. V. Казань 2014. С. 530–539.

47. Идиятуллина Г.Г. Развитие мусульманской мысли после падения Казанского ханства (XVI–XVIII вв.) // История мусульманской мысли в Волго-Уральском регионе. Казань: Издательство ДУМ РТ, 2009. С. 98–114.

48. Камалов Т. Зия Камали: мыслитель, просветитель, религиозный деятель. Казань: Иман, 1997. 53 с.

49. Кемпер М. Суфийские традиции в первой половине XIX века // История татар в сдревнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань: 2013. С. 372–382.

50. Кюгельген Анке фон. Расцвет Накшбандийа Муджаддидийа в Средней Трансоксании с XVIII – до начала XIX вв.: опыт детективного расследования // Суфизм в Центральной Азии (зарубежные исследования): Сб. ст. памяти Фритца Майера (1912–1998) / Сост. и отв. редактор А.А. Хисматулин. СПб.: Филологический факультет СПбГУ, 2001. С. 275–330.

51. Марданшин М.М. Педагогическая деятельность С. Бикбулатова // Казанский педагогический журнал. 2008. №9. С. 115–119.

52. Махмутова А. Традиционные учебные заведения и новометодное образование // История татар с древнейших времен в семи томах. Том VI. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2013. С. 791–816.

53. Миннуллин З. Землячества и благотворительные общества татарских учащихся в мусульманских странах (начало XX века) // Мир ислама. 1999. №1/2. С. 139–148.

54. Миннуллин З.С. Татарские благотворительные общества: от общины к обществу // Миңнуллин Җ.С. Мәкаләләр җыентыгы. Казан: Татар.кит.нәшр., 2023. Б. 337–349.

55. Москалец О.В. Об организации «Союз русских студентов в Египте» (1920–1922 гг.) // Minbar. Islamic Studies. 2019. № 12(4). С. 945–946.

56. Муртазина Л.Р. К вопросу об истории развития коммерческого образования среди мусульман России в начале XX века // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2023. № 2. С. 22–36.

57. Муртазина Л.Р. «Единство языка, мысли и действий»: Вклад Исмаила Гаспринского в развитие просвещения мусульманских народов // Minbar. Islamic Studies. 2022. № 15(3). С. 635–652.

58. Муртазина Л.Р. «Учение и просвещение можно брать везде, где оно есть»: татарские учащиеся в странах мусульманского Востока на рубеже XIX–XX вв. // Minbar. Islamic Studies. 2022. №. 15(1). С. 13–32.

59. Муртазина Л.Р. Научно-педагогическая деятельность Габдуллы Сабировича Шнаси (1885–1938) // Вестник Томского государственного педагогического университета (Tomsk State Pedagogical University Bulletin). 2016. Вып. 8 (173). С. 121–124.

60. Муртазина Л.Р. Садри Максуди с татарскими студентами в Льеже: история одной фотографии // Историческая этнология. 2018. Т. 3, № 2. С. 302–311.

61. Муртазина Л.Р. Ахмедмунир Ибрагимов о системе высшего образования Японии // Культурные, экономические, технологические контакты и взаимодействие Японии и Татарского мира: история и современность: сборник научных трудов. Вып. 3. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2021. С. 135–146.

62. Муртазина Л.Р. Фазыл Бакиров – лучший студент Университета Вальпараисо // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2024. №2. С. 155–160.

63. Муртазина Л., Гибатдинов М. Документальные следы двух татарских студентов в Америке // «Beyond the TARTAROS». A Muslim World in the Heart of Europe between Elbe, Bug and Kama = «По ту сторону ТАРТАРА». Мусульманский мир в сердце Европы между Эльбой, Бугом и Камой. Сборник научных трудов / Отв. ред. М. Гибатдинов, М. Хотопп-Рике, Ш. Тайлиг. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. С. 130–139.

64. Мухамедьяров Ш.Ф. Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства (XV – первая половина XVI вв.). Казань: Изд-во «Ихлас»; Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2012. 277 с.

65. Мухаметдинов Р.Ф. Татары в общественно-политическом движении Османской империи // Тюркологические исследования. 2020, том 3, № 3. С. 8–22.

66. Мухаметзянова Д.С Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. 216 с.

67. Мухаметшин Р. Мусульманское образование у татар в дореволюционной России: состояние, проблемы и перспективы // Minbar. Islamic Studies. 2009. № 2(4). С. 79–93.

68. Насыров Т. Татарская эмигрантская пресса // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2004. №2. С. 117–128.

69. Неслихан Арул Аксой. Точка пересечения народов: Урало-Поволжье и пример изучения исторической судьбы урало-волжских народов с точки зрения интеллигенции: Абдуррашид Ибрагим, его семья и тоска по Родине // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2017. № 7. С. 216–226.

70. Расулов А.Н., Исокбаев А.А., Насретдинова Д.М. Татары в Туркестане на изломе эпох (начало XX века). Казань: ИЯЛИ, 2021. 256 с.

71. Рахимкулова М. Медресе «Хусаиния» в Оренбурга. Оренбург, 1997. 254 с.

72. Рахимкулова М. Рамеевы. Оренбург, 1995. 140 с.

73. Рахимкулова М.Ф. Педагог и общественный деятель // Совет мәктәбе. 1985. № 2. С. 58.

74. Рахимкулова М.Ф. Преподавание естественных наук в татарских школах дореволюционной России: страницы истории татарских школ в России. Оренбург, 1998. 274 с.

75. Рахимов С. Социально-правовой статус татарских учебных заведений последней четверти XIX – нач. XX вв. // Ислам в татарском мире. Казань, 1997. С. 71–82.

76. Садыкова Л.Р. Сохранение и трансформация этнокультурной идентичности в условиях эмиграции: на примере «Тюрко-татарской» диаспоры США. Автореф. ... канд. ист. наук. Ижевск, 2012. 24 с.

77. Сибгатуллина А. Суфизм в Волго-Уральском регионе во второй половине XIX – начале XX вв. // История татар в сдревнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань: 2013. С. 383–390.

78. Сибгатуллина А., Тюркоглу И. Татары и Османское государство // История татар в сдревнейших времен в семи томах. Т. VI. Казань: 2013. С. 344–350.

79. Соловей А.П. К вопросу о включенности женщин в научную деятельность // Роль женщины в развитии современной науки и образования. Минск: БГУ, 2016. С. 835–839.

80. Старостин А.Н. Новые страницы из истории екатеринбургских купцов и меценатов Агафуровых // Minbar. Islamic Studies. 2018. № 11(2). С. 245–260.

81. Тимер А. Возвращение / авт.-сост. Р. Абзалова-Сальманова. Казань: Яз, 2012. 200 с.

82. Тузбекова Л.С. Медресе «Галия» – высшее мусульманское учебное заведение Башкортостана (1906–1919 гг.) // Медресе Южного Урала и Приуралья: история и современность: Хрестоматия. Аминов Т.М. (сост.). Уфа: БГПУ; 2010. С. 344–345.

83. Тюркоглу И. Новые штрихи к творческой биографии Закира Кадыри-Угана // Tatarica. 2019. №1. С. 121–135.

84. Тюркоглу И. Татары в Японии: Хасан Фехми и Габдерашит Ибрагимов // Тюрко-мусульманский мир: идентичность, наследие и перспективы. Казань: Изд-во Казанского университета, 2015. С. 332–337.

85. Усманова Л. Габдерәшит Ибраһим Япониядә // Габдрәшит Ибраһим: фәнни-биографик җыентык / төз. М. Госманов, Ф. Галимуллин. Казан: «Җыен», 2011. Б. 334.

86. Фазлиев А.М., Шакуров Ф.Н., Ибрагимов Р.Р., Нафиков И.З. Общественные организации татарских учащихся в Оттоманской империи в начале XX в. // Современная наука: актуальные проблемы теории и практики. Серия «Гуманитарные науки». 2023. № 9/2. С. 38–42.

87. Фархшатов М. Просвещение // История татар с древнейших времен. Т. V. Казань, 2014. С. 568–583.

88. Фонотов М. Родная старина. Очерки истории Южного Урала. Челябинск: 2013. 216 с.

89. Хабутдинов А. Бухарское образовательное влияние на татарскую элиту в XVIII–XIX вв. URL: http://www.idmedina.ru/books/history_culture/minaret/12/habutdinov.htm (дата обращения: 12.01.2023).

90. Хабутдинов А.Ю. Миллет Оренбургского Духовного Собрания в конце XVIII–XIX веках. Казань: Иман. 2000. 160 с.

91. Хабутдинов А.Ю. Опыт подготовки конкурентоспособной мусульманской элиты: джадидская система образования. URL: http://www.idmedina.ru/books/islamic/?412 (дата обращения: 12.01. 2023).

92. Хабутдинов А.Ю. Этапы развития образования у мусульман Оренбургского магометанского духовного собрания в XVIII – начале XX вв.: региональный аспект. URL: http://idmedina.ru/books/materials/faizhanov/2/plenary_habutdinov.htm (дата обращения: 12.01. 2023).

93. Хадиуллина Г.Н. Экономические воззрения Мусы Акъегетзаде (1864–1923) и их влияние в эпоху младотурков // Социально-экономические явления и процессы. 2008. № 4. С. 83–87.

94. Хайрутдинов А.Г. Из истории туркестанской эмиграции: «Туркестанское благотворительное общество» в Каире // Minbar. Islamic Studies. 2020. №13(4). С. 824–844.

95. Хайрутдинов А.Г. Общественная деятельность Фаузии Ибрагимовой // Minbar. Islamic Studies. 2022. №15(2). С. 306–307.

96. Хайрутдинов А.Г. Последний татарский богослов. Жизнь и наследие Мусы Джаруллаха Бигиева. Казань: Иман, 1999. С. 33–35.

97. Цвиклински С. Из истории татарской прессы и книгоиздательской деятельности татар в Германии (XX – начало XXI вв.) // TATARICA. 2013. №1. С. 176–181.

98. Шакуров Ф.Н. Вступая в век надежд. Казань: Изд-во «Заман», 2000. 25 с.

99. Шангараев Р.Р. История ислама и мусульманских народов России. Хрестоматия. Казань: ИД «МеДДоК», 2020. 308 с.

100. Шихалиев Ш.Ш. Краткие сведения о контактах мусульман Дагестана и Волго-Уральского региона в XVIII-XX вв. // История, археология и этнография Кавказа. Т. 16, №1. 2020. С. 104–128.

101. Шихалиев Ш., Каяев И. Научные и религиозные контакты мусульман Дагестана и Волго-Уральского региона во второй половине XIX – первой трети XX вв. (по материалам арабографичных источников). Махачкала, 2024. 184 с.

102. Юсупов М. Х. Галимджан Баруди. Казань: Тат. кн. изд-во, 2003. 208 с.

103. Ярлыкапов А.А. Становление и развитие исламского образования на Северном Кавказе (VIII–XX вв.) //Духовные ценности ислама и образование: историко-культурная традиция и современность. Томск: Изд-во Том. ун-та, 2008. С. 8–24.

## Чит телләрдәге әдәбият

1. Adiloğlu A. Ceditçilik Dönemi. Kazan Tatar Edebiyatında Kadın Hak Ve Hürriyetleri Meselesi. Ankara: Gece Kitaplığı Yayınevi, 2020. 452 s. (төрек).

2. Алимов И. Қўқон хонлиги мадраса ва мактаблари тарихи. Тошкент: «Фан» нашриёти, 2017. 304 б. (үзбәк).

3. Vüsale Musali. St. Petersburg doğu yazmalari enstitüsü'nde bulunan Dîvân-I Hikmet nüshalari // Türk Kültürü ve Hacı Bektaş Veli Araştırma Dergisi. Kış 2020/Sayı 96. S. 293–318 (төрек).

4. Жуманазар А. Бухоро таълим тизими тарихи. Тошкент: Akademnashr, 2017. 592 б. (үзбәк).

5. Turkoglu I. Japonyada Üniversite Tahsile Gören Bir Tatar: Hasan Fehmi // Proceedings of the Fifth International Symposium on Islamic Civilization in Volga – Ural Region. Istanbul, 2015. S. 111–135. (төрек).

6. Насретдинова Д.М. Туркистоннинг маданий ҳаётида татар-бошқирд аёлларининг тутган ўрни (XIX аср охири – XX асрнинг биринчи чораги). Тарих фанлари номзоди илмий даражасини олиш учун тақдим этилган диссертация автореферати. Тошкент, 2011. 29 б. (үзбәк).

7. Neslihan Arul Aksoy. Abdürreşit İbrahim'in Kızı FevziyeAbdürreşit ve Asar-ı Nisvan Mecmuası // Japonya Seyyahı Abdürreşit İbrahim'in İzinde. İstanbul: Doğu Kütüphanesi, 2020. S. 125–152 (төрек).

8. Ryosuke Ono. Muhacerattakı bır özbek türkü'nün mektuplarina göre türk dünyasi – Abdülvahap Oktay ve mektupları // Ankara Üniversitesi Dil ve Tarih-Coğrafya Fakültesi Dergisi 53, 2 (2013). 563-584 (төрек).

9. Султонов Ў. Тошкент масжидлари тарихи. Тошкент: «Янги аср авлоди», 2010. 158 б. (үзбәк).

10. Thurston. Islamic Universities and Their Global Outreach. [Electronic source]. Available at: http://www.oxfordislamicstudies.com/Public/focus/essay1009_Islamic_Universities.html (Accessed: 10.05.2021). (инглиз).

# КУШЫМТАЛАР

### Кушымта 1.

### Мөселман Көнчыгышында белем алган татар яшьләренең якынча исемлеге[1]

**Алимов (Галимов) Сабир Алим улы** (1873–1939), чыгышы белән Пенза губернасы Татар Таулысы авылыннан. Педагог, журналист, археограф. Бохарада «Мир Гарәб» мәдрәсәсендә укый (1896), «әл-Әзһәр» университетын тәмамлый (1904). Ташкент, Оренбург, Әстерхан уку йортларында укыта, 1900–1910 елларда «әл-Лива» газетасы (Каһирә) мөхбире, Ленинград көнчыгыш институтының штаттан тыш хезмәткәре (1935–1939).

**Апанаев Габдулла Габделкәрим улы** (1862–1919), җәмәгать эшлеклесе, педагог, Казанда Юнысовлар мәчете имам-хатыйбы, 1892 елда мәчет каршында яңа тәртипләргә нигезләнгән мәдрәсә ача. 1880–1890 елларда Төркиядә, Мисырда белем алган.

**Әл-Ашыти Габдрәкыйп бине Габденнасыйр** (1866 елда вафат), Бохарада белем алган.

**Әл-Ашыти Мөхәммәтрәхим бине Йосыф** (1818 елда вафат), 10 ел дәвамында Дагыстанда белем ала.

**Аюханов Закир Насыйр улы** (1889–1961), чыгышы белән Сембер губернасы Татар Калмаюры авылыннан, филолог, педагог, «Хөсәения», «Галия» мәдрәсәләрендә татар теле, тарих, гарәп һәм төрек телләре мөгаллиме, «Том сүзе» газетасының

---

[1] Исемлекне төзүдә Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстафадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар», «Введение к библиографическому словарю «Верность предшественникам и приветствие потомкам» (Мукаддимат китаб Вафиййат аль-асляф ва тахиййат аль ахляф)», «Верность предшественникам и приветствие потомкам. Перевод с арабского избранных биографий, исследование, комментарии, факсимиле о Волго-Уральском регионе», Ризаэтдин Фәхретдиннең «Асар», Каюм Насыйриның «Некролог яки кыскача сиярь» хезмәтләре, «Татар энциклопедиясе», «Татар педагогик фикер антологиясе», «Ислам на Урале», «Ислам на Нижегородчине» һ.б. фәнни, фәнни-популяр һәм белешмәлек китаплар, фәнни монографияләр һәм XX гасыр башында дөнья күргән татар вакытлы матбугатыннан алынган мәгълүматлар файдаланылды.

мөхәррире (1919), рус графикасы нигезендә башкорт алфавитын төзүчеләрнең берсе, әлифба, дәреслекләр авторы. 1911–1914 елларда «әл-Әзһәр» университетында[2] укый.

**Әл-Әйшәви Мөхәммәд бине Бикмөхәммәд бине Рәхмәтулла әл-Казани** (1865 елда вафат). Бохарада белем ала. Ватанына кайткач, Югары Курса авылына имам-хатыйб һәм мөдәррис итеп билгеләнә. Остазы: Салих әл-Худҗанди.

**Әл-Әлдермеши Мостафа бине Муса бине Имәнкол бине Котлы бине Үрмәк бине Алкай әл-Казани** (1835 елда вафат), Ашытбаш авылында имамлык итә. Мәварәэннәһердә, Кабулда укый. Остазы: Фәезхан бине Хәйдәрхан әл-Кабули. Шәкертләре: Шәриф бине Сөләйман әл-Хәербеви, Габделхаликъ бине Гобәйдулла бине Арыслан әл-Казани һ.б.

**Әлмөхәммәтов Хәбибулла бине Мөхәммәд бине Салих** (1840 нчы еллар уртасы – 1896), ишан, шәех, Сафаҗәй авылында мәдрәсә оештыручы. «Мәрҗания» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, укуын Бохарада дәвам итә. Остазлары: Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов һ.б.

**Әлмүшев Хәмидулла бине Фәтхулла бине Тәңребирде бине Әсән бине Тимербулат** (1855–1929), чыгышы белән Сембер губернасы Питрәксә авылыннан. Галим, мәгърифәтче, Петербург мәчетендә имам, мөдәррис. 1894 елдан Питрәксә авылының 4 мәхәллә мәчете имам-хатыйбы, мәдрәсәгә нигез салучы, мөдәррис. 8 яшьлек вакытында әтисе Бохарага укырга җибәрә, 10 ел дәвамында Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләрендә белем ала. Шәкертлек чорында тәрҗемәләр белән шөгыльләнә.

**Әмирханов Хөсәен Әмирхан улы (1814–1893)**. Дин эшлеклесе, тарихчы. Бохарада белем ала. 1846 елда Казанга кайта, 1849 елдан Яңа Татар бистәсендә Иске таш мәчет имамы. «Әмирхания» мәдрәсәсендә укыта. «Тәварихе Болгария» (1883) китабының авторы. Язучы Фатих Әмирханның бабасы.

**Әхмәров Габдрахман Мифтахетдин улы,** Троицк шәһәре хәйриячесе, җәмәгать эшлеклесе. Госманлы дәүләтендә белем алган. «Рәсүлия» мәдрәсәсенә даими рәвештә матди ярдәм итеп торган. 1910 елда Троицкида мөселман кызлары өчен «Сөембикә» дип аталган беренче дөньяви мәктәпне ачкан.

**Байгилдиев Шәриф Камалетдин улы (Шәриф Камал),** (1884–1942), язучы, драматург, тәрҗемәче. Истанбулда дарелмөгаллиминдә ирекле тыңлаучы була, Каһирәдә «әл-Әзһәр» университетында белем ала (1901–1903).

**Байчурин Лотфулла**, дин эшлеклесе, педагог, дәреслекләр авторы («Мәдарис рөшдия өчен дәлаил игътикадия» һ.б.). Пермь имамы, «Галия» мәдрәсәсе мөгаллиме. Төркиядә дини белем алган.

[2] «Әл-Әзһәр»дә, Каһирә университетында, Истанбулда белем алган шәкертләр, дини яисә дөньяви белем алулары турында төгәл мәгълүмат булу сәбәпле, шартлы рәвештә әлеге исемлеккә кертелде.

**Әл-Баллыкүли Габделхаликъ**, Бохарада ишан. Чыгышы белән Спас өязе Баллыкүл авылыннан. Бохарада укыган. Остазлары: шәех Фәезхан бине Хозырхан әл-Кабули һ.б. Шәкертләре: Җәгъфәр бине Салих бине Мөхәммәтгали әл-Кулаткый һ.б.

**Батталов Вәли Габделхак улы** (1888–1961), Оренбург губернасы Рәдүд авылыннан. Мәдинәдә «Гыйрфания» мәдрәсәсендә, Каһирә университетында белем ала.

**Әл-Бәйрәкәви Шәриф бине Ибраһим әл-Болгари әл-Бөгелмәви** (1841 елда вафат), тумышы белән Бәйрәкәдән. Бохарада укып кайткач, балалар укыта, суфи. Хәрәземгә күченеп китә, шунда яшәп вафат була. Хезмәтләре бар. Остазы: Әбу Салих әл-Халаҗи. Шәкерте: Гобәйдулла бине Ибраһим.

**Бәрәзәви Хәмзә бине Мөхәммәд («Хәмзә астроном»)** (1775 еллар тирәсе – 1827), акыл иясе, сәүдәгәр. 10 ел буе Бохарада, Кабулда укый, математика, астрономия фәннәре буенча белемнәр туплый.

**Әл-Бәрәскәви Габдрәхим бине Бикчәнтәй**, Бохарада укый. 1830 елда Бәрәскә авылына имам итеп билгеләнә. Кышкар авылы имамы һәм мөдәррисе.

**Әл-Бәрәскәви Сәгыйть бине Хәмит бине Солтан әл-Казани** (1855 елда вафат), Бәрәскә авылыннан. Мәвараэннәһердә (Бохарада) белем ала. Казанның Беренче җамигъ мәчете имам-хатыйбы һәм мөдәррисе, китаплар авторы.

**Әл-Бәрәңгеви Хафизетдин бине Насретдин** (1827–1917), дин әһеле. Бохарада белем ала, Бәрәңге авылы имамы.

**Бигиев Муса Җаруллаһ улы** (1874–1949), Пенза губернасы Чембар өязе Кикино авылыннан. Дин галиме, публицист, җәмәгать эшлеклесе, татар милли хәрәкәтенең башында торучыларның берсе. «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллиме (1908–1910), дини һәм әдәбият мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр һәм китаплар авторы. Бакчасарайда, Казанда Ш.Мәрҗани мәдрәсәсендә, Бохарада, Сәмәркандта, Истанбулда белем ала. 1900–1904 елларда «Әл-Әзһәр» университетында укый, Каһирә китапханәләрендә шөгыльләнә. 2 ел дәвамында Мәккә, Мәдинә, Һиндыстанда гыйлем эсти. Петербург университетының табигать-фәлсәфә факультетына ирекле тыңлаучы булып урнаша. Остазлары: Мөхәммәд Габдүһ һ.б. Ислам тематикасына багышланган хезмәтләр авторы.

**Бикбулатов Сөнгатулла** (1886–1954), чыгышы белән Уфа губернасы Балыклы күл авылыннан. «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлагач (1906), Хөсәеновлар химаясенә «Әл-Әзһәр» университетында гарәп теле һәм әдәбиятын өйрәнә, Каһирә университетында лекцияләр тыңлый. 1910 елда ислам тарихы һәм гарәп теле белгечлеге алып, «Хөсәения» мәдрәсәсендә, Казан университетында укыта. Ислам тарихы, Шәрык тарихы, гарәп теле буенча дәреслекләр һәм хезмәтләр авторы.

**Биккенин Хикмәт Мифтах улы** (1888–1929), чыгышы белән Тәтеш өязе Кече Салтык авылыннан. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, 1912–1914 елларда Маһруй Барудия фонды акчасына Мисырда Каһирә университетында, соңыннан Мәскәүдә Көнчыгыш эшчеләренең Коммунистик университетында укый.

СССРның Согуд Гарәбстанындагы вәкаләтле илчелегендә дипломатик эштә. Гарәбстанда Җиддәдә вафат[3].

**Болгари Мөхәммәд (әш-шәех Мөхәммәткәрим әл-Болгари)** (? – XIX гасыр уртасы), лексикограф. Бохарада укыган. Шәкертләр өчен «Лөгате төрки вә фариси вә гарәби» сүзлеге авторы.

**Әл-Болгари (Габәш) Гобәйдулла бине Кәлимулла әл-Әлдермеш** (1785–1874 елдан соң), Казан өязе Әлдермеш авылыннан. Дин эшлеклесе, шагыйрь, хаттат, Кече Солабаш авылы мулласы. Хәсәнгата Габәшинең бабасы. 1812–1822 елларда Бохарада белем ала. Бик күп куъязма китаплар авторы.

**Әл-Бөгелмәви Габденнасыйр бине Габдрәхим бине Әхмәр** (1866 елда вафат), Мамадыш өязе Байлангар авылыннан. Бохарада белем алган. Остазлары: Ниязбирде әт-Төрекмәни һ.б. Шәкертләре: Габделлатыйф бине Габденнасыйр бине Госман әл-Мөслими һ.б.

**Әл-Буави Габделвахит бине Габдрәхим бине Мөхәммәд** (1851 елда вафат), гарәп теле, фикъһ буенча атаклы галимнәрнең берсе санала. Бохарада белем ала. Буа мәдрәсәсе мөдәррисе, мәчет имам-хатыйбы. Язма хезмәте бар. Остазлары: Салих әл-Хуҗанди, Нияз әл-Балхи һ.б. Шәкертләре: Әхмәт бине Мөхәммәтшаһ әс-Суыксуви һ.б.

**Әл-Буави Габденнасыйр бине Мөхәммәтәмин бине Әмин бине Җәгъфәр бине Яфис әш-Шурути** (1885 елда вафат). Буа шәһәре имам-хатыйбы һәм мөдәррисе. Бохарада укыган. Остазлары: Габделмөэмин бине Үзбәк әл-Бохари, хаҗи Ходайбирде әл-Байсуни, Салих әл-Хуҗанди һ.б. Шәкертләре: Шакир бине Габделҗәббар бине Габдрахман әл-Буави һ.б.

**Вахитов Шәһидулла Вәлиулла улы**, чыгышы белән Чистай өязеннән. «Хөсәения» мәдрәсәсендә, «әл-Әзһәр»дә белем ала. «Хөсәения»дә гарәп теле һәм дин гыйлеме укыта.

**Габделҗәлилов Садыйк бине Юныс бине Габделҗәлил әл-Җәбәли** (1835?–1886), чыгышы белән Куй Суы авылыннан, шәех, мөдәррис, дин галиме. Бохарада мәдрәсә тәмамлый.

**Габделмәннафов Әбүбәкер бине Габделмәннаф бине Хөсәен бине Солтан Байбулат** (1787 – ?), чыгышы белән Питрәксә авылыннан. Питрәксәдә беренче указлы мулла, Беренче мәхәллә мәчете имамы (1817 елдан). Бохарада белем ала, соңыннан дүрт ел дәвамында Хиҗазда укый, беркадәр вакыт Төркиядә яши.

**Габделмәннанов Әмирхан бине Габделмәннан бине Исмәгыйль бине Морат бине Кадыйрмөхәммәт бине Әхмәт әл-Казани әт-Талкыши** (1828 елда вафат). Ватанда белем алганнан соң, Бохарага барып укый. Казан арты авылларында имам, соңыннан Казанның Яңа Бистә мәчете имам-хатыйбы, мөдәррис. Остазлары: Габдрәхим бине Йосыф әл-Ашыти һ.б. Шәкертләре: Фәхретдин бине Мостафа ән-Норлати һ.б.

[3] Урманче Б. «Мөхәммәдия» // Безнең мирас. 2022. № 9. Б. 34–35.

**Габденнасыйр бине Мөхәммәтәмин** (1816–1886), чыгышы белән Буа өязе Шурут авылыннан. Буа шәһәре имамы һәм мәдрәсә мөдәррисе. Бәрәскә мәдрәсәсендә укыганнан соң, Бохарада белем ала. Ишан.

**Габдессәләмов Әбелмәних Әбелфәез улы (Әбелмәних Каргалый)** (1782–1883), шагыйрь, дин эшлеклесе. Бохарада укый (1816 елга кадәр). Остазлары: Ниязколый Төрекмәни һ.б.

**Габдрахман бине Исмәгыйль Үтәмишев**, Бохарада белем ала.

**Габитов Исмәгыйль Билалетдин улы** (1890/91 елда туган), чыгышы белән Тәтеш өязеннән. Айтуган мәдрәсәсен тәмамлагач (1910), Төркиядә белем ала. Мәккәдә, Мәдинәдә була. 1913–1917 елларда Бишбалта бистәсе мәчете имам-хатыйбы.

**Гаделша Дәүләтша (Дәүләтша бине Гаделша, Дәүләтша ишан)** (1767–1832), чыгышы белән Эстәрлебаш авылыннан. Язучы, дин эшлеклесе. Каргалы бистәсендә, Бохарада белем ала. Кышкар, Югары Бирәзә, Югары Курса мәдрәсәләрендә мөдәррис, Оренбург губернасы Түбән Чебенле авылы имамы. «Рисаләт ән-нәҗатийә» куъязма китабы авторы. Остазлары: Бохарада Ниязколый әт-Төрекмәни һ.б.

**Галиәсгар Дәүләтбакый (Дәүләтбакый бине Галиәсгар, ? – 1840)**, Оренбург губернасы Иманкол авылыннан. Һәвәскәр астроном, Себердә Тара бистәсендә имам һәм мөдәррис. Бохарада белем ала. Гыйльме нөҗүм (астрономия) буенча белем алу максаты белән кабат Бохарага бара, кайткан вакытта юлда вафат була.

**Галиев Габдрахман Мөхәммәтҗан улы (Габдрахман Порохови, 1872–1920),** Казан шәһәрендә туган. Дин әһеле, Галиевләр мәчетенең имам-хатыйбы. 1891 елда Истанбулда белем ала[4].

**Галиев Газизҗан Мөхәммәтҗан улы** (1859–1931), Казанда туган. Сәүдәгәр, «М.Галиев һәм уллары» сәүдә йортының әгъзасы. 1875–1882 елларда Бохарада укый.

**Галиев Галимҗан Мөхәммәтҗан улы (Галимҗан Баруди)** (1857–1921), чыгышы белән Казан өязе Кече Кавал авылыннан. Мәшһүр җәмәгать эшлеклесе, дин галиме, мәгърифәтче һәм педагог, Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең мөдәррисе, «Әд-дин вә әл-әдәб» журналының мөхәррире. Бохарадагы «Мир Гарәб» мәдрәсәсендә белем ала (1875–1882). Мәдрәсәләр өчен күпсанлы дәреслекләр авторы.

**Галиев Салихҗан Мөхәммәтҗан улы (**1862–1932), Казан шәһәрендә туа. Дин эшлеклесе, Казанның Яңа Бистәдәге Унынчы мәхәллә (Ал мәчет) имам-хатыйбы һәм мәдрәсә мөдәррисе, Галимҗан Барудиның энесе. Бохарада «Мир Гарәб» мәдрәсәсендә белем ала (1882 елда тәмамлый). Гарәп теле грамматикасы һәм дини дәреслекләр авторы.

**Гобәйдулла бине Рәхмәтулла**, Бохара мәдрәсәләрендә укыта.

---

[4] Бу хакта Сәлах Камал искә ала (КФУ КСКБ, 2 т ф., бәйл. 1–4).

**Даутов Әхмәтфәиз Сөләйман улы** (1871 – ?), «Кышкар» мәдрәсәсен тәмамлагач, Мәдинәдә белем ала. Троицк, Оренбург шәһәрләрендә, «Бубый» мәдрәсәссендә фикъһ, гарәп теле укыта.

**Динмөхәммәтов Ишмөхәммәт (Ишми ишан)** (1842–1919), чыгышы белән Казан губернасы, Мамадыш өязе Югары Сон авылыннан. Туган авылында, Түнтәр мәдрәсәсендә белем алганнан соң, Бохарада укый. Түнтәр авылы мәчете имам-хатыйбы. 1911 елда ул үзенең Бохара системасы нигезендә оештырган укыту проектын тәкъдим итә. Аңа Коръәнне өйрәнү һәм берничә дини хезмәт керә, алга таба дөньяви белем алу кирәклеге дә танылa.

**Әд-Дөбъязи Якуб бине Яхъя бине Җәгъфәр әл-Казани** (1845 елда вафат). Бохарада укып кайтканнан соң, 1829–1830 елларда Бәрәскә авылы имам-хатыйбы һәм мөдәррисе итеп куела, соңыннан Кышкарда шәкертләр укыта. Шәкертләре: Әхмәт бине Габделкадыйр бине Сәйфелмөлек бине Җәгъфәр әл-Кавали һ.б.

**Әл-Җәбәли Әхмәт бине Миңле бине Габдулла әл-Болгари Шәмсетдин** (1837 елда вафат), Тәтеш өязе Балтай авылыннан. Мәвараэннәһердә белем ала. Бохарада гомер кичерә. Шәкертләре: Фәхретдин бине Мостай ән-Норлатый, Габделвахит бине Габдрахман әл-Буави һ.б.

**Заидов Латыйф Хуҗаәхмәт улы**, Каһирәдә белем ала.

**Әз-Зияви Мөхәммәт бине Йосыф бине Ильяс** (1830 елда вафат), тумышы белән Зия башы авылыннан. Казан шәһәрендә белем алганнан соң, Бохарада укый. Яңа бистәдә имам-хатыйп һәм мөдәррис. Остазлары: Габдрахман әл-Каргалый һ.б.

**Ибраһимов Габдрәшит Гомәр улы (Рәшит казый)** (1857–1944), Тара шәһәрендә туган. Күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче, «Миръат» журналы, «Өлфәт» газетасы мөхәррире, 1892–1895 елларда Уфадагы Үзәк Диния нәзаратендә баш казый, Токио мәчете имамы. Түмән, Кышкар мәдрәсәләрен тәмамлаганнан соң, 1880–1884 елларда Мәдинә шәһәрендә белем ала, моннан тыш, Истанбул уку йортларында белем эсти.

**Ильясов Таһир Әхмәтҗан улы (Таһир Ильяси)** (1881–1933), тумышы белән Саратов губернасы Индеркә авылыннан. Гарәп теле белгече, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллиме, дәреслекләр авторы. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, 1903 елда М.Барудиянең матди ярдәме белән[5] «әл-Әзһәр» университетына укырга керә (1907 елга кадәр укый). «Әл-мөфид» (1912), «Әдәби касыйдәләр» (1908), «Гыйльме җәбер» (1910) китаплары авторы.

**Иманколый Шаһиәхмәт Баязит улы (Шаһиәхмәт бине Баязит бине Рәхмәтулла бин Иманколый әл-Казани),** (1798–1877), чыгышы белән Казан өязе Мамыш авылыннан. Казанның Яңа Татар бистәсендәге «Тәбәнәк Бохаралы» Унынчы мәчетнең имамы, мәдрәсә мөдәррисе (1834–1877). Бохарада белем алган (1834 елда кайткан). Мәшһүр «Җәрүдә» китабын әзерләүче авторлар коллективы әгъзасы.

[5] Урманче Б. «Мөхәммәдия» // Безнең мирас. 2022. № 9. Б. 34–35.

**Иманкулов Мөхәммәтсадыйк Шаһиәхмәт улы (Мөхәммәтсадыйк Иманколый)**, (1870–1932), Казан шәһәреннән. Язучы һәм дин эшлеклесе. 1886–1894 елларда Бохарада укый. Яңа Бистәдәге Алтынчы мәчет имамы. «Тәрҗеман руси, фарси вә төрки» исемле өч телле сүзлек һ.б. китаплар авторы.

**Исхаков Лотфулла Фәтхулла улы (Лотфи Исхакый,** 1925 елда вафат), мәгърифәтче, дин әһеле. Тумышы белән Оренбург губернасы Яңа Муса авылыннан. Иркутскида, Петербургтагы Дүртенче мәхәлләдә имам, мөдәррис. «Әл-Әзһәр»дә белем алган. 1922 елдан Финляндиядә татар мәктәпләрендә балаларга белем бирә, татар кызлары өчен мәктәпләр ачуда катнаша.

**Әл-Кавали Сәгыйть бине Хәмит бине Рахманколый әл-Казани** (як. 1818–1878), кабере Мәдинә шәһәрендә. Тумышы белән Казан өязе Олы Кавал авылыннан. Бохарада, Истанбулда Солтан сараенда галимнәрдән гыйлем туплый. Истанбулда мөдәррис итеп билгеләнә, шунда яшәп кала.

**Кадермәти Минһаҗетдин Йосыф улы («Һинди Минһаҗ»)** (1871–1925). Һиндыстанда белем ала. 1913 елда Казанда «Мөшавәрәт» исемле өстәл календаре бастыра.

**Кадыйров Закир Хәлим улы (Закир Кадыйри)** (1878–1954), Самара губернасы Габдулла авылыннан. Сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, дин белгече, журналист. Бохарада 5 ел ислам фәлсәфәсен һәм табигать фәннәрен өйрәнә, Мәдинәдә, Истанбул университетының илаһият факультетында белем ала. «Әл-Әзһәр» университетында укый (1906 елга кадәр). «Әл-лива» газетасында, «Әл-Галәм-и Ислами», «Әттилмиз» журналларында басыла. «Хөсәения», «Галия» мәдрәсәләре мөгаллиме, «Тормыш» газетасы мөхәррире. Дини һәм фәлсәфи хезмәтләр, дәреслекләр авторы. Хельсинки университетында һәм татар мәктәбендә укыта, дәреслекләр төзеп бастыра. Остазлары: Мөхәммәд Габдүһ һ.б.

**Әл-Казаклари Фәтхулла бине Сәфәр әл-Хөсәен әл-Казани** (1852 елда вафат). Казаклар авылы имам-хатыйбы һәм мөдәррисе. Казанда һәм Мисырда, Төркиядә белем ала. Остазлары: Габдулла әр-Руми һ.б. Шәкертләре: Хөснетдин бине Гомәр әс-Суыксуви, Сәгыйть бине Хәмит әл-Кавали, Зөбәер бине Исхак әл-Айбаши, Заһит бине Рәхим әл-Юртыши һ.б.

**Әл-Казани Әхмәт бине Вафа бине Фазыл бине Сәйфулла** (1869 елда вафат), Казан шәһәреннән. Бохарада белем алган.

**Әл-Казани Әхмәт бине Мөхәммәт бине Габдеразак бине Ишмөхәммәт бине Тими** (1859 елда вафат), чыгышы белән Казан шәһәреннән. Каргалыда, Бохарада белем алган. Шәмәй шәһәрчегендә имам-хатыйп итеп билгеләнә. Остазлары: Вәлиэтдин әл-Багдади һ.б.

**Әл-Казани Габделгафур бине Габделмәннан** (1846 елда вафат), заманының күренекле галимнәреннән берсе. Бохарада белем ала. Чистай шәһәренең имам-хатыйбы һәм мөдәррисе.

**Әл-Казани Габделхаликъ бине Ибраһим бине Ярмөхәммәт бине Иштирәк** (1843(4) елда вафат), Курса авылыннан, Габденнасыйр әл-Курсавиның бертуганы. Бохарада белем ала. Каһирәдә яшәп, Коръәнне көйләп уку дәресләре ала. Курса авылы имам-хатыйбы һәм мөдәррисе, мөридләр тәрбияли. Остазы: шәех Ниязколый әт-Төрекмәни. Шәкертләре: Хәсән бине Сәлим әл-Әлдермеши һ.б.

**Әл-Казани Ибраһим бине Хуҗаш** (1825 елда вафат), чыгышы белән Шарлама авылыннан. Дин эшлеклесе, дин белгече, 1783–1794 елларда Утар-Аты, Яңа Кишет авыллары имамы, 1794–1825 елларда Казанда Беренче мәчеттә имам һәм мөдәррис булып хезмәт иткән. Дагыстанда белем алган. 1781 елда язган китабы Мәрҗани кулында сакланган. Остазы: Гали әш-Ширвани. Шәкертләре: Таҗетдин бине Габдрәшит әл-Иштирәки, Сәйфетдин бине Әбүбәкер әш-Шөнәри, Максуд бине Корбангали әл-Күлбаши, Гали бине Көчек әл-Хаҗитархани һ.б.

**Әл-Казани Мөхәммәт бине Ибраһим бине Хуҗаш бине Габдулла Фәхретдин** (1844 елда вафат), заманының атаклы галимнәреннән саналган. Бохарада укып кайткач, кабат китә, вафаты да шунда. Бохарадагы берничә мәчетнең имамы, Зур мәчеттә имам һәм мөдәррис. Хезмәтләре бар. Остазы: Гатаулла бине Һади һ.б. Шәкертләре: Габдрахман бине Вәлит әл-Казани һ.б.

**Әл-Казани Мөхәммәт бине Фәхретдин бине Мортаза бине Габделгазиз** (1864 елда вафат). Бохарада укыган. Остазлары: Мөхәммәт әл-Бохари һ.б.

**Әл-Казани Сәлахетдин бине Исхак** (1819–1875), дин эшлеклесе, педагог, 1838–1875 елларда «Апанай» мәчете имам-хатыйбы, мәдрәсә мөдәррисе. Бохарада белем ала. Шәкертләре: Г.Баруди һ.б.

**Әл-Казани Хәбибулла бине әл-Хөсәен бине Габделкәрим бине Ярмөхәммәт** (1762–1817/18), Түбән Оры авылыннан. Бохарада һәм Кабулда белем алган, суфи. Оры авылы имам-хатыйбы. Остазы: Фәезхан бине Хәйдәрхан әл-Кабули. Шәкертләре: Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек әл-Җәбәли әл-Ашыти, Юныс бине Җәбәли. Казый Мөхсин бине Биккол әш-Шаши һ.б.

**Әл-Кайбычи Вәлит бине Әмин бине Сөләймани бине Бикми бине Уракай әл-Казани әл-Җәбәли** (1802/03 елда вафат), Вәлид ишан, Вәлиҗан буларак та билгеле. Туган авылында, Каргалыда, Дагыстанда, Бохарада, Кабулда, Һиндыстанда белем ала. Сәгыйть Каргалысында имам, «Хашиййа Мулла Җами» хезмәтенең авторы (1778 елда, Бохарада укыган вакытта тәмам иткән). Хаҗ сәфәре вакытында Мәдинәдә вафат, «әл-Бакый» зиратында күмелгән. Остазлары: Мөхәммәд әд-Дагыстани, шәех Фәезхан әл-Кабули һ.б.

**Камалов Ибраһим Мөхәммәтзакир улы** (1877 – ?), тумышы белән Чистайдан. Чистайның Беренче мәхәллә имамы, мәдрәсә мөгаллиме, «әл-Әзһәр» университетында укый (1903 елга кадәр). Остазлары: Мөхәммәт Габдүһ һ.б.

**Камалетдинов Пәрвазетдин Җамалетдин улы (Зыя Камали)** (1873–1942), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, «Галия» мәдрәсәсенең җитәкчесе, фәлсәфи, дини китаплар, дәреслекләр авторы. Уфадагы «Госмания» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Уфаның «Җәмгыяте хәйрия» оешмасының матди ярдәме белән Истанбулга җибәрелә,

аннан Мисырга китә, «әл-Әзһәр» университетының фәлсәфә факультетында белем ала. Остазлары: Мөхәммәт Габдүһ һ.б.

**Каматуллинов Гыйниятулла хаҗи** (1912 елның 16 октябрендә вафат), Тәтеш өязе Исәк авылы имамы. «Әл-Әзһәр»дә белем алган.

**Кәримов Хәсән Абелдиян улы** (1876–1960), чыгышы белән Яңа Мочали авылыннан. Бохарада белем алган.

**Әл-Кенәри Гатаулла бине Фәез бине Габделгазиз бине Гайсә** (1811–1883), тумышы белән Кышкардан. Түбән Көек авылы имам-хатыйбы һәм мөдәррисе. Бохарада белем ала. Остазлары: Салих бине Надир әл-Хуҗанди, казый әш-Шәриф бине Гата әл-Бохари, Нияз бине Биньямин әл-Бәлхи, Габделмөэмин бине Үзбәк әл-Әфшанҗи һ.б.

**Әл-Кенәри Фәез бине Габделгазиз бине Гайсә әл-Казани** (1837 елда вафат), тумышы белән Кенәрдән. Мәвараэннәһердә, Кабулда, Һиндыстанда белем ала. Кышкар авылының имам-хатыйбы һәм мөдәррисе. Остазлары: Гатаулла бине Һади әл-Бохари, Фәезхан әл-Кабули һ.б. Шәкертләре: Әүхәди бине Искәндәр һ.б.

**Әл-Кибәки Ишмөхәммәт бине Мөхәммәтзаһир** (1750–1841), чыгышы белән Оренбург губернасы Бәләбәй өязенең Күбәк авылыннан. Күбәк авылында имам һәм мөдәррис, 1783 елда Казан шәһәренең Беренче мәчете каршындагы мәдрәсәдә, Иж-Бубый авылы мәдрәсәсендә мөдәррислек итә. Хаҗ сәфәре вакытында Каһирәдә кала, 8 ел дәвамында «әл-Әзһәр»дә укый. Бохарадагы Күкелташ, Сәмәркандтагы «Хуҗа Әхрар» мәдрәсәләрендә шәкертләрне Коръән уку серләренә өйрәтә. Шәкертләре: Таһир бине Сөбхан әл-Адайи, Габделлатыйф бине Сөбхан әл-Кыйрчый, Хәбибулла бине Габделваһаб әл-Чакмагыши, Таҗетдин бине Габдрәшит әл-Иштирәки, Тавабил бине Сабак әл-Йөгәмеши, Нурмөхәммәт бине Ибраһим әл-Казани һ.б.

**Әл-Кили әл-Казани Габделгани бине Салих бине Сәгыйть** (1811–1871), Казанда Печән базары мәчетендә имам. Бохарада гыйлем ала.

**Әл-Кили Салих бине Сәгыйть бине Хәсән** (1825 елда вафат), Киле авылыннан. Дин эшлеклесе, педагог, Казан өязе Иске Кенәр авылы имамы һәм мөдәррисе, Казанның «Апанай» мәчете имамнарыннан берсе, Икенче мәдрәсә мөдәррисе (1808 елдан). Гарәп илләрендә, Бохарада 15 ел буе дини белем алган. Остазлары: Гатаулла бине Һади әл-Бохари һ.б. Шәкертләре: Габделсаттар һәм Габделгаффар әш-Шырданилар һ.б.

**Әл-Кирмәни Искәндәр бине Максуд бине Әхмәт** (1865 елда вафат), Бохарада укый. Кызылъяр шәһәре имам-хатыйбы, мөдәррис. Остазлары: Салих әл-Хуҗанди, Нияз әл-Бәлхи, Хәсән бине Халә әл-Бохари һ.б.

**Әл-Кулаткый Җәгъфәр бине Салих (Сукыр ишан)** (1783–1863), чыгышы белән Саратов өлкәсе Хвалын өязе Кулаткы авылыннан, галим, туган авылы Кулаткыда мөдәррислек һәм шәехлек иткән. Бохара һәм Нәсеф шәһәрләрендә, Багдад, Шам, Мисырда, Мәккә һәм Мәдинәдә сәяхәт кылып йөргән, гыйлем туплаган. Остазлары: Габделхаликъ әл-Баллыкүли әл-Казани һ.б. Шәкертләре:

Габделлатыйф бине Яһүдә, Габделлатыйф бине Халит әл-Бәдәнки, Нәҗметдин бине Әхмәт әл-Әстерхани, Бәрәңге авылының мелла Габделлатыйф ишан бине Халит бине Җәгъфәр бине Алтынбай, Тәлчәй авылының имамы Габделлатыйф бине Биккол, Казан мулласы Хәсәнетдин бине Гомәр һ.б.

**Курсави Габденнасыйр Ибраһим улы (Габденнасыйр Курсави)** (1776–1812), күренекле дин галиме, мәгърифәтче, Югары Курса авылы имамы. Бохарада «Мир Гарәб» мәдрәсәсендә укый. «Әл-иршад лил-гыйбад» һ.б. гарәп телендә язылган хезмәтләр авторы.

**Курсави Габделхаликъ Ибраһим улы (Габделхалик Курсави)** (? – 1843 яки 1844), дин эшлеклесе, Казан губернасы Казан өязе Югары Курса авылы мәчете имамы, мәдрәсәдә мөдәррис. Бохара шәһәрендәге мәдрәсәдә белем ала. Остазлары: Ниязколый әт-Төрекмәни һ.б.

**Әл-Күбәки Ишмөхәммәт бине Заһит бине Бикмөхәммәт бине Алуш бине Колаш бине Талаш бине Кызылбай** (1841 елда вафат). Хаҗга барган җирдән Каһирәдә 8 ел яшәп кала, андагы галимнәрдән гыйлем туплый. Оренбург, Күбәк авылы имам-хатыйбы, мөдәррис. Шәкертләре: Нуретдин Мөхәммәт бине Ибраһим әл-Казани, Таһир бине Сөбхан әл-Адаи һ.б.

**Әл-Кышкари Шәмсетдин** (1831 елда вафат), чыгышы белән Кышкар авылыннан. Бохарада белем алган. Ташкичү мәдрәсәсендә мөдәррислек һәм имамлык иткән, соңыннан хаҗга киткән җиреннән Мисырда төпләнеп кала, Каһирә университетында фарсы теле укыткан. Вафаты Каһирәдә. Остазлары: Гатаулла бине әл-Һади әл-Бохари, Әбу Салих әл-Халаҗи һ.б.

**Әл-Лаҗави Исхак бине Сәгыйть бине Йортбагыш бине Колмөхәммәт бине Ишмөхәммәт әл-Болгари** (1835 елда вафат). Бохарада белем алган. Казанда һәм тирә-юнь авылларда укыткан. Шәкертләре: Сираҗетдин бине әл-Вәлит әс-Сәрдәви, Хәсән бине Хәмит әл-Курсави һ.б.

**Максудов Баһаветдин Җәлалетдин улы**, Уфа шәһәрендә туа. Мисырда белем ала[6]. Һәр эшкә сәләтле, оста кеше була. Мәктәпләргә күргәзмә әсбаплары, агачтан кырып, төрле җиһазлар ясый. Типографиядә эшли[7].

**Әл-Мамыши Шаһиәхмәт бине Әбуязит бине Рәхмәтулла бине Иманкол бине Рахманколый** (1803–1878), чыгышы белән Казан губернасы Мамыш авылыннан. Казанның 8 нче мәчете имамы. Бохарада укыган. Остазы: Гата бине Йосыф әл-Бохари һ.б.

**Әл-Мәңгәри Әхмәт бине Халит** (Әхмәт Халитов, 1810–1870), Троицк шәһәреннән (ата-бабалары Казан артының Мәңгәр авылыннан). 1832–1845 елларда

---

[6] ТР ДА. Ф. 1. Тасв. 6. Эш 99. Кгз. 10.

[7] Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Псевдонимы в татарской литературе / төз.: Л.Ш. Гарипова, Г.Н. Зәйниева. Казан: ТӘһСИ, 2021. Б. 116.

Бохарада укый. 1846 елда Троицк шәһәренең 2 мәчетенә икенче мулла итеп билгеләнә.

**Әл-Мәңгәри Байморат бине Мөхәррәм бине Мөэмин бине Мөслим әл-Казани** (1849 елда вафат), Мәңгәрдән, заманының мәшһүр галимнәреннән. Мәвараэннәһердә белем ала (1813 елга кадәр). Мәмсә авылында, Казанның Яңа бистәдәге 6 нчы мәчетендә имам-хатыйб һәм мөдәррис. Бер үк вакытта сату итү, текстиль җитештерү белән дә шөгыльләнә. Хезмәтләре бар. Остазлары: Салих бине Надирмөхәммәт әл-Хуҗанди һ.б. Шәкертләре: Габделкәрим бине Ишбай әл-Кирмәни, Габделвахит бине Габдрахман әл-Буави һ.б.

**Әл-Мәрҗани Шиһабетдин Баһаветдин улы (Шиһаб Мәрҗани),** (1818–1889), мәшһүр татар дин галиме, тарихчы, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче, педагог. Бохараның «Күкелташ», «Мир Гарәб» (1838–1843), Сәмәркандның «Ширдар» (1843–1849) мәдрәсәләрендә белем ала. Казанның Беренче мәчете имам-хатыйбы, татар тарихы һәм дин гыйлеме буенча хезмәтләр авторы. Остазлары: Салих бине Надир бине Гашур бине Габдулла әл-Хуҗанди, Мөхәммәт бине Сәфәр әл-Хуҗанди, Фазыл бине Гашур әл-Иждувани, Габделмөэмин бине Үзбәк әл-Әфшанҗи, Әбу Сәед әс-Сәмәрканди, Мийан Фазлый Габделкадыйр һ.б. Шәкертләре: Хөсәен Фәезханов, Морад Рәмзи, Камалетдин бине Сәйфетдин, Әбүбәкер бине Яхуд, Гобәйдулла бине Рәхмәтулла, Габделхәбир бине Габделваһһаб әл-Кызылҗари, Борһанетдин әш-Шәбкәви һ.б.

**Әл-Мәрҗани Баһаветдин Мөхәммәт бине Сөбхан бине Габделкәрим** (1787–1856 елда вафат), Казан өязе Бәрәскә авылыннан. Дин эшлеклесе. Ш.Мәрҗанинең атасы. Бохарада «Торсыния» мәдрәсәсендә укый (1802–1814). 1814 елда туган авылына кайта, Ябынчы, Ташкичү авыллары имам-хатыйбы һәм мөдәррисе. Остазлары: Гайсә бине Рәхмәтулла әл-Хукандый, Салих әл-Хуҗанди һ.б. Шәкертләре: Шиһабетдин Мәрҗани, Сәгыйть бине Әхтәм әл-Буави, Фәхретдин бине Әбуязид ән-Наласави, Фәтхулла әш-Шәйморзави һ.б.

**Әл-Мәскүби Дәүләтшаһ бине Гадил** (1831 елда вафат), Мәскәүдән. Бохарада белем ала. Ниязколый әт-Төрекмәни мөриде. Гыйлемлелеге белән танылган. Шәкертләре: Һибәтулла бине Баттал әл-Каргалый һ.б.

**Әл-Мәчкәрәви Габдулла бине Яхъя**, мәгърифәтче. Бохарада белем ала.

**Әл-Минзәләви Әхмәт бине Рафикъ бине Мөэмин бине Хөсәен әс-Сәмәки** (1835 елда вафат). Казанда, Уфада, Мәвараэннәһердә белем ала. Остазлары: Габденнасыйр Курсави һ.б. Шәкертләре: Габделфәттах әл-Мөслими, Габдулла әл-Чәмәки һ.б.

**Минһаҗетдин мәхдүм**, Казалы шәһәреннән, Казалы халкы җыйган иганә хисабына Мәдинә шәһәренә укырга җибәрелә (1908 елда).

**Мортазин Мөхәммәт Хәмит улы**, чыгышы белән Казан өязендәге Әлдермеш авылыннан. Казандагы 10 мәчет каршындагы «Якуп» мәдрәсәсе мөдәррисе (1834 елга кадәр). Бохарада белем алган. Остазы: шәех Ниязколый әт-Төрекмәни.

**Мөхәммәтәмин бине Сәйфулла бине Габделхәмит**, чыгышы белән Сарман ягы Шыгай авылыннан, Наласа авылы имамы һәм мөдәррисе. Бохарада белем ала. 1842 елда хаҗ сәфәренә баргач, ил башлыгы Ибраһим паша тарафыннан кабул ителә, «әл-Әзһәр» университеты укытучысы итеп билгеләнә. Остазлары: Г.Курсави һ.б.[8]

**Насыйров Салихҗан Сәлахетдин улы**, Каһирәдә белем ала.

**Әл-Оруви Фәтхулла бине әл-Хөсәен бине Габделкәрим әл-Казани** (1767–1843), Казан губернасы Түбән Оры авылыннан. Каргалыда белем алганнан соң, Бохарага китә. 1795 елдан Югары Оры авылы мәчете имам-хатыйбы һәм мәдрәсә мөдәррисе, бер үк вакытта, 1814 елдан, Казан губернасы Царёвококшайск шәһәре ахуны. Мөселман хокукы буенча мәкаләләр һәм Коръәнгә аңлатмалар, фикъһ, каллиграфия, болгарлар тарихы, медицина буенча мәгълүмат тупланган җыентык авторы. Остазлары: Габдрахман әл-Каргалый, Гатаулла бине Һади әл-Бохари һ.б. Шәкертләре: Сәгыйть бине Хәмит әл-Бәрәскәви, Мөхсин бине Биккол бине Ибраһим әш-Шаши һ.б.

**Оруви Хәбибулла бине Хөсәен** (1762–1816), чыгышы белән Казан губернасы Оры авылыннан. Бохарада, Кабулда белем ала. Орыдагы 2 мәхәллә мәчете имамы. Остазы: Фәезхан бине Хозырхан.

**Рафиков Гобәйдулла Габдрахман улы** (1887–1935), тумышы белән Оренбург губернасы Каргалы авылыннан. «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, «әл-Әзһәр»дә белем ала. «Хөсәения» мәдрәсәсендә математика, гарәп теле укыта.

**Рахманколый (әл-Мәңгәри) Әхмәтхаҗи Хәмит улы** (1821–1921), мәгърифәтче, педагог. Бохарада «Күгелташ», Истанбулда Әхмәт бине Мостафа Көметчи Хәнәфи мәдрәсәләрендә белем ала. Троицкида Беренче мәхәллә мәчете имамы, китаплар авторы. Остазлары: Әхмәт бине Мостафа Көметчи Хәнәфи һ.б. Шәкертләре: З.Рәсүлев һ.б.

**Рахманколов Хәсән Әхмәтхаҗи улы,** Төркиядә белем алган. Рәдүт авылы имамы, Рәдүт мәдрәсәсендә шәкертләргә белем биргән.

**Рахманколов Мөхәммәтвәли Әхмәтхаҗи улы,** Төркиядә, Каһирәдә белем алган.

**Рахманколов Шаһиәхмәт Таҗетдин улы (Әхмәт Рахманколый),** (1886–1939), драматург. Бохарада, Истанбулда белем ала. 1914 елдан Төркиядә сәүдәгәр Яушевның сәүдә йорты вәкиле була; татар студентларының иҗтимагый хәрәкәтендә, «Тәгареф әл-Ислам» газетасын чыгаруда катнаша. Педагогик һәм әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнә.

**Рәмзи Морад Баһадиршаһ улы (Морад Рәмзи)** (1855–1934), күренекле дин галиме, мәгърифәтче. Ташкент, Бохара (1873–1878), Мәдинәнең «Әмин ага», «Әш-Шифа», «Әл-Мәхмүди» мәдрәсәләрендә (1878–1881), Мәккәдә (1881–1914) белем

[8] Милли-мәдәни мирасыбыз: Арча. Казан, 2017. Б. 28–29.

ала. «Тәлфик әл-әхбар вә тәлких әл-әсар фи вәкаигъ Казан вә Болгар вә әл-мөлүк әт-татар» (1908) һ.б. хезмәтләр авторы.

**Рәсүлев Габдрахман Зәйнулла улы (Габдрахман Рәсүлев)** (1889–1950), мөселман дин әһеле, мөфти (1936–1950). Уфа губернасы Акхуҗа авылыннан. Троицк шәһәрендәге «Рәсүлия» мәдрәсәсе мөдәррисе, Бишенче җамигъ мәчет имамы. 1899–1903 елларда Каһирәдә «әл-Әзһәр» университетында югары дини белем ала.

**Рәсүлев Зәйнулла бине Хәбибулла** (1833–1917), дин эшлеклесе, ишан, шәех. 1869–1870 елларда Истанбулда гыйлем эсти. Остазлары: Әхмәт Зыяэтдин Көмешханәви һ.б.

**Рәсүлев Хәйрулла Зәйнулла улы**, Мәдинә шәһәрендә белем ала, суфилык тарикатенә кабул ителә. Каргалыда имам һәм мөдәррис.

**Әс-Сабави Мөхәммәтәмин бине Сәйфулла бине Габделхәмит бине Динмөхәммәт бине Шифаи бине Мөхәммәт бине Акман бине Илкәй әл-Казани** (1833 елда вафат). Бохарада белем ала. Наласа авылында имамлык һәм мөдәррислек иткәннән соң, 1826 елда Истанбулга, соңрак Каһирәгә килә һәм Шәмсетдин әл-Кышкари вафатыннан соң, аның урынында Каһирәдә укыта башлый. Бик гыйлемле була, китаплар яза («Китаб фил-гакаид» һ.б.). Шәкертләре: Габделвәли бине Вәлит әл-Кәчеви, Вафа бине Фазыл әл-Казани һ.б.

**Сәетбатталов Габделбари Габдулла улы (Габдулла Баттал-Таймас)** (1880–1969), Самара губернасының Яңа Актай авылында туа. Әдип, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, «Йолдыз» газетасы хезмәткәре, тарихи, әдәби, публицистик китаплар авторы. Каргалы мәдрәсәсендә, Троицкидагы З.Рәсүлев мәдрәсәсендә, Мисырда үзлегеннән белемен арттыра (1904–1908). 1920 елдан мөһаҗирлектә. Финляндиядә татар балаларын укыта.

**Әс-Салави Хаммат бине Халит бине Габделваһһаб әл-Җәбәли** (1865 елда вафат). Чыгышы белән Яңа Сала авылыннан. Бохарада укыган. Казанның Яшел мәчете имам-хатыйбы һәм мөдәррисе. Остазлары: Мөхсин бине Биккол бине Ибраһим әл-Казани әш-Шаши. Шәкертләре: Таҗетдин бине Бәшир әс-Суыксуви һ.б.

**Әс-Салавычи Нигъмәтулла бине Биктимер бине Тукай** (Нигъмәтулла Тукаев, 1773–1844), чыгышы белән Салавыч авылыннан. Казанда, Бохарада белем ала (1801 елдан). 1813 елның 22 августында указ алып, Эстәрлебаш мәчетендә имам, мәдрәсәдә мөдәррис. Остазы: шәех Әбу Салих һ.б.

**Әс-Саснавый (Чистави) Мөхәммәтзакир бине Габделваһаб бине Габделкәрим (Мөхәммәтзакир Камалов)** (1815–1893), Малмыж өязе Сасна авылында туган. Дин әһеле, ишан, Нәкышбәндия тарикате вәкиле. Чистайның «Нур» мәчете имам-хатыйбы, «Камалия» мәдрәсәсен оештыручы, мөдәррисе. Казан өязе мәдрәсәләрендә белем алганнан соң, Бохарада укый. Шәкертләре: Гаяз Исхакый, Р.Фәхретдин һ.б.

**Әс-Сәгати Хөсәен бине Мөхәммәт бине Гомәр Мөниретдин Әл-Кирмәни** (1857 елда вафат), Сәгыйть Каргалысыннан. Бохарага күченеп киткәннән соң, андагы

галимнәрдән гыйлем ала. Берничә китап авторы. Остазлары: Шәех хаҗи Сәйфетдин әл-Ламгани әл-Бшавари, Вәлиэтдин әл-Багдади, Габделгазиз бине Габделгани әл-Бохари һ.б.

**Сәйфетдин Камалетдин (Камалетдин бине Сәйфетдин).** «Әл-Әзһәр»дә белем ала, шунда ук фәлсәфә фәнен укыта. Университетның төрки бүлеге педагогы. Казанга кайткач, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә ислам фәлсәфәсе буенча белем бирә. Остазлары: Ш.Мәрҗани һ.б.

**Сәйфетдинов Әмирҗан Хәммат улы** (1890–1966), тумышы белән Оренбургтан. Каһирәдә белем ала. «Хөсәения» мәдрәсәсендә хезмәт кабинеты мөдире, Оренбург мәктәпләре укытучысы.

**Әс-Симәки Шаһиәхмәт бине Рәфыйк бине Габделмөэмин бине Хөсәен** (1787–1837), дин эшлеклесе, Минзәлә өязе Такталачык, Симәк авыллары имамы, мөдәррисе, фикъһ буенча хезмәтләр авторы. Бохара мәдрәсәсендә гыйлем ала.

**Әс-Симети Мортаза** (? – 1723 елдан соң), Симет авылында мәдрәсә ача, мөселман догматикасына багышланган китап авторы. Дагыстанда белем ала.

**Сөбханкулов Җамал (Җамалетдин бине Сөбханкул бине Иманкул бине Мәхмүт)** (1830 елда туган), Троицк шәһәренең 4 нче мәхәлләсе мәчете имамы, мөдәррисе (1879 елдан). Мәчкәрә, Сатыш мәдрәсәләрен тәмамлаганнан соң, Бохарада гыйлем туплый. Бик абруйлы дин әһеле һәм педагог буларак дан казана.

**Әс-Суыксуви Әхмәт бине Мөхәммәтша бине Әхтәм әл-Буави** (1862 елда вафат). Бохарада белем ала. Остазы: Габделмөэмин бине Үзбәк әл-Бохари. Шәкертләре: Хәйдәр бине Әмин әт-Тәнәви һ.б.

**Тимер Габдулла Гыйззәтулла улы**, чыгышы белән Спас өязе Салман авылыннан, «әл-Әзһәр» университетында укый, сугыш башлангач, иленә кайта алмый өзелеп кала, Фәләстыйндагы югары баскыч дарелмөгаллиминне тәмамлый, шунда мөгаллим булып эшли. Фәләстыйнда Хайфа шәһәрендә «Әмирия» мәдрәсәсендә гарәп әдәбияты, фәсахәт дәресләре укытучысы. Лондонда тәрбия һәм эзчелек (скаутлар) институтында укып шәһадәтнамә ала, Фәләстыйндә беренче эзчелек оешмасына нигез салган. «Яңа милли юл» журналында эзчелек тарихына багышланган мәкаләләр бастырган.

**Төхфәтуллин Мотыйгулла Төхфәтулла улы** (1844–1920), Зөя өязе Кече Кайбыч авылында туа. «Мотыйгия» мәдрәсәсе җитәкчесе, Җаек шәһәре мәчете мулласы, ахун. Кышкар мәдрәсәсен тәмамлый, «әл-Әзһәр» университетында укый (1868–1874). Шәкертләре: Г.Тукай, К.Мотыйгый, Ә.Байтирәков һ.б.

**Төхфәтуллин Камил Мотыйгулла улы (Камил Мотыйгый)** (1883–1941), Уральск шәһәреннән. Журналист, нашир, җырчы, «Фикер», «Уклар», «Әлгасрелҗәдит» исемле газета-журналлар чыгара. «Мотыйгия» мәдрәсәсендә, 1900–1902 елларда Каһирәдә «әл-Әзһәр» университетында укый. Остазлары: Мотыйгулла Төхфәтуллин һ.б.

**Әт-Түнтәри Арыслан бине Бәшир** (1941 елда вафат). Бохарада белем ала. Шунда ук озак еллар белем бирә. Ватанына кайтып вафат була. Остазлары: Мөхсин бине Биккол әш-Шаши, Салих бине Надирмөхәммәт әл-Хуҗанди, әмир Хәйдәр. Шәкертләре: Шаһәхмәт әл-Кариле һ.б.

**Әт-Түнтәри Гали бине Сәйфулла бине Габдрәшит әт-Түнтәри** (як. 1794–1874). Мәчкәрә мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Бохарада укый. Түнтәрдә имам һәм мөдәррис (1829–1874). Остазлары: Мөхәммәтрәхим әл-Ашыти, Габдулла бине Яхъя, Мийан Фазлый Габделкадыйр. Шәкертләре: Садретдин ишан Галләмов һ.б.

**Әт-Түнтәри Габделгаффар бине әл-Габделхәмит бине Үтәгән әл-Болгари** (1846 елда вафат), чыгышы белән Түнтәрдән. Бохарада белем ала. Салавыч, Яңа Тазлар авыллары имам-хатыйбы, мөдәррис. Остазлары: Вәлиэтддин әл-Багдади, Габделкадыйр бине Әхмәт әс-Сирхинди, Гата бине Йосыф әл-Бохари, Ийада бине Заһир әл-Хуканди, Шир әл-Хуканди, Салих Хуҗанди.

**Урманов Салихҗан Мөхәммәтфатыйх улы** (1879–1924 елдан соң), сәясәт, җәмәгать һәм дин эшлеклесе, Благовещенск шәһәре ахуны, Диния нәзарәте казые, «Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Ырынбургия» журналы мөхәррияте әгъзасы. Уфа губернасында туа. «Госмания» мәдрәсәсен тәмамлагач, мөселман илләрендә белем туплый[9].

**Утыз Имәни Габдрәхим бине Госман әл-Болгари (Габдрәхим Утыз-Имәни** (1754–1834), шагыйрь, дин белгече, җәмәгать эшлеклесе. 1788–1798 елларда Бохара, Сәмәрканд, Кабул мәдрәсәләрендә гыйлем эстәгән. Бохарада имам булып торган. Ватанына кайткач, Тимәш һ.б. татар авылларында мәдрәсәдә балаларга гыйлем бирә.

**Әл-Ушмави Әхмәтҗан бине Әмирхан** (1783–1813), дин галиме. Каһирәдә белем ала.

**Фазыйлов Хәтмулла,** Истанбулда (кайбер чыганаклар буенча Каһирәдә) белем ала. «Госмания»дә, «Галия»дә укыта, шәкертләргә географиядән белем биргән.

**Фәйзулла бине Галиәсгар** (1852 елда вафат), Оренбург губернасы Иманкол авылыннан. Дәүләтбакый бине Галиәсгарнең энесе. Тара шәһәре мөәзине һәм мөдәррисе. Бохарада ун еллар тирәсе гыйлем алган. Шәкертләре: Тара, Тубыл якларындагы имамнарның күпчелеге, шул исәптән Мәһди бине Сәедик, Насретдин бине Корбан һ.б.

**Фәйрушин Галимҗан Мөхәммәтҗан улы** (1885 – ?), Оренбург губернасы Тозтүбә шәһәреннән. «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Каһирә университетында укый. «Хөсәения»дә табигать белемен укыта, башлангыч сыйныфлар мөдире.

**Фәхретдинов Мөхиссинә** (1885–1937), Түбән Новгород губернасы Краснай авылы имамы. Бохарада белем алган. Остазы: Зәйнебәшир Сабитов.

---

[9] РДТА, 821 ф, 133 тасв., 536 эш, 187 б.

**Хәбибрахманов (Габдрахманов) Габделкотдус Хәбибрахман улы** (1879 – ?), Вятка губернасы Әгерҗе авылыннан. «Бубый» мәдрәсәсен, 1907 елда «әл-Әзһәр» университетын тәмамлый. Әгерҗедә татар мөселман мәктәбендә укыта.

**Хәмзә Таһир бәк**, чыгышы белән Уфа губернасыннан, «Әл-әзһәр» университеты китапханәсе хезмәткәре. 18 ел гарәп дөньясында белем алган, шунда төпләнеп калган. Мисырның «әл-Бәлагъ» газетасында Г.Исхакыйның дүрт мәкаләсен бастырып чыгара[10].

**Хәсәнов Нургали бине Хәсән әл-Морзави әл-Буави әл-Казани** (1852–1919), тумышы белән Тәтеш өязе Морзалар авылыннан. Казандагы «Халидия», «Касыймия» һ.б. мәдрәсәләрдә укыганнан соң, Бохарадагы «Мир Гарәб» мәдрәсәсендә белем ала. Мәдинә шәһәрендә Гали әл-Витридан һ.б. иҗазәт ала. Бохарада берничә йөз голяма алдында имтихан тотып, галимлеген раслый, Бохара галиме булып танyла. 1883–1885 елларда Бохарадагы мәдрәсәләрнең берсендә дәрес бирә, бер үк вакытта белемен арттыра. 1885 елда Бохарадагы «Гатар» мәдрәсәсе мөдәррисе итеп билгеләнә, 1886 елдан Буа мәдрәсәсе җитәкчесе һәм Буа имамы. Остазлары: «Күгелташ» мәдрәсәсе мөдәррисе Ихтиярхон Шәһресабзий, мөфти Габделхәким, шәех Нуретдин әл-Хаварәзми. Шәкертләре: Баки Халидов, Шакир Мөхәммәтов, Һади Атласи, Габдулла Нәҗметдинов, Зариф Бәшири һ.б.

**Хөсәенов Мөхәммәтҗан Хөсәен улы (Мөхәммәтҗан бине Хөсәен бине Мансур бине Габдрахман әл-Казани әл-Борындыкый)** (1756–1824), тумышы белән Оренбург губернасы Солтанай авылыннан. Җәмәгать һәм дин эшлеклесе, Диния нәзарәтенең беренче мөфтие (1788–1824), Диния нәзарәтен үзгәртеп кору, дөньяви фәннәр укытыла торган мәктәпләр төзү проектлары авторы. Бохарада, Кабулда белем ала (1877 елга кадәр). Остазлары: Бохарадада Гатаулла бине Һади, Кабулда Фәезхан Хозырхан Нәкышбәнди һ.б.

**Хөсәенов Мөхәммәтвәли Габделгани улы** (1867–1933), дин эшлеклесе, эшмәкәр, 1899 елдан Оренбургның Беренче җамигъ мәчете мулласы, имам-хатыйбы, «Вәлия» мәдрәсәсе мөдәррисе, «Дин вә мәгыйшәт» журналының нашире. Бохарада, Мәккәдә, Мәдинәдә белем алган.

**Хөсәенов Шәмсетдин Хөсәен улы** (1878–1927 елдан соң), тумышы белән Вятка губернасы Шеңшеңәр авылыннан. Җәмәгать эшлеклесе, мулла, I Дума депутаты. Истанбулда дини белем ала (1904 елда тәмамлый).

**Хуҗаш Фәхретдин бине Ибраһим** (1754 еллар тирәсе – 1844), дин эшлеклесе, каллиграф, фикъһ буенча хезмәтләр авторы. Бохарада укый.

**Әл-Чиртуши Габдулла бине Яхъя бине Мәхмүт әл-Казани** (1859 елда вафат), Бохарада белем алган. Тумышы белән Чистай өязе Чиртуш авылыннан. Мәчкәрә, Мәңгәр, Малмыж авыллары имам-хатыйбы, мөдәррис. Остазлары: шәех Габдрахман, Миркъҗан әл-Бохари һ.б. Шәкертләре: Исмәгыйль бине Муса, Хәсән бине Хәмит әл-Мөслими һ.б.

---

[10] Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. Т. 10. Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. Б. 298, 509.

**Әл-Чокали Габделвали бине Габделгаффар (1821 елда туган),** Казанда XIX йөздә мәдрәсә тотып шәкертләр тәрбияләгән. Бохарада белем алган[11].

**Шамуков Вахит бине Шәмсетдин** (1820 – ?), чыгышы белән Иске Мочали авылыннан. Истанбулда, Бохарада белем ала. 1842 елдан Мочали авылы имамы, мулласы.

**Шамуков Гәрәй бине Вахит** (1860–1937), Мучали авылы имамы. Бохарада укыган.

**Әш-Шаши Мөхсин**, Урта Азия шәһәрләре мәдрәсәләрендә дин белеме ала.

**Шәмсетдинов Габдулла Хәсән улы** (1870–1936), җәмәгать һәм дин эшлеклесе, Көлҗәдә имам, 1908 елдан Мәскәүдәге Беренче мәчет имамы. Бохарада укый.

**Әш-Шырдани Габделгаффар бине Сәгыйть бине Әхмәт әл-Казани** (1831 елда вафат), дин эшлеклесе, Казанда мәдрәсә тота (әтисенеке). Мәварәэннәһердә белем ала. Бохарада мөхтәсиб, Казан шәһәрендә һәм тирә-як авылларда имам-хатыйб була. Остазлары: Салих бине Сәгыйть әл-Кенәри, Миркъҗан әл-Бохари, Гайсә бине Рәхмәтулла әл-Хаваканди, Гатаулла бине Һади әл-Бохари, Гайсә бине Заһир әс-Суди, Шир әл-Хуканди һ.б.

**Әш-Шырдани Габделсаттар бине Сәгыйть** (? – 1831), дин эшлеклесе, Казанда Бишенче мәхәллә имамы, 1821 елдан өлкән ахун. 1814 елга кадәр Бохара янындагы Нәсеф шәһәрендә мөхтәсиб, мәхкәмә башкаручысы һәм казый. Бохарада белем ала. Остазлары: Салих бине Сәгыйть әл-Кенәри, Миркъҗан әл-Бохари, Гайсә бине Рәхмәтулла әл-Хаваканди, Гатаулла бине Һади әл-Бохари һ.б.

**Шәмсетдин Зыяэтдин Әхмәт**, чыгышы белән Кече Тархан авылыннан, Буа шәһәрендә, аннан соң Истанбулда һәм Хиҗазда укып, Мәдинәдә мөдәррислек һәм мөҗавирлек иткән. Шигырьләр язган[12].

**Әл-Эстәрли Камалетдин бине Шәрәфетдин**, Эстәрлетамак мәдрәсәсе мөдәррисе. Бохарада белем алган.

**Әл-Эстәрли (Тукаев) Мөхәммәтхарис бине Нигъмәтулла** (1810–1870), Оренбургның генерал-губернаторы тарафыннан 1833 елның 24 сентяберендә Бохарага барырга бирелгән 1380 нче номерлы рөхсәт кәгазе белән 1833 елда Бохарага сәфәргә чыга, 1841 елда гыйлем алып кайта. Эстәрлебашта имам, мөдәррис һәм Эстәрлебашның шәехе булып хезмәт итә. Остазлары: Хәсән бине Хәл әл-Бохари, мәүләнә шәех Ниязколый әт-Төркмәни һ.б.

**Әл-Эстәрли Мөхәммәтхәррас бине Нигъмәтулла** (1814–1871), 1844 елда Бохарага гыйлем алыр өчен сәфәргә чыга, 1852 елда әйләнеп кайта, Эстәрлебаш мәдрәсәсендә шәкертләргә белем бирә.

---

[11] Бустанов А.К. Библиотека Зайнап Максудовой = Зәйнәп Максудова китапханәсе. М., 2019. С. 333.

[12] Шунда ук.

**Әл-Эстәрлебаши Габделмәҗит бине Мөхәммәтхарис** (1867–1893), Минзәлә өязе Чакмак авылы мәдрәсәсендә укый. 1886 елда Бохарага укырга китә. 1892 елда Эстәрлебашка кайтып, шәкертләргә белем бирә. Хаҗ сәфәрендә вафат, кабере Мәккәи Мөкәррәмәдә «Җәннәти Мөгаллә» исемле зиратта.

**Әл-Эстәрлетамакый Шәрәфетдин бине Зәйнетдин** (1845 елда вафат). Казанда, Бохарада һәм Эстәрлетамакта уку-укыту эшендә, шәехлектә.

**Юнысов Мөхәммәтзариф бине Мөхәммәтшакир бине Мөхәммәтюныс** (як. 1850 – 22.11.1914), чыгышы белән Түбән Новгород губернасы Куй Суы авылыннан. Казандагы «Апанай» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, укуын Бохарада дәвам итә. 1874 елда Санкт-Петербург шәһәренең Беренче мәхәлләсе ахунының ярдәмчесе, имам-хатыйбы һәм мөдәррисе итеп билгеләнә.

**Ялчыгол Таҗетдин** (1768–1838), шагыйрь, галим. Әтисе белән Әстерхан һәм Дагыстан аша Төркиягә (Диярбакыр) килә, 14 ел гыйлем туплый. Ватанына кайткач, Кече Сөн, Җирекле һ.б. авылларда балаларга белем бирә. Фикъһ, педагогика, әдәбият, медицина буенча хезмәтләр авторы.

**Яһүд Әбүбәкер (Әбүбәкер бине Яһүд),** Ш.Мәрҗани укучысы, «әл-Әзһәр»дә белем ала. «Әл-Әзһәр»дә фәлсәфә фәнен укыта.

## Кушымта 2.

## Ватаннан читтә дөньяви уку йортларында белем алган татар шәкертләренең якынча исемлеге

**Агафуров Нуретдин Зәйнетдин улы** (1890–1923), чыгышы белән Екатеринбургтан, сәүдәгәр, 1915 елда Екатеринбург мөселман хәйрия җәмгыяте идарәсе әгъзасы. 1912 елдан Лейпциг шәһәрендә (Германия) югары уку йортында укый. Революциядән соң гаиләсе белән башта Харбинга, аннан Япониягә күченә.

**Агафуров Бәдретдин Кашшафетдин улы** (1901 – ?), чыгышы белән Екатеринбургтан, сәүдәгәр, Томск университетының хокук факультетында укый. 1919 елдан Япониядә. 1921 елда Берлин сәүдә институтына укырга керә. 1924–1932 елларда Маньчжуриядә «Бертуган Агафуровлар» фирмасында эшли, Харбин шәһәрендәге мөселман җәмгыяте әгъзасы.

**Акчурин Ибраһим,** Дрезденда Югары техник мәктәптә белем алган (1918 елда укый).

**Акчурин Йосыф Хәсән улы (Йосыф Акчура)** (1876–1935), сәясәтче, журналист, җәмәгать эшлеклесе. Истанбулда урта һәм югары хәрби белем алганнан соң (1888–1896), Париждагы хосусый «Ирекле сәясәт» һәм Сорбонна университеты каршындагы югары мәктәптә укый (1899–1903).

**Акъегетзадә Муса Мөхәммәтҗан улы** (1864–1923), язучы, журналист, икътисадчы галим. Тумышы белән Пенза губернасы Чембар шәһәреннән. Өчәләй авылында мәдрәсә белеме алганнан соң, рус мәктәбендә, Пенза шәһәрендә гимназиядә укый. Мөгаллимлек итә, 1886–1887 елларда «Тәрҗеман» газетасында журналист булып эшли. 1888–1891 елларда Истанбулда дәүләт оешмалары өчен югары белемле хезмәткәрләр әзерли торган «Мәктәбе мөлкия-и шахане» мәктәбендә укый, шәһәрдәге Югары хәрби мәктәптә һәм Хәрби академиядә рус теле һәм икътисад буенча дәресләр бирә, «Мәтен» («Асыл нөсхә»), «Өч кардәш» исемле газеталар нәшер итә, Измир һәм Сивас шәһәрләрендә җирле идарә оешмаларында эшли, Истанбулда Казаннан сатып алынган Н.Ф.Катанов китапханәсен тәртипкә салу төзү эше шөгыльләнә.

**Аллаяров Гани,** чыгышы белән Троицк шәһәреннән, Истанбулда «Мәктәбе Солтания»дә, Париждангы Сорбонна университетында белем ала. Төркия хөкүмәте стипендиясенә укыганлыктан, шунда кайтып, «Мәктәбе Солтания»дә укыта.

**Алмаев Мәхмүт Садретдин улы** (1874–1907), журналист, полиграфчы һәм шагыйрь, Казанда Кәримовлар, Оренбургта Кәримов-Хөсәеновлар ширкәте типографияләрендә техник җитәкче, «Хөсәения» мәдрәсәсендә бухгалтерия дәресләре укытучысы. Истанбулда укый, Лейпцигта полиграфия эшенә өйрәнә.

**Әмирханов Ибраһим Зариф улы** (1889–1938), юрист, дипломат, 1924–1926 елларда Согуд Гарәбстанында СССР илчелеге секретаре. 1927–1935 елларда

ТАССРның Юстиция халык комиссариаты коллегиясе һәм Югары мәхкәмәсе әгъзасы. Бәйруттагы Америка көллиятен тәмамлый (1914).

**Әнвәров Фуад,** чыгышы белән Себердән, Зайсан өлкәсеннән. 1914 елда Американың Индиана штатында урнашкан Вальпараисо университетында белем ала. «Вакыт», «Шура» һ.б. басмаларда Америка уку йортлары турындагы язмалары басыла.

**Әхмәт Ләбиб Каран** (1878–1964), табиб (медицина докторы), фәнни китаплар, мәкаләләр авторы. Тумышы белән Каран авылыннан. 1909 елда Истанбулда Вафа лицеен, Истанбул университетының медицина факультетын тәмамлый. Измир һәм кайбер башка шәһәрләрдәге хастаханәләрдә эшли. Исхакый чыгарган «Милли юл» («Яңа милли юл») журналында да эшләп ала, анда мәкаләләрен бастыра.

**Әхтәмов Хәбибулла Габделхак улы** (1883–1938), чыгышы белән Уфа губернасының Төркәй авылыннан. Дин әһеле, ахун. Истанбулда белем ала.

**Байбулатов Хәбибулла,** 1911 елдан Сан-Франциско шәһәрендәге Химия институтында укый. «Вакыт», «Сибирия» газеталарында Америка уку йортлары, аларда уку шартларын яктырткан мәкаләләрен бастыра.

**Байкин Җәлал** (1886–1954), Җ. Байкин, Б. Җәмил тәхәллүсләре белән билгеле. Тумышы белән Пенза өлкәсе Качкаров авылыннан. Әстерханда татар театрын башлап оештыручыларның берсе. Казанда «Касыймия» мәдрәсәсендә, аннан соң ике ел Истанбулда укып кайта.

**Бәкер Баһаветдин** (якынча 1899 елда туган), 1911 елдан Истанбулдагы «Мәктәбе Солтания»дә белем ала.

**Бәкер Фазыл** (1896–1923), Троицкидан. Истанбулда, Бәйрутта, Американың Вальпараисо университетында укыган, 1923 елда вафат.

**Бакиров Хәнәфи Кәрим улы** (1884–1934), Уфадан, педагог, журналист. 1911 елда Истанбул университетын тәмамлый. 1911–1919 елларда «Хөсәения» мәдрәсәсендә мөгаллим, укыту һәм фән эшләре буенча мөдир урынбасары. Татар милли мәгариф институтында (ТИНО) табигать белеме, физика, химия, биология, анатомия фәннәре буенча белем бирә. 1925–1932 елларда Казан химия-технология институтында укыта. Ботаника, зоология, анатомия, кеше физиологиясе, физика һәм химия буенча дәреслекләр авторы.

**Богданова Гайшә Габдулла кызы** (1890 – ?), Казан шәһәреннән. 1908 елда Мария гимназиясен тәмамлый, Төркиядә француз һәм төрек телләрен өйрәнә. Казанга кайткач, теш табибы һөнәрен үзләштерә. «Бубый» мәдрәсәсендә рус теле укыта. Парижда чыгучы «Мусульманин» журналында 1910–1911 елларда «Париж

очерклары» («Очерки Парижа») циклы авторы. Кайбер тикшеренүчеләр фикере буенча, медицина буенча укуын Сорбоннада дәвам итүе мөмкин[13].

**Вәһапов Мөхәммәтзакир**, Троицкидан. Әхмәтхаҗи ахун Рахманколый мәдрәсәсе хәлфәсе. Җәдитчә белем алу өчен Истанбулга җибәрелә.

**Вәһапов Хәбибулла**, Бәйрут көллиятен, Вальпараисо (Төньяк Америка) шәһәрендә университет тәмамлый.

**Габдрахманова Мәрьям,** 1912 елдан Женева университетының (Швейцария) медицина факультетында укый[14], Россиягә кайтып кабат диплом ала.

**Габдуллин Закир**, чыгышы белән Уфа губернасы Бәләбәй өязеннән, Истанбулда, Мисырда (кайбер чыганаклар буенча Бәйруттагы Америка көллиятендә) белем алганнан соң, 1913 елда Американың Айова университетындагы зирагать (авыл хуҗалыгы) институтының авыл хуҗалыгы инженерлары әзерләү көллиятенә укырга керә. Америкадагы уку йортлары, уку шартлары турындагы мәкаләләре вакытлы матбугатта басылып чыга.

**Газизов Габдулла Кәлимулла улы (Сакмарый, Сакмарлы),** чыгышы белән Оренбург губернасы Сарыкташ авылыннан. Журналист. Бәйруттагы Америка көллиятендә белем ала. Революциядән соң Харбин шәһәрендә «Мең ел» дигән бер көнлек газета чыгаруда катнаша.

**Галиева Әминә Салихҗан кызы**, 1908 елда Истанбулда Шәйхелислам Касыйм хәзрәтнең кызы Хөсния ханымнан хәзерлек дәресләре алганнан соң, университет каршында оештырылган «Аналар мәктәбе»ндә укый, гуманитар фәннәр буенча белем ала, Балкан сугышы башланганнан соң, Россиягә кайта. Казандагы Шумкова гимназиясенә йөреп, ашчылык курсларын тәмамлый. 1914 елда кызлар өчен ачылган коммерция мәктәбендә, Л.Хөсәения мәктәбендә укыта.

**Зәйнетдинов Хәбибулла Хәлиулла улы (Хәбиб Зәйни)** (1890–1968), педагог, дәреслекләр авторы. Истанбул педагогия институтының биолого-география факультетында белем ала (1908–1912). Хаксызга гаепләнеп, кулга алына, Колыма лагерьларында утыра (1938–1944).

**Ибраһимов Әхмәтмөнир Габдерәшит улы (Мөнир Ибраһимов, Әхмәтмөнир Рәшиди)**, тумышы белән Тара шәһәреннән. Төркиядә «Мәктәбе Солтания»дә белем алганнан соң, Петербург университетының хокук факультетына укырга керә, әмма тәмамламый, әтисе Габдрәшит Ибраһимов киңәше белән Төркиягә китә, 1911 елдан Васеда университетының (Япония) хокук-сәясәт факультетында укый.

[13] Галләм Р., Биктимерова Т. Айшә Богданова: «ИРЕКЛЕ Франциянең ирекле хатын-кызы туры мәгънәсендә дә, күчерелмә мәгънәсендә дә кол ул...». URL: https://cyberleninka.ru/article/n/gaysh-bogdanova-irekle-frantsiyane-irekle-hatyn-kyzy-tury-m-gn-send-d-k-cherelm-m-gn-send-d-kol-ul (мөрәҗәгать итү датасы: 11.12.2023).

[14] Вакыт. 1912. 24 август.

**Ибраһимов Габдулла Сабир улы (Шнаси)** (1885–1937), педагог, татар мәдрәсәләре өчен татар телендә язылган беренче химия дәреслекләре, шулай ук физика, тәрбия эшләре буенча әсбаплар авторы. Төркиядә Истанбул шәһәрендә гимназиядә һәм университетның табигать фәннәре факультетында белем ала. «Галия»дә физика, химия, математика фәннәрен укыта, «Хөсәения» мәдрәсәсендә фән һәм укыту эшләре буенча мөдир урынбасары булып эшли, табигать фәннәрен, педагогика, дидактика, физик тәрбия дәресләрен, факультатив рәвешендә француз телен укыта.

**Идриси Галимҗан Җәгъфәр улы** (1884(7) – 1959), журналист, җәмәгать эшлеклесе, дин эшлеклесе. Тумышы белән Акмулла өлкәсе Петропавловск шәһәреннән. «Хөсәения» мәдрәсәсендә ибтидаи сыйныфлар бүлеге мөдире. 1902–1907 елларда Бохарада белем ала. 1912 елда Истанбул университетын тәмамлый (кызыл диплом ала), 1913–1914 елларда Лозаннада (Швейцария), Льежда (Бельгия) укый. 1922–1924 елларда Бохара халык совет республикасының Германиядәге вәкиле, СССРдан Германиягә килгән студентлар җәмгыяте («Русия мөселман таләбәләренә ярдәм җәмгыяте») рәисе. 1915–1915 елларда «Төрек йорты» журналының икенче мөхәррире.

**Идрисов Мөхәммәт Ибраһим улы** (1882–1948), полиграфист, каллиграф, рәссам, бердәм калыпка салынган гарәп шрифтын барлыкка китерүче, төрки һәм шәрык телләре белгече. 1905 елда Төркия, Ливан, Мисырда каллиграфия, типография эшен өйрәнә, гарәп, фарсы телләрен камилләштерә.

**Ишмөхәммәтов Гаяз Мәһди улы** (1897–1971), тумышы белән Җаектан. Педагог, гарәп теле белгече, лексикограф. Мисырда гарәп телен өйрәнгән. 1946 елдан Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан университеты хезмәткәре, сүзлекләр, уку әсбаплары авторы.

**Камалетдинов Җамалетдин Сираҗетдин улы** (1883–1937), педагог, җәмәгать эшлеклесе. Төркиядә белем ала.

**Камалетдинов Сәлахетдин Камалетдин улы (Сәлах Камал)** (1885–1954), Сембер губернасы Шәйморза авылыннан. Педагог, мәгърифәтче, педагог. Казанда Айтугановлар мәктәбен тәмамлаганнан соң, Истанбул университетының физика-математика факультетында укый (1901–1905). «Хөсәения» мәдрәсәсендә, Хәрәзем педагогия техникумында, Казанда татар педагогия училищесында укыта. Татар телендә дәреслекләр, методик кулланмалар авторы.

**Кәрам Габдрахман Хәбибулла улы (Рәхмәтуллин)** (1878–1947). Тәхәллүсләре: Г. Кәрам, Габдрахман Кәрам, Г. Рәхмәтуллин. Журналист, язучы. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен, Истанбул университетының сәнгать факультетын тәмамлый. Солтан Рахманкулов белән русча-татарча лөгать төзиләр.

**Кәримов Мөхәммәтфатих Гыйльман улы (Фатих Кәрими)** (1870–1937), педагог, нашир, җәмәгать эшлеклесе, дәреслекләр авторы. Истанбулда «Мәктәбе мөлкия-и шахане» дөньяви мәктәбендә белем ала (1892–1896).

**Кошай Хәмит Зөбәер** (1897–1984), Минзәлә өязе Теләнче Тамак авылыннан. Истанбулда шәхси дәресләр алып, башта лицей сыйныфына, 1914 елда Солоникидагы Мидхәт паша мәктәбенә укырга керә. Истанбулда ике ел укып, мөгаллимлек шаһадәтнамәсе ала, Кадикой бистәсе мәктәбендә физик тәрбия укытучысы булып эшли. Будапешт университетын тәмамлап, докторлык дәрәҗәсе ала, Әнкарада этнографик музей оештыра.

**Крымбаев Мирсаяф** – шагыйрь, журналист, 1908–1910 елларда Парижда чыккан «Мусульманин» журналында сәркатиб. Сорбонна университетында укый (1912 елдан).

**Локман Кәмал** (1899–1976), Төркиянең беренче нефть инженеры. Чыгышы белән Казалы шәһәреннән. Төркиядә башлангыч һәм урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Бәйруттагы Америка көллиятендә[15] (кайбер мәгълүматлар буенча Шамда), Франциядә Политехник уку йортында, аннан соң Гренобльдә һәм Страсбургта Югары милли нефть мәктәбендә белем ала.

**Максудов Борһан,** чыгышы белән Касыймнан. 1908 елда Фрайбург шәһәрендәге (Германия) Тау академиясен тәмамлый.

**Максудов Гаяз Гыйсаметдин улы** (1891–1942), Казан губернасы Лаеш өязе Югары Кибәхуҗа авылыннан. Җәмәгать эшлеклесе, галим-математик, педагог. Төркиянең Солоники шәһәре лицеенда (1910–1912), Льеж (1913–1914), Истанбул (1917–1919) университетларының физика-математика факультетларында укый. Физика-математика фәннәре кандидаты. «Мәгариф» журналының мөхәррире, Академик Үзәк рәисе (1922–1924).

**Максудов (Вильданов) Нияз Мөхәммәтхаҗи улы,** чыгышы белән Уфа шәһәреннән. Троицк шәһәрендә Гайния Яушеваның мөгаллимәләр әзерли торган мәктәбендә (дарелмөгаллимат) укытучы, 1915 елда ачылган «Вазифа» ир-ат мөгаллимнәр әзерләү мәктәбе (дарелмөгаллимин) мөдире. Бәйруттагы Америка көллиятендә белем ала[16]. 1914 елда Нью-Йорк университетының педагогика факультетында укый.

**Максудов Садретдин Низаметдин улы** (1878–1957), сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, милли хәрәкәт лидеры, тюрколог. Сорбонна университетының хокук факультетында белем ала (1902–1906).

**Мәүләбирдиев Нәҗип (Нәҗип Гасрый)** (1886–1937). Әстерхан губернасы Казын авылыннан. Казанда Мәрҗани мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Төркиядә Истанбул дарелфөнүненең әдәбият бүлеген тәмамлый. Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта, Әстерханда «Сарай» газетасының редакторы.

---

[15] Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. Т. 10. Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. Б. 341.

[16] Шунда ук.

**Мостакаев (Биги) Габдулла Хәсән улы** (1890 – ?), Саратов губернасы Хвалын өязе Татар Шәмалыгы авылыннан. «Бубый» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Бельгиядә Энергетика буенча югары белем ала. 1964 елга кадәр Үзбәкстан Фәннәр академиясендә эшли.

**Мөҗавиров Зыя,** «Бубый» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, 1915 елда Вальпараисо университетында белем ала, совет сәнәгатендә хезмәт итә. «Вакыт» газетасында мәкаләләр бастыра.

**Мусин Әхмәтсәлим**, чыгышы белән Семипалат шәһәреннән. 1912 елда Лейпциг шәһәрендә (Германия) Сәүдә академиясен тәмамлый, дагыстанлы иптәше белән мөселман сәүдә конторасын ача, йон, тире товарлар белән сату-алуны оештыру, арадашчылык хезмәтен үти.

**Насыйров Зыя Сибгатулла улы** (Н.Зыя, З.Насрый, 1889–1937), Уфа губернасы Бәләбәй өязе Корманайбаш авылыннан. Җәмәгать эшлеклесе, язучы, педагог. Төркиядә (1912 елдан) белем ала. «Шура» журналында, «Вакыт», «Йолдыз» газеталарында мәкаләләре басылып чыга (чит илләр тормышы хакында).

**Нигъмәтуллин Гобәйдулла Габделгалләм улы (Гобәйдулла Буби)** (1866–1938), педагог, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, Иж-Бубый мәдрәсәсе җитәкчеләренең һәм мөгаллимнәренең берсе, дәреслекләр авторы. Истанбулда «Мәктәбе мөлкия-и шахане» дөньяви мәктәбендә (1890–1895) белем ала.

**Рахманкулов Әхмәттаҗетдин Мөхәммәтҗан улы (Әхмәттаҗетдин, Ә. Рахманкулов, Шәяхмәт).** Журналист, язучы. Троицк шәһәрендә туа. Төркиядә югары белем ала. 1910 елда Истанбулда «Тәгърифел-мөслимин» исемле журнал чыгара. Русиягә кайткач, төрле матбугатта язышa. Революциядән соң 1917 елда Троицкида «Хөр милләт» газетасын чыгара. 1920 елда Казанга килеп, хикәя-роман, пьеса, сценарийлар яза.

**Рәмиев Габдрахман**, Бәйрут көллиятендә, Женева университетында (1912 елдан) белем ала, шунда ук төрки телләр укытучысы булып укытырга кала.

**Рәмиев Гариф Мөхәммәтзакир улы** (1893–1971), Бельгиянең Льеж электр-техника институтында укый. 1914 елда Бөтендөнья сугышы башланганнан соң, бүленеп кала. Финляндиядә педагоглык эше белән шөгыльләнә. Вафаты Рим шәһәрендә.

**Рәмиев Искәндәр Мөхәммәтзакир улы** (1886–1943), 1901 елда «Хөсәения» мәдрәсәсен һәм Петербургта гимназия тәмамлаганнан соң, Германиядә Фрайбург Тау академиясендә укый. 1914–1918 елларда Рәмиевләрнең алтын приискаларында, «Башзолото» трестында лаборатория мөдире.

**Рәмиев Әхмәтмидхәт Мөхәммәтшакир улы**, (1893 – ?), 1912 елдан Льеж техника институты студенты. Беренче бөтендөнья сугышы башлану белән, туган иленә кайта алмый бүленеп кала, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Америкада яши.

**Рәмиев Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы (Дәрдемәнд)** (1859–1921), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, эре сәнәгатьче, хәйрияче. 1880–1881 елларда Истанбулда хосусый рәвештә төрек теле һәм әдәбиятын, француз телен, нәшрият эшен өйрәнә.

**Рәмиев Мәхмүт Мөхәммәтшакир улы,** 1912 елдан Бельгиядә Льеж электр-техника институтында белем ала. Сугыш башлангач, шунда бүленеп кала.

**Рәсүлев Габделкадыйр Зәйнулла улы** (1888 – ?). Уфа губернасы Аккуҗа авылыннан. Истанбулда гимназия тәмамлый, Әстерхан шәһәре мәчетендә имам.

**Рәсүлева Гайшә**, Истанбулдагы Солтания мәктәбендә укый, ахырдан хатын-кыз укытучылар мәктәбенең бишенче курсын тәмамлый.

**Рәсүлева (Мәүлүдова) Зәйтүнә**, 1915 елда Истанбул университетында ирекле тыңлаучы буларак лекцияләргә йөри, соңыннан Сатигъ бәк мәктәбен тәмамлый. Бәйрутка мөгаллимә итеп билгеләнә, тик Россиягә кайту мөмкинлеге чыгу белән, гаиләсе белән ватанына кайта.

**Сабитов Хәлим** (Хәлим Сабит Шибай, 1883–1946), Сембер губернасы Кече Тарханлы Лабит авылыннан. Самарада, Олы Тарханда мәдрәсә белеме ала, рус уку йортында имтихан тапшырып аттестат ала. «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. 1904 елда Истанбулда Фатих мәчетендә Дагыстанлы Абдулфәттах әфендедән укып иҗазәтнамә ала (моның өчен 1906 елда көмеш медаль белән бүләкләнә), «Мәрҗан» мәктәбендә имтихан биреп, шәһадәтнамә ала. Истанбул университетының рухани бүлеген тәмамлый, педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү өчен университетта махсус имтиханнар тапшыра. 1912 елдан Геленбеви мәктәбендә, 1914 – 1919 елларда Истанбул университетында ислам тарихы укыта башлый. «Ислам энциклопедиясе»н төзүдә катнаша. 1944 елдан Дин эшләре буенча рәиснең киңәшчесе, Төрек белем җәмгыятенең ислам бүлеге рәисе булып эшли.

**Садретдинов Зәкәрия Садретдин улы** (Зәкәрия Садри, 1930 елда вафат), журналист, «Кояш» газетасының мөхәррире, нашире. Ш.Мәрҗанинең бертуган энесе Садретдинның улы. «Кояш» газетасының нашире. Төркиядә югары белем алган, 1908–1909 елларда «Галия» мәдрәсәсендә укыткан.

**Садыйкый-Җаекый Габдулла Гыйззәт улы** (XIX гасырның икенче яртысы – XX гасырның беренче яртысы), язучы. 1898–1899 елларда Бәйруттагы Америка колледжында укыган.

**Салих Әфәнде,** Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлый, Льеж электротехника мәктәбендә укый, Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Льежда бүленеп кала.

**Сатыев Габдулла Габделкәбир улы (Габдулла Фәйзи)** (1886–1958), педагог, дәреслекләр авторы. Истанбулда укытучылар семинариясендә (1906–1909), Университетның физика-математика факультетында (1909–1912) укый.

**Сафа әфәнде,** чыгышы белән Оренбургтан. Һиндыстанда Дәһли университетының медицина факультетын тәмамлый, шунда яшәп кала.

**Сәгъдиев Габдрахман Гайнан улы (Габдрахман Сәгъди)** (1889–1956), әдәбият галиме, педагог; Казан, Ташкент, Сәмәрканд уку йортларында укыта, әдәбият гыйлеме мәсьәләләренә багышланган фәнни хезмәтләр авторы. Истанбул университетын тәмамлый (1911). Докторлык диссертациясе яклый.

**Сәгыйров Кәбир Сәгыйрь улы** (1886–1970). 1904–1906 елларда Самара шәһәрендәге «Шиһабия» мәдрәсәсендә укыта. 1913 елда Истанбулда дарелмөгаллимин тәмамлый. 1914 елдан «Хөсәения» мәдрәсәсендә мөгаллим, 1920–1924 елларда Оренбург шәһәрендәге 10 урта мәктәп директоры. 1924 елдан Бохара укытучылар институтында, Ташкент шәһәре уку йортларында педагог булып эшли.

**Сәйфелмөлеков Бәдретдин (Бәдри Камалетдин)** (1896 елда туган), чыгышы белән Казалыдан, журналист, табиб. Истанбулда «Мәктәп Солтания»нең медицина факультетын тәмамлагач, 1913 елда Швейцариянең Льеж университетының медицина факультетында белем ала, 1916 елдан Берлин университетында укый. Татарларның тешләре һәм этнографиясе хакында диссертация яза. 1917–1918 елларда Германиянең Дюссельдорф шәһәре әсирләр лагерендагы татар солдатлары өчен «Татар иле» газетасының мөхәррире.

**Сәйфелмөлеков Галимҗан**, чыгышы белән Ташкенттан, 1914 елда Американың Индиана штаты Вальпараисо университетында белем алган.

**Сәйфелмөлеков Мостафа,** Германиядәге Лейпциг университетында белем ала. Сугыш башлангач, шунда бүленеп кала.

**Сибгатулла әфәнде**, Истанбулда «Тыйббия» мәктәбендә укыган.

**Сөбханкулов Габдулла** (Габдулла Сөбханкул). 1894 елда Троицк шәһәрендә туа. Төркиядә югары белем ала. 1919 елларда Уфада «Ватан» газетасын чыгара.

**Сөләйманов Габдулмөхәммәт Хәлил улы (Габдулла Сөләймани)** (1886–1937), дин эшлеклесе, Диния нәзарәте казые, китап һәм мәкаләләр авторы. Бәйрутта Америка көллиятендә укый.

**Сыртланова Суфия Шәхәйдәр кызы,** чыгышы белән Уфа шәһәреннән. 1912 елда Женева университетының медицина факультетында укый. Казанда университет тәмамлап, табиблык дипломы ала. Гражданнар сугышыннан соң Төркиягә китә, Германиядә яши.

**Тупеев Исмәгыйль Фәйзрахман улы** (1887 елда туган), чыгышы белән Уфа губернасы Бөре өязе Өчбүлә авылыннан. Истанбулда укыган, табиб һөнәрен үзләштереп, Уфа шәһәрендә эшләгән.

**Тупеев Әхмәтзыя Фәйзрахман улы** (1885–1946), чыгышы белән Уфа губернасының Бөре өязе Өчбүлә авылыннан. Бәйруттагы Америка көллиятенең табигать фәннәре факультетында укый. Россиягә кайтканнан соң, башта мулла, совет чорында укытучылык итә, Уфадагы 15 нче татар мәктәбенең директоры.

**Фатих әфәнде,** Льеж университетында укыган чорда (1913–1914 еллар) Петербургка кайтып, шәрык кичәләре оештырып йөргәнлеге мәгълүм.

**Фәйзуллин Харис Зариф улы (Харис Фәйзи-Чистапули)** (1871–1933), җәмәгать эшлеклесе, педагог, журналист, «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллиме, «Әхбар» газетасының нашир-мөхәррире, мәдрәсәләр өчен география, физика, тарих дәреслекләре авторы. 1891–1896 елларда Истанбулда «Госмания» мәдрәсәсен тәмамлый.

**Фәйрушин Шакирҗан Мөхәммәтҗан улы** (1881 – ?), Оренбург губернасы Тозтүбә шәһәреннән. «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Истанбулда[17] (кайбер тикшеренүләр буенча «Әл-Әзһәр»дә) белем ала. «Хөсәения»дә төгәл фәннәр укыта, мөдир урынбасары була. 1911 елда «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллимнәре эзәрлекләнә башлагач, Төркиягә китә. Кайбер мәгълүматлар буенча, Истанбулда инженерлар әзерләүче урта-һөнәри уку йорты директоры булып эшли.

**Фәхри Габдулла** (Габдулла Фәхри, Г. Фәхри). Касыймнан. 1908–1909 елларда «Шура», «Вакыт»та язышa. Истанбулда гимназиядә укый, медицина факультетының 4 нче курсын тәмамлый. «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. 1923 елда Казанга тәгълим-тәрбия техникумында укытучы булып чакырыла. Дәреслек китаплары авторы.

**Хәбиб Борһан**, «Мөхәммәдия»не тәмлаганнан соң, Бәйрутта Америка колледжында укый, «Мөхәммәдия»дә, Ташкентта мәгариф институтында мөгаллим, математика, физика фәннәрен укыта[18]. Методик мәкаләләр авторы.

**Шакиров Мидхәт,** Шарлоттенбургта Югары техник мәктәп студенты (1918 елда), «Россия мөселман студентларына ярдәм җәмгыяте» (Берлин) әгъзасы.

**Шакулова Сара Касыймхан кызы** (1887–1964), педагог, җәмәгать эшлеклесе. Сорбонна университетының механика-математика факультетын тәмамлый (1912).

**Шәмсетдинов Габдрахман**, Казалы шәһәреннән, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем алгач, Казалы халкы җыйган иганә хисабына Истанбулга укырга китә (1909 елда).

**Шәрәфетдинов Шәһретдин Шәрәфетдин улы (Шәрәф Шәһәр)** (1877–1938), педагог, җәмәгаь эшлеклесе, татар мәдрәсәләре өчен дәреслекләр авторы. Төркиядә гыйлем өсти (1904).

**Әш-Шырдани Габделгаффар бине Сәгыйть (дамелла Габди хәзрәт)** (? – 1831), дин эшлеклесе, Казанда мәдрәсә тота (әтисенеке). Бохарада Гайсә бине Заһир әс-Суди һәм Шир әл-Хокандидан белем ала.

[17] РДТА (РГИА), 821 ф., 133 тасв., 626 эш, 63 кгз. и.я.

[18] Урманче Б. «Мөхәммәдия» // Безнең мирас. 2022. № 9. Б. 34.

## Кушымта 3.

## Чит мәмләкәтләрдә укыган татар шәкертләренең XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында басылып чыккан кайбер язмалары

### *Хәбибулла Байбулатов. Америкадан мәктүб*[19]

Сан-Франциско шәһәреннән.

Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде!

Обшу мәктүбемне гәзитәңезгә басуыңызны үтенәм.

Мин мәхыз (бары тик) бер һөнәр вә сәнәгать үгрәнү касды (теләге) илә Америкага китәргә карар биргәч, якыннарымнан вә дус-ишләремнән берничә кешеләр минем юл расходым өчен иганәдә булыштылар. Барлыгы 87 сум иганә булды. Мин шул акча белән Шимали Америкага килдем вә Сан-Франциско шәһәрендә гыйлем кимия (химия) мәктәбенә кердем. Хәзер шунда торып тәхсил итәргә (белем алырга) тырышамын. Иганә итеп, минем монда килеп җитүемә сәбәп булган мөхтәрәм затларның һәркаюсына чын күңелдән тәшәккер укып рәхмәт әйтәмен. Шуны да гыйлавә итәмен (өстәп әйтәм) ки: максудым, һәр ни кадәр җәфа да чигеп булса да, бер һөнәр үгрәнгәннең соңында, үз ватандаш вә милләттәшләремә хезмәт итмәк вә файда китермәктер.

Мәктәбемездә дәресләр кич укыла. Укыткан өчен акча алмыйлар. Каю мәмләкәт кешесе булса да, кабул итәләр. Программы вә уку тәртибе бик мөкәммәлдер.

*Америка, Сан-Франциско, Х. Байбулатов*

Мәктүб илә хәбәрләшергә теләгән кардәшләрем вә дус-ишләрем өчен адресым будыр:

America, s k
Kunacoff, 928.
Arkansas, St.
San Francisco. Cal. Habibulla Baibulatoff.

[19] Байбулатов Х. Америкадан мәктүб // Вакыт. 1911. 11 сентябрь

## *Хәбибулла Байбулатов. Америка мәктүбләре*[20]

Мәдәни милләтләр өчен сәяхәт итү бик җиңел, бик күңелле бер эшдер. Бәлки алар өчен тәбдил (үзгә) һавадыр. Чөнки мәдәни милләтләрдә байлык бар. Яхшы мәктәпләрдә укыганга күрә, үз телләреннән башка чит телләрдән бер яки ике телне мөкәммәл беләләр. Безнең татар балалары, тәртипле мәктәпләрдә укымаганга, үз телләре илә тугры сөйләшә, тугры вә язу яза белмиләр.

Мин авылда туган, авылда үскән татар малаемын. Мәдрәсәдә миемне черетеп чыккач, эшкә яраксыз булып каңгырып йөрдем. Суыкка дер илә Себергә бардым.

Тайга станцасында Мулланур әфәнде Магазовка хезмәткә кердем. Дүрт ел хезмәт иттем, бераз акча хәзерләдем.

Ниһаять, Америкага китәргә карар бирдем. Хуҗамнан чыгып, дүрт ай кадәр инглиз теле үгрәндем. Чөнки Америкада инглиз теле илә сөйләшәләр. 1911 елда 13 июньдә Владивосток, Япония аркылы Американың Сан-Франциско шәһәренә юнәлдем. Август башында Сан-Франциско шәһәренә җиттем. Япониядә берничә көн пароход көтеп яттым. Икмәк-тоз сорарлык кадәр тел өйрәнгәнгә күрә, һич аптырамадым. Шәһәр хәле илә таныштым. Үземә үзем исем китеп йөрдем. Һәр мәмләкәттә яшәгән кешеләрнең табигатьләре башка икән. Һәр көнне зур урам почмакларында югары бер урынга басып гыйлем, һөнәр, мәктәпләр, хезмәтчеләр, дин хакында лекцияләр сөйлиләр. Бу лекцияләргә урам дәресләре дип әйтәләр. Хезмәтчеләр сигез сәгать хезмәт итәләр. Хезмәтеннән кайткач, матур киемнәрне киеп, яшьләре кичке мәктәпләргә, картлары урам дәресләренә баралар. 1915 нче елда Сан-Франциско шәһәренең читендә бик зур гомуми выставка булачактыр. Америка мәмләкәтенең гыйлем-һөнәрен күрергә теләгән кешегә бу выставканы күрү тиештер. Үзем кичке мәктәпкә кердем. Тырышам. Акрынлык илә инглиз теленә төшенә башладым. Көндез автомобиль фабрикасында хезмәт итәм. Моннан соң «Сибирия» газетасына «Америка мәктүбләре» серләүхәсе илә даимән язып торачакмын.

*Хәбибулла Байбулатов*

## *Хәбибулла Байбулатов. Америка мәктүбләре*[21]

Мин җәгъръафия ихтыйляхынча (атамасы буенча) «Иске дөнья» аталган Русиядә тудым. Русиядә үстем. Хәзер сигезенче айдыр, «Яңа дөнья» дип йөртелгән Америкада торам. Америкага киткәндә, «Сибирия» газетасының чыгуына рөхсәт алынган иде. 1 нче номерга кыска гына бер мәктүб тә язган идем. Менә икенче мәктүб язам. Минем яшем олуг исә дә, шәкертмен. Шәкерт мәктүбе бик мөһим булмаса да, бөтенләй үк файдасыз булмас.

Америка мәмләкәте 1492 елда, 3 августта Христофор Колумб исемендә бер кеше тарафыннан ачылган. Бу кеше беренче мәртәбә Сан-Сальвадор дигән җиргә аяк баскан.

[20] Байбулатов Х. Америка мәктүбләре // Сибирия. 1912. 18 февраль.
[21] Байбулатов Х. Америка мәктүбләре // Сибирия. 1912. 10 март.

Христофор Колумбка кадәр Америка мәмләкәте юк иде. Шуның өчен дә Америкага «Яңа дөнья» диләр. Америка ачылганга хәзер 420 елдыр. Мондагы халык Европаның төрле җиреннән килеп күчеп утырганнар. Иң күбе инглизләрдер. Шуның өчен дә Америкада рәсми, гомуми тел инглиз теледер.

Америка мәмләкәте Европа, Азиягә караганда яңа ачылган, яңа дөнья булса да, гыйлем, һөнәр һәҗәтеннән барысыннан алда, барысыннан югары дәрәҗәдә торадыр. Америкадагы халыкның тырышлыгына, аларның байлыгына бөтен дөньяның исләре китәдер.

Американың һәртөрле машиналары бөтен дөньяга таралдыгы кеби, тегү-чигү һәм дә иген машиналары бөтен Русиянең авылларына кадәр тараладыр. Эдисонның[22] яңа иҗат кылган нәрсәләренә бөтен халык кызыгадыр. Аның граммофоннары бөтен халыкны шатландырадыр. Американың һиммәтле (тырыш, омтылучан) байларыннан Карнаҗиның гыйлем юлына тоткан ярты миллиард акчасы анчак Америкада гына табылгандыр.

Америкада булган миллионер, миллиардерларның саннары башка мәмләкәтләрдә бик аздыр. Америкада һөнәр шулкадәр тәрәкъкый иткәнгә, һәрнәрсә машина илә эшләнәдер. Җирне карый машина, агыр нәрсәләрне күтәрүче машинадыр. Америка халкы җир йөзендә булган бөтен нәрсәләргә үзләре хаким булдыклары кеби, һәр нәрсәне үзләре буйсындыралар. Менә шуның өчен дә Америкадагы инглизләрнең тырышулары нинди гыйлем, һөнәрләргә ирешергә сәбәп булган. Юкса ул инглизләр дә безнең кеби адәмнәрдер, ике башлы түгелләр.

Һөнәр мәктәпләрендә халык тулыдыр. Дәресләр китаптан түгел, машиналардан укыладыр. Андагы фабрикалар мәктәпләрдер. Мәктәпләре исә шуны югары дәрәҗәгә чыгарган.

Машиналар никадәр тиз эшләсәләр, машиналарны эшләгән кешеләрнең куллары да тиз рәсем ясыйдыр. Дөньяда эштән арымаган, эшне яратып эшләгән халык бар исә, алар да американнардыр. Кеше Америка хакында никадәр күп укып белсә дә, күз илә күргәне кеби түгелдер.

Кяшки (әгәр дә) 100 татар баласын Американың һөнәр мәктәпләрендә укытса идек. Безнең халык арасында тизлек илә һөнәр таралуга сәбәп булыр иде. Бу хосуста, хәмиятле (яклаучы) бай татар кардәшләренең уку, укыту эшендә һөнәрчеләр җитештермәк өчен артык һиммәт, гайрәт күрсәтүләрен үтенәм.

Бездә һөнәр бик түбәндер. Ибтидаи хәлдәдер. Үлгән вакытта кия торган кяфенемезне чит милләтләр эшәп бирәләр. Һөнәр, дөнья тормышында беренче рольне уйныйлар.

Хөрмәтле кардәшләрем! Яңа дөньядагы һөнәрләрне файда итмәсәңез дә, иске дөньяда булган Россиянең һөнәрләреннән файда итәргә тырышыңыз.

*Сан-Франциско, Хәбибулла Байбулатов*

[22] Томас Альва Эдисон – Америка уйлап табучысы, эшмәкәр. АКШда 1093, башка илләрдә 3 мең тирәсе патент алган (фонограф, телеграф, телефон, кино җиһазларны камилләштерү һ.б.).

## *Хәбибулла Байбулатов. Америка мәктүбләре*[23]

Америка Русия, Франция, Италия, Япония, Германия вә башка мәмләкәт кешеләре илә тулыдыр. Фәкать Америкага барып торган кешеләр бер дә америкалашмыйлар. Һәркем үз гадәтен, динен саклыйдыр. Американың голүм һөнәреннән, байлыгыннан гына файда итәләр.

Америкада һәр хосуста иркенчәлек булганга, һәркем үзенең көче кадәр эш күрә, үзенең белдеге кадәр яза, сөйли алалар. Һәр милләтнең үзләренә махсус гыйбадәтханәләре улдыгы кеби, һәркем үз динен таратырга ихтыярлыдыр.

Америкада мөселманнар бик аздыр. Америка кеби гыйлем-һөнәрнең учагы булган бер мәмләкәттә мөселманнарның аз булуы бик үкенечтер. Мөселманнар үз мәмләкәтләрендә укымадыклары кеби, чит җирләргә дә китеп укымыйлар.

Безнең Русиядә бай балалары аталары тапкан малга ышанып, гыйлем, һөнәр өйрәнмиләр. Фәкыйрьләр читкә китеп укый алмыйлар, чөнки байлар үз балаларын чынлап укытмадыклары кеби, башка кешеләрнең уку эшләренә ярдәм итмиләр. Бичара татар балаларының акчалары, бик мәшәкать илә табылса да, бик җиңеллек илә бетә, урынсыз җирләргә су кеби агадыр.

Америкада төрекләр байтак бардыр. Бу көннәрдә мин Истанбулдан килгән өч төрек илә таныштым. Мөселман дөньясында кая гына барма, кайгырудан башка нәрсә юктыр. Әлеге таныш төрекләр дә төрек дөньясының гыйлем, һөнәрсезлектән бетәргә якынлашканына бик кайгырып сөйлиләр. Минемчә, хәзер кайгыру илә эш булмыйдыр. Чынлап гыйлем, һөнәр өйрәтүгә тиештер.

Дөнья эшләрендә бар америкалы кебек тырыш, гыйлем-һөнәргә ия булырга кирәктер. Дин эшендә монафыйкъ, мөтәгассыйб (фанатик) булмыйча, чын мөселман ак йөрәкле, матур холыклы, Җәнабе Аллаһның әмерләрен белеп, аңлап кылырга ляземдер. Турысын әйткәндә: безнең мөселманнар мөбарәк дин исламны тапладылар. Гыйлем җиренә наданлык, тырышу җиренә ялкаулык, кардәшлек урынына дошманлык, тугрылык урынына ялганчылык, байлык урыныа фәкыйрьлек, теләнчелек, батырлык урынына мескенлек кергәндер.

Бу начар сыйфатларны бетермичә, мөселман дөньясы алга бармаячак. Бу яман сыйфатларны бетереп чын мөселман булмак өчен татар мәдрәсәсендә генә мине черетмичә, Америкага, Европага китеп укырга, бик күп гыйлем-һөнәр әһеле хәзерләргә форсаттыр. Тәрәккыйнең юлы шулдыр. Әмма бездә бәлеш янында, базарларда, урамнарда, үзара сугышларда шуның илә эш тәмам буладыр.

Кардәшләр! Мин сезгә бик ерактан кычкырам. Алай да булса минем сүзләремне ишетеңез. Себер мәмләкәте байлык ягыннан үзе икенче Америкадыр. Кулыгыздагы форсатны качырмагыз. Дөньяның һәр ягына таралып, гыйлем-һөнәр өйрәник!

*Сан-Франциско, Хәбибулла Байбулатов*

[23] Байбулатов Х. Америка мәктүбләре // Сибирия. 1912. 13 май.

## *Закир Габдуллин. Америка мәктүбләре*[24]

«Вакыт» гәзитендә минем Америкага килгәнлегемне күреп бәгъзе ватандашларымнан («Вакыт» идарәсеннән адрес алып булырга кирәк) хатлар килде. Америкага килеп укырга теләгәнлекләрен белдереп язалар. Уку шартларын, тормыш җайларын сорыйлар. Ихтимал моннан соң да шул рәвеш сораучылар булыр. Шунлыктан мин бу әфәнделәрнең һәркаюсына аерым хат язу урынына «Вакыт» аркылы шул мәслихәтләрне язып китим дидем. Миңа хат язып уку җайларын сорашкан әфәнделәр хатларында шул түбәндә язылачак сөальләрнең җавапларын тиешледерләр:

1. Нинди мәктәпкә керергә тиешләр, ягъни мәктәп бетергәннән соң кем булырга вә нинди эшкә керергә уйлыйсыз?
2. Моңа кадәр кайда укыдыгыз? Татар мәдрәсәләренең берсендә укымыш исәңез, дөньяви фәннәрдән нинди һәм никадәр беләсез?
3. Яурупа лисаннарыннан (тел) нинди лисан беләсез?
4. Акчаңыз бармы? Күпме бар һәм монда килгәч җибәреп торуларына ышанасызмы? Булса, күпмегә ышанасыз?
5. Яшегез ничәдә?
6. Бу сөальләр монда һәр мәктәпкә кергән вакытта сорала торган сөальләрдер. Шул язылган вакытта хат язып сораучыларга җавап бирү җиңел булачак, тәкърар сорашып торырыга хаҗәт булмаячактыр.

Монда беренче дәфга (тапкыр) килүчеләр булмаганда беренче елларын тәэмин итеп килү тиештер. Ят җир булгач, аннан башка да авырлыклар булачагы шөбһәсездер. Безгә дә байтак зәхмәт килде. Сабыр вә мәтанәт (чыдамлык) булып түзгән вакытта ничек тә максудка җитеп була икән. Максудка җиткәч, эш табылып, иптәшләр күбәйгәннән соң, күргән, горбәт чиккән (илдән аерылып, читтә булган) зәхмәтләрнең бары да онытылды.

Америкага килергә теләүчеләр шуны да белергә тиешлеләрдер ки, монда татар мәдрәсәләре, Истанбул җамигъләре юк, мәктәпкә кергән вакытта шул мәктәптә укыла торган дәресләрне яхшы, монтазам (тәртип белән) алып барырлык булсаң гына кабул итәләр. Эш бик катгый. Икътидарың (мөмкинлегең, сәләтең) юк икән, туп-туры: кабул итә алмыйбыз, диләр. Затән (нигездә) бу хәл Европа мәктәпләрендә дә шулайдыр. Шуның өчен кабул булуына ышана алмаган кешеләр теләдекләре мәктәпкә кирәк өчен хәзерлек үтәргә кирәк булачагын да уйлап килергә тиешлеләрдер. Монда һәр мәктәп янында дип әйтерлек ибтидаи сыйныфлар булып, инглиз телен белмәгән кешеләргә шунда кереп инглизчә үгрәнергә, шуннан соң, икътидарлары (мөмкинлеге, көч-куәте) булган кешеләргә, турыдан-туры гали сыйныфларга имтихан кылынырга мөмкиндер.

Гомумән, Америкага килүчеләр, монда килмәстән борын, аз булса да инглизчә үгрәнеп килергә тиештерләр. Инглизчә белү монда эшне яртылай җиңеләйтәдер.

Хаслап (аеруча) үзем укыган мәктәп хакында хәзергә шуны яза аламын: бу мәктәп «Iowa State College» исемле булып, бу көн Америкада мөһәндислектә (инженерлыкта) беренче, зирагатьтә (авыл хуҗалыгында) икенче урын тотадыр. Монда зирагать, мөһәндислек, икътисад, мал докторлары кыйсемнәре бар. Зирагать

[24] Габдуллин З. Америка мәктүбләре // Вакыт. 1913. 25 октябрь.

кыйсеме үз башына: зирагать мөһәндислеге, агроном, судчылык шөгъбәләренә аерыла. Моннан башка ялгыз зирагатьтән мәгълүмат бирә торган бер шөгъбәсе бар. Бу шөгъбәләрнең зирагать шөгъбәсеннән башкалары бар да дүрт сәнәлек гали сыйныфлардыр. Мөһәндислек кыйсеме тагы шулай берничә шөгъбәләргә бүленә. Мәгъдән (рудник, шахта), тимер юл, электрик, машиначылык, биначылык кыйсемнәренә аерылып, һәрберсе бишәр еллык гали сыйныфлардыр.

Бу мәктәптән чыккан кешеләр байтак эш күргәзәләр. Америкадагы Панама каналының бер кыйсемен, Сан-Франциско портын, Колорадода диңгезгә салынган тимер юлны, Чикагода дөньяның беренче станцаларыннан булган станца бинасын, Филиппин әдаләрендә Манила портын бу мәктәптә укып чыккан кешеләр эшләтмешләрдер. Америкада булган бөек эшләрнең һәрберсе дип әйтерлек бу мәктәптән чыккан кешеләр тарафыннан яки аларның катнашы белән эшләнәдер.

Бу мәктәптә еллык расход 800 сум тирәседер. Эш эшләп шуны 300 сумга калдырырга була. Фәкать безнең профессорлар беренче елны эшкә ышанып килүне муафыйкъ күрмиләр. Җәй көннәрне утарларда эшләп ашау-эчү өстенә айга 45–50 сум чамасы табарга буладыр.

Бу мәктәп шул губернаның үз әһалисеннән (халкыннан) алынган налогтан салынмыштыр. Хәзерге тәрбиясе шул вилаятьтә булган халык өстендәдер. Шунлыктан уку хакы үз губернасыннан килгән шәкертләрдән генә алынмыйдыр. Башка губерна яхуд башка мәмләкәтләрдән килеп укучылардан еллык уку хакы 100 сум алынадыр. Фәкать анда да түли алмаслык фәкыйрь кешеләр шул губерна тәбгысы (подданные) булып язылып, акча түләүдән котылалар. Хәзер дә мәктәпнең бөтен мөлкәте 5 миллион 44 мең, 980 сум 44 тиен торадыр. Бу ел бу мәктәптә 2 мең 600 дән артык таләбә (укучы, студент) бар. 220 мөгаллим-мөдәррис дәрес итәдер.

Монда чит хөкүмәтләрдән, хәзинә хисабына җибәрелгән шәкертләр дә бар. Күбесе Җәнүби (Көньяк) Америкадан килгәннәр. Кытайдан бер, Мексикадан бер хәзинә хисабына укый торган шәкерт бар. Монда 120 миллионер баласы укый. Монда һич бай, ярлы аермасы юк. Шул миллионер балалары белән бер табында ашап-эчеп йөриләр.

Минем татарлык монда үзенә күрә кечкенә бер сенсация (кызык вакыйга) булып калды. Зур мәкли (җирле) газеталарның берсендә минем бунда килүемне «Айова зирагать мөһәндислеге мәктәбенә ерак Русиядән бер татар егете килгән» дип язганнар иде. Бик күп кешеләр мәктәпкә килеп, күрешеп чыктылар. «Бу нинди кеше икән?» – диделәр бугай.

Минем гади бер адәм баласы булып башкалардан күп аермам юклыгын күргәч, үзләре дә килеп йөрдекләренә үкенми (разочароваться итми) калмаганнардыр. Бервакыт трамвайда барганда шулай янымда утырган ике ханым, газетада күреп булырга кирәк, «Шул татарны күрәсе иде, нинди кеше икән?» – дип баралар иде. «Шулай бигүк күрәсеңез килә мени?» – дип каршыларына чыгып, американча: «Менә ул күрергә теләдекеңез татар егете мин инде, туйганчы күрергә кулыңыздан килә, хак алмыйм», – дидем. Аптырап калдылар. Монда татар дигәч тә әллә нинди бер халык дип уйлыйлар шикелле. Күргәч, бик озак ышанмый тордылар.

## *Закир Габдуллин. Америкада әҗнәби мәмләкәт таләбәләре*[25]

Американың Айова шәһәренә килеп мәктәпкә керүем илә шул мәктәптә укый торган Кытай, Мексика, Филиппин, Япония, Һулләндия (Голландия) вә гайре мәмләкәтләрдән килгән чит ил таләбәләргә катнаштым. Бик гариб вә бик гаҗиз бер вакытта бу чит мәмләкәт таләбәсе миңа зур бер ярдәм итте. Яныма киләләр, сораша, мотаябә кылалар (кара-каршы күңелле сүзләр әйтәләр), йөрергә алып чыгалар, әлхасыйль, нинди булса бер юл табып, минем ялгызлыгымны оныттыралар иде. Болар арасында мин иң гариб (ватанымнан аерылып, читтә яшәү) булырга тиешле бер вакытымызны да иң күңелле бер сурәттә уздырдым. Болар миңа шулкадәр рәхимле, шулкадәр шәфкатьле иделәр, болар арасында булган вакытта мин үземне Русиядә, туган гаиләм янында кебек хис итә идем. Шунлыктан мин ерак Ватанымда булган иң якын кардәшләремә мәктүбләр язган вакытта бу иптәшләремнең арадашлык юлында кылган инсаниятлекләрен зикер итми (искә алмый) китә алмыйм.

Тәхсил (уку) башы белән чит мәмләкәт таләбәләре үзара җыелышып бер җәмгыять ясаганнар иде. Бу җәмгыять бер пансион тотып, америкалылардан аерым хөр вә мөстәкыйль бер идарәле пансион ачты. Мин дә бу җәмгыятькә әгъза булып шул пансионга язылдым. Кеше башына 150 сумнан акча салдык. 17 кеше җыйналды. 18нчегә мин булдым. Беренче өч ай эчендә, яңа башланган бер эш булганга, расход күп чыга. Хәтта күп кешеләр бурычка керделәр. Соңгы ике ай эчендә һәр эш үз юлына кереп, мәсариф башка гаиләләрдә вә башка пансионнардагы дәрәҗәгә төште. Хәзер бу пансионның кулында шәһәрнең урта бер йирендә иҗарәгә (файдаланып тору, арендага) зур бер йорты бар. Гаилә вә башка пансионнарда[26] торган вакытта үз ихтыярың үзеңдә булмаганлыктан, байтак уңайсызлыклар хасса ителә (хас була).

Әмма монда һәркем үз ихтыярында. Эшне шул пансионнан карап торыр өчен сайлап куйган үз идарә әгъзаларыбыз идарә кыладыр.

Америкада булган чит мәмләкәт таләбәләренең һәр дарелфөнүндә (университетта) шундый бер җәмгыятьләре, пансионнары була икән. Бу пансионнарны яхшырту вә хәлен кайгырту өчен чит чит мәмләкәт таләбәләренең һәр ел гомуми җыелышы да (съезды) була. Үткән җыелыш безнең Айова дарелфөнүнендә булды. Алдагы 1915 елда Сан-Францискода ясарга карар бирделәр. Монда бер Америка гына түгел, бөтен дөнья дарелфөнүннәреннән вәкилләр җыелачактыр. Панама каналының ачылуы мөнәсәбәте илә төрле мәмләкәт вә хөкүмәтләр тарафыннан вәкилләр җыелып, бик зур бер тантаналар булачагыннан дарелфөнүн таләбәләренең җыелышлары да шуннан итагать фарыз кылынадыр.

Бу җыелышның рәисе үткән бер мәктүбендә миңа: «Татар мәктәпләреннән вәкил килсә, һич шөбһәсез, сезгә дә, безгә дә файда булыр», – дигән иде. Мин дә, үз тарафымнан, бик мәслихәт булыр, дип яздым. Һәм, вакыйган, татар шәкертләре, я татар яшь зыялылары исеменнән һич булмаса бер вәкил күндерелсә, яхшы булыр иде. Бу җыелыш гаять дәрәҗәдә киң мәсләкле бәйнәлмиләл бер җыелыштыр. Исеменә

[25] Габдуллин З. Америкада әҗнәби мәмләкәт таләбәләре // Вакыт. 1914. 11 февраль.

[26] Шәкертләр шундагы гаиләләрдә һәм пансионнарда яшәгәннәр. Бу телне өйрәнү өчен уңайлы булган.

«Космополитан» димәктә. Баш сүз (мәузугъ) Motto – «Бөтен милләтләр өстендә бер инсаният»тер.

Мин бу җыелышка килүнең килгәч вә күргәч аңланырга тиешле булган файдалары хакында сүз озайтмыйм. Аны болай да тәхмин кылырга (чамаларга) мөмкиндер. Ләкин асыл шундый җәмгыятьләргә кушылып бәйнәлмиләл хәрәкәте эчендә булынырга тырышу үзе безнең дөньяда барлыгыбызны исбат кылыр дәрәҗәдә бөек бер эш булачактыр. Шунлыктан мин русияле татар шәкертләренә самими калебтән (йөрәктән) бу җәмгыятькә вәкилләр, һич булмаса бер вәкил йибәреп исбат вөҗүд кылуны (катнашуны) тәүсыя кыламын (киңәш итәм). Ләкин шуны да әйтергә телимен ки, бу иҗтимагъка вәкил булып килү өчен инглиз телен белү мотлак ляземдер (тиеш). Чөнки әксәриятнең (күпчелекнең) карары илә һәр эш инглиз телендә йөртеләдер. Татар таләбәләреннән бу җәмгыятькә иштирак итәргә (катнашырга) теләгегез булса, алдан хәбәрләшеп куярга кирәк булыр.

Хәбәрләшү вазифасын мәгальмәмнүният (шатланып) үз өстемә алырга әзердермен.

*Закир Габдуллин (Айова)*

## *Сакмарый. Шам хатирәте*[27]

Поезд барып туктагач та, вокзалга төшеп, шәһәргә китү чараларын төшендек. Янybызда авыр нәрсә булмаганлыктан, җәяү китү дә мөмкин иде. Бервакытларны Истанбулда чыга торган бер журналда мөхәррирлек иткән кырымлы һәмшәһри (якташ): «Татарга паспорт кирәкми», – дия. Вә моннан: «Татар кайда гына күренсә дә, ачык танылып тора», – диюне аңлата иде. Без сумкабызны отельгә алып бару өчен хәммаль (йөк ташучы) берлән сөйләшеп торганда, янымызга яшь кенә бер кеше килеп, татарча эндәште. Ул безне кыяфәтемездән таныган. Без дә аның килгәнен күрү берлән үз кешемез икәнен зан иткән (аңлаган) идек. [...] Бу әфәнде – Шамның «Мәккәи Мөкәррәмә» отелендә мосафир ирләр кабул итеп торучы русияле Талип әфәндедер. Ул безне тугры үзләренең отеленә китерде вә анда калган бер хәфтәдә (атнада) һәр җәһәттән безне рәхәт итте.

Төркиядә бер акча мәсьәләсе бар ки, кайда гына барсаң да, шуның рәхмәтен күрәсең. Син Истанбул я Бәйрутта эстәсәң, бөтен гомерең буе утыр, Шам, Хәләб, Багдад шикелле башка бер йиргә барсаң, акча мәсьәләсендә аптырап каласың вә беренче мәртәбәсендә, мотлакан (һич бернигә карамый), алданасың. Талиб әфәнде безгә бу хосусларда да ярдәм итте, безнең бер тиенемезне дә башкаларга йибәрмәде. Шамда алданмый, таланмый, рәхәт-рәхәт көн үткәреп китәргә теләүчеләр мәзкүр Талип әфәндегә юлыксалар, һәр җәһәттән мәмнүн калачакларына әминмен. Талип әфәнде аларның мәшһүр зиярәтләрне карап-танышып йөреп чыгуларына вә юл өчен лязем булган әсбапларны, кайтышлый булса, Русиягә китерәчәк Шам хатирәсе һәдияләрен алданмый алуларына ярдәмче булачактыр.

Мөнәсәбәте чыккач шуны да әйтеп үтим әле: безнең Русия мөселманнарында тәшәббес (тапкырлык) шәхсән төрекләр вә гарәпләрнекеннән күп алда диләр. Менә моңа бер мисал кирәк булса, ул Талип әфәндедер. Шамда берничә елдан бирле

[27] Сакмарый. Шам хатирәте // Шура. 1913. № 20. Б. 613–614.

хаҗилар каршылау вә озату берлән шөгыльләнгән бу әфәнде читтән килүче мосафирларга Шамның мәшһүр зиярәтләрен, мәхәлләләрен күрсәтерлек дәлилләр юклыгын игътибарга алып, аларга бераз ярдәмче булу өмиде берлән бу шәһәрнең мәшһүр урыннарын бәян итеп, бер рисалә тәртип иткән вә эченә Шам мосафирларына лязем бәгъзе мәгълүмат вә тәнбиһәт (искәртүләр) дә куелган. Ул аны тиздән бастырып чыгарачак. Мондый рисаләләрнең сәяхләр өчен булган әһәмияте язып бетергесез. Тарихи урыннарның рәсемнәрен генә күрү берлән, аларның ни икәнлеген белми генә карап чыгу арасында күп фәрекъ (аерма) юк. Талип әфәнденең бу тәшәббесе мондагы төрек вә гарәп зыялыларына бер гыйбрәт булырга тиештер. Ләкин, әминмен ки, аны игътибарга алып, уйлап караучы булмас. Америкада утырган бер христианның Сүрия харитасын (картасын) ясап бирүеннән мөтәәссир (тәэсирләнгән) була алмаган кешеләр үз диндәшләреннән берсенең Шам дәлиле язып чыгаруына күп игътибар итмәсләр. Моннан соң Шамны зиярәт итүчеләр бу рисаләдән файдаланырга тиешле. [...]

### *Фуад Әнвәров. Вальпараисо университеты (Америкада)*[28]

Вальпараисо шәһәре Шимали җөмаһир мөтәфәкъкыяның (Төньяк берләшкән җөмһүриятләре)[29] Индиана вилаятендә Чикаго шәһәренә ике сәгатьлек җирдә 4–5 мең халыклы бер илдәдер. Мистер Браун атлы мәгариф сөюче бер кешенең[30] тәшәббесе (инициативасы) илә 1873 елда шушы шәһәрдә университет ачылган[31]. Шуннан бирле дәвам итеп килә. Ачылган вакытында бу университетның шөгъбәләре (бүлекләре, факультетлары) бары ике, шәкертләре дә ялгыз 35 кенә булган. Шуннан бирле дәвам итеп, 40 ел эчендә шөгъбәләре 23 кә, шәкертләре саны алты меңгә җиткән. Америкада тәрәкъкыйнең ничек барганлыгын күрсәтергә бу кяфи (җитәрлек) булса кирәк. Хосусән үземезнең Русия мөселманнарында 10 ел эчендә булган тәрәкъкыйнең ни дәрәҗәдә генә икәнлеге күз алдына китерелсә, фәрекъ (аерма) бигрәк ачык зәһи булыр (яхшы күренер).

Бу шөгъбәләрнең иң мөһимләре зирагать (игенчелек, агрономия), тиҗарәт (сәүдә), тыйб (медицина), хокук, ташчылык (төзелеш), голүме табигыя (табигать белеме), мәгариф, музыка шикелле гыйлем вә фәннәрдән гыйбарәттер.

Бу университетка керергә хәзерләү өчен шунда үзенең янда ук, гимназия дәрәҗәсендә булган «Һай шкул»[32] вә «колледж» кыйсемнәре (өлешләре, бүлекләре) дә бар. Мәктәпнең ишеге һәркем өчен ачык. Дин, милләт, мәзһәб аермалары һич

---

[28] Әнвәров Ф. Вальпараисо университеты (Америкада) // Шура. 1914. №22. Б. 697–699, 1915. №2. Б. 54–56.

[29] Төньяк Америка берләшкән штатлары – АКШ.

[30] Генри Бейкер Браун, педагог.

[31] Вальпараисо университеты 1859 елда Кушма Штатлардагы ир балалар һәм кызлар бергә укый торган иң беренче көллиятләрнең берсе буларак барлыкка килә. Гражданнар сугышы вакыйгалары белән бәйле рәвештә 1871 елда ул ябыла. Кабат 1873 елда эшли башлый. 1900 елда университет статусын ала.

[32] Хай-скул (high school) – Америкада көллияткә яисә университетка керү өчен мәҗбүри урта белем дәрәҗәсе, 9–12 сыйныфларга туры килә; урта мәктәп.

игътибарга алынмый, һичкемгә кысынкылык вә процентлар да куелмаган. Шуның өчен монда дөньяның дүрт тарафындан вә җәһәтендән биш кыйтгасыннан шәкертләр бар. Ирләр илә кызлар бергә укый. Шәкертләрнең ярты микъдары кызлардыр. Затән (нигездә) бу Вальпараисо шәһәре үзе дә Америкада гыйлем вә тәхсил (гыйлем алу) шәһәре булып танылган.

Бу дарелфөнүндә (университетта) укучы студентларның хәят мәҗмугасына (бу урында: төрлелегенә) карасак, үзеңне милләтләр выставкасында дип хисап итәргә мөмкин: испанияле, итальян, серб, болгарлардан башлап, Европадагы һәртөрле милләтләрнең шәкертләре өстенә, монда иранлы, яһүди, татар, поляк, литвин (литвалы) балалары да аз түгел. Бу төрле милләт балалары арасында күплекне Русия кул астында булган әҗнәбиләр (инородецлар, рус булмаган милләтләр) тәшкил итәләр. Русча сөйләшүчеләрнең күплегенә караганда, бу җирне Русия инородецларының колониясе дип әйтергә мөмкиндер. Шушы кадәр күп милләтләр вә мәзһәбләр арасында, мәгатәәссеф (кызганычка каршы), мөселманнарның хисапларын санар өчен ике кулдагы бармаклар җитә. Бәлки бераз артып та кала: ике татар, ике гаҗәми (гарәптән башка, иранлы, фарсы), ике гарәп, бер һиндлы. Барлыгы җиде кеше! Мөселманнарның саннарына күрә иң азсанлы икәнлеге шөбһәсез.

Университет демократический әсасларга (нигезләргә) корылган. Монда нәсел, байлык, кибарлык (зурлык, бөеклек), мәзһәб, милләт, табгалык (кемгәдер иярү) шикелле нәрсәләр һичбер роль уйнамыйлар. Мәктәп идарәсе мондый хәлләрне белми, шәкертләрнең мондый җиһәтләрен (якларын) һичбер игътибарга алмый. Аның каршында һәммәсе дә тигез. Һәммәсе дә мәктәп өчен мөкатдәс (изге, бөек) балалар санала. Мәктәп шәкертләргә: «Укырга, гыйлем вә мәгариф тәхсил итеп бер мәсләк (дөньяга караш, принцип) вә һөнәр иясе булырга килгән», дип карый вә аларны шул максатларына ирештерер өчен һәммә хезмәт вә фидакарьлекне итә. Мәктәп идарәсе үзен шулкадәр яхшы куйган ки, шәкертләр бу мәктәпне мәхыз (фәкать, бары тик) үзләренең сәгадәтләре дип, күктән иңдерелгән бер нигъмәт дип карыйлар, мәктәпне чын күңелдән, чын мәхәббәт илә сөяләр. Шулай итмәслек тә түгел: уку касды (нияте) илә бу мәктәпкә килгән кеше һичвакыт кире кайтарылмый. Гыйлем йортына килгән кешене маэйүс (өметсез) итеп, кире борып җибәрүне америкалылар «гөнаһе кәбаир»дән (зур гөнаһтан) саныйлар. Мәктәпкә мөрәҗәгать иткән кешенең укырлык, торырлык байлыгы булмаса, мәктәп идарәсе үзе рәтен табып, аны укыта, эш бирә, фатир бирә, мәукыйть (вакытлыча) бер заман өчен аңа һәрнәрсә тәэмин итә. Ләкин буш түгел. Америкада «буш», «сәдака» дигән нәрсәләр юк. Булса, белә монда һичкем: андый йөз суы мокабиленә (алмашына) алына торган нәрсәләрдән файдаланачак түгелдер. Монда һәр нәрсәнең мокабиле эштер. Монда һәрнәрсә эш. Соңгы вә гайрәт илә алына вә бирелә.

Мохтаҗ шәкертне мәктәп идарәсе шулай үзе тәэмин итәчәк, үзе өчен чыккан һәммә мәсарифны (чыгымны) түләргә аннан бер сәнә (расписка) ала. Тәгътыйль заманы (каникул, ял вакыты) җитү илә, мәктәп идарәсе аңа үзенә мөнәсәбәт вә үзе белгән берәр хезмәт табып бирә. Шулай итеп, акча тапкач, шәкерт үзенең мәктәп идарәсенә булган бурычын түли. Аның өстенә бераз мөддәт (вакыт, срок) укырлык акча да хасыйл итә. Икенче тәгътыйльдә тагы шулай итә. Шул таригъча (ысул белән) уку сәясендә укып кәмаләт (өлгергәнлек) вә һөнәр кәсеп итә бара. Бәрәкәтле хәрәкәт түгелме? Затән (чынлыкта) монда гыйлем вә мәгарифкә дә бүтән төрле карыйлар. Монда гыйлем дип эшли белүгә, ясый белүгә, такыр-токыр акча китерә торган

нәрсәләрне мәйданга китерә белүгә әйтәләр. Файдалар ятлау, шулай булса болай булыр, болай булса тегеләй булыр, дип чүбек чәйнәп торырга, күңелдән вә фарыз берлән әллә нинди мәсьәләләргә фәтвалар бирүгә монда гыйлем димиләр. Ни дип әйтә торганнардыр, белмим. Чөнки монда андый нәрсәләр бөтенләй юк.

Мәктәптә укый торган шәкертләр шул шәкертлек заманнарында ук эшләгәннәре өчен ашау-эчү илә көненә бер доллар (ике сум) акча таба алалар. Шул сурәттә (рәвешле) фәкыйрь шәкертләр үзләре эшләп акча табып тәхсилләрен дәвам иттерә алалар. Фәкать бу рәвешчә уку җиңел бер эш түгел. Чөнки гомуми тәгътыйль вакытларында гына тәхсил өчен җитәрлек акча табып булмый. Шуңа күрә тәхсил вакытларында укуны мәукыйть (вакытлыча) туктатып торып, эшләп алырга тугры килә. Бу исә уку мөддәтен (срогын) кичектерергә сәбәп була. Мәсәлән, монда укып яткан ике татар баласы, шул акчасызлык сәбәпле укуымызны 2 ел ярымга кичектерергә мәҗбүр буламыз. Бу ике ел ярым мөддәт шул мәктәптә укуымызны тәэмин итәр өчен акча табуга сарыф улыначактыр. Акчасы булган шәкертләр гаять рәхәтлектә уларак тәхсил итәләр, бик рәхәт гомер кичерәләр.

Мәктәп уку урыны гына түгел, шәкертләрнең ашау-эчүләре, торулары да шунда. Боларны барысын да мәктәп идарәсе карый. Мәктәп янында шул алты мең студент торырлык бик зур һәйбәт биналар бар. Болар әллә ничә бина. Һәркаюсында икешәр кешелек бүлмәләр ясалган. Бүлмәләрдә кирәкле һәммә мебельләр, карават, юрган, мендәр, одеал, җөласа: һәммә нәрсә бар. Һәркаюсы искиткеч яңа һәм тәза. Һәрнәрсә нәфис вә гүзәл. Керләрне һәр атнада юып тапшырып торалар. Боларның барысы да мәктәп идарәсеннән. Монда шәкерт мәктәпкә килгәндә бездәге шикелле постельләр, мендәрләр вә әллә нәрсәләр йөкләп йөрмиләр. Китабын тотып килә. Ашау да мәктәпнең үзендә. Мөкәммәл (камил) ашханәләре бар. Гаять зур һәм монтазам (тәртипкә салынган) столовойлар бар. Ир вә кыз шәкертләр бергә утыралар. Хәтта 12 урындыклы бер өстәл тирәсенә утырганда шәкертләрнең алтысы ир, алтысы кызлар булалар. Шулай таныйлар монда мөсавәтне (тигезлекне). Шулай һәр тәрбия эшләре монда яшьләрне шундый хөр вә идракъле (аңлап эш итүчән, хәлгә керүчән) тәрбия генә адәмне адәм иткәнлеген монда бик яхшы аңлаганнар.

Иртә вә көндез кич берлән өч мәртәбә аш бирәләр. Аш хакы айга 36 сум илә 48 сум арасындадыр. Эшләр шул тарафча корылганга, һәммә нәрсә монтазам машина шикелле эшләп тора. Шәкертләрнең һәр нәрсәләре тәэмин ителгән. Күңелләр тыныч, бөтен мәшгулиятләре дәрес кенәдер. Ләкин шуны да истә тотарга кирәк ки: мәктәп идарәсе дигән әйбер дә монда шәкертләр үзләредер. Бу эшләрне бер кешенең приказы, әмере йөртми. Шәкертләрнең совет мәҗлесләрен аларның үз тәдбир (алдан күрүчәнлек) вә фикерләре йөртә. Мәктәп мөдире бары машинаның кабиленнән (кабул итүче), назыймы (тәртипкә салучы) гынадыр. Ул шул эшләрнең монтазам йөрүләренә нәзарәт (күзәтчелек) кенә итеп тора. Хәтта мәктәпнең идән себерү, бүлмәләр җыештыру, аш пешерү, табак-саба юу, кыш көне пичләрне ягу шикелле эшләрне дә шәкертләр үзләре эшлиләр. Фәкать боларны шәкертләр эшли. Буның өчен аларга хак тәгаен ителгәндә, эш өчен акча түләүдән гафу ителәләр һәм бу эшләү аларның тәхсилләренә дә манигъ (киртә) булмый, чөнки эшләре көненә ике сәгатьтән артмый. Шуны да хәтердә тотарга кирәк: бездә гыйбадәткә ничек мөкатдәс карыйлар исә, монда эшкә шулай мөкатдәс карыйлар. Бездә гыйбадәт иткән кеше, кем генә булсын, ничек кенә булсын, ничек кенә яхшы саналмакта исә, монда эшләгән кеше файда гына булсын вә ни генә эшләсен, кем генә булсын, шулай яхшы

саналмактадыр. Эшләү монда һичкем өчен, һичвакытта гаеп саналмый. Эшләмәү, эштән тартылу, эштән җирәнү генә иң зур гөнаһ санала. Андый кешегә машинаның хәрәкәтенә манигъ булып торган бер чөй дип карыйлар. Бара торгач, ул чөйләр читкә ыргытылырга мәҗбүр булалар.

Әгәр, бездә шулкадәр күп җирле башкортлар бар, җирләрен эшләп файдаланмыйлар, җир эшләү голүмнәрен үгрәнмиләр; ач торырлар, алама яшиләр, бәгъзеләре хәер сорашалар яки башка кешеләрнең нәрсәләрен угрылыйлар дип сөйләсәң, вә Алла Әгъләме (иң яхшы белүче), һичкемне ышандыру мөмкин булмастыр. Чөнки андый бер хәлне халык зиһеннәренә һичбер төрле сыйдыра алачак түгелләр.

Без, монда ике татар баласы, укудамыз. Иптәшем Ташкент татарларыннан Галимҗан әфәнде Сәйфелмөлековтыр.

Вальпараисода ысулы тәдрис (дәрес бирү) безнең белгән ысулдан бөтенләй башкачадыр. Монда дәрес тәгаен итү мәктәп идарәсенә түгел, бәлки шәкертләрнең үзләренә гаидтер. Шәкерт үзенең көче җитүенә карап, көненә 4–5–6 сәгатьләр дәрес укырга мөмкин. Хәтта урта мәктәпләр илә бәгъзе бер шөгъбәләрнең уку мөддәтләре бөтенләй тәхдид тә ителмәгән (чикләү куелмаган). Һәр дәрес өчен бер мөгаллим тәгаен ителгән вә һәр мөгаллимгә бер сыйныф бирелгән. Сыйныфтан сыйныфка йөрү бездәге шикелле мөгаллим вазифасы түгел, бәлки шәкерт вазифасыдыр. Кайсы дәрес булса булсын, атнада биш сәгать укыла вә билгеле бер мөддәт зарфында (шартында) икъмаль ителәдер (камилләштерелә).

Монда елның бер ае тәгътыйльгә (каникулга) бирелә. Калган дүрт кыйсем «тәрм»гә (семестрга) бүленә. Сәнәви (еллык) имтиханнар монда юк. Һәр тәрмдә өч мәртәбә имтихан бирелә. Бу өч имтиханда алган балларның мәҗмугын (барысын бергә туплап) өчкә бүлеп, шәкертләргә балл бирәләр. Шулай итеп, шәкерт бер ел эчендә унике имтихан тота. Имтихан бик еш булганга күрә, шәкерт өчен бер дә читенлек бирми. Имтиханнар һәрвакыт тәхрири (язу, язмача) вә фәүкылгадә (гадәттән тыш) нәзарәт (күзәтчелек, контроль) илә иҗраэ ителәләр (башкарылалар).

Университетның һәйят (комитет) мәҗмугасы бер гаилә учагына охшый. Һәйят идарә бу гаиләнең рәисе, шәкертләр дә ифрадыйдыр (аерым). Мөдиррият һәрвакыт үз шәкертләренең рәхәте вә сөһүләтләрен (уңайлыкларын) төшенеп тора. Акчасы булмаганнарга эш бирә. Хәтта хутор вә фирмалар илә хәбәрләшеп, акчага ихтыяҗы булган шәкертләрне шунда эшкә җибәрә.

Затән тәгътыйль вакытында шәкертләрнең барысы да диярлек шундый фирмаларга хезмәткә таралып бетәләр вә уку елы башына кадәр эшләп бер кыш укырлык акча тәэмин итәләр. Монда таләбә хәяте шулайдыр. Урта дәрәҗә вә фәкыйрь булган шәкертләр үз көннәрен үзләре күрәләр. Аталарыннан күргән ярдәмнәре үзләре тапканга караганда бөтенләй юк дәрәҗәдә.

Университетның бинасы, идарәсе вә һәммә шөгъбәләре Вальпараисо шәһәренең бер читендә булып, аерым бер мәхәллә тәшкил итмәктәдер. Ишгаль итдеге (шөгыльләнү өчен) берничә урамында һәр нәрсә табыла. Сачтараш, тегүче, аптека вә һәртөрле магазиннар бар. Йомыш үтәр өчен шәһәргә барып маташырга бер дә кирәкми. Һәр нәрсә янында. Өеңнән чыгып мәктәпкә, мәктәптән чыгып өйгә керәсең. Кыш көннәрендә мәктәпкә бару өчен туннар киеп, шарфлар урарга хаҗәт булмаган шикелле, җәйнең эссе көннәрендә сыйныфка кергәнчегә кадәр тирләргә дә вакыт калмый. Мәктәп янында. Аш-су хәзер. Хәят тыныч. Дәрестән башка һичбер

мәшәкать, һичбер эш юк. Шәкерт хәяте даимән шатлык илә үтә. Студентлар даимән бер-бере берлә сөйләшеп, уйнап-көлеп йөриләр. Араларында тәмам дуслык вә мөсавәт (тигезлек).

Мәктәпнең театр залында тәгътыйль көннәрендә театрлар уйнала, концертлар, конферанслар бирелә, төрле уеннар тәртип ителә. Халисән (чын күңелдән), кайгысыз бер хәят кичерелә. Көннәрнең үткәне сизелми дә кала. Үткән көннәр берсеннән-берсе зәвыклы вә нәшатлы (шатлыклы) була бара. Бу яшьләр җәмгыяте арасында яшәгән саен, кешенең яшисе килә, хәяткә мәхәббәте арта.

Атнаның шимбә вә якшәмбе көннәрендә тәгътыйль була. Шимбә көн шәкертләрнең үз хосусый эшләрен карауга хәзер ителә. Бу көн таләбә үзләренең керләрен юалар, бүлмәләрен тазартып, интизамга (тәртипкә) куялар, эссе ванна алалар. Якшәмбе көннәре исә ялгыз истирахәткә (тынычлыкка, ял итүгә) махсустыр. Бу көн ир вә кыз шәкертләр барысы бергә катнашып гөруһ-гөруһ (төркем-төркем) булып тәнәззеһ (күңел ачу) вә истирахәткә китәләр, кырларга чыгалар, урманнарга баралар, анда ярыш, көрәш ясыйлар, туп уеннары уйныйлар.

Монда укучы чит милләт шәкертләренә карап: «Аһ, безнең татарлар да күбрәк булса иде», – дип әйтми үтеп булмый. Башка милләт яшьләренең мәгарифкә куйган һәвәсләрен, аларның фигълияте (эш-гамәлләрен) вә рухлыкларын күреп кеше кызыга. Кешеләр дөньяның һәр тарафыннан монда бар. Туган-үскән ватаннарыннан аерылып, Америка шикелле ерак бер җиргә килгәннәр. Максат вә мәсләк (тоткан юл) хакына рәхәтләрен фида иттереп (корбан итеп), кичә-көндез тырышалар вә ахырында, һич шөбһәсез, максатларына наил булалар (ирешәләр).

Бездә дә тырыш, гыйлем-мәгърифәт гыйшкы булган, шуның илә бәрабәр зиһен вә фикерләре башка милләт балаларыннан бер дә ким булмаган татар балалары аз түгел. «Шушындый җирләрдә укысалар, боларның да башка милләт балалары шикелле үк кеше булачаклары, болар арасында да зур кешеләр, гыйлем-мәгърифәт әһелләре, һөнәр вә сәнәгать әрбабы (әһелләре) җитешәчәге кояш кебек заһирдыр (ачык).

Мин бу мәктүбемне үз милләттәшләремнең назар-дикъкатьләрен җәлеп итәр өчен язам. Безнең яшьләр арасында да ерак җирләргә китеп тәхсил һәвәсендә булган кешеләр аз түгел. Мин шундый кешеләрне Вальпараисога чакырам. Без дә башка милләт яшьләре кебек барлыгыбызны күрсәтик, татарның нәрсә икәнлегеннән хәбәре булмаган америкалыларга аның Шәрыктан туып килә торган кояш шикелле төрле вә өметле бер милләт булганын белдерик. Безнең яшьләр, мәгатәәссеф белән (кызганычка каршы), чит мәмләкәт мәктәпләренә аз баралар. Русия мәктәпләрендә укучылары да күп түгел. Милләтемезнең тамырларын бераз киңрәк сахәләргә (мәйданга) таба җәеп җибәрик. Үземездән гали булган башка милләтләр арасында таралыйк. Алардан дәрес алып бераз дөнья күрик. Америка, телдән сөйләргә ерак кебек күренсә дә, хакыйкатьтә ул кадәр ерак түгел. Килер өчен юллары бик монтазам һәм ансат. Монда килгәндә вәхши бер мәмләкәткә килеп төшелми. Мәдәният, инсаният вә гыйлем дәрьясына килеп төшелә.

Шулкадәр бар ки, һәрнәрсәдән бигрәк телгә ихтыяҗ бар. Монда инглиз теле истигъмаль ителә (кулланыла). Ул бик авыр бер тел дә түгел. Бер мәртәбә әсасенә (нигезенә) төшенгәннән соң, бу телне шәкерт үз-үзеннән тәрәккъый иттерергә мөмкин. Шуның илә бәрабәр әүвәлдән белмәгән кешенең әүвәлге елы шушы инглиз телен өйрәнүгә китәчәктер. Моны аз да булса электән белеп килү бик файдалыдыр.

Уку өчен еллык мәсариф шөгъбәләргә карап төрлечә була. Мәсәлән, музыка, ташчылык, тыйбби шөгъбәләре өчен уку хакы еллык 300 сум. Урта тәхсил дәхел улдыгы (кушылган) хәлдә, башка шөгъбәләр 130 сум. Ашау вә фатир өчен еллык иң аздан 180 сум чыга. Китап вә башка нәрсәләр өчен еллык 60 сум кадәр расход чыга. Халисән, һичбер төрле эш белән шөгыльләнмәенчә вә эшләп читтән акча табарга мохтаҗ булмаенча укыр өчен, сәнәви аздан 370–400 сум акча хаҗәт буладыр. Ләкин моннан куркырга ярамый. Эш эшләп укырга да бик мөмкин. Мәсәлән, эш өчен алсагыз, бу мәсарифның яртысы берлән үткәрергә мөмкин. Җәйнең бер ай тәгътыйлендә дә эшләп ташласаңыз, мәсариф бөтенләй азая.

Вальпараисога килеп төшкәндә янында 500 сум акчасы булган кеше шул акча илә максудына ирешкәнчегә кадәр укый аладыр. Русия урта мәктәпләренең шәһадәтнамәсен алган кешеләрне монда гали шөгъбәләргә имтихансыз кабул итәләр. Моңа малик (ия) булмаган кешеләр илә монда килгәч ике елда урта мәктәп тәхсил тәмам итә алалар.

Монда килергә теләгән кеше, сәфәргә чыкмастан, элек күзләрен яхшы докторга күрсәтеп сәламәтлегенә даир шәһадәтнамә алырга кирәк. Авыру күзле кешеләрне монда кертмиләр. Хосусан, Нью-Йоркта юлчыларның күзләрен бик дикъкать итәләр.

Мин үзем монда Истанбул аркылы килдем. Истанбулдан туры Нью-Йоркка билет 66 сумга алдым. Нью-Йорктан Вальпараисога барыр өчен тимер юл 10 доллар (30 сум түләдем).

Дәхи дә (тагын да) күбрәк мәгълүмат алырга теләгән кеше булып, миңа мөрәҗәгать итсәләр, мәгалмәмнүния (шатланып, бик теләп) җавап язачакмын.

Адресым түбәндәгечә:
*Сибирияле Фуад Әнвәров.*
Америка
Amerique
m-r F.Anveroff. South compus № 2.
Valparaiso University.
Valparaiso Indiana. N.S.A.

## *Мөҗавир З. Америка хәяты (Шимали Америкада, Вальпараисода)*[33]

Мин Америкага килмәс борын Америкада киченү бик авыр булыр дип уйлый идем, минем шикелле бик күп татар таләбәләренең дә шул фикердә булулары мөмкин, ләкин бу бер дә тугры фикер түгелдер. Чөнки уку фикеренә бирелгән бер талиб һәрвакыт истикъбале (киләчәге) хакында төшенә һәм үз мохитенең мөмтаз (аерылып торган, өстен) бер фәрде (аерым шәхесе) булырга тырыша, шуның өчен дә гомеренең газиз бер кыйсемен парлак (данлы, күркәм) истикъбальгә малик булу өчен хыялланып уздыра, ул сәгатьләрчә хыял диңгезендә чума, дөньяның әллә нинди караңгы почмакларына кадәр китеп булса да укуга разый була. Фәкать икътисади

[33] Мөҗавир З. Америка хәяты (Шимали Америкада, Вальпараисода) // Вакыт. 1915. 4 апрель.

кысынкылык зәвалы (житешмәве) таләбәнең парлак фикерен җимерә, ул үзен мәхдүд (чикләнгән, чикле) бер рамка арасына кысылган, мәхбүс (тоткын) бер инсан фарыз итә, өметсезләнә, зарлана, дөньядан бизгән кайгылы кыяфәт күрсәтеп ялкынлы сулыш ала вә шуның белән бергә төзелгән бөтен планнары да янып көл булып оча. Ул никадәр уйласа да, фәкыйрьлек, зурайганлык аякларын чала, үзе өчен һичбер төрле хәят, вөҗүд (барлык, булу) тасвир итә алмый.

Ләкин хәят ялгыз бер Русиядә генә түгел. Дөньяның һәр тарафында яшәп була. Хосусан америкалылар шикелле инсан белән хайван арасында аермасы там (тулы) мәгънәсе илә аңлаган бер милләт арасында яшәү тагын да җиңелрәк, тагын да уңайрак булырга тиешле һәм шулай да. Мондагы хәятнең әсасе (нигезе) уку белән эшләүгә бинаэн ителгән, уку юлына кергәннәре үлгәнчегә кадәр укыйлар, чөнки мондагы укуның чиге юк, дәрәҗә дәрәҗәгә бүленеп тәгали итә (югарыга бара, үсә, бөекләнә) бара, университет бетергән бер таләбә бер-ике сәнә профессорлык итә, я башка бер эш белән шөгыльләнә дә, соңра мәктәпкә килеп бер сәнә укып бер фәндә ихтисас (берәр эшнең яхшы белгече) кәсеп итә. Тагын да дөньяга чыгып бер-ике сәнә эшләгәч, кире килеп бер сәнә тагын да укый, икенче бер фәндә ихтисас кәсеп итә. Һәр сәнә укыган саен жалованьесы дә, дәрәҗәсе дә арта бара. Шулай итеп, үлгәнгә кадәр укуны дәвам итәдер.

Эшче кыйсеме исә армый-талмый вакытында бер минут та әрәм итми (Америкада «Вакыт нөкуд (акча)» димиләр, бәлки «Вакыт – хәят» диләр), гомеренең соңгы чигенә кадәр эшли, эшләүнең сыйххәткә (сәламәтлеккә) бөек файдасы бар идеген хак илә тәкъдир иткәннәр. Көн дә илле рубля мәгаиш (яшәү өчен кирәкле акча) алган бер карт профессор өйләдән әүвәл дәрес укыта. Өйләдән соңра исә иске киемнәрен киеп кулына сәнәген тотып кырга эшләргә китә. Ул яшь вакытыннан ук шул хәяткә үгрәнгән, вөҗүден ныгыткан, безнең бабайлар шикелле ыңгырашып һич мич башында ятмыйлар.

Әлхасыйль, Америка хәяте безнең хәяткә бөтенләй башка бер агым белән ага, рухлы, татлы бер юл белән бара. Бу мохиткә килеп кергән кеше эстәр-эстәмәс фигълияткә (эшләр) үгрәнә, хәятын тәртипкә сала. «Инсан мохитенең әсиредер» кагыйдәсе гомуми булганга күрә, Америка мохите монда килүчеләрнең хәятен күп вакытта чыгырыннан да чыгарып җибәрә. Мәмләкәтләрендә кара эш белән киченүгә үгрәнмәгән кешеләр дә, монда килгәч уку юлына кереп киткәннәр.

Вальпараисо дарелфөнүненең бик күп таләбәләре дөньяның һәр тарафыннан эш эзләп килгән эшчеләрдән гыйбарәттер. Бер-ике сәнә эшләп акча тапдыгынан соңра мохиттән гыйбрәт алып, 30–40 яшендә булуларына карамыйча, уку юлына кергәннәр. Электән уку күрмәгән бу кыйсем халык өчен тәхсил (белем алу), гыйлем өслүбенә төшенеп китү авыр булса да, америкалыларның «Түзем генә төзәтер эшегезне» дигән кагыйдәсе буенча бер-ике сәнә югалтуларына рәгъмән (каршы килеп) һәртөрле авырлыкларга каршы күкрәк киереп укуда дәвам итәләр һәм дарелфөнүн бетереп, үзләренең «көтүче» исемен профессор я докторга әйләндереп, мәмләкәтләренә кайтып китәләр.

Хасыйли, Америкага килүеннән мәмнүн булмаган һич кешегә очрамадык. Чөнки бу вакытка кадәр монда килүчеләрнең күбесе хәятларыннан бизгән кешеләр булган, мәмләкәттә эш юк, кичену авыр яхуд башка бер сәбәпләрдән тулаем хәяттан туйганга күрә, дөньяның ерак бер читенә башын алып качуны интизам иткән (тиеш дип тапкан) һәм Американың шәфкатьле кочагына килеп атлаган.

Америкада һәр сыйныф өчен вөҗүд бар, бигрәк тә һөнәрле кешеләр бик күп казануга мөмкин. Сәнәгыять бөтенләй мәхрүм кара эшчеләрдә иң киме көнлек дүрт рубляга кадәр эшлиләр. Берничә сәнә эшләп өчәр-дүртәр мең рубля казанып мәмләкәтләренә янә китүче кешеләр дә бик күп. Дөньяның һәр тарафыннан миллионнарча эшче халык Америкага агылганы хәлендә, безнең татарлардан бу вакытка кадәр килүче бер дә ишетелмәгән, Америкага килү юк. Килгәч тә үгрәнүгә мөмкин. Галәлхосус (бигрәк тә) татарлар шикелле һәртөрле кәлимәне (сүзне) тәләффыз (әйтелеш) итүгә мөсагыйд (мөмкинлек бирүче) лисанга (телгә) малик (ия) булган бер милләт өчен инглизчә үгрәнү бер дә кыен түгел. Инглиз лисанының тәләффызы бераз зәхмәт чиктерә, юкса грамматикасы бик җөзьи (әһәмиятле түгел, авыр түгел), никадәр лөгать ятланса, шулкадәр беләнсөйли башлауга мөмкин.

Фәкать Америкага килү өчен кулда бер адрес булынуы мотлак (шарт) ляземдер. Пароходтан төшкәч тә шул адрес күрсәтелсә, поездга үзләре билет алып бирәләр, үзләре озаталар. Әлхасыйль, адрес кай җиргә исә, шунда алып барып төшерәләр. Әгәр кулда адрес булмаса, кабул итми кирегә кайтаралар. Күз авыруына дикъкать итсәләр дә, трахомадан башкасы докторга табиг тотып төзәлтүгә тырышалар. Трахомалы кешене бер дә кабул итмиләр. Күз авыруыннан салим (сәламәт) булып кесәсендә илле рубля акчасы, кулында мөгайин (билгеләүче) бер адресы булган кеше Америкага кереп китә ала.

Пароходтан төшкәч тә бөтен юлчыларны мөгайянә итәләр (билгелиләр), соңра вак гадәдләрне (саннарны) җәмиг (кушу) вә тарых (алу) иттереп һәм санатып карыйлар, әгәр юлчы аңгыра булып җавап бирә алмаса, яхуд (яки) бик җончып бәлҗерәп торса, кире кайтарып та җибәрәләр. Әгәр таләбә идегенә даир Америка мәктәпләренең берсеннән алган шәһадәтнамәсе булса, мөгаянәгә дә бик тотылмый, хәтта акчасы булмаса да, кертеп җибәрәләр.

Биш-ун сәнә тирәсендә генә мәйданга чыккан уку дәрте бик кинәт парлап киткәнгә күрә, татар таләбәләрен ике кыйсемгә аерып җибәрде. Бер кыйсеме яшьләре узмаган һәм башка маниглардан (киртәләрдән) да азат булганга күрә рус мәктәпләренә кереп китә алдылар. Бу кыйсем яшьләр гаять мосыйб (дөрес, туры) юл белән баралар. Язуда максатыбыз боларга гаид түгелдер (карамый). Бәлки икенче кыйсем, ягъни яшьләре узган яхуд рус мәктәпләренә керүдән мәхрүм калган сыйныфга гаидтер. Болар өчен Америка мәктәпләре ачыктыр. Бу вакытка кадәр укыган фәннәрдән бик күп истифадә итүгә мөмкин.

Вальпараисо дарелфөнүненә керү өчен яшьнең әһәмияте булмаган шикелле, дәрәҗәи тәхсыйльнең дә тәэсире юктыр. Таләбә үзенең кувә галәмиясенә күрә, мөгыйн фәннәр өчен мәхдүд (чикләнгән) заман тәгаенли һәм шул вакыт зарында очлап чыга ала.

Америка мәктәпләре безнең мәктәпләр шикелле сыйныфларга бүленмәгән, мәктәпнең бер шөгъбәсеннән шәһадәтнамә алу өчен мәктәптә фәлән сәнә укуның лөзүме юк. Бик лязем булган фәннәрне хәзерләп имтихан бирергә тиешле. Берәү сәнәнең алты аен укыр, алты аен эшләп акча казаныр, яки истирахәт итәр. Берәү исә истирахәт фида итеп, мөтәмадиян (өзлексез) укыр һәм мәктәпне тиз бетерер, ул җәһате таләбәнең ихтыяҗына тапшырылган.

Мәктәп ел буе 12 ай ачык булып, таләбә эстәдеге вакыт килеп керә ала, эстәдеге вакыт чыгып та китә ала. Мәктәптә ике ай дәвам иткән булса, безнең шикелле бер сәнә югалтмый, ике ай гына югалта. Ягъни дәрес нинди ноктада калдырылган, шул

җирдән башлап китә ала. Көченә алу, көченә алмау җәһәте бер дә төшенүгә ярамый. Чөнки Америка таләбәләр өчен бер дар (ил) рәхәттер.

Бу сәнә мөхарәбә гомумиядән (гомуми сугыш) Америкада мөтәзаррирлар (зыян күрүчеләр) булды. Монда да икътисади мөшкиләт (проблемалар): миллионнарча эшчеләр эшсез калдылар. Бик күп фабрикалар ябылды. Фәкать мәктәпләрнең алар белән котлы бер мөнәсәбәте булмаганга күрә, таләбә хәяты иске хәленчә дәвам итмәктәдер. Чөнки мәктәп идарәсе бик бай һәм бик бай кеше тарафыннан идарә улына. Мәктәп өчен лзем булган нәрсәләрнең барысын да үзләре хәзерлиләр. Кырлары, бакчалары, урамнары, кулләре барысы да мөкәммәл. Шулай булса да, һәр җирдә булганы шикелле, монда да акча бик зур роль уйный, бөтенләй акчасыз яшәү дә мөмкин. Фәкать бу ысул таләбә булган бар кеше өчен бик авырга туры килә, мөһим гомернең бер кыйсеме эшкә фида ителә. Шуңа күрә монда килүчеләр һәрхәлдә сәнәви бер микъдар акча килерлек хәзерләп килергә тиешләр. Мине Америкага китергән пароходта ике яһүди хатын бар иде. Берсе мөкәммәл русча, немецча, французча, бераз инглизчә, икенчесе исә мөкәммәл французча, итальянча, гарәпчә, төркичә беләләр иде. Үзләре ялгыз булдыкларын хәлендә, кочакларында яшь балалар булуына рәгъмән (карамастан), Америкага киләләр иде. Шуңа күрә дә яһүдиләр гадәдән бездән аз булдыклары хәлендә үзләрен бөтен дөньяга танытканнар һәм бөтен дөньяның тиҗарәтен кулларына алганнар. Без исә әтраф белән бөтенләй мөнәсәбәтсез бер хәлдә яшибез.

Америкада русиялеләрдән башка татарларны белүче милләт юк дип әйтерлек. Өч йөз миллионнан гыйбарәт, мөхтәлиф милләтләргә мәнсуб мөселманнарның иң мөтәрәкъкыйсе, шөбһәсез, татарлардыр. Шуңа күрә һәртөрле фидаилекне (фидакарьлекне) илтизам итү (үзеңә тиешле дип санау, кабул итү) безгә тәртип итә. Һәр изгелек хосусында үрнәк булу безнең бурычымыз булып күренә.

Дарелфөнүне белән бөтен дөньяга мәшһүр булган Бәлҗиканың Льеж шәһәрендә йөзләрчә милләттән гыйбарәт меңнәрчә таләбәләр арасында беренчелекне бер яһүди, икенчелекне татар Гаяс Максудов казанды. Истанбулдан исә татар таләбәләре иҗтиһадлары, истигъдадлары (сәләтлеклек, булдыклылык) белән мәшһүр Бәйрут америка көллиятендә татар таләбәләре алдынгы сафта баралар иде. Рус мәктәпләрендә дә шулай ук. Димәк, бездә һәр нәрсәгә истигъдад вә һәр нәрсәне алырлык зәкявәт (зирәклек, үткенлек) бар, тик хәсән истигъмаль (файдалану) вә җәсарәт (кыюлык, йөрәклелек) кирәк.

*Вальпараисо университеты таләбәләреннән Пржевальскилы Зыя Мөҗавир.*

### *Әхмәтмөнир Рәшит. Япониядән мәктүб. Япониядә таләбә тормышы*[34]

Берничә вакыттан бирле безнең татар шәкертләре арасында чит мәмләкәтләргә китеп укырга, хосусан гарәп мәдәниятен тәдкыйк итәргә (җентекләп тикшерергә) яки гарәп ысулынча мәгълүмат кәсеп итәргә бер һәвәс уянганлыгы күреләдер. Бик күп шәкертләрнең Лондон, Берлин вә Париж кебек шәһәр вә мәмләкәтләрнең таләбә

[34] Рәшит Ә.-М. Япониядән мәктүб. Япониядә таләбә тормышы // Вакыт. 1914. 21 май.

тормышын сорап язган хатларын анда торучылардан алып укыдыгым кеби, ишетергә дә туры килде. Шулай ук Америкада Сан-Францискода торучы мөхтәрәм «Вакыт» мөхбире Хәбибулла әфәнде дә шул рухта бик күп мәктүбләр ала имеш. Шундый ук мәктүбләр миңа Япониягә дә бик күп киләләр. Хәзергә кадәр килгән хатлар арасындагы иң мөһим вә җавап бирерлек булганлыгына 25–30 чамасында булды.

Шәкертләремез арасында һәр яктан мәгълүмат алырга, төрлечә тормыш юллары эзләргә, гыйлем тәхсыйль итәргә теләү хисенең бу дәрәҗәдә тирәндән уянуы кемне булса да сөендерерлек хәлләрдәндер дип уйлаймын. Хосусан сөальләрнең бик җитди булганнарын укып, хәзерге дәрәҗәдәге гомуми мәгълүматымыз вә мәктәпләремез илә шундый тирән уйлаучыларның мәйданга чыгуына сөенмәү мөмкин түгел. Бу сөальләрнең бик күп булуына мәбни (нигезләнеп), мин аларны шушы рәвешчә җавап бирүне муафыйкъ таптым.

* * *

**1 нче сөаль.**

**Япониядә мәгарифнең тәрәкъкые өчен хөкүмәт тарафыннан нинди мәгавәнәтләр (ярдәм) күрсәтеләдер?**

Япония хөкүмәте мәмләкәт эчендәге барча мәктәпләрне үз кулы астына алган; хосусый мәктәпләр ялгыз 5–10 гынадыр. Болар да миссионерларның, яхуд гарәп халыкларының иске правалы заманнарында ачкан мәктәпләрдер. Бу мәктәпләрнең шәкертләре дә күбрәк монда торучы чит җирләрдән килгән халыкның балаларыдыр. Башка мәктәпләр барчасы хөкүмәт тәхете идарәдә вә хоусый булганнары да ялгыз исмән (исеме белән) вә рәсмән (рәсми рәвештә) хосусый булып, хөкүмәт мәктәпләренең програмнарыннан вә хөкүмәтнең контроле астыннан һичбер вакыт читкә чыга алмыйлар. Хөкүмәт шәкертләре булсын, хосусый мәктәпләр булсын, барысы да «хөр тәгълим» (ирекле укыту) ысулына күрә ясалган програмнар буенчадыр.

Әльяум (бүгеге көндә) хөкүмәт бу мәктәпләрнең шәкертләреннән ибтидаи дәрәҗәдәгеләрдән айда 7 тиеннән 20 тиенгәчә; рөшди дәрәҗәдәгеләрдән 30 тиеннән 50 тиенгә; игъдадия дәрәҗәдәгеләрдән 1 сумнан 3 сумгача, вә дарелфөнүн шәкертләреннән 3 сумнан 4 сум 50 тиенгәчә акча аладыр. Бу хөкүмәт мәктәпләрендә булсын, һәрбере дә бердер. Моннан артык мәөсарифка мохтаҗ булган мәктәпләргә хөкүмәт тәмам җитәрлек дәрәҗәдә һәрвакыт мөгавәнәт итә (ярдәм итә) вә һичбер мәктәп хөкүмәттән сораган пособиесен алмыйча калмыйдыр. Ялгыз пособиенең сарыф иткән урыны ачык күрсәтелергә тиеш.

**2 нче сөаль.**

**Япониядә шәкерт тормышы илә тору өчен айда никадәр акча кирәктер?**

«Шәкерт тормышы» сүзенең мәгънәсе бик киң. Чөнки шәкерт тормышы илә торып, айда 20 сум сарыф итү мөмкин булган кебек, айда 70 сум да сарыф итәргә мөмкин.

20–25 сум илә торыр өчен иң әүвәл тәмаман япон ашларына үгрәнергә вә аларны ашый белергә кирәк. Японнар үзләре иртә дөге (суда пешкән) илә бераз торма вә бераз борчак ашыйлар. Төшенә шул дөге илә бераз балык вә янә тозлы торма вә

борчак ашыйлар. Кичке ашларында башка бер нәрсә булмый. Яки шул ук ашамлыклардыр. Шушы ашлар илә пансионнарда 15 сумларга торып буладыр. Калган 5 сум да китапларга вә вак мәсарифка җитә. Ашау-эчүне көндә бер мәртәбә генә булса да үз мәмләкәтебездә үгрәнгәнчә кылганда да, айда азында 40–50 сум кирәк буладыр. Анларның барысын да үз ысулымызда иткәндә, 60–70 сум җитәдер.

**3 нче сөаль.**

**Япониядә фәнни мәктәпләр арасында иң алга киткәннәре кайсылары?**

Япониядә иң алга киткән фән технологиядер. Токиодагы технологический институтта 28 факультет булып, чүлмәкчелек, столярлыктан башлап, кинематограф факультетына кадәр һәртөрле гыйлемләрне үгрәнү мөмкин. Бу мәктәпкә керер өчен Русиянең рөшди дәрәҗәсендәге мәктәпләрнең програмыннан мәгълүматлы булу җитәдер; ялгыз инглизчә вә һәндәсә (геометрия) илә җәбер (алгебра) дә мөсәлләсаттан (тригонометрия) имтихан ителәдер. Бу имтиханнар барчасы инглизчәдер. Икенче дәрәҗәдә мөтәрәккъый (алга киткән) мәктәпләр полицейский, тыйб вә тел мәктәпләредер. Сәясәт фәнендә алга киткән мәктәп «Васеда» исемендәге 8000 шәкертле хосусый бер дарелфөнүндер. Тыйб вә тел фәннәрендә исә хөкүмәтнең 6 мең шәкертле Токио дарелфөнүне вә 18 төрле тел тәгълим ителә торган Әлсинә әҗнәбия (чит телләр) мәктәбедер. Шулай ук дарелмөгаллиминнекеләр соң елларда бик тәрәккъый итеп киләләр.

Бу хакта «Американ риву ауф риву»[35] дигән бер мәҗәллә шушы рәвешчә яза:

«Япониянең мәгарифтәге тәрәккъыяте үлчәнер өчен аның дарелмөгаллиминнәрен кулга алып мисал күрсәтергә мөмкин. Япония дарелмөгаллиминнәре бер мөгаллим түгел, бәлки бер табиб, психолог, атлет, мусыйкый (музыкага караган) шинас (кызыксынучы) вә мәрхәмәтле мөрәбби (тәрбияче) хәзерлиләр», – ди.

**4 нче сөаль.**

**Япониядә, Америкада булган кебек, һәм укып, һәм акча табып тамак туйдыру мөмкинмедер?**

Һәр никадәр бик аз япон шәкертләренең моңар муафыйкъ булганлыклары күренсә дә, бу бик аз вә бик авырдыр. Чит халыклар өчен исә һич мөмкин түгелдер. Япониянең халкы күп, җире тар булганлыктан, бик күп японнарның да муафыйкъ эш таба алмый, дарелфөнүннәр икъмал итеп приказчиклык иткәнлекләрен, яхуд рестораннарда лакейлык иткәнлекләрен күрдем.

**5 нче сөаль.**

**Япониядә никадәр ислам бар?**

Бу сөаль иң авыр бер сөальдер. Чөнки моңа җавап бирер өчен иң әүвәл японнарның дингә булган карашларын аңлау тиеш була. Безнең татарларда дин беренче дәрәҗәдә вә милләт икенче дәрәҗәдә килгәне хәлдә, японнар милләтләрен диннәреннән артыграк ихтирам итәләр. Бинаән галәйһи, дини мәсьәләләр илә

---

[35] «The American review of reviews» журналы хакында сүз бара.

икенче дәрәҗәдә шөгыльләнәләр. Японнарның фикеренчә, ата-анасын танымаган бер кешенең Ходага иман иттерүеннән файда юктыр, чөнки милләтпәрвәрлек японнарның асыл диннәре булган шинтоизмның (синтоизм) асылы вә асәседер.

Бу сәбәпкә мине һәр никадәр исламияткә мәхәббәт итүче вә исламиятне тәдкыйкъ итеп (җентекләп) үгрәнергә тырышучылар вә хосусан исламиятнең заманга муафыйкъ гали хөкемнәреннән ләззәт алып исламият хакында байтак әйберләр язучылар булса да, мөселманлыкның бездәге мәгънәсе илә мөселман булганнарга бик аз тугры килүенә, бәлки юк дип әйткәндә дә хата булмаячактыр. Моның да сәбәбе монда чит җирләрдән килеп торучы вә исламиятнең игъмаль кыйсемне үгрәтерлек мәгълүматлы мөгаллимнәрнең вә мөгаен дини урынымызның да юклыгыдыр.

**6 нчы сөаль.**

**Японияде һәм сәүдә, һәм тәхсил итү мөмкинме?**

Япониядә безнең өчен мөмкин булган ялгыз шушы хосусдыр. Бу көн Япониягә Русиядән миллионнарча сумлык солдат итеге вә башка аяк киемнәре өчен төрле сорттан күннәр кертелә. Шулай ук май сәүдәсе көннән-көн тәрәккъый итеп бара. Чөнки япон байлары вә хәллерәк халыклары соң елларда акрынлап Аурупа ашларына һәвәс итәләр вә майлы ашның бәдәнгә файдасын күреп, кайсы бер мәктәп-пансионнарда да риязат (файдалы) ашы кебек япон ашларын акрынлап ташлап баралар. Шулай ук япон фабрикаларында соң елларда йон өчен бик зур ихтыяҗлар булып, елдан-ел йонлы маллар тукучы станоклар артып барадыр. Безнең татарларның специальносте булган шушы сәүдәләр бүген яһүдиләр кулында.

Монда сәүдәгәрләргә вә приказчыкларга махсус махсус һәртөрле фәннәрне үгрәтүче бик мөһим мәктәпләр бар. Бу мәктәпләрнең күбесендә дәресләр практика иләдер.

**7 нче сөаль.**

**Японнар безнең татарларга нинди күз илә карыйлар?**

Японнар гомумән татарларны бик яхшы танымыйлар. Безне күбрәк инглиз вә рус китапларыннан укып таныганлыкларыннан барыбызны да кыргызлар кеби дип беләләр; яки мөселман руслар диләр. Ләкин сугыш вакытында монда торган әсир солдатларымыздан берничәсе кем икәнлегебезне бер дәрәҗәгә кадәр аңлатканнар вә анна соң тарихи вә этнография бәгъзе тәдкыйкълар (дикъкать) илә шөгыльләнүче националист профессорлар да безне бер дәрәҗәдә тагын да якыннан танытып, телләремездәге охшашларны, вә хосусан сарыф вә нәхүемезнең тәмаман бер булганын күрсәтеп якынлаштырганнар. Шулай ук экономия ягыннан безнең татарларның Шәрыктагы урыннарын күрә белгән фирмалар безнең илә якынлашырга бик телиләр.

Хәтта берничә банкир конторалары яшь берничә японга татарча укытыр өчен мөгаллим алып укыттыра башладылар. Болар татарча үгрәнгәннән соң, Маньчжуриянең вә Сибириядә важурлык итмәкче булалар.

**8 нче сөаль.**

**Япониядә шәкертләрнең сәясәт илә шөгыльләнүләренә мөсәгадә (ярдәм) итәме?**

Япония иң хөр мәмләкәтләрдән булганлыктан, һәркем теләсә ни илә шөгыльләнә аладыр, ләкин мәктәп бинасы эчендә һичбер сәяси сүз сөйләүгә мөсәгадә ителми (мөмкинлек бирелми), хәтта мөмкин мәртәбә дини бәхәсләрнең дә мәктәп эчендә сөйләнүенә мөсагадә итмиләр.

Ләкин мәктәп тышында шәкертләргә махсус әллә ничә төрле сәяси клублар, партияләр вә җәмгыятьләр бар. Бонлар арасында иң зуры – «Асияле тәрәккыйпәрвәр таләбә җәмгыяте»дер. Җәмгыять әгъзалары арасында 6–7 йөз япон, шул ук микъдарда кытай, 200 кадәр куралы, 20 ләп могул, сиямлы, һиндлы, төрек вә татар бар.

Бу җәмгыять күбрәк читтән килгән шәкертләргә юл күрсәтә. Мәктәпләргә керүгә васитачылык (арадашчылык) итә, шулай ук асияле шәкертләр арасында даими бер мөнәсәбәт вә шул юл илә Асия сәүдәсенә юл ачарга тырышадыр. Җәмгыятьнең рәисе граф Шибузава ел саен 10 мең сум чамаларында җәмгыятькә мөгавәнәт итеп, шәкертләрнең һәр тәрәкъкыйләренә ярдәм итәдер.

(Галиәсгар Камал әфәнденең «Беренче театр» нам әсәре ошбу җәмгыятьнең театрында японча уларак мондан ике ай әүвәл уйналды).

* * *

Сөальләр бу кадәрдер.

Бу дәрәҗәгә кадәр мөляхәзә (игътибар) ителсә, ягъни бу сөаль вә җавапларның накыйс (тулы, җитәрлек дәрәҗәдә түгел) икәнлеге күреләбелер. Ләкин минем күп еллардан бирле татар галәмендән озакта торуым да моңа сәбәп булырга мөмкин. Әгәр мөфассал сөальләр бирүчеләр булса, янә вакыт-вакыт ошбу рәвешчә «Вакыт» сәхифәләрендә мәгълүмат бирергә вәгъдә итеп, хәзергә шул кадәр илә тәмам итәм.

*Әхмәтмөнир Рәшит*

PS.

Мөрәҗәгать итүчеләргә адресым шул рәвешчәдер:
Tokyo, Waseda University
Munir Ibrahim

***Муртазина Ляля Раисовна***

**Зарубежные образовательные центры и татарское просвещение**
**(XVII – начало XX вв.)**

**[Ватаннан читтә белем алу үзәкләре һәм татар мәгарифе**
**(XVII гасыр – XX гасыр башы)]**

*(на татарском языке)*

*Монография*

Оригинал-макет – *А.Р. Тухватуллина*
Подписано в печать 20.06.2025 г. Формат 70х100 $^{1}/_{16}$
Усл. печ. л. 19,9875. Тираж 100 экз. Заказ № 56/1

Отпечатано с готового оригинал-макета
в типографии ООО «Фолиант»
420095 г. Казань, ул. Восстания, 100, корп. 6130 (корп. 153)
Тел.: (843) 212-52-25; e-mail: foliantkazan@mail.ru

Сайт
Института истории
Академии наук РТ
**Татаровед.рф**